Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

Казан • Казань
2025

**Духовное наследие**
Поиски и открытия
*Выпуск 28*

**Газиз Губайдуллин**

# ИЗБРАННЫЕ СОЧИНЕНИЯ

Том 3

**Рухи мирас**

Эзләнүләр һәм табышлар

*28 нче чыгарылыш*

**Газиз Гобәйдуллин**

# САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

3 том

УДК 94 (093)
ББК 63.2
С 93

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

Проект «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау»
ТР Дәүләт программасы кысаларында ТР Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Язма мирас үзәге тарафыннан гамәлгә ашырыла

**Редколлегия:**
***И.И. Халиков (рәис), И.Г. Гомәров,***
***Л.М. Гыйниятуллина***

**Фәнни редактор**
*филология фәннәре кандидаты* ***И.Г. Гомәров***

**Рецензентлар:**
*филология фәннәре кандидаты* ***А.М. Ахунов,***
*тарих фәннәре кандидаты* ***Ә.В. Аксанов***

**С 93** **Газиз Гобәйдуллин. Сайланма әсәрләр.** Т.3 / Г.Гобәйдуллин; төз., текст. иск. һәм аңл. әзерл.: Л. Ш. Гарипова, Л. Р. Надыршина, Г.М. Ханнанова; кереш сүз авт. И.Г.Гомәров. – Казан: ТӘһСИ, 2025. – 256 б. («Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие: поиски и открытия» сериясе. 28 нче чыгарылыш).

ISBN 978-5-93091-522-8

«Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең егерме сигезенче чыгарылышы тарихчы галим, язучы, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Газиз Салих улы Гобәйдуллинның (1887–1937) «Татар тарихы» (1925) һәм «Насыйри кулъязмаларының гыйльми кыйммәтләре турында» (1926) фәнни хезмәтләрен үз эченә ала.

Басма белгечләр, татар тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксынучы киң катлау укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-93091-522-8 (3 т.)
SBN 978-5-93091-521-1

© ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2025

# ФӘННИ МИРАС ЯҢАРЫШЫ: ГАЗИЗ ГОБӘЙДУЛЛИН ҺӘМ АНЫҢ «ТАТАР ТАРИХЫ» ХЕЗМӘТЕ

Әлеге китапта тарихчы галим Газиз Гобәйдуллинның «Татар тарихы» әсәренең өченче басмасы укучылар игътибарына тәкъдим ителә. Бу басма беренче тапкыр 1925 елда Мәскәүдә СССР халыкларының үзәк нәшриятында дөнья күрә һәм бүгенгәчә борынгы дәверләрдән алып XIX гасырга кадәрге чорны тулы колачлаган, фәнни-методик яктан төпле тарихи тикшеренүләрнең берсе булып кала килә.

Газиз Салих улы Гобәйдуллин (1887–1937) тарихчы галим буларак татар җәмгыяте үзенең рухи тормышында зур үзгәрешләр кичергән катлаулы бер дәвердә формалаша. Ул «Халидия» мәдрәсәсен, Казан университетын тәмамлый һәм алга таба Шиһабетдин Мәрҗани, Морад Рәмзи, Ризаэддин Фәхреддин кебек рухани-галимнәребез нигезләгән тарихи-мәдәни традицияләрнең яңаруга мохтаҗ бер чорында фән юлына аяк баса.

Мәгълүм булганча, XIX гасырда Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтләреннән башланган тарихи традицияләрдә хаким-идарәчеләрнең нәсел шәҗәрәләре, сәяси тарих һәм дини тормыш вакыйгалары үзәккә куелды. Ул Шәрыкның нарратив чыганакларына һәм тарихи традицияләренә таянган хәлдә, Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы арасындагы мәдәни дәвамчанлыкка нигезләнгән татар тарихы концепциясен фән мәйданына тәкъдим итте. Әмма 1920 елларда инде, җәмгыятьтә барган үзгәрешләргә мөнәсәбәттә, әлеге концепция билгеле бер дәрәҗәдә яңаруга һәм фәнни җәһәттән тирәнәюгә мохтаҗ иде.

1920 елларда тарихчы галим алдында яңа мөмкинлекләр ачыла. Элгәреләр асылда Көнчыгышның традицион язма чыганакларына таянган булса, Г. Гобәйдуллин архив материалларына, административ документларга, хуҗалык язмаларына мөрәҗәгать итү мөмкинлеге ала, шуларны анализлау аша тарихка бөтенләй башкача караш формалаштыра.

Әсәрнең язылу һәм басылу тарихы да аның үзенчәлекле якларын билгеләүдә аерым әһәмияткә ия. Текстның беренче варианты 1919 елда ук тәмамланып, 1922 елда нәшер ителә, әмма автор үзе аны ахыргача камил вариант дип санамый. Берникадәр үзгәртелгән икенче басмасы 1923 елда дөнья күрә. Галим әлеге басманың да бербөтен һәм җитәрлек дәрәҗәдә системалы булмавын таный. Мәскәү нәшрияты өчен өченче басма әзерләү мөмкинлеге тугач, Г. Гобәйдуллин хезмәтне тулысынча яңарта: тикшеренүләрне яңа методологик нигезгә кора, периодлаштыру принципларын үзгәртә, бигрәк тә социаль-икътисади тарих буенча зур күләмле яңа материаллар, архив документлары өсти. Автор үзе язганча, өченче басма нәтиҗәсендә иске һәм яңа вариантлар арасында «бөтенләй аерма» барлыкка килә һәм бу аерма материал күләмендә генә түгел, ә аны аңлату һәм системалаштыру ысулларында да чагылыш таба.

Газиз Гобәйдуллин хезмәтенең төп үзенчәлекләренең берсе аның татар тарихына социаль-икътисади күзлектән чыгып бәя бирү омтылышында ачык

күренә. Хакимнәрнең генеалогик чыгышлары турындагы мәгълүматларны, аларның династияләре арасындагы катлаулы бәйләнешләрне һәм тарихи вакыйгаларны искә алу белән бергә, ул төрле татар дәүләтләрендәге феодаль мөнәсәбәтләрнең төзелешен дә анализлый. Анда авыл халкының көндәлек хәлен тирәнтен өйрәнү, һөнәрчелек һәм сәүдә үсешен бәян итү, шәһәрнең социаль-икътисади үзәк буларак формалашуын тикшерү мөһим урын били. Мәсәлән, Болгар чоры турында сүз барганда, Газиз Гобәйдуллин сәяси вакыйгаларны гына тасвирлап калмый, икътисади үсеш мәсьәләләренә дә махсус туктала: җир эшкәртү һәм терлекчелекнең ничек үсүен, шәһәрләрнең барлыкка килүен, Болгар җирләрен тышкы дөнья белән тоташтырган сәүдә юлларын карый. Казан ханлыгы чоры анализында ул тышкы сәясәт һәм тәхет варислыгы мәсьәләләре янәшәсендә җәмгыятьнең төрле катлауларының икътисади хәлен, крестьян тормышы шартларын, феодаль иерархия төзелешен дә тикшерү объекты итә.

Газиз Гобәйдуллинның «Татар тарихы» хезмәтендә урын алган аерым бер фикерләре бүгенге тарихи гыйлемнәр күзлегеннән караганда тәнкыйди караш таләп итсә дә, аның тарихи барышны тикшерүгә комплекслы якын килүе, социаль-икътисади нигезләргә игътибар итүе, чыганакларга тәнкыйди мөнәсәбәте хәзер дә күпләргә үрнәк булып кала.

Бүген «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясендә «Татар тарихы» хезмәте һәм «Насыйри кульязмаларының гыйльми кыйммәтләре турында» мәкаләсенең гамәлдәге графикада кабат басылуы татар халкының милли аңын үстерү, киң тарих аренасында үз урыныңны табу һәм аңлау өчен дә әһәмиятле икәнен онытырга ярамый. Җәмгыять үсешенең катлаулы чорларында тарихи гыйлемнәрне актуальләштерү, фәндә төп урын тоткан текстларны яңадан әйләнешкә кертү тарихи хәтерне һәм мәдәни үзенчәлекне саклау өчен мөһим фактор буларак чыгыш ясый. «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясе нәкъ менә онытылган яисә билгесез чыганакларны бүгенге фәнни әйләнешкә кире кайтару максатын күз уңында тота.

* * *

Галим Газиз Гобәйдуллинның югарыда искә алынган хезмәтләрен басмага әзерләү барышында зур текстологик эш башкарылды: гарәп имласындагы оригинал текст автор стиле һәм орфографиясе сакланып транскрипцияләнде. Хезмәтнең искергән сүзләренә, атамаларга аңлатмалар бирелде, аерым бер тарихи вакыйгаларга һәм шәхесләргә мөнәсәбәтле шәрех-комментарийлар язылды. Үз чорында хаталы басылган өлешләрне яки ялгыш төшеп калган кушымчаларны, сүзләрне төзәтү зарурлыгы туганда, бу төзәтмәләр квадрат җәяләр эченә алып бирелде. Әлеге алым укучыга автор тексты белән фәнни редакцияләү нәтиҗәсендә өстәлгән өлешләрне ачык аерырга мөмкинлек тудыра.

*И. Г. Гомәров*

# ТАТАР ТАРИХЫ

## ЯЗУЧЫДАН

Татарстанда минем тарафтан язылып, ике мәртәбә басылып таралган «Татар тарихы» 1919 елларда тәмам булган бер әсәр иде. Бу әсәрне икенче мәртәбә бастырган чагымда шактый күп яңа нәрсәләр керткән булсам да, ахырыннан алып төзәтә алмадым. Матбугага тиз генә бирергә сораганлыкларыннан, алдагы фасыллары бөтенләй искечә калдылар. Арттагы кисәкләренә бәгъзы яңа нәрсәләр арттырылса да, аз вә тәртипсез иделәр; шуның өстенә дә тагы икенче бер уңайсызлык туды: әсәрнең баштагы әсаслары[1] белән ахырдагылары арасындагы аерма зур булып чыкты. Әлхасыйль[2], әсәр бер бөтенлек ясый алмады. Инде бу өченче басма «Татар тарихы» СССР халыкларының үзәк нәшрияты тарафыннан басылырга алынгач, ул әсәрне төбеннән-тамырыннан алып төзәтергә, яңа материаллар күтәрергә, яңа әсасларга салырга ирешә алдым дип әйтә алам. Шуның өчен дә хәзерге «Татар тарихы» белән әүвәлгеләре арасында бөтенләй аерымлык килеп чыкты. Бу аерымлык – һәм материал сайлау, һәм нигез салудадыр. Әүвәлге басмаларында тарихи агымны идеалистларча аңлау исе аңкып торса, бу төзәтелгәнендә инде мин татар тарихын материализм әсасына салдым вә марксизм нигезләренә бик якынлаштым дип әйтә алам. Билгеле, бу әсаста тарих язу өчен рәкымлы[3] статистика мәгълүматлары күп кирәк, мондый мәгълүматларны табарга тырышсам да, максатыма тәмам ирешә алдым дип әйтә алмыйм; шулай да теләккә бер дәрәҗә ирешә алдым дип әйтергә хакым бар. Бу әсәремдә яңа нәрсәләрдән берсе татар тарихын яңа әсаста дәверләргә бүлү булса, икенчесе – татар тарихын XIX гасырның эченә алып керүдер. Өченче бер яңа нәрсә дә татар өчен тарихи, моңарчы истигъмальдә[4] булмаган кульязма хәлендә архив вә аерым кешеләрдәге булган яңа материаллар белән файдалануым булды. Шуның өчен дә мин бу басма татар тарихын искеләреннән бөтенләй башка әсәрем дип әйтә алам.

*Г. Газиз*

*Мәскәү, 3 февраль, 1924 ел*

[1] Әсаслары – кисәкләре.
[2] Әлхасыйль – нәтиҗәдә.
[3] Рәкымлы – санлы.
[4] Истигъмальдә – кулланылышта.

# I Татарларны тудырган гонсырлар [1]

**Татарлар.** Хәзерге заманда «татар халкы» дип йөртелә торган дүрт миллион чамасында бер халык бар. Бу халык төрк җенесеннән. Боларның телләренең асылы да – шул төрк теле, шуның өчен дә татар халкы, үзенең язган китапларын укый белсә, «төрки таныйм» дип әйтә. Бу татарларның тора торган асыл урыннары Иделнең урта агымында; ләкин шулай булса да, җир аз булганга вә төрле кәсеп итү өчен, татарларның бик күбесе Шәркый Яурупа вә Сибириянең башка бик күп җирләренә таралганнар. Шуның өчен дә хәзерге Советлар Союзының бик күп губерна, бик күп шәһәрләрендә шактый гына татарларны очратабыз.

Һәрбер халыкта булганы шикелле, татарлар арасында да төрле бер-берсеннән бәгъзи[2] сүзләр, аларны әйтү, азмы-күпме сарыф вә нәхү ягыннан үзгәлек белән аерыла торган шиваләр бар. Шуның өчен дә бу татар дип атала торган төркләрнең бер кисәген, башлыча, икегә бүләргә мөмкин: мишәрләр һәм Казан вә аның әтрафындагы татарлар. Мәдәният аз, бер-берсе белән катышу ким чакларда татарларның сөйләшә торган телләре тагын да аерымлы булган, ләкин хәзер татар дип аталган халыкның әгъзаларының телләре һаман да берләшергә бара, болар бер-берсеннән сүзләр алалар, аларның сарыф вә нәхү формаларын да хәят берләштерә, шуның аркасында татарларның һәммәсенә уртак булган әдәби тел туып, шул тел белән язылган зур әдәбият мәйданга чыккан. Бу әдәби тел, татарларның

[1] Гонсырлар – элементлар.
[2] Бәгъзи – аермалы.

борынгы заманнан бирле килгән мәдәният вә сәясәт мәркәзе булган Казан һәм аның әтрафы татарларының сөйләшә торган телен нигезгә салып, шуңарга төшергән сүзләрне мишәр дип аталган татарлардан алып ясалган.

Татарларга күрше булган, аларга бик якын кардәш булган тагын ике төрк кабиләсе бар: аларның берсе – хәзерге Әчтерхан[1] вилаяте вә шимали[2] Кавказда торган нугайлар һәм [икенчесе] – хәзерге Башкортстан җөмһүрияте, Пермь, Вятка вә Татарстан җөмһүриятенең бәгъзы шәркый[3] кантоннарында торучы башкортлардыр. Билгеле, бу ике төрк кабиләсенең үзләренә аерым тарихлары бар. Шулай булса да, бу халыкларның тарихлары, татарларныкы белән нык бәгланганга күрә һәм бу җирләргә көчеп шактый гына татар килеп утырганга, нугай вә башкортларның тарихына аз гына кагылмый китми булмыйдыр.

Бөтен төрк халыклары арасында татар халкы – иҗтимагый җәһәттән иң алга киткән бер халыктыр. Боларның һәммәсе дә хәзер утраклы, күбрәк игенчелек белән көн күрүчедер. Бу халыкта революция алдында, Русиядә башка халыкларда булган сыйныфлар булып, сыйнфый дифференциация тәмам була язган иде. Табигый, татарларның хәзерге хәлен, аларның икътисади, иҗтимагый, мәдәни дәрәҗәләрен тикшерү – этнография исемле гыйлемнең эшедер. Шуның өчен без, бу мәсьәләләрне озын итеп сөйләүне үз әһеленә тапшырып, татар халкының үткәнен тикшерә башлыйбыз.

**Татарларның тарихы.** Бөтен кешеләрнең тарихларын, аларның тәкъдирләрен[4] этеп йөртүче гамил[5] – игътибардыр. Бу гамил – бөтен башка сәбәпләрнең атасы, аларны тудыручыдыр.

Шуның өчен дә татарларның тарихын өйрәнү аларның икътисади тормышларын тикшерүдән гыйбарәт булырга кирәк. Шул сәбәпле без бу китабымызда шуның белән күбрәк шөгыльләнәчәкбез. Татарның үткәнен тикшереп карасак, бер төрле икътисади халәтнең икенчесенә күчүеннән вә шул хәятында гамил булган төрле

[1] Әчтерхан – Әстерхан.
[2] Шимали – төньяк.
[3] Шәркый – көнчыгыш.
[4] Тәкъдирләрен – язмышларын.
[5] Гамил – сәбәп, фактор.

сыйныфларның бер-берсе белән күнешләреннән[1] гыйбарәт икәнен күрәбез. Ләкин бу мәсьәләгә күчмәс борын, бу тарихыбызда иң элек ике мәсьәләне хәл кылып үтәчәкбез: ул да булса – татар халкының ясалышы мәсьәләседер. Шуның өчен дә без татарның тарихын шушы кисәкләргә бүлеп өйрәнәчәкбез:

1) Татарларны тудырган гонсырлар[2] (ыруг-патриархат дәвере). Мәгълүм ки, төрле кисәкләрдән ясалмаган дөньяда бер генә халык та юк. Һәрбер нәрсә үзенең ясалган матдәләренә тәхлил кылынганы[3] шикелле, һәрбер халыкны да аерып, аның нинди гонсырлардан хасил булганын белергә тиешбез. Бер нәрсәне тикшергәндә, аны тәшкил иткән матдәләрне белмәсәк, ул нәрсәне белдек дип әйтеп булмый. Шулай ук татар халкының нинди халыклардан җыелып ясалган икәнен белү дә безгә аның тормышын, мәдәниятен вә башка бик күп якларын белергә һәм аның соңгы тарихын аңларга зур ярдәм итәчәктер.

2) Татар халкының ясалу процессы (татарларда феодализмның тууы).

Бу баб исә татарларның ясалган матдәсен өйрәнгән соңында, шул матдә (халыклар)ларның ничек итеп бер-берсенә кушылганын күрсәтәчәктер. Инде татар халкының ничек итеп ясалганын белгәч, безгә татар халкының чын тарихына да тотынырга мөмкин була; шуның өчен без калган бабларны түбәндәге кисәкләргә бүләбез:

3) Татарларның феодализм дәвере.

Татарларның ясалу процессы мәсьәләсен сөйләгән чакта, без ул халыкның ыруг-патриарх тормышын күреп узабыз, ыруг-патриархат дәверенең бетә башлавы белән татар халкының ясалышы да башлана, шуның өчен безгә феодализм мәсьәләсенә күчәргә зур имкян[4] кала.

4) Феодализмның бетүе вә сәүдә капиталының чыгуы.

5) Татарларда сәүдә капиталы хөкем сөргән дәвердә сәнәгать капиталына таба адымнар.

Менә шуның белән без татар тарихын XIX гасырның башларына илтеп терибез дә, бу җилдне[5] шуның белән тәмам итәбез.

[1] Күнешләреннән – мөнәсәбәтләреннән.
[2] Гонсырлар – элементлар, өлешләр.
[3] Тәхлил кылынганы – аерылганы.
[4] Имкян – мөмкинлек.
[5] Җилдне – томны.

**Төркләр вә аларның Шәркый Яурупага килүләре.** Гайсә тумастан бик күп гасырлар элек Алтай вә Саян таулары арасында яшәгән Урал-Алтай нәселенә мәнсуб[1] төрк халыклары, күбәеп, үзләренең асыл ватаннарыннан таралып, Азиянең төрле җирләренә азык эзләп күчкәннәр иде.

Болар болай күчкән чакларында инде Азиянең яхшы җирләре, җылы һавалы, иген үстергеч яхшы туфраклы урыннары – һәммәсе дә башка нәсел халыклары тарафыннан ишгаль кылынган[2] иде. Шуның өчен дә яхшы вә һавалы җирләр эзләүче төркләр өчен бу күчүләр тыныч кына узмады – аларга иранлылар, кытайлар белән каты вә канлы сугышлар кылырга тугры килде. Болар инде, бу асыл ватаннарыннан күчкән чакта ук, тимер кораллар эшли беләләр, мал асрыйлар, иген чәчүнең дә нәрсә икәнен беләләр, иҗтимагый яктан да патриархат дәверенә җиткәннәр, ыруг вә кабиләләргә бүленгәннәр иде. Бары тик матриархат (аналар башлык булган) дәвереннән калган гаиләдә олуг хатынның башлыгы шикелле үк бәгъзы гадәтләр калган иде. Бу мәдәни, утраклы күршеләре белән сугышта төрк кабиләләренең кайсылары яхшы җирләрнең бәгъзыларыннан иске хуҗаларын җиңеп куып килеп утырып, үзләре иген белән шөгыльләнә башладылар, кайсылары исә, бу күршеләре тарафыннан җиңелеп, аларга кол булдылар. Ләкин бу азык эзләп күчүче төркләрнең күбрәге сахраларда, степьләрдә тора башлап, шул җирләрдә мөмкин булган мал асрау белән мәшгуль булып, күчмә хәлдә булып калдылар. Күчмә тормыш өчен күп җир кирәк була. Әгәр иген белән мәшгульләнгәндә[3], бер кешегә, мәсәлән, бер дисәтинә җитсә, күчмә – мал асрап тору өчен шуннан ничә мәртәбә күбрәк җир кирәк. Төркләрнең саны арткан саен яисә, корылыклар булып, әүвәлдә күчеп йөргән сахраларда малга азык вә су беткәч, төркләр һаман күчү өчен яңа җирләр эзләргә, тамак өчен ничәшәр мең чакрым җирләргә күчеп китәргә мәҗбүр булдылар.

Әгәр без Азия һәм Шәркый Яурупа (Русия) харитасына[4] карасак, бер кызык нәрсә күрәбез: Монголиядәге Гоби яисә Шамо чүленнән алып Маҗарстан (Венгрия) сахрасына кадәр тоташ бер зур сахра,

[1] Мәнсуб – караган.
[2] Ишгаль кылынган – биләп алынган.
[3] Мәшгульләнгәндә – шөгыльләнгәндә.
[4] Харитасына – картасына.

хәзер Җәнүби[1] Украина, Дон буе, Иделнең түбән агымы шикелле җирләр хәзер инде сәнәгать вә мәдәниятнең артуы белән ямь-яшел тигезлеккә әйләнгәннәр, ләкин болар да, нәкъ хәзерге Төркестан вә Кыргызстан сахралары шикелле, әүвәле заманнарда сахра-степь иделәр. Димәк, Шамодан алып Маҗарстанга кадәр бер тоташ сахра дәвам итәдер. Ләкин бу Азиядәге сахра белән Шәркый Яурупадагы сахраны Урал таулары аерып торсалар да, хәзерге Җаек сахрасы янында Урал таулары сөзәкләнеп килеп, Каспий диңгезенә җитәрәк бөтенләй бетәләр. Менә шул җир тарихларда «Каспий капкасы» дип йөртеләдер.

Әгәр Яурупадагы сахралар белән Азиянең шималендәге кыргыз сахралары җәгърафи[2] яктан тоташ сахра булсалар, билгеле, көтү көтәр өчен җайлы урыннар эзләүче төрк кабиләләре Урал тауларына килеп җитеп, әүвәлге «Каспий капкаларыннан» үтеп, һәм Яурупага чыгып торганнар.

Бу төрк кабиләләренең кайсы вакытта Шәркый Яурупага килүләре мәгълүм булмаса да, Гайсәдән өч-дүрт йөз ел элекке заманнарда инде Шәркый Яурупада юнаннар[3], гомумән «скиф» исемендә аталып йөрткән күчмә халыкларның арасында төркләрнең булуы да ихтимал тотыла. Ләкин һәрхәлдә миладтан[4] йөз ел соң заманнарда төркләрнең Шәркый Яурупага килеп йөрүләре мәгълүм. Шул заманнарда ук русча Волга вә Урал елгаларының хәзерге төркләр атый торганча «Идел» вә «Җаек» исемендә булулары шуны күрсәтәләр. Ләкин төркләр тарафыннан оештырылган булуында вә көчнең мәркәзе[5] дә шул ук халык кулында булуы мөхәкъкаграк[6] булган һун урдасының Шәркый Яурупага килеп чыгулары – тарихта ачык мәсьәләләрнең берседер. Гомумән, кирәк һуннар, кирәк алардан Шәркый Яурупага килеп чыккан башка төрк урдалары булсын – аларның һәммәсенең иҗтимагый төзелеше бертөследер. Ул да булса, ыруг-патриархат тормышыдыр. Ләкин моны күрсәтер өчен, шул халыклар хакындагы сакланып калган хәбәрләрне җыеп күрсәтеп

[1] Җәнүби – көньяк.
[2] Җәгърафи – географик.
[3] Юнаннар – греклар.
[4] Миладтан – Гайсә пәйгамбәр туганнан.
[5] Мәркәзе – үзәге.
[6] Мөхәкъкаграк (мөхаккаграк) – ачыграк.

торырга кирәк, шуның өчен тарихка ачык мәгълүм булган һуннар хакында бераз тукталып узарбыз.

**Һуннар.** Кытай мәнбәгъләрен[1] ныклап тикшерелгән соңында һун халкының кытайлар «һиунг-ну» дип йөри торган халыклар белән бер булганы исбат ителде. Гайсәдән өч йөз ел элек Кытайдагы Сары елганың шималендә Һиунг-ну урдасы төзелә; бер вакытларда бу урда Кытай белән сугышка керешеп, шул көрәш аркасында һиунг-нулар арасында, барысын берләштереп, көрәшне алып барырлык бер организация ясалып, бу урда бер күчмә дәүләт рәвешенә керә; ләкин миладтан элек илленче елларда бу урда яңадан тәхлил ителергә[2] башлап, үзара көрәш башланып, икегә аерыла. Табигый, бу эшкә ул заманның мәдәни Кытай империясенең дипломатиясе дә зур хезмәтләр күрсәтте. Бу бүленгән вә зәгыйфьләнгән халыкка һәм кытайлар, һәм күршеләре тунгуслар шикелле шималь халыклары һөҗүм кыла башладылар. Менә шуның аркасында һиунг-нуларның бер кисәге, гаребкә таба китеп, Арал диңгезе буйларына барып, миладтан туксан еллар соң тагын күнешеп[3], бер зур сахра дәүләте ясадылар. Ниһаять, болар IV гасырда, тагын да урыннарыннан кузгалып, гаребкә таба киттеләр. Юлда очраган күчмә төрк халыкларын ияртеп, буйсындырып, тагын көчәйделәр. Инде без бу һиунг-нуларны 372 елда рума[4] вә юнан мәнбәгъләрендә «һун» исеме белән Идел елгасы буенда очратабыз. Әмма һуннар 375 елда гарби Яурупага һөҗүм кылалар. Бара-тора һуннар Яурупада баш бер гонсыр булып китәләр, мәшһүр гарби Рума империясенең бетүендә зур ярдәм итәләр. Бу урданың Яурупадагы бик зур хакимияте 433 елдан алып 454 елга кадәр хөкүмәт сөргән һуннарның Аттила[5] исемле ханнары заманында була. Билгеле, безгә һуннарның тәфсилле тарихлары кирәк түгел, без бу мәсьәләдә язабыз икән, бары ничек итеп

[1] Мәнбәгъләрен – чыганакларын.
[2] Тәхлил ителергә – аерылырга.
[3] Күнешеп – берләшеп, мөнәсәбәтләр урнаштырып.
[4] Рума – Рим.
[5] Аттила (?–453) – борынгы Европа һуннары (ак һуннар) берләшмәсе башлыгы. Һуннарны куәтле империягә туплаучы буларак танылa. Аттила идарә иткәндә, һун кабиләләре югары иҗтимагый үсеш дәрәҗәсенә ирешәләр. Аттиланың дәүләтенә Иделнең түбәнге өлешеннән алып Рейн елгасына, Көньяк Германиядән Альп тауларына һәм Дунай буйларынача булган җирләрдә яшәүче кабиләләр кергән.

төркләрнең Шәркый Яурупага килеп чыгуларын вә аларның анда калдырган эзләрен белдерер өчен генәдер. Табигый, һуннарның Шәркый Яурупага килеп чыгып, аның җәнүби сахраларын тотырулары Азиядән төрк халыкларының килүенә зур юл ачты, вә һун урдасы үзе белән бергә башка төрк кабиләләрен дә алып килде. Моннан чыга торган нәтиҗәләрне соңыннан күрербез.

Һуннарның тормышы – ыруг-патриархат тормышы дигән идек; аларның дәүләтләре дә, башка күчмә дәүләтләр шикелле үк, яңа җирләр эзләп күчеп йөргәндә, башка көчле халыклар белән очрашканда көрәшү өчен ясалган бер оешма гына иде. Шуның өчен дә һуннар, Яурупаны алып, урдага көн күрергә уңай Маҗарстан вә җәнүби Русия сахраларын ишгаль кылгач[1] та таралды, Һун дәүләте үзенең ясалган ыруг вә кабиләләрдән гыйбарәт булган гонсырларына тәхлил ителеп бетте. Ләкин дәүләт бетсә дә, ул халык калды, әмма башка исемдә соңыннан тагы тарих сәхнәсенә килеп чыкты, шул халыктан башка сәяси оешма ясалды.

**Һуннарның тормышы.** Һуннар күчмә төркләр өчен махсус булган (типичный) тормыш вә гадәткә малик[2] иделәр. Бу тормышны белү безгә татар халкын ясауда гонсырлык ролен үтәгән башка төрк халкының тормышын аңларга зур ярдәм итәчәктер. Без бу урында һуннарның тормышын үзебез тасвир кылырга азапланмыйча, шул заманнарда язган рума мөәррихе[3] Аммиан Марцеллин[4] дигән кешенең әсәренең бер урынын тәрҗемә кылып үтәбез. Бу кисәк безгә ачык бер тасвир бирәчәктер. Ләкин бу кисәкне укыган чакта, Марцеллинның психологиясенә дә кереп чыгарга кирәк: ул, румалы булганга күрә, һуннарга ифрат ачуланып, аларны ватанны җимерүче сыйфаты белән тасвир кыла: «Һун кабиләсе хакында борынгы язучылар бик аз беләләр. Һуннар Меотия сазлыгының[5] (ягъни Азак диңгезенең) Шимали Боз диңгезе ягында торып, үзләренең кыргыйлыкларында чиктән чыкканнар. Алар, бала тугач та, яңакларын

[1] Ишгаль кылгач – биләгәч.
[2] Малик – ия.
[3] Мөәррихе – тарихчысы.
[4] Аммиан Марцеллин (якынча 330–395 елдан соң) – борынгы Рим тарихчысы.
[5] Меотия сазлыгы – хәзерге вакытта Дон елгасының Россия көньягындагы тамагындагы сазлыкларны һәм Азов диңгезен эченә алган территориянең борынгы атамасы.

үткен пычак белән ярганнар[1]. Моны алар яңакларына сакал чыкмасын өчен ясыйлар. Шуның өчен һуннар гомер буе сакалсыз яшидер, һәм алар, ифрат кыяфәтсез булып, печтерелгән кешеләргә охшап калалар[2]. Аларның әгъзалары мускуллы һәм таза, муеннары калын, үзләренең төсләре гаҗәеп ямьсез һәм куркыныч, шуның өчен дә аларны ике аяклы ерткыч дип белергә яки каба[3] рәвештә юнып ясалган, күпер башларына куела торган сын (чурбан) дип белергә мөмкин. Шулай кыяфәтсез булсалар да, алар шулкадәр чыныкканнар ки, адәмгә махсус хәзерләнгән пешкән ашка да мохтаҗ түгелләр. Алар кырда үсә торган үләннәрнең тамырлары һәм төрле хайваннарның итләре белән тукланалар. Алар, чи итне асларына салып, атка атланалар да, шунда җылытып ашыйлар. Алар бер вакытта да бертөрле бина эченә кереп тормыйлар, бәлки алар, кабергә керүдән качкан шикелле, йортлар яратмыйлар. Аларда хәтта камыш белән капланган чатыр да юк. Алар тауларда, урманнарда күчеп йөриләр, яшьтән үк суыкка, ачлык вә сусызлыкка чыдарга өйрәнгәннәр; алар тәннәрен киндер яисә урман тычканнарының тиресенннән теккән кием белән каплыйлар; аларда өйдә кия торган вә кешелек кием арасында аерма юк – бер кигән киемне алар таланып, тузып беткәнче өсләреннән салмыйлар; башларын алар кәкре бүрекләр белән каплыйлар, әмма төкле аякларын – кәҗә тиресе белән. Аларның аяк киемнәре, бер төрле дә калыпка салынып тегелмәгәнгә күрә, йөргәндә адымнарын уңайсызландыра, шуның өчен алар (һуннар) җәяүле сугышка ярамыйлар, алар атларының өстенә үсеп чыккан төсле; аларның атлары таза булсалар да, әмма төскә ямьсезләрдер; алар ат өстендә, хатыннарча утырып, үзләренең гадәттәге хаҗәтләрен үтиләр, көн-төн шөгыльләнәләр һәм атларының муеннарына ятып шулкадәрле каты йоклый алалар ки, шунда төш тә күрәләр. Алар, җыелып киңәшкән чакта да, ат өстендә мәҗлесне үткәрәләр. Алар патшаның каты хакимиятен белмиләр, әмма үзләренең аксакалларының берсенә буйсыналар, юлда очраган бөтен нәрсәне

[1] Моннан Полинезия вәхшиләрендәге шикелле татуировка модада булса кирәк. *(Авт. иск.)*

[2] Әүвәл заманнарда Шәрыктагы төсле хәрәм агалары – коллар булган. Марцеллин һуннарга сакал чыкмауны шуннан күрсә дә, хакыйкатьтә аларның бу эшләре бары монгол-төрк җенесеннән килгәнлекләреннән генәдер. *(Авт. иск.)*

[3] Каба – тупас.

җимерәләр. Бәгъзы вакытта алар, бер-бер нәрсәгә ачуланып китеп, сугышка керешәләр. Алар сугышка гаскәрләрен чөй (клин) рәвешендә тезеп керешәләр һәм шул ук вакытта бик яман тавыш чыгарып кычкыралар; алар бик җиңел вә (сугышта) тиз хәрәкәтчән; сугышканда алар төп-томал[1] таралып китәләр дә, бер тәртип белән тезелмичә, әле бер җиргә, әле (дошманның) икенче җиренә һөҗүм кылалар вә дошманны яман күп үтерәләр… Алар бик яхшы сугышчылар дип танылырга хаклылар, чөнки алар сөяктән ясалган бик яхшылап очланган уклар белән ерактан торып сугышалар. Соңра, дошманга якын килеп, зур бер гайрәт күрсәтеп, кылыч белән сугыша башлыйлар һәм үзләре, дошманның хәмләсеннән[2] таелып, шул вакытта ук, ат өстендә утыра алмасын һәм җәяү китә алмасын дип, дошманга аркан ыргыталар. Аларның берсе дә сукаламый, һәм беркем дә алардан сукага кул тиергән кеше юк. Мәгълүм бер тора торган урынсыз, йортсыз, законсыз, утраклы тормышсыз – алар нәкъ мәңгелек качаклар шикелле тирмәләре (кибитка) белән күчеп йөриләр һәм шул тирмәләрдә көн кичерәләр. Шунда аларның хатыннары аларның кызганыч киемнәрен тегәләр, ирләре белән якынлык кылалар, зурайганчы балалар туйдыралар. Аларның берсе дә «Син кайда торасың?» дигән сөальгә җавап бирә алмый: ул бер җирдә ана карынында яратылган, аннан еракта туган вә аннан да ерак җирләрдә үскән…» Менә рума тарихчысының ачу белән һуннарны тасвиры шунда тәмам була.

Ләкин нәзек тормышка өйрәнгән рума зыялысына бу халык ифрат кызык вә кыргый тоелган, шуның өчен ул аларны ямьсез буяулар белән тасвир кыла. Әмма монда аларның күчмә хәятын вә сәяси тормышларын тасвир тугрыдыр. Ләкин һуннарга барган Рум илчеләреннән башкалары, шул ук һуннарда хөкем сөргән ыруг-патриархат төзелешен, аларның күчмә хәятларын тасвир итсәләр дә, алардагы тәртип вә яхшылыкларны да онытмыйлар вә һуннарның, мәдәни Яурупаның эченә кереп тора башлау белән, мәдәниятнең бәгъзы якларын ала башлауны да әйтеп китәләр. Мәсәлән, Истан-

[1] Төп-томал – тиктомалга.
[2] Хәмләсеннән – һөҗүменнән.

булдан һуннарга илче булып барган Приск[1] исемле бер галим Паннониядә[2], хәзерге Токай[3] шәһәре янында һуннарның ханнарының тора торган җиренә барып җитәрәк бер авыл күрә: уртада агачтан салынган бер сарай тора, бу йортта Аттиланың хатыннары һәм хезмәтчеләре торалар, авылда бөтен йортлар агачтан вә балчыктан ясалганнар. Бары мунчалар гына бер рума мөһәндисе[4] тарафыннан таштан салынган булган. Монда бөтен Яурупадан алынган мал җыелганга күрә, зиннәтле вә тантаналы тормыш хөкем сөргән. Хөкүмәт сөрүче сыйныф, хан, кабилә башлыкларының йортларында кыйммәтле паласлар, алтын-көмеш савытлар, хәтта энҗе белән зиннәтләнгән иярләр һәм башмакларны да Приск күргән. Шулай булса да, хан үзе һуннарның бөтен кабиләләренең башлыгы гына булуын онытмаган булса кирәк, агач табак-савыттан ашаган һәм гади һун көтүчесе шикелле киенгән булган. Аттила ыруг башлыкларын үзенең ыругына хөкем иткән рәвештә хөкем итә торган булган.

**Аварлар.** Һуннар, буран уйнатып Шәркый Яурупадан узып, Гарби Яурупага барып кереп бер заман торгач, һәрбер күчмә төрк оешмалары шикелле, соңра тагын кабиләләр вә ыругларга бүленеп беттеләр. Ләкин алар бетәр-бетмәс, Идел буена шул ук Каспий капкаларыннан 667 елда янә бер халык китеп чыкты, болар аварлар иде. Боларның да төрк булуын бәгъзы галимнәр дәгъва кылсалар да, хәзергә кадәр бу мәсьәләдә бер фикергә киленгәне юк. Ләкин боларның тормышы шул ук төрк кабиләләренең тормышлары төсле: башлыкларын «хакан» дип атыйлар, шулай ук ыруг-патриархат хәяты белән көн күрәләр иде. Аварларның да, һуннар шикелле үк, күбрәк хәрәкәтләре Гарби Яурупада, Балкан ярыматавында, Дунай белән Днестр елгалары арасында булды.

**Хәзәрләр вә болгарлар.** V–VI гасырларда Азиядән төрле төрк кабиләләре Шәркый Яурупага килеп чыгып торсалар да, аларның күбесе вакытлы гына хөкүмәт ясап торып, соңра таралып бетеп, яңадан икенче исем астында берләшеп тордылар. Ләкин шушы төрк

---

[1] Приск (?–472 елдан соң) – V гасырда яшәгән тарихчы һәм язучы. Көнчыгыш Рим императоры Феодосий II тарафыннан Аттилага илче итеп җибәрелгән һәм шунда күргәннәрен язып калдырган.

[2] Паннония – Венгриянең борынгы атамасы.

[3] Токай – Венгриядәге шәһәр.

[4] Мөһәндисе – инженеры.

яисә төркләргә кардәш булган күчмә халыклар арасында тарихта өчесе эз калдырдылар. Шуларның берсе – хәзәрләр, икенчесе – болгарлар; өченчесе – мадҗарлардыр. Боларның Шәркый Яурупага кайчан килеп чыгулары мәсьәләсендә төрле, бер-берсенә каршы булган фикерләр сөйләнә. Безгә бу чын-чын археология мәсьәләсе мөһим түгел, шуның өчен без хәзәр вә болгарлар хакында иң шаигъ[1] булган фикерләрне җыеп, бер системага салып сөйләп үтәбез. Бу ике халыкның тарихы һуннар вә алардан соң килгән халыкларныкыннан аерыла: һәм болгарлар, һәм хәзәрләр икесе дә шактый гына яшәгән мәдәни дәүләтләр ясый алдылар, моның сәбәбе дә – бу халыкларның борынгы заманның сәүдә юлы өстендә ятуларыдыр. Болар аркылы үткән мал, сәүдәгәр боларга мәдәният керткән һәм, күчмә төркләрне утраклы ясап, дәүләттә тәртип ясарга да сәбәпче булган. Шул сәбәпле, бу ике төрк халкының тарихлары, бөтен инсаният тарихы өчен мөһим булганы шикелле, татар тарихы өчен дә мөһимдер. Боларның торган урыннары соңра татар халкының торган вә яшәгән урыннарында иде. Бер дә шиксез, бу ике төрк оешмасы татар халкын ясауда гонсырлык ролен зур уйнады.

**Хәзәр вә аларның җирләре.** Хәзәрләрнең төп җирләре Идел елгасының түбәнге агымы иде. Борынгы заманда да Идел елгасы Азиядән килгән сәүдәгәр вә башка халыкларның – Яурупага, Яурупадан килгәннәренең Азиягә китеп йөри торган юллары иде. Борынгы Шәркый Яурупаның озын сахра-чүлләре, балта, пычак кермәгән сазламыклары, баткалыклар белән тулган урманнары арасыннан йөри торган юллар юк иде. Ул җирләрдә – кыргый күчмә төрк кабиләләре, урманнарда исә фин халыклары торалар, шуңа күрә сәүдәгәрләр өчен коры җирдән йөрү куркынычлы да һәм малны коры җирдән йөртү кыйммәткә төшәдер иде. Шул сәбәпле сәүдәгәрләр әллә ничә көймә белән Идел өстендә йөриләр һәм, дошман һөҗүменнән сакланып, үзләре белән бергә кораллы сакчылар да алалар иде.

Һәрбер патшалыкның җиренең чикләре заман үтүе белән алмашынып тора, шуның өчен хәзәрләрнең җирләре дә әле зурая, әле кечерәеп торган. Хәзәрләрнең иң куәтле, иң зур вакытлары – VIII гасырның урталары һәм IX гасырлардыр. Бу чакта аларның

[1] Шаигъ – билгеле.

чикләре җәнүбтә Кавказ тауларына карап тора. Гаребтә ул заманда славяннар тора торган Днепр елгасына барып җитеп, Кырым ярымтавының күп җирләре хәзәрләр кулында булган. Бары тик Кара диңгез якасындагы бәгъзы шәһәрләрдә генә греклар (румнар) торганнар. Шимальдә аларның җирләре Җаек елгасына барып җитеп, Идел елгасының урта агымында булган болгар, төркләрнең җирләре белән чиктәш булган.

**Халык.** Хәзәр илендә халык төрле җенестән иде. Кавказ тирәсендә Кавказдагы хәзерге чәчән[1], лезгин күк тау халыкларының бабалары торалар. Болгар иленә таба хәзерге Саратау[2] губернасы тирәсендәге урманлык җирләрдә фин кавемнәре торганнар. Хәзәр илендә килмешәк гарәп, Иран сәүдәгәрләре дә торалар. Ләкин мәмләкәттә төп асыл дәүләт ясап торучылар хәзәр исемендә йөртелә торган төрк халкы булып, шулай ук хәзерге җәнүби Русиянең сахраларында күчеп торучы төрле исемле төркләр дә Хәзәрстанда булган.

**Хәзәр дәүләте. Хакан.** Гайсәдән соң биш йөзенче елларда ук хәзәрләр дәүләт ясаганнар. Димәк, алар бер төрле законга – гадәткә буйсынганнар, гаепле кешеләрне хөкем итәр өчен казыйлары, халыкны саклар өчен гомуми гаскәрләре булган.

Дәүләтнең башы һәм аны идарә итүче нәселдән нәселгә булып килә торган бер патшалары булып, аны хәзәрләр башка төркләр шикелле үк «хакан» дип йөргәннәр. Бөтен гаскәр аңа табигъ[3], бөтен түрәләрне ул куя, ул солых ясый, сугыш игълан кыла. Хакан үзе Идел елгасының диңгезгә коя торган урынында салынган Идел исемле шәһәрдә тора, шунда шәһәрнең бер кисәгендә, бер атауда аның сарае бар иде. Дошман һөҗүм иткәндә, хаканны үтермәсеннәр яисә тотып алмасыннар дип, калын, биек койма белән сарайны әйләндереп алынган. Шул койманы саклап, анда унике мең гаскәр торган. Хакан, башка төрк патшалары күк, күп хатын ала. Гарәп сәйяхләренең әйтүенчә, аның никахлы, үзенә буйсынган төрле патшаларның кызларыннан гыйбарәт булган егерме биш хатыны булган, имеш.

Хакан булу өчен байлык шарт түгел. Аларга мәгълүм бер нәселдән генә килү шарт булган. Бер вакытта күмәч белән сәүдә кылып

[1] Чәчән – чечен.
[2] Саратау – Сарытау (Саратов).
[3] Табигъ – буйсынучы.

йөрүче малайның, хаканнар нәселеннән килгәнгә күрә, хакан булганлыгын сөйлиләр.

Хаканнарны халык бик хөрмәт итә, чөнки ул алардан шомлана вә бик курка торган булган. Хаканнар бер дә тышка, шәһәргә чыгып йөрмиләр. Бик сирәк вакытларда гына чыгарга туры килсә дә, халык очраганда аңар таба карау ярамаган эш хисапланганнан, ул үтеп киткәнче сәҗдә кылып җиргә ятып калалар, хәтта үлгән хаканнарның каберләре яныннан үткәндә, атыннан төшеп, зиярәт күздән югалганчы җәяүләп баралар иде. Хакан сугышка да бик сирәк кенә бара. Барганда, арбага утырып, кеше күрмәсен өчен башына ефәктән кара бөркәнчек ябына торган булган.

Шулай булса да, Хәзәр илендә хаканга каршы ихтилаллар[1] чыгып торган. Бәгъзы вакытларда халык, җыелып килеп, аның үтерелүен теләп һөҗүм итеп, аны тотып үтерә торган булган. Илдә булган һәрбер уңайсызлык, ачлык, муаффәкыятьсез[2] сугыш, үләт күк бәхетсезлекләрне халык хаканнан күреп, шундый вакытларда хаканны төшергәннәр яки үтергәннәр. Гомумән, хәзәр халкы бер хаканны кырык елдан артык хөкүмәт сөрергә ирек бирмәгән; аларның фикеренчә, бер кеше кырык елдан артык патшалык сөрсә, аның гакылы бетәр иде.

**Түрәләр.** Хаканнан кала мәмләкәтне идарә итүче бер вәзир булып, аны «хаканбәк» дип йөргәннәр. Хакан үзе идарә эшләренә күп катышмый. Патшалык эшләрен шул хаканбәк идарә кылган. Аның хакимияте бик зур булып, ихтилал чыгып, халык хаканның төшерелүен сораган вакытта, шул ук хаканбәк хаканны хөкем итә. Гөнаһлы булса, төшерә яисә халык кулына бирә, гөнаһсыз тапса, халыкны куып тараткан.

Хакимияте шулкадәрле зур булса да, хаканбәк патшаны хөрмәт итә, хакан янына кергәндә яланаяк кереп, сәҗдә кылып ята, бары тик хакан рөхсәт иткәч кенә, торып, аның янына утырып, эш хакында сөйләшә, киңәшә иде.

Янә «кәндер хакан» дигән хакан хаканбәкнең булышчысы, кул астындагы бер түрә булып, ул да хакан янына керә алган. «Үлишә» атлы тагын бер түрә булып, ул илнең гаскәри көчләре белән команда

[1] Ихтилаллар – фетнәләр, бунтлар.
[2] Муаффәкыятьсез – уңышсыз.

иткән. Зур шәһәрләрдә хаканның уллары, якын кардәшләре вәли (губернатор) булып идарә кылып торганнар.

**Гаскәр.** Илне һәрьяктан дошман чолгап алган. Азиядән килеп чыгарга торган әллә никадәр төрк халыклары һәрвакытта Хәзәр мәмләкәтен куркуга салып торганнар. IX гасырдан алып әрмәннәр, көймәләргә утырып Идел белән төшеп, илне талап йөргәннәр, VIII гасырларда руслар да, хәзәрләр кул астында булганга, һаман да ихтилал кузгатып торганнар. Дон, Идел белән Днепр араларында ул вакытларда маҗарлар (венгрлар) да һаман Хәзәр иленә һөҗүм иткәннәр, мөселман хәлифәләренең гаскәрләре дә, Кавказ тауларын үтеп, Хәзәр илен басып керергә өметләнеп торганнар. Шул сәбәпле хәзәрләр зур гаскәри куәт тотарга мәҗбүр иделәр. Аларның хаканны саклый торган унике мең хасса[1] алае (гвардия)ләреннән башка чит халыктан ялланган, һәрвакытта сугышка хәзер торган ун мең атлы гаскәрләре булган. Бу гаскәр кылыч, ук, сөңге, калкан белән коралланган булган. Тагын һәрбер бай кеше, үз малының санына карап, ат биреп, киендереп, азык белән гаскәр бирергә мәҗбүр булган.

Хәзәрләрнең гаскәрләрендә низам[2], тәртип бик куәтле булып, сугыш сафыннан качкан кешеләргә бик каты җәза бирелгән, ләкин шулай булса да, чит милләтләрдән ялланган гаскәр күп вакытта ихтилал чыгара, хөкүмәтнең сүзенә каршы килгән.

**Хөкем.** Хәзәр иленә чит халыклардан бик күп сәүдәгәрләр килеп торганнар. Бу сәүдәгәрләргә һәртөрле уңайлыклар эшләргә хөкүмәт бик тырышадыр иде. Халык бер-берсенә хаксызлыклар эшләмәсен, бер-берсен рәнҗетмәсен өчен, Хәзәр дәүләте хөкем (суд) эшенә бик әһәмият биреп, зуррак шәһәрләрдә мөмкин кадәрле төрле дин әһеленнән булган яхшы казыйлар куярга тырышадыр иде. Мәсәлән, хәзәр хаканының торган шәһәрендә ике мөселман, ике христиан, ике яһүд, бер мәҗүс казые булган. Мөһим мәсьәләләр чыкканда, алар җыелып киңәшеп хөкем итәләр, хәл итә алмаслык мәсьәләләр булганда, мөселман казыеның сүзечә хөкем кылганнар. Хаканбәк хөкем эшенең ничек баруы хакында һәрвакытта хәбәрдар булып тора, аның илчесе казыйлар янына килеп-китеп йөри торган булган.

[1] Хасса – биредә: үз халкыннан тупланган.
[2] Низам – тәртип.

**Дин.** VIII гасырга кадәрле хәзәрләрнең күбрәге борынгы төрк дине булган шаман динендә иделәр. VII гасырдан игътибарән[1] Хәзәр иленә сәүдә белән төрле дин әһелләре килә башлаган. Сәүдәгәрләр белән төрле дин халыкларының галимнәре киләләр; алар хәзәр халкын үз диннәренә өндиләр иде. Бу заманнарда хәзәрләрнең зур шәһәрләрендә дин хакында моназарәләр[2] була. Һәркем үзенең динен куәтләп нотыклар сөйли, хаканнар дин мәсьәләләренә әһәмият бирәләр, үзләре дә шул моназарәләрне тыңлыйлар иде.

VII гасырның ахырларында гарәп мөселман хәлифәләренең куәтле чаклары булып, мөселманнар, Кавказ тауларын үтеп, гаскәрләре белән кереп, хәзәрләрне ислам диненә өндәр өчен дигән булып, аларны вә алар ишгаль кылып[3] торган шимали Кавказ һәм Идел буен үзләренең сәүдәләренә буйсындыру өчен сугышалар иде. Бервакытта, VIII гасырда, хәзәрләр мөселманнар тарафыннан җиңелеп, мөселман дәүләтләре белән дус тору аркасында сәүдәне зурайту фикере белән хәзәр хаканы мөселман динен кабул иткән булган.

VIII–IX гасырларда халык арасында ислам дине таралган. Шул ук вакытта төрле мөселман, христиан илләреннән сөрелгән яһүдиләр дә дингә ирек бирүче хәзәрләргә килеп сыенганнар һәм алар да үзләренең диннәрен халыкка таратырга тырышканнар. Ниһаять, VIII гасырның ахырларында, Булан исемле хакан заманасында, бу хакан яһүди динен кабул итеп, IX гасырда яһүди дине хәзәрләрнең хөкүмәт ирләре вә эгъяны (аксөякләр) тарафыннан рәсмән кабул ителгән иде. Яһүдләр белән катнашу хәзәрләрнең хөкүмәт сөрүче сыйныфын мәдәни яктан күтәргән. Хәзәрләрдә әдәбиятның булуы хакында хәбәрләр аз, ләкин X гасырдагы хакан Йосыфның[4] Әндәлестәге Хасдай ибн Шапрут[5] дигән бер яһүд галименә язылган хаты шушы заманга кадәр сакланып калган. Хат яһүд телендә языл-

[1] Игътибарән – башлап.
[2] Моназарәләр – бәхәсләр.
[3] Ишгаль кылып – биләп.
[4] Йосыф хакан (?–965тән соң) – Хәзәр дәүләте идарәчесе. Аның Хасдай ибн Шапрут белән алышкан хатлары борынгы болгарлар һ.б. Идел буе халыклары турында мөһим мәгълүмат бирә.
[5] Хасдай ибн Шапрут – Испания хәлифәсе Габдеррәхман III сараенда елъязмачы, яһүд галиме.

ган, төрк телендә язылган әсәрләр бер дә калмаган. Хәзәрләрнең шәһәрләрендә балалар укыр өчен мәктәпләр дә булганы мәгълүм.

**Хәзәр мәдәниятенең дәрәҗәсе.** Хәзәр халкының төп шөгыльләре бакчачылык, игенчелек, хайван асрау, сәүдә булган. Хәзәрләр күчмә тормыштан яңа гына чыгып киләләр, шуның өчен алар кыш көннәрендә шәһәр, авылларда торалар да. Җәй булгач та, һәркем үзләренең бакчасына киләләр иде. Җәнүбтәрәк торучы хәзәр халкы бодай чәчә, йөзем утырта һәм башка җимеш агачлары җитештерә, һәрбер гаиләнең үзләренең бабаларыннан мирас булып калган җирләре буладыр иде.

**Сәүдә.** Хәзәрләр сәүдә өчен бик мәгъкуль[1] һәм искедән бирле сәүдә юллары булган өч елга өстендә утырганнар. Алда сөйләгәнчә, хәзәрләрнең беренче торган урыннары Идел елгасының түбәнге агымы булып, алар бу юл белән Хәзәр (Каспий) диңгезеннән Кавказның шәркый ярлары буеннан мал китерәләр. Идел елгасыннан башка, Азак[2] диңгезенә агып чыга торган Дон елгасы да хәзәрләр кулында иде. Идел елгасы буенча килгән мал, Дон елгасының Иделгә якын килеп аккан урыныннан төшерелеп, Дон елгасы белән диңгезгә чыгып, Азак диңгезеннән Кара диңгезгә күчеп, Истанбулга, аннан башка илләргә җибәреләдер иде. Чит илләрдән килгән мал да, шул ук юл белән Хәзәрстанны үтеп, Шәрык илләренә китәдер иде. Хәзәрстанга бал, тире, йон, май шикелле нәрсәләр килә. Шулай ук Русиягә Новгород аркылы килә торган маллар да Идел елгасы белән китереләдер иде.

Җаек (Урал) елгасы да хәзәрләр кулында иде. Урал тауларындагы урманнарда тотылган җәнлек тиреләре, ул таулардан чыккан алтын, көмеш, бакыр күк мәгъдәннәр[3] – һәммәсе дә Хәзәрстанның мәркәзенә китерелеп, аның базарларында сатылалар. Хәзәрстанның үзеннән дә бәгъзы мал чыгадыр иде. Ул исә балык, балык мае булып, хәзәрләрдән алынган балык Гарби Яурупа һәм Русиянең киң базарларында сатыладыр иде. Хәзәр дәүләтенең иң зур килере шул сәүдәгәрләрдән алына торган пошлинадан гыйбарәт булганга, Хәзәр хөкүмәте мөмкин кадәрле сәүдәне куәтләргә, сәүдәгәрләрне илгә җәлеп кылырга тырышадыр иде.

---

[1] Мәгъкуль – лаек, яраклы.
[2] Азак – Азов.
[3] Мәгъдәннәр – металлар.

**Шәһәрләр.** Бер мәмләкәттә сәүдә булды исә, анда шәһәрләр дә була. Шәһәрләр ул заманнарда сәүдәгәрләр торыр өчен, мал куяр өчен салыналар. Хәзәрләрнең әллә ничә дистәләп олы һәм кечкенә шәһәрләре бар иде.

Иделнең Хәзәр диңгезенә коя торган хәзерге Әчтерхан[1] урынында Идел исемле шәһәр бар иде. Бу шәһәр Хәзәрстанның сәүдә мәркәзе булып, Яурупа белән Урта Азиянең зур алыш-биреш урыны булган. Анда әллә никадәр мөселман, христиан, яһүд мәгъбәдләре[2] һәм мунчалары бар. Зур бина мәсҗед җамигъ булып, аның манарасы хаканның сараена таба карап торадыр. Бу шәһәрдә зур базар урыны булып, анда төрле милләттән булган сәүдәгәрләр сәүдә кылып утыралар. Андагы өйләр күбрәк балчыктан һәм агачтан салынган булып, шәһәрнең бер аерымрак урынында кирпечтән ясалган крепость (кальга) белән әйләндереп алынган, хаканның таштан салынган сарайлары булган. Башка кешеләргә кирпечтән өй салу мәмнүгъ[3] булган.

Кавказның Хәзәр диңгезе буенда Дәрбәнд шәһәре белән Итил шәһәрләре арасында Сәмәндәр исемендә янә бер зур шәһәрләре бар иде. Бу шәһәр Хәзәрстанның зур истихкямы[4] булып, шулай ук Һинд, Иран илләреннән килә торган сәүдә кәрваннарының туктый торган урыны иде. Бу шәһәр бакча эченә батып утыра. Борынгы заманда хәзәрләрнең патшалары торган урын шушы шәһәр булган. Җаек елгасының диңгезгә коя торган урынында янә бер зур шәһәрләре булып, аны Саксин дип атыйлар иде. Бу шәһәр Азиядән Хәзәрстанга һөҗүм итәргә торган күчмә төрк кабиләләреннән илне саклау өчен салынган крепость (кальга) иде. Монда да күп мәсҗедләр, зур бакчалар бар иде.

Бу шәһәрнең урыны салкынчарак урында булганга, өйләре бүрәнәдән булып, эче киез белән өртелгән буладыр иде. Хәзәрләр тагын Донның Идел елгасына якын килә торган урынында, рум

[1] Әчтерхан – Әстерхан.
[2] Мәгъбәдләре – гыйбадәтханәләре.
[3] Мәмнүгъ – тыелган.
[4] Истихкямы – хәрби ныгытмасы.

осталары китереп, Саркел[1] атлы бер шәһәр бина иткәннәр иде. Бу шәһәрдә крепость булып, Саркел румалар белән хәзәрләрнең сәүдә кыла торган урыннары булган.

**Хәзәр дәүләтенең шәп вакыты.** VIII–IX гасырларда Хәзәр дәүләтенең иң куәтле, шәүкәтле чаклары иде. Бу заманнарда хәзәрләр бөтен Шәркый Яурупа сәүдәсенең хуҗалары иде. Руслар, болгарлар, башка фин кабиләләре, шимали Кавказдагы тау халыклары хәзәрләрнең кул асларында булып, аларга хираҗ (дань) түләп торалар. Шулай булса да, хәзәрләр, Азиядән Яурупага һөҗүм итәргә генә торган төрле күчмә төрк кабиләләрен үзләренең гаскәри куәтләре белән басып, ул чактагы Шәркый Яурупаның тынычлыгын саклау ролен үтиләр иде. Хәзәрләрнең зур җирләрендә дә әллә никадәр күчмә төрк кабиләләре булып, хәзәрләр дәүләте көчле чакта болар буйсынып тордылар.

**Хәзәр дәүләтенең зәгыйфьләнүе – бетүе.** X гасырларда Днепр тирәсендәге руслар куәтләнә башлаганнар. Алар, Скандинавиядән килеп йөри торган батыр, сугышчан норманнарга[2] буйсынып, аларның кенәзләрен үзләренә патша иткәннәр иде. Шул руслар, үзләренең башлыклары белән көймәләргә утырып, Идел елгасы белән төшеп, хәзәрләрне талый, аларның шәһәрләрен җимерә башлаганнар. Алар, берничә мәртәбә барып, Итил шәһәрен дә харап итеп килгәннәр. Башка халыклар да хәзәрләр кул астыннан чыга башлаганнар, сугышлар, чуалулар булып торгач, сәүдәгәрләр дә аз килә башлаганнар. Моңарчыга кадәр Рум (Византия) патшалыгы да, Гарәп хәлифәтенә каршы сугышларда хәзәрләр белән файдаланып, сәүдә өчен файдалы булганга, хәзәрләрне яклап килсә дә, X–XI гасырларда ул заманның бәйнәлмиләл[3] сәясәте үзгәргән иде. Хәзәр Византиягә күбрәк Яурупадан килгән әһле салиб[4] гаскәре белән берләшергә туры килә, шуның өстенә бу заманда инде Византиягә гарәпләрнең

[1] Саркел (Шаркил) 830 елларда византиялеләр ярдәме белән төзелә. Вакытлар узу белән, эре сәүдә-һөнәр үзәгенә әверелә. 965 елда Киев кенәзе Святослав I тарафыннан басып алына. XII йөз уртасына кадәр Белая Вежа дип йөртелә, шуннан акрынлап таркала.

[2] Норманнар – Урта гасырларда Скандинавия халкына карата кулланылган гомуми этноним.

[3] Бәйнәлмиләл – халыкара.

[4] Әһле салиб – тәре йөртүчеләр.

һөҗүмнәре дә кимегәнлектән, ул сәүдәдә конкурент булган хәзәрләрне яклый алмый да һәм аңарга артык тырышмаган да булырга кирәк. Сәүдә кимегәч, хәзәрләргә тамга акчасы[1] аз керә башлагач, байлык кимегәч, гаскәр яллар өчен дә көчләре калмаган; яллаган гаскәр дә дини сәбәпне бәһанә[2] итеп, ягъни: «Без ни өчен яһүд динендәге хөкүмәткә буйсыныйк?» – дип, гаугалар кузгата башлаганнар иде. Хәзәрләрнең сахралы урыннарында күчеп йөри торган күчмә халыклар да һөҗүмгә башлаганнар, Каспий капкаларыннан чыгарга омтылып торган күчмә төркләргә шуның өчен капка ачылган иде. Без бу халыкларның килеп чыгулары, аларның тормышлары хакында түбәндә сөйләрбез. Ләкин Идел елгасы шикелле табигый бер сәүдә юлы бер минут та сакчысыз тормады вә анда тәртип ясалырга тиеш булды. Менә ул тәртипне саклаучы, Идел-Чулман (Кама) елгаларыннан күчеп, Азия, Җәнүби вә Шимали Яурупага китә торган мал юлын тотучы яңа бер оешма дәүләт килеп чыкты, ул да булса башта хәзәрләргә буйсынып торган, җәнүбтән күчеп килеп, урманлык вә басулык урыннарны ишгаль кылган[3] болгар төркләре иде.

**Болгар иленең урыны һәм аның табигате.** Болгарларның җирләренең тәүмәле (микъдары) төрле вакытларда үзгәреп торган: аларның җирләре Урал тауларыннан вә Иделнең урта агымыннан алып Сура һәм Уфа елгалары тирәләренә, Вятка вә Кама буйларын эченә алып, Дон, Хопра һәм Самара елгаларына кадәр барып җиткән. Ләкин болгар җиренең мәркәзе хәзерге Татарстан җөмһүриятенең Спас, Арча, Лаеш, Чистай кантоннары булган.

Болгар иле чын-чыннан могтадил[4] һавалы җирнең салкын җирләргә күчә торган урыннарында ятадыр иде. Бу илдәге җәйге озын, кышкы кыска көннәр монда килеп йөрүче могтадил һәм эссе һавалы җирләрнең сәйяхләрен шаккатырган. Бу җирләрдә инде төркләр, үзләренең төп ватаннары булган Урта Азиядәге күк, юка киез өйләрдә тора алмыйлар, чөнки өзеп алырлык кышкы салкыннар, көзге карлы яңгырлар кешеләрне өшетә, агач йортлардагы җылы мич алларына куадыр иде.

[1] «Тамга акчасы» дигән сүздән гөмрүк акчасы яисә пошлина акчасы морад. *(Авт. иск.)*
[2] Бәһанә – сәбәп.
[3] Ишгаль кылган – биләгән.
[4] Могтадил – уртача.

Болгар җире Хәзәр иле шикелле түгел. Анда күбрәк урманнар хөкем сөрә, ул урманнарда чиксез күп җәнлекләр яшиләр, аның җиренең күбрәк урыны кара балчык. Шуның өчен бу җирләрдә салкынчарак һавалы җирләрдә үсә торган игеннәр һәммәсе дә җитешкән.

Ләкин әүвәлерәк, IX гасырларда, урманнар күплектәнме, Болгар иле тагын да юеш булган. Хәзер бик шәп булып алма җитешә торган Спас кантоны урынында булган җирләрдә алма пешеп җитә алмаган.

**Бу җирнең әүвәлге халкы.** Болгар иленең төп халкы ярым вәхши, бары ау аулап, аз гына иген чәчеп, агач вә жердалардан ясалган йортларда, землянкаларда торучы тәбәнәгрәк буйлы, кысык күзле фин халкы иде. Бу финнар – хәзерге чирмеш, мукшы, аларның бабалары. Һуннар килгән чакта, боларга Азиядән килүче төрк дулкынының очы гына җитеп калган булса да, төрк халкы, аяклы хайван асраучы халык булганга, бу урманлык-сазлык җирләрдә калмыйча, җәнүби Русия сахраларын ихтыяр иткәннәр[1].

**Болгарларның килүе хакында хорафат[2].** Һуннар дәүләте егылу белән, тәкъдирнең кушуы буенча, бу урманлык, печәнлек, сазлык Идел вә Кама буйларына төркләр килеп утырып, төп җирле фин халыкларын үз кул асларына алганнар, имеш.

Борынгы заманнардан калган әкиятләрне хорафат яисә мифлар, диләр.

Менә шундый хорафатның берсе болгарларның Идел һәм Кама буйларына килеп утырулары хакында шундый хәбәр бирә: һуннарның шөһрәтле башлыклары Аттила 454 [елда] үлгәннән соң, аның сөекле улы (Әрнияк – болгарча Ирнипәк[3]), заманасында үзләренең дошманнары тарафыннан җиңелеп, хәзерге Шәркый Яурупаның (Русия) киң сахраларына үзенең урдасы белән килеп утырган. Ул үлгәннән соң, шул ук җенестән Корт[4] (Куварат) исемле кеше хан булган. Бу вакытта болгарлар хәзерге Азак диңгезе һәм Кубань

[1] Ихтыяр иткәннәр – сайлаганнар.
[2] Хорафат – легенда.
[3] Ирнипәк (Ирник) – Аттиланың өченче улы, һуннарның соңгы хөкемдары. Аттиланың вафатыннан соң, аның уллары арасында һуннар державасының таркалуына китергән үзара ызгышлар башлана. Ирнипәк, абыйсы Эллак һәлак булгач, 454 елда хакимияткә килә.
[4] Кубрат хан (?–640 еллар) – Бөек Болгар дәүләтенә нигез салучы һәм аның идарәчесе (632 елдан).

елгасы буенда торалар. Бу Корт хан, үләр алдыннан, үзенең дүрт улына бер дә таралмаска, бергә торырга васыять әйтеп калдырган. Ләкин балалар вә халык арасында татулык булмыйча, болар таралдылар. Шуларның бер кыйсеме китеп, хәзер Балкан ярыматавында торучы славянлашып беткән болгар халкын ясаган, имеш; ләкин аларның бер кисәге Азак диңгезе кырыенда калган.

Шул рәвешчә, башта Шәркый Яурупаның Дон, Днепр, Азак диңгезе буенда утыручы һуннарның бер кисәге булган болгарларның берникадәресе, Гайсә пәйгамбәрдән соң VII–VIII гасырларда килеп, Идел, Кама елгалары буена утырганнар, имеш.

**Болгар дәүләте.** Финнар арасына, урманлык җирләргә килеп утырган күчмә болгарлар дәүләт төзегәннәр иде. Бу Болгар дәүләте хәзәрләрнең шәүкәтле вакытларында, IX гасырларда, руслар шикелле үк, Хәзәр дәүләтенә хираҗ (дань) түләп, аларга буйсынып торганнар. X гасырның башларында Хәзәр дәүләте зәгыйфьләнгәч, болгарлар аларның кул асларыннан чыкканнар.

Мәмләкәтнең башында хан тора; ул финнарны үзләренә буйсындырган төрк кабиләсенең патшасы булган. Җирле фин кабиләләренең дә үзләренең хөкүмәтләре, ханнары вә тарханнары булган. Ул ханнар барысы да Болгар ханына буйсыналар, ханга чит илләрдән мөһим илчеләр килгәндә, тантаналы мәҗлесләрдә ханның уң ягында утыралар, Болгар ханы үзе парча материя япкан тәхеттә утырадыр иде. Болгар ханы урамда очраганда, халык башыннан бүреген алып, аңа хөрмәт күрсәтә торган булган.

**Болгар дәүләтенең килере.** Болгар дәүләтенең башлыча килере бу җиргә килеп сәүдә кылучыларның малыннан алына торган пошлина булган. Алар пошлина итеп китерелгән малның ун өлешеннән бер өлешен (гошерен) алалар иде. Ашлык чәчүчеләрнең игененнән салым алынмаган. Борынгы күчмә төркләрдәге күк, халык хөкүмәткә һәрбер йорттан бер үгез тиресе, һәрбер өйләнүче кеше ханга бүләк итеп атлана торган бер ат биргән. Әгәр бер-бер халык белән сугышып, бер микъдар мал алсалар, шуның бер кисәген хөкүмәт ала торган булган.

**Хөкем.** Болгарларның хөкем эшләре хәзәрләрнеке күк тәртипкә куелганы мәгълүм түгел. Шулай да аларда җинаять кылучыларны җәза кылу шикелле хөкем булган. Болгар илендә хөкем эшләрен

ыруг башлыклары башкаралар һәм ул кешеләрне «түрә» дип атаганнар.

Болгарлар, гаепле кешеләрнең гөнаһларын әйттерер өчен, гаепләнүченең башын таяк белән кыйнаганнар. Аларда бик зур гаеп кеше үтерү, гаиләгә хыянәт кылу хисапланган. Кеше үтерүчене болгарлар, агач сандык эченә салып, бер озын багана өстенә менгереп асалар да аңар ашарга, эчәргә бирмиләр, шунда гаепле кеше үләдер иде. Гаиләгә хыянәт иткән кешеләрне аяк-кулларыннан дүрт казыкка бәйләп, муеныннан алып озынчага икегә кискәннәр. Сихерчелектә гаепләнүче кешеләргә дә бик каты җәза булган: мондый кешеләрнең муеннарына җеп тагып, агачка асып куя торган булганнар.

**Шәһәрләр.** Болгарларның ханы, хөкүмәте шәһәрдә торган. Болгарларның шәһәрләре күп булып, хәзерге Казан губернасының Спас, Чистай, Лаеш кантоннарында болгарларның шәһәрләре булган. Шуларның берсе Спас кантонында Болгар исемле шәһәр булган; аннан башка Биләр, Суар, Кашан исемле вә башка бик күп шәһәрләре булган. Болгар шәһәрләре шактый зур булалар, аларның кайсыларында тора торган халыкның саны ун меңнән арта; шәһәрләр күбрәк елга буенда салыналар, тирә-ягы тирән чокыр белән әйләндереп алынып, чокырның эчке ягыннан биек калын имән бүрәнәдән салынган койма белән шәһәр чолгап алынган була. Шәһәрдәге гади кешеләрнең өйләре бүрәнәдән салынган һәм киез өйләрдән гыйбарәт буладыр иде.

Болгарлар X гасырның башында рәсмән[1] ислам дине кабул иткәннәр. Шушы вакыттан соң Гарәбстаннан мөселман осталары китерелеп, таштан мәсҗедләр, сарайлар салынганнар. Бәгъзы шәһәрләрендә әллә ничә манаралы мәсҗедләр салынган; таш мәсҗедләр, читтән чишмәләрдән шәһәргә килә торган су юллары (водопровод) ясалган. Мәшһүр кешеләр үлгәч, аларның каберләре өстенә, бик матурлап гөмбәз ясап, биналар салып куйганнар.

Шәһәрдә урамнар тар, ләкин сәүдәгәрләргә сату итү өчен базар итеп киң мәйданнар калдырылган булган.

**Болгарларның шөгыльләре.** Болгарларның авыл-шәһәрләре кыш өчен генә булып, җәй көне шәһәрләрдә бары сәүдәгәрләр белән һөнәрчеләр генә калалар иде: күбрәк кеше җәйләүгә,

[1] Рәсмән – рәсми рәвештә.

кырга чыгып китәләр, бөтен җәйне кырларда, болыннарда үткәрәләр. Болгарлар җәй көне үзләренең ат, сыер, сарыкларын Идел һәм Каманың киң болыннарында көтеп йөриләр. Алар үзләренең мөнбит (иген уңа торган) җирләрендә иген дә чәчәләр иде. Аларның җирләрендә бодай, арпа, тары һәм башка төрле икмәк тә үскән. Болгарларның җимеш бакчалары да булып, алма агачы күп утырталар. Аларда иген шулкадәр күп буладыр иде, күршеләре русларда ачлык булган вакытларда, аларга иген күндереп торалар иде. Мәсәлән, 1006 елда Суздаль Русиясеннән, көчле ачлык булганда, болгарларга барып, руслар иген алып кайтып котылулары, шулай ук 1229 елда Русиядә ачлык булганда, болгарлар Идел һәм Уфа елгалары белән иген алып барып сатып, болгар ханы да, рус кенәзе Юрийга[1] утыз баржа икмәк биреп, ачлыктан котылдырылганнары мәгълүм. Хайван асрау, игенчелек белән бергә болгарлар сәүдә белән дә шөгыльләнәләр. Хәзәр дәүләте бетмәс, зәгыйфьләнмәс борын, болгарлар күбрәк Идел елгасы белән Азия, Гарби Яурупадан килгән малларны, Кама вә Вятка елгалары белән барып, шималь илләрендә, Урал тауларында торучы башкорт, бортас күк төрк, фин кабиләләренә саталар иде.

Болгар иленнән Шәрык илләренә төрле җәнлек тиреләре, балавыз, эре балык, балык җилеме, мамонт һәм морж тешләре, гәрәбә, бал, урман чикләвеге, каен агачы җибәрәләр иде. Бу нәрсәләрне алыр өчен болгар сәүдәгәрләре, Шимальнең шәрык өлкәләренә менеп, ул җир халыкларына кирәкле нәрсәләргә алмаштырып төшәләр; ул җирләргә болгар сәүдәгәрләре су белән, ат белән, хәтта эт җигеп тә баралар иде. Болгар сәүдәгәрләре Гарби Яурупага да барып сәүдә кылалар. 970 елларда хәзерге Венгриягә дә килгәннәр, монда аларга Дунай суының сул ягында җир биреп, шунда болгарлар Будапешт шәһәрен салганнар. Болгар базарларында бик күп коллар сатыладыр иде. Борынгы заманнарда әсир төшкән кешеләрне нәкъ мал саткан шикелле итеп базарларда сату гадәте булган. Бигрәк тә аларның базарларында славян җенесеннән булган коллар күп булган. Шулай ук болгарларда эшләнгән нәрсәләр белән дә сату итәләр: ерак җирләргә барып һәм үз шәһәренең базарларында чит-

[1] Юрий Всеволодович (1188–1238) – Владимир (1212–1216, 1218–1238), Городец (1216–1217), Суздаль (1217–1218) кенәзе.

тән, бигрәк шимальдән килгән алучыларга алар уклар, кылычлар, көбәкүз киемнәр, төрле бакыр, көмеш, алтыннан алка, беләзек, йөзек, чулпы, тәңкәләр күк зиннәт нәрсәләре дә саталар иде.

**Һөнәр вә сәнәгать.** Алда әйтелгән нәрсәләрнең күбесе болгарларның үзләрендә эшләнәдер иде. Аларда эшләнгән нәрсәләрнең иң күбе кәҗә тиресеннән ясалган күн булып, хәтта ул тире «болгар тиресе» исеме белән Гарби Яурупага да мәгълүм иде. Болгарларда читек тә эшләнә. Шуның өчен русларның бер мәшһүр кенәзе болгарларны – читекле халык, үзләрен чабаталы халык дип атаган. Болгар шәһәрләрендә агачтан савыт-саба, кашыклар эшләнә, һәм алар, бик матур бизәкләр төшереп, чүлмәкләр эшлиләр. Болгарлар тимердән, бакырдан бик оста итеп төрле нәрсәләр ясыйлар; мәгъдәннәрне[1] алар Урал тауларыннан чыгаралар. Яисә шуннан чыгартучылардан алмаштырып алалар. Шул ук мәгъдәннәрдән, алтын-көмештән балдак, йөзек, тарак, төймә күк зиннәт әсбаплары хәзерлиләр иде. Болгарларның мигъмарчылык[2] эшендә оста кешеләре бик күп булып, алар, Русиягә барып, шәһәрләрдә зур биналар салганда, шул биналарны эшләп бирәләр иде.

**Дин.** Беренче мәртәбә Идел, Кама буйларына килеп утыручы болгар төркләре мәҗүс булып, башка төркләр күк шаман динендә иделәр. Сәүдә тәрәккый итүе белән, Болгарга да чит мәдәни илләрдән сәүдәгәрләр килеп йөри башладылар. Бу сәүдәгәрләр мөселман мәмләкәтләреннән, Яурупадан вә славяннардан һәм Хәзәр иленнән килеп торганнар. Сәүдә белән килүчеләр арасында дин өйрәтүчеләр дә булып, алар үзләренең диннәренә халыкны өндиләр. Бәгъзы шәһәр халыклары яһүд диненә күчкәннәр. Болгар, Суар шәһәрләрендә дә башта шул вакыйга булган иде. Ләкин болгарларга күбрәк мөселман сәүдәгәрләре киләләр, һәм шуның аркасында болгарларда IX гасырларда ук ислам дине бик таралган. Ниһаять, болгарларның Алмас исемле ханы Багдадта торучы мөселманнарның башлыгы хисапланган хәлифәгә илчеләр җибәртеп, үзләренә дин өйрәтү өчен галимнәр, таш бина салдыру өчен осталар сораткannaр. Шул эш өчен хәлифә бер һәйят[3] күндергән, һәм бу кешеләр

[1] Мәгъдәннәрне – металларны.
[2] Мигъмарчылык – архитектура.
[3] Һәйят – төркем.

922 елда Болгарга килеп җиткәннәр. Болар килгәч, Болгар шәһәрләрендә мәсҗед, мәктәпләр салынган, халыкның күпчелеге ислам динен рәсмән кабул иткән, имеш.

Мөселман динен кабул иткәч, болгарлар үзләренең әүвәлге баксыларын (багучы шаман) бетерергә керешкәннәр. Сихерчелек, багучылыкта гаепләнгән кешеләрне бик каты җәза кылалар. Болгарлар Мәккә, Мәдинәгә хаҗга бара башлаганнар. Шулай итеп, ул заманның мәдәни мөселман җирләре белән нык сәүдә мөнәсәбәте дә башланган. Хәтта, бара торгач, бөтен Шәркый Яурупа вә Шимали Яурупада гарәп акчасы йөри башлаган. Шуның өчен хәзерге Скандинавиядә бик күп гарәп акчалары табыла. Болгар муллалары Русиягә килеп, рус кенәзләрен вә халкын үз диннәренә өндиләр иде. Болгарларның шәһәрләрендә бәгъзы вакытта, тәгассыбка[1] бирелеп китеп, мөселман булырга теләмәгән кешеләрне үтергәлиләр дә иде. Болгарларның исламият кабул итүләре аларга ислам мәдәнияте керүгә сәбәп булды. Шулай ук сәяси җәһәттән рәсмән болгарлар Габбас хәлифәләренә буйсындылар. Хөтбәләрен алар исеменә укый башладылар. Хәтта акчаларны да Болгарда сугып, өстенә Габбас хәлифәләренең исемнәрен язалар иде.

**Әдәбият, гыйлем вә мәгариф.** Болгарлар, ислам динен кабул иткәч, гарәпләр истигъмаль итә торган хәрефләр белән китаплар яза башлаганнар. Хәтта бер болгар галиме гарәп телендә болгарларның тарихын язган. Болгар галимнәре тыйб гыйлеменнән дә әсәрләр язганнар. Кайсылары башка мөселман галимнәре тарафыннан язылган китапларга шәрехләр баглаганнар[2]. Болгар галимнәре, гарәп сәйяхләренең әйтүенә күрә, шималь җирләренә барып, йолдызларның йөрешләрен тикшереп кайтканнар, ләкин бу әсәрләр безнең заманнарга кадәр калмаганнар, бары тик бер-ике төркичә китапның шул заманнардан калган булуы ихтимал тотыла һәм таза эшләнгән кабер ташларындагы язулар гына шул заманның мәдәниятенең шаһитләре булып калганнар.

**Болгарларның күршеләре белән мөнәсәбәтләре.** Болгарлар урманлык җирләрдә торганлыкларыннан, аларга хәзәрләргә

[1] Тәгассыбка – фанатизмга.
[2] Ягъни аңлашмаган җирләрен аңлатып, озын итеп язганнар дигән сүз. *(Авт. иск.)*

кылган шикелле күчмә халыклар күп һөҗүм кылмаганнар, ләкин аларның җирләре дә шәрык вә җәнүбкә таба, степьләргә таба ачык булганга, хәзерге җәнүби Русиядә күчүче төркләр болгарлар белән мөнәсәбәттә булганнар, аларның арасында сугышлар да булып торган. Шулай ук рус эслаулары[1] да аларны тыныч тотмаганнар, һаман сугышып торганнар. Ләкин борынгы руслар белән болгарлар арасында дуслык мөнәсәбәте дә булган. Мәсәлән, болгарлар белән русларның 980 елдан алып 1015 елга кадәр хөкүмәт сөргән Владимир[2] арасында 1006 елдан сәүдә мөгаһәдәсе[3] ясалганы һәм 1024 елларда Суздаль руслары белән болгарлар арасында нык сәүдә барганы ачык мәгълүм. Русларда ачлык булган чакларда, болгарларның күршеләренә иганәт[4] кылулары да мәгълүм. Мәсәлән, 1229 елда Русиядә нык ачлык хөкем сөргән чакта, Болгар хөкүмәте олуг кенәз Юрийга утыз баржа икмәк биргәне вә шуның каршысына Болгар хөкүмәте бүләк итеп тула, парча, балык сөякләре вә башка зиннәт нәрсәләре алганы мәгълүм.

Болгар дәүләте XII гасырның беренче ярымында, бөтен Идел буе монголлар кулына кергәч, истикъляльен[5] югалта һәм Алтын Урданың бер провинциясе булып кала. Хәзерге шәһре Болгар хәрабәләрендә сакланып калган бина вә мәсҗед калдыклары – шул Алтын Урда дәверенең, димәк, татарларның әсәрләредер.

**Шәркый Яурупада күчмә төркләр.** IX–X гасырлар – төркләрнең яңадан иске күчеп йөри торган урыннарыннан купкан заманыдыр. Бу заманда – Кара диңгезнең ике ягында Урта Азиядән килгән төркләрнең агып килеп чыгып, бу урыннарны яңадан үзләренең малларын туйдыруга урын ясаган чакларыдыр. Угыз нәселеннән дип үзләрен хисап кылучы төркләр соңра Арал диңгезенең уң ягындагы Кечек Азиядә XI гасырның башында сәлҗукыйлар дәүләтен төзегәннәр иде.

Төркләрнең бик күбесе, филҗөмлә[6] хәзерге төркмәннәр дә, үзләрен угыз нәселеннән дип йөриләр. Хәзерге фәнни әдәбиятта

[1] Эслаулары – славяннары.
[2] Владимир Святославич (якынча 960–1015) – Новгород (970–988) һәм Киев (978–1015) кенәзе.
[3] Мөгаһәдәсе – килешүе.
[4] Иганәт – ярдәм.
[5] Истикъляльен – бәйсезлеген.
[6] Филҗөмлә – шул исәптән.

төркләрнең нәселләрен угызга илтеп терәүдә «тотемизм» күрәләр, «угыз» дигән сүзнең дә «үгез» дигән сүз белән бер булганын сөйлиләр. Төркләр ислам кабул иткәч, моны исламча тәгъриф кылырга[1] азапланып, Угыз хан Яфәснең[2] нәселеннән бер хан булган да, шул нәселдән төркләр киткән дип сөйлиләр.

Кара диңгезнең шималь ярлары буе сахралары исә, алда сөйләгәнчә, күчмә халыкларның искедән килеп-китеп йөри торган җирләре иде. Бу тәртипсез рәвештә килү-китүләр Хәзәр дәүләте көчле вә исән чакта азайган, ләкин бу дәүләтнең бетүе исә бу күчмә төркләргә Азиядән агып чыгып торырга тагын юлны ачты. X гасырда бу халык агышы тагын да көчәйде. Шәркый Яурупа, Маҗарстан вә Балкан ярыматавына әллә никадәр төрк халыклары килеп чыктылар. Бу халыкларны без шул заманнан калган язуларда төрле исемнәрдә очратабыз. Элек IX йөздә «бәҗәнәк» исемле төркләр Шәркый Яурупаның җәнүбенә килеп күчеп йөри башлыйлар, соңра без мәнбәгъләрдә – «гуз» вә рус мәнбәгъләрендә шул ук халыкны «төрк» (турки[3]) исеме белән очратабыз. 1055 елда Яурупа мәнбәгъләре – «куман», рус мәнбәгъләре – «половец», әмма Шәрык мәнбәгъләре «кыпчак» дип йөри торган халыкны очратабыз. Соңгылары хәзерге җәнүби Русиядә XII гасырда булган татар-монголлар һөҗүменә кадәр шул җирләрдә хуҗалык кылып торалар.

Бу халыкларның телләре, тормышлары бертөсле үк булган. X–XII гасырда язган Рум (Византия) вә гарәп язучыларының берничәсе, кирәк бәҗәнәкләр, кирәк кыпчаклар булсын, бер-берсенең телләрен белгәнлекләрен әйтеп китәләр.

Күчмә төркләрнең төрле кабиләләренең аерым-аерым исемнәрдә йөргәнлекләрен вә ул кабиләләрнең бер-берсе белән сугышып торуларын игътибарга алып, борынгы язучылар аларны аерым халыклар итеп тасвир итсәләр дә, күбесе аларның бер нәселдән булганын әйтеп китәләр. Мәсәлән, борынгы рус рузнамәсе (летописе), борынгы Бабил[4] хорафаты белән файдаланып вә аларның кардәш халыклар икәнен аңлап: «Исмәгыйль унике угыл тудырды, шулардан төрк-

[1] Тәгъриф кылырга – аңлатырга.
[2] Яфәс – Нух пәйгамбәрнең улы. Борынгы төркиләр үзләрен Нух пәйгамәбәрнең улы Яфәскә, Яфәснең улы Төрккә барып тоташа дип санаганнар.
[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[4] Бабил – Вавилон.

мәннәр, бәҗәнәкләр һәм төркләр (турки[1]) һәм половецлар киткәннәр», – ди. Ни өчен соң бу халыклар аерым исемдә йөртелгәннәр? Моны аңлар өчен хәзерге көндәге татарларның «Казан татары», «мишәр», «типтәр» һәм аларның үзбәк вә кыргызлар тарафыннан «нугай» дип йөртелүләрен генә игътибарга алсак та җитә. Бу күчмә төркләрнең иҗтимагый тормышлары ыруг-патриархат тормышыннан гыйбарәт булганын түбәндә күрәбез. Гадәттә, төрле ыругларга бүленеп аерым яшәгән төркләр, яхшы җирләр өчен күчеп яңа җирләргә килгәндә яисә бер-бер халык белән сугышырга кирәк булган чакларда, бергәләшеп хәрәкәт кылырга кирәк булгач, вакытлы бер оешма ясый торган булганнар. Бу оешма гадәттә күчмә төркләрдә шулай ясала икән. Бер баерак, көчлерәк, батырлары күбрәк бер ыруг, яисә үз теләкләре белән, яисә көчләп, үзләренә башка ыруглар вә кабиләләрне буйсындыра торган булганнар. Менә шушы оешманың башында торучы ыруг яисә кабиләнең һәрвакытта берүзенә махсус аерым исеме була торган булган. Менә шул яңа ясалган оешманың аты да шул көчле вә берләштерүче ыруг яисә кабиләнең исеме белән китә торган булган. Менә бер вакытта теге максатка ирешкәч, аларны бергә бәйләп торучы сәбәп беткәч, яңадан ясалган вак ыруг я кабилә оешмаларына таралып, тагы бер-берсе белән сугышып тора башлыйлар. Заман үтүе белән, яңадан берләштерүче сәбәпләр килеп чыга: яисә яңадан ризык эзләп яңа җирләргә күчеп китеп, анда торучы халыклар белән сугышырга кирәк була, яисә аларның күчеп йөри торган җирләренә бер дошман һөҗүм итә. Шул сәбәпләр аркасында, таралган ыруг вә кабиләләр яңадан берләшәләр. Ләкин хәзер берләштерүче ыруг яисә кабилә башка вә бүтән исемдә булганга күрә, яңа ясалган оешма да яңа исем белән йөртелә башлый, вә ул исемне дә күршеләре аерым бер халыкның исеме дип белеп яза торган булганнар. Менә шуның өчен дә җәнүби Русиядә татарлар килгәнче булган төрк кабиләләре элек – «бәҗәнәк» исеме белән, соңра ясалган оешмада «төрк» яисә «гуз» исемле уртак исем белән йөртелсәләр, актыктан Шәркый Яурупадагы күчмә төркләр «половец», я «куман», я «кыпчак» исеме белән йөртелә торган булганнар.

**Аларның тормышы.** Без әсәребезнең планын кыска гына сөйләгәндә үк, татар халкын ясауда гонсырлык ролен үтәгән

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.

XIII гасырга кадәрле Шәркый Яурупада торучы төркләрнең тормышлары ыруг-патриархат тормышы дигән идек. Хәзер шул тормышны тасвир кылмас борын бирелергә мөмкин булган бер сөальгә җавап биреп китәргә кирәк була. Ул сөаль шулай бирелергә мөмкин: «Соң хәзәр вә болгар халыклары бу кагыйдәдән тышта (мөстәсна) мыни? Алар бит чын-чыннан дәүләт ясап тордылар».

Ләкин без монда да бер каршылык күрмибез. Без монда да шул ук процессның әсасын күрәбез. Дөрес, хәзәр, болгарлар шактый мәдәни бер дәүләт төзеделәр. Ләкин моннан һичбер төрле асыл Хәзәрстан вә Болгарстанда торучы масса ыруг тормышыннан чыкмады. Бу халыклар заманның бөтен җиһан сәүдәсендә мөһим урын тоткан елга буйларын, юл өсләрен кулларында тотып торганлыкларыннан, һәм хәзәрләр, һәм болгарларны оештыручы ыруг үзе шулкадәр икътисади күчмә малик булып китте ки, аның хөкүмәт сөрүче гонсырлары ыруг-патриархат тормышыннан феодализмга күчә башладылар. Әмма шәһәрләрдән ерак торучы кабиләләр исә һаман да ыруг вә патриархат тормышыннан чыкмадылар. Чөнки Русиядәге төркләр берничә ыругка бүленеп яшиләр иде. Мәсәлән, бәҗәнәкләр (печенеги[1]) – унөч ыругка, әмма половец яисә кыпчаклар унике ыругка бүленәләр иде. Һәрбер ыруг үзләренең бер патриарх аксакалларының исеме белән йөртеләләр. Мәсәлән, рус летописьләренең сүзләренә күрә, бәҗәнәкләрдә шундый ыругларның барлыклары мәгълүм: вобочевичи, горчево чадо, Уломевичи, бастеев чадо[2], шул ук аксакаллар үзләренең ыругларын идарә дә кылып торганнар. Боларның хакимияте халык җыелышы белән чикләнә торган булган. Бәҗәнәкләрдә булган бу җыелышны румнар «коментон» дип атыйлар. Коментон сугыш яки килешү мәсьәләләрен хәл итү, ыруглар арасында булган хуҗалык эшләрен карау һәм патриархларны сайлау – һәммәсе дә шул коментон кулында булган.

**Аксөяк вә карасөяк ыруглары.** Бу күчмә төркләрдә без ике төрле ыругны күрәбез: берсе аксөяк (аристократик), икенчесе – карасөяк (яисә ярлы) ыруглары. Менә бу ике төрле коллектив арасында каты көрәш хөкем сөргән. Мәсәлән, XI гасырда бәҗәнәкләрнең бер ыруг

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган. «Чадо» дигән сүз борынгы рус телендә бала мәгънәсендә йөртелә. *(Авт. иск.)*

башлыкларыннан Килдар углы Тирах[1], үзе аксөяк ыругыннан булганга күрә, башта бөтен бәҗәнәк урдасы эчендә баш булып торган. Ләкин бәҗәнәкләр кыпчак һәм гузлар белән булган сугышта җиңелгәч, аның авторитеты беткән, ярлы вә гади ыругларны йомшаклык һәм куркаклыкта гаепли башлаганнар. Ләкин бәҗәнәк урдасы эчендә гади ыруглардан килгән бик гайрәтле Кәгән[2] исемле аксакал күтәрелеп киткән, халык та аңарга ияргән. Тирах белән Кәгән арасында сугыш башланган, ләкин Кәгәнне башка ыруглар да яклый башлаганнар, әмма аксөяк ыругының башлыгы Тирахны да ничектер яклаучы ыруглар калган. Кәгән һәм аңарга ияргән гади ыруглар рум тәэсиренә барып, ярдәм алып, бөтен бәҗәнәк урдасына башлык булып танылган.

**Икътисади хәят.** Бу күчмә төркләр, хәзерге монголлар вә күчмә кыргыз-казакълар шикелле, тирмәләрдә торганнар, болар иген игү белән күп шөгыльләнмәгәннәр. Аларның тамак туйдыра торган нәрсәләре – мал көтүләре булган. Ләкин уңайлы урыннарда алар тары шикелле ансат үсә торган вә туфракны талымламый торган нәрсәләр дә чәчкәләгәннәр.

Боларның тормышында алыш-биреш булмаган дип әйтер хәл юк. Аларның җирләре Кара һәм Азак диңгезләре буйларындагы рум, итальян сәүдә колонияләре белән чиктәш булганга, төркләр бу халыкларның Азия белән йөрткән сәүдәләрендә иштиракь кылганнар[3]. Мал йөрткәннәр һәм кол сату вә ганимәт[4] малны сату белән шөгыльләнгәннәр. Шулай ук үзләренең аяклы малларын да сатып торганнар. Мәсәлән, соң заманда кыпчак иленә килеп йөрүче сәйяхләр кыпчакларның, Һиндстанга кадәрле илтеп, ел саен 15–20 мең баш яхшы атлар сатканнарын сөйлиләр. Шулай ук кыпчак илендә калалар да булган (мәсәлән, Шарукань, Сургуф, Басин[5] шәһәрләре), бу шәһәрләрдә чит ил сәүдәгәрләре торганнар, һәм кыш көннәрендә бу урыннарны күчмә төркләр кышлак итеп тә истигъмаль кылганнар.

[1] Тирах – 1048 елда бәҗәнәкләр юлбашы булган шәхес.
[2] Кәгән (?–1050) – византиялеләргә буйсынган бәҗәнәк ханы, христиан динен кабул итә. Тирах хан белән сугышып тора һәм шул яуларда үтерелә.
[3] Иштиракь кылганнар – арадаш булганнар, катнашканнар.
[4] Ганимәт – трофей.
[5] Рус елъязмаларында Шарукань, Сугров һәм Балин дигән кыпчак шәһәрләре искә алына.

Бу төркләрнең аксакаллары кулында кыйммәтле вә зиннәт нәрсәләре дә, алтын-көмеш акчалары да булган. Бу, талап, ганимәттән җыелган нәрсәләрне алар төрле җирдән килгән сәүдәгәрләргә һәм рум, итальян колонияләренә илтеп сата торган булганнар.

Бу күчмә төркләрне шул заманның гарәп язучылары шактый ямьсез буяулар белән тасвир итеп килделәр. Ләкин шулай булса да, бу ачулы тасвирлар безгә шактый материал бирәләр. Шуның өчен монда без бер-ике кисәкне тәрҗемә итеп китәрбез.

Салониклы[1] рум язучысы XII йөздә кыпчаклар хакында шулай язды: «Бу халык бер мәгълүм җирдә генә басылып тормый. Шуның өчен ул гражданлыкка малик түгел. (Ягъни бер дәүләт ясап тормый.) Һәрбер җирне алырга омтыла, ләкин берсен дә халык белән тутыра алмый, шуның өчен дә бу халык – күп күчүче бер халыктыр (poloploviton[2]). Болар – очкычы халык. Шуның өчен аларны тотып та булмый. Аларның шәһәрләре дә, авыллары да юк. Шуның өчен алар ерткыч», – ди.

1170 елда Регенсбург шәһәреннән Азиягә барганда, Шәркый Яурупа сахраларыннан үтүче яһүд раввины Петахия[3] кыпчакларны күрде һәм алар хакында язган урында шундый хәбәрләр язды: «Кедар[4] (кыпчак) җирендә икмәк истигъмаль кылмыйлар, әмма дөге һәм тары ашыйлар. Боларны алар сөттә пешерәләр. Шулай ук сөт һәм богырт (сыр) ашыйлар. Алар итне турап ияр астына салалар да шуның өстендә утырып йөриләр һәм атны тирләгәнче куалар. Ит җылына, һәм шуннан соң ашыйлар...». «Команнар (кыпчаклар) ның һәммәсенә дә уртак булган патшалары юк, ләкин бикләре һәм аксөяк фамилияләре бар. Алар чадырларда торалар, бик ерактан күрәләр, аларның күзләре бик яхшы. Чөнки алар тоз ашамыйлар һәм бәгъзы төрле үсемлекләрне истигъмаль кылалар. Алар бик оста укчылар һәм очкан кошны атып төшерәләр», – ди.

---

[1] Салоники (Фессалоники) – Византия империясендә зурлыгы һәм әһәмияте ягыннан Константинопольдән кала икенче шәһәр.
[2] Латин хәрефләре белән бирелгән.
[3] Петахия (якынча XII–XIII гасыр башы) – Көнчыгыш Европа, Кавказ һәм Якын Көнчыгышка сәяхәт кылган һәм күргәннәре турында язмача теркәп калдырган XII гасыр чех сәяхәтчесе.
[4] Кедар – Библиядә күчмә халыкларның гомуми атамасы.

**Күчмә төркләрдә мәдәният.** Ул заманның гарәп язучылары, югарыда күрелгәнчә, бу күчмә төркләрне бик вәхши итеп тасвир итсәләр дә, ләкин аларда үзләренең дәрәҗәләренә күрә мәдәният бар иде. Элек боларның диннәре хакында бер сөйләп узыйк. Боларның диннәре, башка күчмә төркләрнеке төсле, табигатьнең көчләренә ышану вә танудан гыйбарәт иде. Алар йолдызларга, аларның кешеләрнең тормышларына тәэсир итүләренә ышаналар; үзләренең үткәндәге патриарх бабаларына ышаналар; сугышлардан бушаган чакларында аларның җырчылары, аларның каһарманлыкларын мактап, җыр-дастаннар көйли, аларның үзләренә махсус рухани шаманнары булып, шул кешеләргә багыналар иде. Болар тәңреләргә корбаннар чалалар, үлгән кешеләрне яндыралар, аларны күмеп, каберләре өстенә балчыклар өеп, курганнар ясыйлар, таштан «балбан»[1] аталган төрле бик матур рәвештә ясалган сыннар куялар иде. Әлегә кадәр болар Русиянең җәнүби вилаятьләрендә исән торалар, кайсылары музәханәләргә[2] җыелганнар. Дин мәсьәләсендә бу күчмә төркләр бер дә тәгассыблы[3] түгел, диннәрен тиз алыштыралар иде. Алар үзләре белән бергә Яурупага Азиянең төрле диннәрен китергәннәр. Шуның өчен боларның диннәренең эчендә без табигый дин белән бергә Ирандагы зәрдәштилек[4], христианнарның бер бәд[5] мәзһәбе булган манилык[6] калдыгын да табабыз. Хәтта бусын алар Балкан ярыматавында рум вә эслаулар арасында да җәйгәннәр иде. Бу күчмә төркләр, Яурупага килеп чыккач, христиан дине тәэсиренә дә бирелгәннәр, хәтта болар эченнән рәһбаннар[7], кәшишләр[8] дә чыккалаган иде. Ләкин бу халыкларның ислам җирләре белән мөнәсәбәтләре булганга, ислам дине дә болар арасында шактый җәелгән, шуның аркасында боларның телләрендә дәллял[9], кассаб (мал суючы), галәмәт, хәммаль[10], җәрихә (җәза), савап, вәгъдә, хәләл,

[1] Дөресе: балбал.
[2] Музәханәләргә – музейларга.
[3] Тәгассыблы – фанатик.
[4] Зәрдәштилек – зороастризм дине.
[5] Бәд – бозылган.
[6] Манилык – манихей дине.
[7] Рәһбаннар – монахлар.
[8] Кәшишләр – христиан руханилары, монахлар.
[9] Дәллял – маклер.
[10] Хәммаль – күтәреп йөк ташучы.

гаиб[1], шәһәр, милек, нигъмәт, шулай ук кыпчакларның телләренә мөҗәррәд мәфһүмнәрне аңлатучы (отвлеченные понятия[2]) гомер, әҗәл, ләззәт, вакыт, гариб, гашыйк, гакыл, садака шикелле сүзләр дә кергән. Димәк, гарәп сүзләре Яурупа төркләренә ислам кабул иткәнче үк кергән, һәм хәзер дә шул сүзләр сакланып, бу төркләр «татар» исемен алып киткәч тә калган. Шуның өчен дә татар теленә кергән гарәп сүзләрен мөселманлык белән генә керде дип әйтеп булмыйдыр.

Кыпчаклар атнаны – 7 көнгә, елны 12 айга бүлгәннәр һәм аларга үз исемнәрен кушып йөрткәннәр: март – яз ае, апрель – элек яз ае һәм төп ай, май – яз ае, июнь – соң яз ае, октябрь – кыш ае, ноябрь – урта кыш ае, гыйнвар – сифер ае, февраль – сифер ае[3] дип йөргәннәр. Боларда әдәбият та аз гына булган, ләкин бу әдәбият христиан вә ислам дине китаплары вә догалыкларыннан гыйбарәт булган.

Көн исемнәрен хәзерге татарларча атап, бары җомганы – «айда» (атна), шимбәне яһүдләрчә «сабат көн» дип йөргәннәр. Болар телендәге әдәбият кисәкләренең төрләрен без «Татар әдәбият тарихы»[4] исемле әсәрнең икенче җилденә керткән идек, шуның өчен теләгән кешегә шул китапка мөрәҗәгать итәргә тәүсия итәм[5].

Гомумән, бу күчмә төркләрдә нинди хоруфат[6] истигъмаль кылынуы хакында мәгълүмат аз. Ләкин һәрхәлдә әле бәҗәнәкләрдә дә язу сәнгате булган булырга кирәк. Мәсәлән, рум язучыларыннан кайсар Константин[7], Х гасырда аларга илче җибәргәндә, телләрен белә торган кеше аркылы хат җибәргәнен сөйли.

---

[1] Гаиб – юкка чыккан.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Биредә типография төгәлсезлеге киткән булса кирәк. Гали Рәхим һәм Газиз Гобәйдуллин тарафынан әзерләнгән «Татар әдәбияты тарихы» хезмәтендә февраль ае «соң ай» дип бирелгән.
[4] Биредә Сүз Гали Рәхим һәм Газиз Гобәйдуллин тарафыннан әзерләнгән һәм 1922–1924 елларда өч том булып нәшер ителгән «Татар әдәбияты тарихы» китабы турында бара. Бу хезмәт «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең 15–16 чыгарылышларында нәшер ителде (2022).
[5] Тәүсия – киңәш.
[6] Хоруфат – алфавит, язу.
[7] Константин VII Багрянородный (905–959) – рәсми рәвештә 913 елда император дип игълан ителеп (регентлардан башка мөстәкыйль рәвештә 945 елдан идарә итә башлый), 959 елга кадәр тәхеттә утырган Византия императоры. Империя тормышы һәм сәясәт турында күпсанлы әсәрләр яза.

Минорит[1] үзенең бер миссионеры, кыпчакларга бармас борын, уйгур хоруфатын өйрәнгәнлеген сөйли. Ләкин болар өчен яурупалылар да, үзләренең латин хәрефләрен бераз алмаштырып, җитешмәгән хәрефләрен яңадан ясап, бер әлифба ясаганнар иде.

Әлхасыйль[2], бу күчмә төркләр Яурупа язучылары тарафыннан никадәр вәхши итеп тасвир кылынсалар да, боларда мәдәният юк түгел иде.

**Нәтиҗә.** Шәркый Яурупа вә Идел буе бик борынгы заманнан бирле күчмә төрк халыклары тарафыннан ишгаль кылынган. Бу халыкларның асыл иҗтимагый хәятлары ыруг вә патриархат халәтендә булган. Бу халыклар, төрле исемдә йөртелсәләр дә, аерым төрк шивәләрендә сөйләсәләр дә, асылда бер-берсен аңлашканнар вә бер-берсе белән катнашканнар. Боларның исемнәренең башкалыгы күп вакытта хөкүмәт сөрүче ыругның исеме белән йөртелгәннән генә килә. Бәгъзы вакытта аларны гомум исем белән «гуз-угыз» яисә «төрк» дип тә йөргәннәр. Менә шулай итеп, XIII гасырның башына кадәр Шәркый Яурупаның җәнүбендә һәм Идел буенда төрк халыклары хөкем сөргәннәр. Ләкин аларның иҗтимагый дәрәҗәләре, берләшеп, бер дәүләт ясарга ирек бирмәгән.

Ләкин Идел-Дон елгалары шикелле сәүдә гамилләре[3] боларны берләштереп, дәүләт организациясен ясаштырып караган, ләкин XIII йөзнең башына кадәр бары Идел елгасының урта агымында гына Болгар дәүләте сакланып калган. **Менә шул төркләр киләчәктә татар халкын эшләнү процессына гонсырлык ролен үтәгәннәр.** Соңра шуларның бергә катнашуыннан татарлар килеп чыкканнар. Менә бу процессны без тикшереп карыйк. Иҗтимагый яктан бу процесс ыруг вә патриархат тормышының егыла башлап, Шәркый Яурупа төркләренең феодализм дәверенә керү вакытына туры килә. Шуның өчен дә бу дәвердә һәм этнографик, һәм иҗтимагый дәверләр берләшәләр. Менә без хәзер шул яңа дәвергә күчәбез.

[1] Сүз Франциск Ассизский тарафыннан 1208 елда оештырылган католик ордены турында бара. Орден әгъзалары үзләрен «миноритлар» дип атап йөрткәннәр һәм аскетлык идеясен алга сөргәннәр.

[2] Әлхасыйль – кыскасы.

[3] Гамилләре – сәбәпләре.

# II Татар халкының ясалу процессы
## яисә ыруг-патриархат тормышыннан феодализмга таба күчү дәвере

### 2.1. Шәркый Яурупада Идел буе төркләренең монголлар кул астына керүләре

**Азиядә сәяси инкыйлаб.** Азиянең уртасында Кытай иле белән безнең Сибирия арасында Гоби яисә Шамо дигән бик аз үлән үсә торган бер чүл бар. Хәзердә анда монгол халкы тора. Шул сахраның шималендә Байкал күле бар. Теге сахрадан агып чыгып, шул күлгә коя торган елгалар бар. Борынгы заманда шул елга кырыйларында хәзерге монголларның бабалары – монголлар торалар иде. Аларның күршеләрендә төркләр гомер итәләр, һәм аларның бу урында берничә зур патшалыклары да булып үткән. Төркләрнең дәүләтләре бар чакта монголлар төркләр кул астында торалар. Ләкин монголларга күрше урыннарда төркләрнең зур дәүләтләре XI–XII гасырларда инде юк иде.

XII гасырда монголлар, берләшеп, төркләр шикелле үк олуг дәүләт ясарга омтыла башлаганнар, XII гасырның ахырларында бу эшнең башында Тимучин исемле, соңыннан Чыңгыз хан ләкабен[1] алган бер кеше торган.

**Тимучин – Чыңгыз хан.** Монголлар арасында Ясүкәй[2] баһадир атлы бер кечерәк кенә кабиләнең башлыгы, үзенең гайрәте белән дан казанып, «баһадир» исемен алган. Ул бәгъзы монгол кабиләләре, Кытай императоры белән муаффәкыятьле[3] сугышлар

[1] Ләкабен – кушаматын.
[2] Ясүкәй батыр (чама белән 1134–1171) – Чыңгыз ханның әтисе. Күпчелек монгол кабиләләренең җитәкчесе.
[3] Муаффәкыятьле – уңышлы, нәтиҗәле.

кылган. 1162 елларда аның Улын Әкә атлы сөекле хатыны бер угыл китергән. Бу угылга Тимучин дип ат куйганнар иде. Тимучин тугач, илнең иң олугларыннан берсе: «Бу углан олуг патша булыр. Җир йөзенең барчасын алыр. Күп илләрне, вилаятьләрне катиле гам кылыр»,[1] – дигән, имеш. Бу сүзләрне дөрестән дә әйткәннәрме, юкмы – анысы безгә мәгълүм түгел, ләкин Тимучинның атасы янына җыелган баһадирлар «җир йөзенең барчасын алу» фикеренә төшкәннәр. Димәк, икътисади вә иҗтимагый сәбәпләр мондый шәхеснең чыгуына юл хәзерләгән булганнар. Бала унөч кенә яшендә вакытта, ясалып килә торган бер зур кабиләне ташлап, Ясүкәй баһадир үлеп китәдер. Бала – бары анасы белән генә; зурайган кабилә дә тарала башлады. Ләкин анасы үзе иренең юлы белән китеп, сугышып, сәясәт белән кабиләне янә зурайтырга кереште.

Тимучинның бөтен гомере сугыш белән үтте. Аның бөтен тәрҗемәи хәле кан кою белән тулган. Яшь вакытыннан алып 66 яшенә кадәр ул гомерен сугышта үткәрде. Элек Тимучин үзенең тирәсендәге монгол, төрк кабиләләрен берләштерү, үз кулына кертү юлына төште. Ниһаять, бик күп сугышлардан соң, Тимучин 1206 елда бөтен Монголиядәге төрк, монгол кабиләләрен кулына кертте. Ләкин күп мәгъмүр[2] илләрне җимерде.

**Корылтай.** Төрк, монгол халыклары кардәш вә бертөсле тормыш белән гомер кичерүче халыклар булганга күрә, аларның гадәт, йолалары бертөсле иде. Алар бер-берсенә шулкадәр якын ки, монголлар вә төркләр сөйләшә торган сүзләрнең өч чиреге – уртак сүздер. Бик борынгы заманнардан бирле үк төркләр, монголларда бер гадәт булып, алар яңа хан сайлаганда яисә бер-бер зур эш эшләр алдыннан корылтай атлы бер җыелыш ясыйлар иде. Төрк әкиятләренең сүзенә күрә, бөтен төрк халкының бабалары дип йөртелә торган Угыз хан да шундый җыен ясаган. Корылтайга килә торган әгъзалар һәрбер кабиләләрнең башлык һәм олуг кешеләреннән, сугышчы зур батырлардан гыйбарәт буладыр иде. Тимучин да 1206 елда Орхон суының кырыенда, илнең зурларыннан, кабилә башлыклары, батырлардан гыйбарәт «корылтай» аталган бер мәҗлес җыйды, бу мәҗлестә бөтен монгол-татар, төрк кабиләләренең бергә җыелганы

[1] Катиле гам – үтереп бетерү дигән сүз. *(Авт. иск.)*
[2] Мәгъмүр – төзек.

игълан кылынып, Тимучинны шушы зур илнең башлыгы – ханы сайлап, аңар Чыңгыз хан дип исем бирделәр[1].

**Чыңгыз ханның фөтухаты[2].** Чыңгыз хан бу бөек корылтайдан соң чын ихласы белән сугышка тотынды. Элек ул, Кытайга зур гаскәр белән барып, Кытай императорын җиңде. Соңыннан хәзерге Төркестан, Иран, Әфганстанның бер кисәгендә хөкүмәт сөрә торган Харәземшаһлар мәмләкәте дигән патшалыкны төздереп, мөселман төрк, Иран илләрен үзенә каратты.

**Монгол гаскәренең Кыпчак иленә килеп чыгуы.** Борынгы заманда хәзерге җәнүби Русиядәге Днепрның, Иделнең, Донның түбәнге агымнары тирәсендәге коман яисә кыпчаклар тора торган зур степьне Дәште Кыпчак дип йөртәләр иде.

Чыңгыз ханның зур шаһларны җиңеп, алар яклы башка патшалыкларны алып йөргән гаскәренең Чәбә[3], Сөбетай[4] исемле ике батыр командасындагы гаскәре, Кавказны үтеп, 1224 елда җәнүби Русия иленә, кыпчак сахрасына килеп чыктылар. Чыңгызның Кыпчакка килеп чыккан ардусы эчендә бик күбесе төркләр булган. Бу монгол гаскәре килеп чыкканны ишетеп, бу җирдә күчеп йөри торган половец (кыпчак) исемендәге төркләр аларга каршы чыктылар. Бу вакыйганы ишеткән Чыңгыз батырлары аларга илче җибәреп: «Без дә сезнең шикелле үк төркләр ләбаса, чит халыклар белән бергә үз кардәшләрегезгә каршы киләсез, безнең белән дусланыгыз, без сезгә теләгәнегез кадәрле алтын, яхшы киемнәр бирербез», – дигәннәр. Вакыйган[5], половецлар үзләре генә түгел, рус кенәзләре белән берләшеп киләләр. Русларга да Чыңгыз ардусы тарафыннан илче җибәрелеп: «Безнең алмаган җиребез юк. Бары тик безнең тәбәгаләребез (колларыбыз) булган половецлар гына (кыпчаклар гына) безгә каршы киләләр» – дип, русларны сугышмаска димләгәннәр.

[1] Чыңгыз – «чын куәтле, бик куәтле» дигән сүз булырга кирәк. *(Авт. иск.)*
[2] Фөтухаты – яулап алу сугышлары.
[3] Чәбә (Җәбә, Җәбә-нойон; монг. җәбә – ук, чын исеме – Җиргоадай) (1181–1225 яки 1231) – монгол гаскәр башлыгы, төмәнче, Чыңгыз ханның иң яхшы гаскәр башлыкларыннан берсе.
[4] Сөбетай (Сөбүдәй, Сүбәдәй, Субудай батыр, 1176–1248) – татар-монгол армиясенең күренекле гаскәр башлыгы, Чыңгыз ханның көрәштәше. 1223–1242 еллардагы татар-монгол яуларында сәләтле сәргаскәр буларак таныла.
[5] Вакыйган – дөрестән дә.

Ләкин половецлар да, руслар да илчеләрнең сүзләрен тыңламадылар, шуңар күрә дә сугыш булды. Половецлар җиңелеп качтылар. Руслар да җиңелделәр. Соңыннан монголлар Болгар иленә һөҗүм итеп, Болгар шәһәрен талап, яндырып, кире Урта Азиягә кайтып киттеләр.

**Чыңгызның шәхесе.** Дөньяда шәхесләрне җәмгыять вә коллективлар тудыру мәсьәләсен ачык күрәсе килгән кеше Чыңгыз ханга нисбәт бирелә торган зур монгол империясеннән генә карап та белә ала. Шуның өчен без, башка язучылар шикелле, Чыңгызның шәхесенә зур әһәмият бирмибез. Чыңгызга нисбәт бирелә торган бөек эшләрнең күбесе соңыннан ясалган уйдырма вә хорафаттан гыйбарәттер. Соңга монголлар аны алла дип тану дәрәҗәсенә дә килеп җиттеләр вә Чыңгыз тәңрегә сын ясап табына башладылар.

**Безнең фикеребезчә, Чыңгыз империясенең ясалуы – монгол-төрк кабиләләренең ыруг-патриархат дәверен уздыра башлап, феодализмга таба авуыннан башка бер нәрсә түгелдер.**

Чыңгызны тудыручы коллектив та – шул монгол аристократияседер; шуның өчен дә Чыңгызның шәхесе хакында сөйләүдән бигрәк, Чыңгыз дәверендәге монгол империясенең төзелеше хакында сөйләү файдалырак булачактыр. Язарга ансат булсын өчен, без, бу хакта сөйләгәндә, Чыңгызны ия итеп сөйләвебездән аның шәхесенә зур әһәмият бирү аңлашылмаска тиештер.

**Монгол империясенең иҗтимагый маһияте[1].** Чыңгыз дәүләте аристократик бер патшалык иде; затән[2], ул үзе дә аксөяк-аристократик вә карасөяк-демократик ыругларның көрәшеннән туды. Монгол дастаннары шул заманның аристократиясе баһадирлары белән Чыңгызның шартнамәсен шагыйранә шулай тасвир итәләр: баһадирлар Чыңгызга әйткәннәр, имеш: «Син безгә хан булгачтын, чиксез күпсанлы дошманнар белән булган сугышларда без иң алда булырбыз; гаять гүзәл хатын-кызларны, менә дигән яхшы халыкларны кол алгач, аларның башын да сиңа бирербез; ау артыннан киткән чакта, һәммәсеннән алда булырбыз һәм тоткан җәнлекләрне сиңа тапшыра барырбыз». Чыңгыз үзенең баһадирларына бервакыт әйткән, имеш: «Мин халыкларның көтүләрен, тирмәләрен, хатыннарын, балаларын

[1] Маһияте – хәле.
[2] Затән – нигездә.

бик күп алдым һәм сезгә бирә бардым. Сезнең өчен даладагы ауларда кучмәләр һәм кормалар кордым һәм аулыкларны сезнең якка куып җибәрдем». Бу шагыйранә тасвирдан менә без Чыңгыз белән аристократия арасында ни өчен берлек булганын ачык күрәбез: хан үзенең яраннарын җиңүгә алып бара, ә ганимәт[1] икесенә дә эләгә... Шул заманның мәнбәгъләре безгә бу ак вә карасөякләр арасында булган көрәшне бик матур тасвир кылып, бай вә аксөякләренең Чыңгыз янына җыелганлыкларын, әмма карасөяк ыругларның Җамуха[2] тирәсендә тупланганлыкларын белгертә[3] вә көрәшне «ат тотучылар» (аристократлар) белән «куй көтүчеләр» (демократия) арасында булган көрәш рәвешендә тасвир итәләр; соңгыларын исә монгол язучылары – аристократиянең ялчылары – «хәбәрсез, аңсыз, мәгълүматсыз» кешеләр итеп тасвир кылалар. Менә аристократиянең җиңүе Чыңгызның баш булуы белән тәмам була, шуның өчен, мәнбәгъләргә караганда, соңра Чыңгыз үзенең хакимиятенең иҗтимагый маһиятен ачып биреп: «Миңа хәтле далада һичбер тәртип вә низам юк иде; кечекләр олугларны тыңламыйлар иде, кул астындагылар баскакларга ихтирам итмиләр, баскаклар кул астындагыларга булган мөнәсәбәтләрендә тиешле вазифаларын үтәмиләр иде. Мин тәхеткә утыргач ук тәртипләр керттем һәм һәрберенә үзенең урынын күрсәттем», – дигән.

Вакыйган, Чыңгыз империясе – чын-чыннан бер аристократик дәүләт оешмасы иде. Менә феодализмның әсасы[4] да шунда салынган иде. Империядә иң гали[5] аристократия «нойон»нар булган; «олуг нойон» дип Чыңгызның кечек углын йөрткәннәр. Ләкин бу аристократиянең түбәнге дәрәҗәсендә тарханнар торганнар, болар да салымнар түләмәгәннәр, сугышта алган ганимәтләре үзләренә була торган булган, алар һәрвакытта бер дә рөхсәтсез хан янына керә алганнар, аларны, бары җиде мәртәбә җинаять кылгач кына, хөкемгә бирә алганнар, хан мәҗлесләрендә тарханнар хөрмәтле урын

[1] Ганимәт – трофей.
[2] Җамуха (Җамуга, ?–1205) – монголларның хәрби һәм сәяси лидеры, монгол кабиләләрен берләштерүдә Тимучинның төп дошманы.
[3] Текстта «тупланганлыкларыннан белергә» дип бирелгән.
[4] Әсасы – нигезе.
[5] Гали – югары дәрәҗәле.

тотып, аларга берәр тустаган шәраб бирә торган булганнар. Аристократия корылтайларда иштиракь кыла[1] торган булган. Бу вакытта аристократиянең хакимияте зур булып, алар хөкүмәт эшенә катышсалар да, патриархат тормыш массада хөкем сөргән, һәм хөкүмәт сөрүче Чыңгыз ыругы, гаиләдә ата ничек бөтен нәрсәгә хуҗа булса, шулай ук бөтен киң илне үзенең малы вә милке дип хисаплаган, хан да, гаиләдәге ата шикелле, бөтен илне идарә кылган. Шуның өчен дә элек Чыңгыз үзенең җирен балаларына, үлмәс борын ук, ата балаларына малын «васыять итеп» калдырган шикелле бүлеп-тәгаен итеп куйган. **Менә шушы гадәт соңра феодализмның әсасларыннан бере булган сәяси хакимиятнең бүленүен китереп чыгарган.** Ләкин шулай гадәттә Чыңгызның теләге булмыйча мәмләкәт Чыңгызның дүрт углына бүленсә дә, шуннан аерым Үгәдәй[2], Чыгтай[3], Тули[4] вә Җүҗи[5] бүлешләре килеп чыксалар да, аларда берлек югалмаска тиеш иде, чөнки патриархат төрк-монгол гадәтенчә төп йорт кечек углы Тулигә калып, шул бөтен илгә суверен хуҗа булырга кирәк, әмма башкалары шуның вассаллары булырга тиеш иде. Ләкин бу суверен вә вассаллык 1260 елларга кадәр барса да, соңра дүрт олыс мөстәкыйль ханлыкларга әйләнделәр. Без монда,

[1] Иштиракь кыла – катнаша.
[2] Үгәдәй (1229–1241) – Чыңгыз ханның өченче улы, атасы төзегән Монгол империясенең турыдан-туры варисы. 1229 ел корылтаенда хан итеп сайлана, Чыңгыз хан сәясәтен дәвам итә.
[3] Чыгтай (Чагатай, Җагатай, 1185–1242) – Чыңгыз ханның икенче улы, монгол ханы. Урта Азиядә әле XV гасырда да Чыгтай олысы җирләрендә яшәүче төрки кабиләләрнең бер өлеше (җалаирлар, барласлар, каучиннар, әрләтләр, коңгыратлар, мангытлар һ.б.) үзләрен чыгтайлар дип атыйлар. XV гасырда бу термин белән монгол яулары вакытында килгән кабиләләрне генә түгел, бәлки Мавәраэннәһердә яшәүче барлык төркиләрне атый башлыйлар. Төрки әдәби телнең тимурилар вакытында формалашкан көнчыгыш тармагы да шушы исем белән йөртелә.
[4] Тулуй (Тули, Толуй, 1186/1190–1232) – Чыңгыз ханның кече – дүртенче улы. 1227 елда Чыңгыз хан вафатыннан соң 1229 елгы Корылтайга кадәр дәүләт белән идарә итеп тора.
[5] Җүҗи (Җүчи, 1185–1227) – монгол яубашы, Җүчи олысы ханы (1224 елдан), Җүчиләрнең нәсел башы. Атасыннан биләмә сыйфатында Иртеш елгасыннан Уралга кадәрге һәм аннан да көнбатыштарак яткан җирләрне ала. 1222 елдан башлап, Каракорымнан бәйсез сәясәт үткәрергә тырыша. Фетнә нәтиҗәсендә үтерелә. Җүчи олысы аның улы Батуга күчә.

Яурупада Олуг Карл үлгәч башланган феодализм әсаслары туган төсле, киләчәктә татар феодализмының башлануын күрәбез.

**Җүҗи олысы[1] вә Алтын Урда.** Чыңгыз зур углы Җүҗигә Иртешның гареб тарафын, Кыпчак илен – хәзерге кыргыз-казакъ степьләрен, Идел, Дон буйларын, Харәзем (Хива) илләрен бирде. Ләкин Җүҗи Чыңгызның үзе исән вакыта ук үлеп китте. Ул үлгәч, тагын дәүләткә хөкүмәт сөрүче чыңгызиларның милке итеп карау вә патриархат әсаслары өскә чыктылар, Җүҗинең балалары аңарга Чыңгыз тарафыннан идарәгә тапшырылган җирләрне монгол гадәте рәвешендә бүлделәр. Нинди җирнең Җүҗинең кайсы углына тигәнен ачык белеп булмаса да, тәхминән[2] без мәмләкәтнең шулай бүленгәнен әйтә алабыз. Җүҗинең икенче углы Батуга[3] – кыпчак иле вә аннан гаребтә булган җирләр, Җүҗинең өченче углы Тук-Тимер[4] – Батуга тигән җирнең шималендәге җирләр (ихтимал, Идел-Кама Болгарстаны); дүртенче углы Шәйбанга[5] хәзерге җәгърафияләрдә кыргыз сахрасы дип мәшһүр ителгән степьләр; бишенче углы Тәүвәлгә[6] Урал белән Эмба елгалары арасындагы күчмә төрк кабиләләре тиде. Ләкин шушыларның һәммәсенә дә баш (суверен) булып Җүҗинең зур углы Урда[7] калса да, ул үлгәч, Бату хан – суверен, әмма калганнары аңарга буйсынган вассаллар булып калдылар. Димәк, яңа удел-феодаль мәмләкәтләр килеп чыктылар. Без монда Русия феодализмының башланган вакытындагы шикелле бер халәт күрәбез. Анда да Рюрик җенесеннән Ярослав

[1] Текстта «олышы» дип бирелгән.
[2] Тәхминән – якынча.
[3] Бату хан (чама белән 1207–1256) – Алтын Урданы нигезләүче хан, Чыңгыз ханның оныгы, Җүчинең улы. Атасы вафатыннан соң олыс идарәчесе (1227). Монгол империясе корылтае кушуы буенча, Идел буе Болгарына, рус кенәзлекләренә һәм Көнбатыш Европа илләренә яулар оештыра.
[4] Тука-Тимер (Бука-Тимер) – Җүчи ханның унөченче улы. Атасы вафатыннан соң Күк Урдада бер олыска ия булып кала. Тарихчылар билгеләвенчә, Казан ханлыгына нигез салган Олуг Мөхәммәд шуның нәселеннән.
[5] Шәйбан (Шибан) – Җүчинең бишенче улы. Аның нәселеннән шәйбанилар династиясе барлыкка килгән.
[6] Тәүвәл (Тувал, Бувал) – Чыңгыз ханның кече улларыннан берсе. Тарихта аның турында мәгълүматлар аз сакланган.
[7] Урда Ижен (1204–1251) – Җүчиның олы улы.

Мудрый үлгәч, мәмләкәт Рюрик сөляләсенең[1] хосусый ыруг милеге хисапланганга күрә, бөтен Киев Русиясе аның угыллары арасында бүленгән, шуның иң карты Киев шәһәрендә торырга вә башкаларга баш хисапланырга тиеш иде, шуннан башлап Русиядә феодализм башланып киткән иде. Без татарларда да шундый ук вакыйганы очратабыз. **Әлхасыйль, Алтын Урда дәүләте ясалыр-ясалмас, анда феодализмның сәяси галәмәтләре күрелә башлаган.**

**1229 ел корылтае.** Чыңгыз хан үлгәч ике елдан соң (1229), Монголиядә Каралан суының кырыенда ак киездән зур-зур киез өйләр корылган; төрк-татар урдасының аксакаллары, гаскәр башлыклары, Чыңгызның уллары, олының олылары – һәммәсе дә корылтайга яисә «туй»га[2] җыелганнар. Бу бөек җыелышка Каспий диңгезе кырыйларыннан Чыңгызның сөекле улы Бату хан да килгән. Кырык көн мөзакәрәдән[3] соң, Чыңгызның васыяте буенча, улы Үгәдәй бөтен төрк-татар мәмләкәтенә баш булып сайланган.

Сайлау беткәч, борынгы бабайлар гадәтенчә, төрк-татар иленең аксөякләре бәйрәм итәргә керештеләр. Күп куй, җылкылар суйдылар, бик күп кымыз эчтеләр, уйнадылар, җырладылар; уен-көлке арасында эшне дә онытмадылар. Бату хан командасында Каспий (Хәзәр) диңгезеннән гаребтә булган тирәләрне, анда торучы халыкларны алу өчен зур гаскәр җибәрергә карар кылынды. Чыңгызның кечкенә улы Тули белән Үгәдәй хан үзе Кытай иле өстенә йөрергә булдылар. Ләкин ни өчендер бу юлы Шәркый Яурупага карар кылынган сәфәр булмыйча калды.

Бату килүдән элек Шәркый Яурупа төркләре, 1224 елда Шәркый Яурупаның җәнүби сахраларында күчеп йөрүче кыр угызлары яисә кыпчакларның һәм Сөбетәй баһадирның һөҗүме соңында күчеп, Венгрия сахраларына кереп качканнар иде. Шулай булса да, иске ватаннарында калучылары да аз түгел. Алар һаман да иске хәятларын дәвам кылдыралар, рус кенәзләренең бер-берсе белән булган низагларына катнашалар, җае килгәндә, үзләре дә аларга һөҗүм итүдән тартынмыйлар иде.

---

[1] Сөляләсенең – нәселенең.

[2] Моны һәм «туй» дип тә йөриләр иде. *(Авт. иск.)*

[3] Мөзакәрдән – фикер алышудан.

Болгар дәүләте монголларның Шәркый Яурупага беренче һөҗүмнәре вакытында таланган, яндырылган, пайтәхет булган Болгар шәһәре дә шактый зарарланган иде. Моннан соң да Болгар иленә татар гаскәре фиркалары һаман да килеп йөриләр, һаман да һөҗүмнәрен, җимерүләрен туктатмыйлар. Җитмәсә, тагын руслар да беренче мәртәбә 1224 елда татар-монголларның һөҗүмнәре вакытында болгарлар белән солых ясап торган булсалар да, татар-монголлар Русия өстеннән югалып торган мөддәттә[1] яңадан болгарларга һөҗүмнәр ясый башлаганнар. 1230 елда Болгар ханы Владимир кенәзенә буйсынган иде. Әлхасыйль, XII гасырның беренче чирегенең ахырларында Шәркый Яурупадагы төркләр тәмам зәгыйфьләнгәннәр, аларны яңадан бер кулга җыючы Азиядән килгән татар-монгол ардулары булды.

**1235 ел корылтае.** Бөтен төрк-татар илләренә баш итеп ясалган Үгәдәй хан хөкүмәте инде үзенең күчмә дәүләтлегеннән чыга башлаган, хөкүмәт янына мөселман, Кытай, Яурупа илләреннән галимнәр, хөкүмәт ирләре, осталар җыелганнар. Байкалга агып төшә торган Орхон елгасы кырыена Каракорым исемле бер пайтәхет шәһәр салынып, анда хөкүмәт тора башлаган иде. Анда халык ифрат күп булып, көн саен халыкка ашарга биш йөз арбага төягән азык килеп тора; менә 1235 елда шунда бөек корылтай җыелган иде.

Бу корылтай мөһим кануннар чыгарган. Әүвәл заманда, Чыңгыз заманында, мәмләкәт ат өстендә торып, кулда кылыч тотып кына эшләгәнгә, бөтен эш гаскәри идарә кулында иде. Бу корылтайда исә гаскәри эшләр идарәи милки (гражданский) идарәдән аерылган: милки эшләрне идарә кылырга монгол-татар халыклары, үзләре белмәгәнгә, бу эшкә белекле кешеләрне читтән китерткәннәр, бөтен илдә иң гали хөкем йорты (сенат) ясалган иде. Шул ук корылтайда хөкүмәтнең мәсарифләре[2] өчен әһалидән[3] алына торган салым да бер тәртипкә куелган: һәрбер йөз аяклы малы булган кеше ел саен хөкүмәткә [шул малның] берсен, иген чәчеп шөгыльләнүче кеше мәхсулатның[4] ун өлешеннән бер өлешен хөкүмәткә бирергә тиеш

[1] Мөддәттә – вакытта.
[2] Мәсарифләре – чыгымнары.
[3] Әһалидән – халыктан.
[4] Мәхсулатның – уңышның.

иделәр. Шуның өчен бөтен илдәге халыкның санын язып чыгарга (перепись) карар кылынган иде. Шулай ук, кытайларга тәкълидән[1], кәгазь акча чыгарылган, почта ясалган иде.

Шушы корылтайда Шәркый Яурупага кылыначак сәфәр карар кылынган. Элек олуг хан Үгәдәй үзе гаскәре белән Русия, Болгар илләренә барырга уйласа да, соңыннан корылтай бу ардуның башында торырга Бату ханга тапшырган иде. Ардуда Чыңгызның балалары, торыннары, башка төрк-татар җирләренең вассаллары бар иде.

Бату ханның Арда[2], Шәйбан, Тангут[3] атлы кардәшләре, Чыңгызның Урта Азиядәге өлешендә хөкем сөрүче улы Чыгтай ханның улы Байдар[4] торыны Бүре, Үгәдәй ханның улларыннан кече Кадан[5] вә башкалары, Чыңгызның кече углы, соңыннан хан булган Мәнгу хан[6] да бар иде. Шундый зур ардуның алды сафында, алдагы фирканең башында мәшһүр командан Сөбетай килә. Бату хан – шушы бөек гаскәрнең баш команданы; гаскәрнең башында торучылар, түрә, команданнарны саклаучылар гына монгол җенесеннән булып, ардуның иң күбесе төркләрдән гыйбарәт иде.

Төрк-татарларның бөек ардулары, ташу күк агып, юлда очраган шәһәр, авылларны яндырып, каршы торган халыкны кырып, разыйлык белән бирелгәннәрен үзләре белән ияртеп, 1337 елда Шәркый Яурупага килеп керделәр. Боларның каһәрләре иң элек мәгърур, матур Болгар шәһәренең диварларына барып бәрелде. Болгар шәһәре тагын җимерелде, бик күп халкы кырылды, Болгар иле хәрабәгә әйләнде. Шуннан соң татарлар русларның шәһәрләрен бер-бер артлы ега, яндыра, талый башладылар. 1240 елда Русиянең борынгы

[1] Тәкълидән – ияреп.
[2] Биредә сүз Җүчинең олы улы Урда Иҗен турында бара.
[3] Тангут (Тангкут, 1210–1246 елдан соң) – Җүчи нәселеннән ханзадә, Чыңгыз ханның оныгы. 1236–1242 елларда монголларның Көнбатышка яуларында гаскәр башлыкларыннан берсе була.
[4] Байдар – монгол ханзадәсе, Чыңгыз ханның оныгы, Чыгтайның улы. 1236–1242 елларда монголларның Көнбатышка яуларында катнаша.
[5] Кадан (Хадан) – Үгәдәйнең алтынчы улы. 1236–1242 елларда монголларның Көнбатышка яуларында катнаша.
[6] Мәнгү (Мөнке, 1208–1259) – Чыңгыз ханның кече улы Тулинең улы. 1251–1259 елларда Монгол империясенең бөек кагана.

пайтәхете Киев алынды. Әлхасыйль, Русия төрк-татар дәүләтенең бер өлешенә әйләндерелде. Руслар, әллә никадәр вак кенәзлекләргә бүленгәнгә күрә, һәммәсе дә аерым-аерым гына татарларга каршы торып, бергә хәрәкәт итә алмадылар. Шуның өчен русларны җиңү Бату өчен бик уңайлы булды.

**Татарларның Гарби Яурупага һөҗүмнәре.** Бату хан Русияне алу белән генә канәгатьләнмәде. Ул бер рус воеводасының мәслихәте белән Польшага да һөҗүм итте. Польша да, нәкъ Русия шикелле үк, вак патшалыкларга бүленгәнгә күрә, аларда да берлек юк иде. Татар ардусы, ике фиркагә бүленеп, бөтен Польшаны харап итәргә, шәһәрләрне яндырырга тотынды.

Ниһаять, татарлар Польшадан соң Мажарстанга (Венгриягә), соңыннан Далмация, Хорватиягә һөҗүм итеп, калаларны алып яндырып йөри торгач, Австриягә дә килеп чыгып, Венаның диварлары алдына килеп җиттеләр. Бу вакытта бөтен Гарби Яурупа татарлардан курыкты. Һәр җирдә татарларның һөҗүме, явызлыгы хакында гына сөйлиләр иде. Хәтта Франция короле дә Франциянең шәһәрләрен төзәттерә, дивар, истихкямнәрен[1] ныгыттыра башлады.

Шушы вакытларда Үгәдәй хан үлеп китте. Бату ардусы эчендә булган шаһзадә, олуглар Каракорымга корылтайга кайтырга ашыктылар. Бату хан да, гаскәрен кире борып, Идел буена китерде дә шунда тукталды. Шушы вакыйга да Яурупаны һун һөҗүменең тәкрарлануыннан[2] котылдырды.

## 2.2. Алтын Урда яисә Кыпчак дәүләтенең ясалуы

**Шәркый Яурупадагы татарларның олуг ханлыктан аерылулары.** Бату хан 1255 елга кадәр яшәде, 31 еллап хөкүмәт сөрде. Чыңгызның балалары, торыннары эчендә Бату хан иң батыры, иң гайрәтлесе дип санала. Шуның өчен дә бөтен Чыңгыз балалары, аның балаларының балалары аны хөрмәт итәләр. Каракорымда хөкүмәт сөрә торган олуг хан үлгәч тә, ул килмәсә, хан сайлый торган корылтай җыелмый, ил хансыз торадыр иде, гомуми корылтайларда да аның сүзе белән эш кылалар иде.

[1] Истихкямнәрен – хәрби ныгытмаларын.
[2] Тәкрарлануыннан – кабатлануыннан.

Бату хан монгол империясендә чын мәгънәсе белән берлек хөкем сөргән чакларында үлеп китте. Аның соңыннан улы Сартак[1] бер генә ел чамасы хан булганнан соң вафат булды. Ул үлгәч, Каракорымда хөкем сөрүче бөтен төрк иленең башы хисапланган Мәнгүнең (1251–[12]59) теләве буенча Җүҗи олысына Батуның кече борадәре[2] Җүҗи улы Бәркә[3] хан булды. 1255–[12]66 [елларда] ул хөкүмәт сөргән вакыт бөтен монгол империясе өчен фаҗигалы бер заман иде. Мәнгү хан үлгәч, «Яса»да әйтелгән бөек корылтай җыелмыйча, Мәнгүнең энесе Кублай[4] олуг ханның тәхетен ишгаль кылды[5]. Аны хәзер бөтен төрк-татар олуглары түгел, бәлки үзенең партиясе генә сайлады. Шуннан соң Чыңгыз ыругы арасында сугыш чыкты. Һәммә олыслар аерылдылар. Шулай итеп, Шәркый Яурупадагы төрк-татарлар да, олуг ханлыктан аерылып, мөстәкыйль дәүләт булып китте. Акчаны да үз исемнәреннән суктыра башладылар. Менә бу дәүләтне инде Җүҗи олысы дип түгел, бәлки Алтын Урда ханлыгы яисә Кыпчак иле дип йөриләр.

**Монголларның төркләшүе.** Бату хан командасында Шәркый Яурупага килгән гаскәрнең бик азы гына монголлардан гыйбарәт булып, күбесе төрк җенесеннән иде[6]. Бу аз гына монгол, Шәркый

---

[1] Сартак (?–1256) – Батый ханның өлкән улы; тарихи хезмәтләрдә тәхет варисы буларак искә алына. Бүленмәс Монгол империясе тарафдары. Атасы вафатыннан соң, Алтын Урда тәхетенә бөек каган Мәнгү тарафыннан билгеләнә. Каракорымнан Идел буена кайтышлый юлда кинәт вафат була, аның улы һәм варисы Улакчы да берничә ай идарә иткәннән соң үлеп китә.

[2] Борадәре – ир туганы.

[3] Бәркә (1209 ел тирәсе – 1266) – Җучи ханның улы, Бату ханның энесе. Алтын Урданы Монгол империясеннән аеру сәясәтен яклый. Сартак һәм Улакчы ханнарның бер-бер артлы вафат булуыннан соң (1256), Бәркә Алтын Урда тәхетенә утыра. Бәркә идарә иткән дәвердә Алтын Урда дәүләтендә ислам дине йогынтысы көчәя, илдә тәүге тапкыр Җучиләр тамгасы белән акча сугыла башлый, халык саны исәпкә алына, акча-үлчәү берәмлекләренә үзгәреш кертелә, салым түләү тәртибе камилләштерелә. Бәркә хан чорында Алтын Урда Монгол империясеннән аерылып чыгу юлына баса, чит мәмләкәтләр белән мөстәкыйль сәясәт алып бара башлый.

[4] Хубилай (1215–1294) – Чыңгыз ханның оныгы, Юань монгол дәүләтенә нигез салучы. Марко Поло язмаларына «Кублай-хан» исеме белән кергән.

[5] Ишгаль кылды – кулына төшерде.

[6] Тәхминән Бату ханның алты йөз мең гаскәреннән бары алтмыш мең чамасы гына монгол иде. *(Авт. иск.)*

Яурупадагы җирле төркләр, төркләшкән финнар арасына килгәч, озакламый үзләре төрккә әйләнә башладылар. Бары зур түрәләр, гаскәр команданнары берничә вакытлар монголлардан булып килделәр. Болгарда половецлар өстеннән карап торырга монгол түрәләре куелды. Мәсәлән, Бату хан половецларга баш итеп үзе белән килгән ике монголны куйган, шулай ук болгар өлешенең башына да монгол куелган иде. Ләкин озакламый Алтын Урда Монголия белән элемтәсен өзде; кечкенә генә монгол халкы үзенең бөтен көчен Иран, Кытай, Төркестанга җибәреп торырга мәҗбүр иде. Шуның өчен Монголиядән күп булышлык алырга мөмкин түгел иде. Бара-тора монголлар башлыклар вә хөкүмәт сөрүче бер гонсыр булып кына калдылар. Бара-тора бу төрк җиренә килеп утырган монголлар үзләренең гадәт вә йола һәм телләрен оныта, кыпчак вә башка төркләр белән катыша башладылар. Шәркый Яурупа төркләре даладан вә ерак Азиядән килгән монголлардан мәдәнияттә алда булганга вә өлкәдә күпчелек вә масса да шулардан гыйбарәт булганга, төркләрнең хөкүмәт сөрүче монгол гонсырларына тәэсирләре зур иде; рәсми язулар да төркчә языла башладылар.

Бу төркләшү шулкадәр тиз бер агыш белән барды ки, 1312–1340 еллар арасында хөкүмәт сөргән Алтын Урда ханы Үзбәк[1] янына килгән гарәп сәйяхе Ибн Баттута[2] бу мәмләкәтне бер монгол мәмләкәте итеп түгел, бәлки кыпчак төркләре патшалыгы итеп тасвир кыла, хәтта сарайда рәсми телнең төркчә булуын сөйли. Шул рәвешчә, Алтын Урданы алган монголлар төркләшәләр, массаның теле хөкүмәт теле булып китте, бары тик монгол гадәтләре вә телләре бәгъзы церемонияләрдә генә калды.

Мәгълүм ки, Чыңгыз хан чыккан монгол кабиләсе «кара татар» исемле иде. Димәк, сөяләнең ыруг исеме «татар» атлы иде,

[1] Үзбәк хан (Мөхәммәд Солтан) (?–1342) – Мәнгү Тимер ханның оныгы, 1312 елдан Алтын Урда ханы. Мәмләкәтне ныгыту, үзәкләштерү сәясәтен үткәрә, исламны дәүләт дине буларак кабул итә. Үзбәк хан идарә иткән утыз ел дәверендә Алтын Урда үз тарихында иң югары үсеш чорын кичерә.

[2] Ибн Баттута (тулы исеме: Әбү Габдуллаһ Мөхәммәд ибн Габдуллаһ әл-Ләвати әт-Танҗи,1304–1377) – гарәп сәяхәтчесе. 1334 елда Алтын Урдага килә, Болгарны күрә, берникадәр вакыт Үзбәк хан даирәсендә яши. «Төхфәт ән-наззар фи гараиб әл-әмсар вә гаҗаиб әл-әсфар» («Төрле шәһәрләр һәм сәфәрләрдә гаҗәеп хәлләргә шаһит булучыларның бүләге») исемле сәяхәтнамә авторы.

читтән килгән сәйяхләр дә боларны хаким сыйныфлары игътибары белән «татарлар» дип йөртәләр иде. Димәк, бара-тора «татар» исеме сөлялә исеменнән бөтен Алтын Урда дәүләтенә кергән төрк җенесеннән булган халыкларга исем булып килде. Бу эш бер бездә генә түгел, русларда вә французларда да шулай. IX гасырда бөтен Шәрык славяннарына баш булган рус кабиләсеннән чыккан норман кенәзләре исеме белән Шәрык славяннары «рус» дип аталалар. Франция әүвәле Галлия дип аталадыр иде. Галлар кельт җенесеннән иде. Менә бервакыт галларны герман җенесеннән булган франклар алдылар. Франклар галлаштылар. Әмма Галлия исемен җуеп, бөтен Галлиягә Франция исемен бирделәр.

Димәк: **татар халкы – Шәркый Яурупада торган төркләрнең вә аз хаким монголларның вә төркләшкән финнарның кушылуыннан ясалган бер халыктыр.** Аның массасында төрк-фин каны күбрәк булса, революциядән алда булган аксөяк мирзаларында монгол каны күбрәк, чөнки мирзаларның күбесе – шул Бату гаскәре белән килгән монголлардан чыккан бер сыйныфтыр. Бу татар халкының ясалу процессы, димәк, Шәркый Яурупа төркләре (кыпчаклар, болгарлар вә башкалар) һәм монгол вә берникадәр финнарның катышу процессы болай сөйләгәнчә тиз булмады. Аңарга ничә гасырлар кирәк булды.

# III Татарларда феодализм дәвере

## 3.1. Алтын Урда

**Башлангыч.** Шәркый Яурупа төркләрен монголлар килеп алып оештыру белән татар тарихында бер яңа дәвер туды. Бу яңа дәвердә ике төрле хосусият бар: 1) татар халкының ясалуы. Бу вакыттан алып Шәркый Яурупаның төрк вә төркләшкән монгол-фин гонсырларын турыдан-туры «татар» дип атап йөртергә мөмкин; 2) татарларда акрынлап «феодализм» исемендә йөртелә торган икътисади-иҗтимагый хәятның башлануы. Дөрес, Алтын Урда ханлыгы ясалмас борын да, төркләрнең сәяси оешып дәүләт ясаганнарында бу феодализмга таба бару күренәдер иде. Мәсәлән, болгар вә хәзәрләрнең дәүләт төзелешендә без моны сизә алабыз, ләкин ничек тә масса, шәркый Русия төркләренең күбрәге әле һаман да ыруг-патриархат тормышыннан чыгып бетмәгәннәр, вә шул хәят күбесендә хөкем сөрмәктә иде. Әмма илне монголлар килеп оештыргач, мөмкин булган җирләрдә утраклы тормыш башлангач, феодализм да килеп чыкты. Билгеле, «татар» феодализмында Яурупаныкының һәммә галәмәтләрен табарга азапланырга ярамый. Чөнки бәгъзы исемнәре дә вә кайсыбер җирләрендә татар феодализмы белән Яурупаныкында аерма табарга мөмкин; ләкин һәрхәлдә искенең дә асылы вә төбе бердер.

Феодализм туа башлау белән Алтын Урдада ыруг-патриархат тормышы тиз генә бетте дә китте дип уйларга ярамый. Нитәкки[1],

[1] Нитәкки – шул рәвешле.

татар халкы үзенең оешкан халыкларыннан бер халыкка төп-томал әйләнмәде, нәкъ шуның шикелле үк феодализм хәяты элек мәркәзләрдә, су юллары өстендә вә халыкның күчмә, ләкин ярым вә яисә бөтенләй утраклы тормышка күчкән урыннарда туды. Дөньяда адәм җәмгыятьләре тормышында ару бер җәмгыять формасы табуы читен. Шуның өчен Алтын Урдада күчмә халыклар эчендә, хәтта хөкүмәт сөрүче монгол нәселе арасында күп заманнар ыруг тормышы калды; әмма мәркәз зур шәһәрләрдә вә сәүдә, сәнәгать өйләрендә исә тормыш үзенең бәгъзы кисәкләрендә феодализмнан үтеп, сәүдә капитализмына охшаган бер тормышка да күчә башлавын күрергә мөмкин. Без, шуны күрер өчен, хәзер Алтын Урданың тормышын һәрьяктан тикшереп узып, соңра феодализм мәсьәләсенә тукталачакбыз.

**Алтын Урдада матди мәдәният вә хуҗалык.** Монголлар килеп Шәркый Яурупаның җәнүбендәге күчмә вә ярым утраклы төрк халыкларын оештырып дәүләт ясагач, әүвәлге хәзәрләр заманындагы вә күчмә халыклар килү белән бераз бозылган сәүдә вә читләр белән ихтилят[1] тагын терелде. Рум, итальян, яһүд, әрмән вә башка җир сәүдәгәрләре тагын үзләренең эшләрен корып, төзәтеп җибәрделәр. Алтын Урданың мәркәзе тагын, зур юллар өстендә ятканга, бөтен Шәрык һәм Гареб мәдәниятенең бер-берсе белән катнаша вә якынлаша торган киң бер базары, мәйданы булып китте. Шуның нәтиҗәсендә Алтын Урданың «тамга» акчасы (таможня) күп җыелу һәм сәүдәнең күбәюе аркасында икътисади тормышы күтәрелеп китте. Шул да мәдәниятне күтәрергә сәбәпче булды. Тиз заманда шәһәрләр төзәтелә вә яңадан салына башладылар.

Хаким монголлар «ат өстендә төзегән илне ат өстеннән торып идарә кылып булмаячагын» бик яхшы белделәр. Хәзерге Саратау белән Әстерхан арасында бик күп яңа шәһәрләр төзелде. Әүвәлге Болгар илендә башта татарларның һөҗүме чагында көл булган шәһәрләр яңадан төзәтелделәр вә яңалары да тагын салына башладылар. Бату хан заманасыннан алып Мәнгү Тимергә[2] кадәр (1266–1282) җәгърафи уңайлыгы аркасында акча сугыла

[1] Ихтилят – дустанә мөнәсәбәт.
[2] Мәнгү Тимер хан (?–1282) – Батый ханның оныгы, 1266–1282 елларда Алтын Урда ханы. Алтын Урданың Монгол империясеннән аерылып, мөстәкыйль яшәвен ныгыта.

торган мәркәз Болгар хисапланса да, Бату хан заманасында ук (1224–1256) Иделнең шул ягында Хәзәр (Каспий) диңгезеннән ике көнлек юлда (Әстерханнан 100–120 чакрым югары) Сарай исемле шәһәр салынды. Үзбәк хан заманында (1312–1340) хәзерге Царицын тирәсендә яңа Сарай (Сарай җәдид) ясалды. Тагын Гөлестан, Бәлҗәмин, Үксәк[1], Сарычин шикелле вә Җаек елгасының диңгезгә коя торган урынында – Сарайчык, Иделнең Каспийга төшә торган җирендә Әстерхан заһир булды[2]. Болгар, Суар да тагы терелеп киттеләр. Бу шәһәрләрнең барысын монда санап тормыйбыз, ел саен боларның яңаларын археологлар җир астыннан казып чыгарып торалар.

Бу шәһәрләрнең йортлары гади вә кургашын катышкан кирпечтән, балчыктан һәм агачтан булып, зур сарайлар, төрбәләр, мәчетләр, дәрвишләр (суфилар) тора торган урыннар, мәдрәсәләре, мунчалары вә чит халыкларга махсус мәгъбәдләре[3] булган. Хәтта бер сәйях гарәп Сарай шәһәренең бер ягыннан икенче ягына чыгарга иртә намазыннан өйләгә кадәр вакыт атка атланып барырга мәҗбүр булган. Бәгъзы шәһәрләрдә төрле милләтләр өчен аерым квартал бистәләр вә зур базарлар булган.

Шәһәрләргә су махсус чүлмәк трубалар белән китерелгән булып, байларның йортлары матур бакчалар, фонтаннар белән, эчләре изразцыдан[4] төрле төстәге үрнәкләр белән бизәлгән булган. Бу бизәкләрне эшләүче татар сәнгатькярләренең үзләренә махсус зәвыклары булып, үзләренә өслүб ясарга муаффәкъ булганнар[5]. Мәсәлән, алар күбрәк һәндәс[6] һәм нәбати[7] үрнәкләр төшереп, бу үрнәкләрдә бер төрле дә куе төс, кара, кызыл төс истигъмаль итмәгәннәр; төсләрне зәвыклы рәвештә бер-берсе белән баглый белгәннәр.

Алтын Урда татарлары биналары өчен хәзергә кадәр составы беленмәгән гаҗәп каты цемент ясап, шуны истигъмаль иткәннәр. Төрле мәгъдәннәрдән төрле зиннәт әсбаплары вә кораллар, ханнар-

[1] Хәзерге вакытта «Үкәк» варианты фәнни кулланылышта.
[2] Заһир булды – барлыкка килде.
[3] Мәгъбәдләре – гыйбадәтханәләре.
[4] Изразцы – бизәкле кафель.
[5] Муаффәкъ булганнар – сәләтле булганнар.
[6] Һәндәс – геометрик.
[7] Нәбати – үсемлекләргә караган, ботаник.

га алтын-көмештән тәхетләр ясаганнар. Балчыктан вә таштан изразцылар вә бик матур төсләрдә буяп чүлмәк савыт-сабалар ясаганнар. Бу Алтын Урда мәмләкәтенең мәркәз шәһәрләре XII гасырда ук мәстур[1] мәдәният урыны булып китте. Шуның өчен Ибн Гарәпшаһ[2] исемендәге бер ислам галиме үзенең бер әсәрендә «Сарай гыйлем мәркәзе һәм яхшылыкларның мәнбәгы[3] булып китте, аз вакытта анда күп кенә галим-голәма һәм мәшһүр кешеләр җыелганнар», – ди. Башка бер гарәп галиме әл-Гомәри[4], Бәркә хан (1256–1266) заманындагы Сарайны тасвир кылганда: «Сарай – бер зур шәһәр, анда базарлар, мунчалар, гыйбадәтханәләр бар, ул (Сарай) – маллар килә торган урын... Анда хан үзе тора торган сарай бар, аның башында алтын ай куелган ки, аның авырлыгы Мисыр үлчәве белән ике кыйнтар[5] зурлыгында. Ханның йортын диварлар, манаралар һәм икенче йортлар кыршап алганнар, аларда аның әмир (түрәләр)ләре тора», – ди.

Соң, бу кадәрле шәһәрләрне вә мәдәни җирләрне җимерүче татар-монголлар ничек болай мәдәният торгыза алганнар?

Моның сере ачык мәгълүм. Дөрес, монголлар дошманнарының бөтен әсәрләрен җимергәннәр, туздырганнар. Әмма кирәк Урта Азиядә, кирәк Иран вә Кытайда булсын, алар тагын мәдәниятне төзергә тотынганнар. Шуның өчен дә монголлар, үзләренә каршы кылыч күтәрүчеләрне кырган чакта, Чыңгыз исән чакта ук, галим-голәма вә һөнәр ияләрен коткарганнар, аларга эш биреп, үзләре белән алып китә торган булганнар; шуның аркасында аларның кулларына әллә

[1] Мәстур – рәт-рәт тезелгән.
[2] Ибн Гарәпшаһ (1389–1450) – гарәп язучысы һәм тарихчысы. Аксак Тимер гаскәрләре тарафыннан гаиләсе белән Сәмәркандка китерелгәч, төрки, фарсы, монгол телләрен өйрәнә. Соңрак Төркестан буенча сәяхәт итә, Монголия, Кытай чигенә кадәр барып җитә, шуннан Харәземгә кайтып, Сарай һәм Әстерханга бара.
[3] Мәнбәгы – чыганагы.
[4] Әл-Гомәри (тулы исеме: Шиһабетдин Әхмәд ибне Яхъя әд-Димәшкый әл-Гомәри, 1301–1349) – гарәп язучысы, энциклопедияче. Димәшкъта һәм Каһирәдә яши, Мисыр дәүләт канцеляриясендә эшли. Алтын Урда тарихы буенча мәгълүматлар теркәлгән «Дәүләтләрнең эре үзәкләре буйлап күзәтүләр» (т. 1–32) исемле тарихи-географик хезмәт һәм башка әсәрләр авторы.
Төп текстта әлеге авторның исеме ялгыш «әл-Гофари» рәвешендә басылган.
[5] Кыйнтар – 44,928 кг авырлык үлчәве, искергән берәмлек.

никадәр осталар җыелган, аларны монголлар үзләре белән бергә йөрткәннәр. Менә монголлар Алтын Урдага килгән чакта да үзләре белән шундый осталарны китергәннәр дип уйлана. Шулай ук монголлар килмәстән борын ук Шәркый Яурупа бер вәхши ил түгел иде, анда хәзәр вә болгарлар һәм кыпчаклар яхшы гына мәдәният тудырганнар; җәнүбтә исә румнар, итальяннар вә сәүдәгәр гарәпләр – һәммәсе дә үзләре бу мәдәнияткә булышлык итәләр иде. Ләкин бары монголларга кадәр каты куллы хөкүмәт юк, башбаштаклык вә анархияне тыярлык бер көч кенә җитми иде.

**Сәнәгать вә бакчачылык.** Бу кадәрле мәдәният, билгеле, шактый тәрәккый иткән сәнәгать булганлыгын алдан ук белдереп тора.

Шәһәрләр җир астыннан йөртелгән чүлмәк трубалар аркылы суарыладыр иде. Монда ул заманда мәдәни Урта Азиядә истигъмаль кылына торган арык системалары да кертелгән булган. Бу суның бер кисәге шәһәр кирәкләренә, мунчаларга китеп, бер кисәге белән шәһәрнең эчендәге гөл бакчалары (гөлстан), җимеш бакчалары суарылган, әмма бер кисәге техникага төрле нәрсәләр ясаганда кирәк булган су көче истигъмале өчен сарыф ителгән. Алтын Урданың бер шәһәр хәрабәсендә су көче белән әйләндерелә торган тугыз потлы чәдем (Приводное колесо[1]) табылган. Шәһәрләрне вә аларның янындагы бакчаларны суару бик кирәкле эш булган, чөнки зур вә Сарай шикелле мәркәз шәһәрләр һәммәсе дип әйтерлек шул заман мөхәррире әл-Гомәри сүзе белән әйтсәк, «Идел белән комлык арасында» булганнар. Шуның өчен, шушы шәһәрләрне ком һөҗүменнән саклау өчен, ком белән көрәшергә дә кирәк булган.

Алтын Урда осталары бер яктан ком белән сонгый[2] суару ысулы белән көрәшсәләр, икенче яктан күчеп йөри торган ком таучыкларын ныгытуга да зур әһәмият биргәннәр. Шәһәр янындагы шундый таучыкларның кырыен казып, эченә бүрәнә салып, соңра самандан[3] диварлап ясап беркетә торган булганнар. Менә элек салган иске Сарай шундый комлык җирдә, сахрада булганга күрә дә, мәркәзне яхшырак балчыклы яңа Сарайга күчергәннәр.

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Сонгый – ясалма.
[3] Саман – балчыкны салам белән катыштырып ясалган кирпеч. *(Авт. иск.)*

Ләкин шулай да иске Сарай, һаман да үзенең әһәмиятен югалтмаенча ук, сәнәгать вә сәүдә мәркәзе булып калган. Шуның өчен дә иске Сарай тирәсендә казып тикшерүчеләр бик күп сәнәгать йортларын, хәрабәләрен табалар. Бу урыннарда хәзер бик күп зур мичләр табыла вә аларга ягылган нәрсәләрдән калган бик күп өелгән көл табалар. Ул көлне җыеп алып, шунда торган халык хәзерге көндә дә кер юуга истигъмаль кыла. Бу мичләрдә төрле мәгъдәннән нәрсәләр койганнар, акча сукканнар, кораллар, зиннәт әсбаплары эшләгәннәр. Монда казучы археология галимнәре шунда әллә никадәр гарна (Горн[1])лар, бакырдан нәрсәләр коя торган чүлмәк савыт формаларын тапканнар, димәк, Алтын Урдада да үзенә вә заманына күрә металлургия сәнәгате дә булган. Шул ук шәһәр калдыкларын казытканда, зур чүкечләрнең табылуы бу фикерне куәтлиләр. Мичләрне ягу өчен утын Болгар иленнән килә торган булган. Бу хакта бер искедән калма татарча кулъязма хикәядә Зөя тамагыннан Идел елгасы белән җәнүбкә сал төшерүләре тасвир кылына. Әмма мәгъдәннәрене булса, суда кәрван юлы белән Уралдан китерә торган булганнар. Иске Алтын Урда шәһәрләре урынында шулай ук пыяла савыт-саба вә өргән пыялалар бик күп табылалар, бу нәрсәләр дә беркадәр читтән килгән булсалар да, бәгъзы галимнәр бу шәһәрләрнең үзләрендә пыяла эшләнгәнлеген дә дәгъва кылалар. Ләкин һәрхәлдә иң күп вә яхшы эшләнгән нәрсә булса – чүлмәк савыт-саба булган. Сарай шәһәренең урынын казыган чакта бер дүрткел чакрым урында ватык чүлмәк белән тулган урын табылган; шулар эчендә сәламәт калган савытлар да бик күп. Бу урында зур гына чүлмәк вә савыт-саба эшләнә торган заводлар булган дип уйланыла. Чүлмәк савыт-саба һәм фаянс (ак вә сары балчык савытлар) нәрсәләр эшли торган ике этажлы мичләр табылган. Бу савытларның арасында бик матур буялганнары, хайван вә үсемлекләр сурәтләре төшерелгәннәре һәм төрле язулар, бәйтләр[2] язылганнары да табылганнар. Боларның рәсем вә язуларының күбесе Урта Азия вә Иранныкыларга охшатып ясалган булса да, арасында оригиналь булганнары да бар. Алтын Урдада табыла торганнары да юк түгел.

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Бәйтләр – ике юллы шигырьләр.

Алтын Урдада тагы бер күп эшләнә торган нәрсә булса, ул да ак вә башка төсләрдәге кирпеч вә изразцы (чынаяк кирпечләр)дер. Бу нәрсәләр гаять таза итеп эшләнгән булып, дүрт-биш еллар җир астында ятсалар да, һич бозылмаганнар. Шуның өчен дә тирә-юньдә хәзерге көндә тора торган халык аларны казып алып кайтырга бик яраталар. Иске Сарай урынында шундый матур кирпеч һәм чынаяклар ясый торган бер завод хәрабәләре дә табылган. Вә алардан шактыйлары хәзер мәркәз, Саратау, Казан музаханәләрендә[1] куелган. Моннан башка Алтын Урдада эшләнә торган нәрсәләрдән: түгәрәк һәм яссы шешәләр, тустаганнар, поднослар, шәмгыданнар[2] булган. Ләкин Алтын Урдада алтын вә көмештән бик күп беләзек, йөзек шикелле зиннәт нәрсәләре дә эшләнә торган булган.

Шул ук сәнәгать Алтын Урданың бер өлеше булып киткән Болгар шәһәрләрендә тәрәккый иткән булган, мондый сәнәгатьнең булуы бәгъзы кабер ташлары белән дә исбат кылына. Мәсәлән, бер кабер ташына шулай язылган:

Һуа әл-хәйү әл-ләзи лә йәмүт[3].
Йекетләр күрке, күңелләр үзге,
галимнәрне агырлаган, ятим, тол,
үксезләрне асраган Муса углы
алтынчы Шәһидулла зияраты торур.
Һиммәт кыйлун шәрру рабих ли-әүвәлнең үзәсендә
тарихка 717[4].

**Сәнәгатьнең хуҗалары вә эшчеләре.** Сәнәгать хакында сөйләнде исә, хәзер күз алдына мөһим бер сөаль килеп баса: бу сәнәгать кем кулында, анда эшләүчеләр кемнәр булган?

Мәгълүм ки, Алтын Урда дәүләтендә коллык бар иде: әсирләр кол ителә, базарларда коллар алына, сатыла вә аларны чит илләргә җибәрәләр иде. Ихтимал, борынгы Рума вә Юнанстандагы һәм ул

[1] Музаханәләрендә – музейларында.
[2] Шәмгыданнар – шәмдәлләр, люстралар.
[3] Ул (Аллаһ) мәңге тере, үлемсез.
[4] Дөресе: Рәхмәт кыйлсун рабигъ әл-әүвәлнең уртасында, тарихка 717.
Төгәл укылышын һәм тәрҗемәсен кара: Татарская эпиграфическая традиция. Булгарские эпиграфические памятники XIII–XIV вв. Кн. 1. / Авт.-сост.: И. И. Гумеров, А. М. Ахунов, В. М. Усманов. – Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2021. – С. 65.

чактагы ислам дөньясындагы шикелле, бу сәнәгать йортларының хуҗалары хаким сыйныф – феодаллар булгандыр да, аларда эшләүчеләр дә коллар булганнар. Шулай да Алтын Урдада хезмәт әһеленең булганлыгын күрсәтә торган бераз гына дәлилләр бар. Билгеле, бу хезмәт әһелен хәзерге мәгънәсе белән пролетариат дип әйтеп булмый.

Шушы елларда гына Алтын Урда урынындагы казу, эзләнүләр Алтын Урда шәһәрләрендәге эшче халыкның торган урыннарын да ачып бирде. 36 квадрат чакрым урын алып торган Иске Сарай шәһәренең шималендә 3 дүрткел чакрым урында фөкара[1] шәһәрдәге чүлмәк-кирпеч вә мәгъдән нәрсәләр эшли торган кярханәләрнең[2] эшчеләре торган. Бу сыйныфның йортлары һәммәсе дә балчыктан эшләнгән. Монда табылган нәрсәләр бу сыйныфның фәкыйрь торганлыгын күрсәтәләр.

Ләкин сәнәгатьтә иштиракь кылучы сыйныф, феодаль Яурупа шәһәрләрендә булганы шикелле, безнең фикеребезчә, һөнәрчеләр булырга кирәк. Алтын Урда дәвереннән калган рәсми ярлыкларда «хезмәт агасы» дигән һөнәрчеләрнең башлыкларын укыйбыз. Ихтимал, монда да шул цех системасы хөкем сөреп, шуларның башлыклары, мастерларын шулай атаганнардыр. Менә югарыда әйтелгән «алтынчы Шәһидулла» да шулар җөмләсеннән булуы бик мөмкин.

**Игенчелек вә игенчеләр.** Алтын Урданың төп халкы вә ядросы, бер дә шиксез, Гомәри әйткәнчә, «чатыр ияләре», күчү[3] халык иде. Ләкин шулай да, шул ук гарәп язучысының әйтүенчә, Алтын Урдада аз булса да богдай, арпа чәчкәннәрен сөйли.

Әмма югарыда сөйләнгән ярлыкларда, төрле сыйныфларны санаганда, «хөкүмәт сабанчы» дигән бер сыйныф барлыгын да белдерәдер. «Тегермән акчасы» дигән бертөрле салым да телгә алына ки, әгәр дә Алтын Урдада игенчелек булмаса иде, бу салымны телгә алу да юк эш булыр иде. Шуның өстенә дә Алтын Урда хәрабәләрен казыганда килеп чыккан орлык калаклары шуны ук куәтлиләр. Әлхасыйль, Алтын Урданың Кырым ярыматавы вә елга буйлары, Иделнең урта агымында булган Болгар олысы шикелле җирләрдә

[1] Фөкара – ярлылар.
[2] Кярханәләрнең – остаханәләрнең.
[3] Күчү – күчмә.

бер дә шиксез иген чәчелә вә анда сабанчы дигән бер хокук җәһәтеннән ирекле, әмма экономика ягыннан алпавыт-таранчыларга буйсынган игенчеләр булган.

**Алпавытлар вә аларның кулындагы игенчеләр.** Алтын Урдада тагы бер иген белән шөгыльләнүче алпавыт сыйныфы бар иде. Болар күбрәк аксөякләрдән булып, боларның иң гадиләре тарханнардан буладыр иде. Моңарга да иң матур дәлилне алда сөйләнгән ярлыклардан беләбез. Зур нәселдән килә торган бикләрнең җирләре булуы хакында безгә XIV гасырның бөек философ вә тарихчыларыннан Ибн Хәлдун[1] белдерә. Аның әйткәненчә, Алтын Урдада төрле җирләрне идарә кылучы «монгол әмирләренең (әмир әлхәфәл) кулында» Сарай тирәсендә (әвами әс-Сарай) зур җирләре булган. Бу әмир вә тарханнардан гыйбарәт булган феодаллар ихтыярлы сыйныфлар булып хисап ителәләр, салым түләмиләр иде.

Менә бу чакта без Тимер Котлыг[2] атлы Алтын Урданың бер ханының ярлыгында шулай укыйбыз: «... Мөхәммәднең угланлары элиге Хаҗи Мөхәммәд вә Мәхмүд азад тархан булсун. Буларның йир-суларынга, баг-бакчаларыга, текермәнләрегә тасарруф кыла торган йирләрегә борындин калган азадларыга, баса калаларыга, сабанчы, уртакчыларыга кем-кем ирсә көч уга тигүрмәсүн...»[3]

Моннан күрелә ки, алпавыт-феодалларның кулында «җир-сулары вә иске режимдагы Франциядәге төсле «текермән»нәре, авыл-салалары булганлыгы, ул җир-салаларда «азад», ягъни колдан азат ителгән крестьяннары, «сапанчы» аталган крестьяннары булганын күрәбез; шулай ук бу кисәктән алпавыт хуҗалыгының алпавытның үзенә табигъ шушы крестьяннар тарафыннан һәм «уртагына» бирелеп эшләтә торган җирләре булып, эшләрне «уртакчылар» аталган крестьяннар эшләгәне күрелә. Димәк, без монда һәрбер феодализм хөкем сөргән җирләрдә булганы шикелле зур җирләрнең, тегермәннәр вә суларның алпавытлар, феодаллар ку-

[1] Ибн Хәлдун (тулы иseme: Әбү Зәйд Габдрахман ибн Мөхәммәд ибн Хәлдун әл-Хадрами, 1332–1406) – гарәп фәлсәфәчесе һәм тарихчысы.

[2] Тимер Котлыг (1370–1400) – 1395–1399 елларда Алтын Урда ханы.

[3] Мөхәммәднең улларыннан олысы Хаҗи Мөхәммәд һәм Мәхмүд азат тархан булсыннар. Боларның җир-суларына, бакчаларына, тегермәннәренә, кул астындагы җирләренә, электән азат булганнарга, алардан калган башкаларга, сабанчы, уртакка алып иген игүчеләргә (каршы) беркем дә көч кулланмасын.

лында булуын вә аларның кулында булган крестьяннары булганын бик яхшы күрербез.

Алпавытлар Гарби Яурупаның феодализм дәверендәге шикелле «шато» яисә, русча әйтсәк, мөхкәм[1] «замкаларда»[2] торалар иде. Шуның өчен дә алда әйтелгән ярлыкта «борынгы замандин бирү мөтәгаддид[3] тархан булган Индирчи саласы белән шәһәр каласы» дигән сүзне очратабыз. Бу сүзне мәшһүр мөстәшрикъ Радлов русчага шулай итеп тәрҗемә кыла: «с прежних времен, где были многочисленные тарханы из деревни Индирчи и известного замка ея[4]».

Без алпавыт-задәкян[5] хакындагы сүзне тәмам итеп, укучыларга бу сөйләгән сүзләрне дәүләт төзелеше хакындагы урынга җиткәнче хатирәләрендә тотуларын тәүсыя кылып[6], Алтын Урдадагы икътисадның икенче бер мөһим җәһәте булган сәүдәгә күчәбез.

**Сәүдә вә сәүдәгәрләр.** Алтын Урда, югарыда әйтелгәнчә, борынгы заманның сәүдә юлы өстендә ятадыр иде. Бу сәүдә юлының ничек булганын без хәзәрләр хакында сөйләгәндә күрдек. Ләкин монголларның Кубалай ханга кадәр (1259–1295) Балтыйк диңгезеннән алып Охотский вә Сары диңгезләргә кадәр булган җирләрне бер кул астына кертүләре, вә аларның «ям» почта ысулын кертеп, яхшы юллар ясаулары тагы шул сәүдә юлын яхшылатты. Бу заманда бай вә мәдәни Кытай белән Яурупа, Кара диңгез һәм хәзерге җәнүби Русия аркылы мөнәсәбәт тота башлады. Хәтта XIV гасырда бу Кытай юлы итальян җөмһүриятләрендәге сәүдәгәрләр өчен шулкадәр әһәмият алып китте ки, бу юл хакында алар сәүдәгәрләр өчен махсус кулланмалар да ясый башладылар. Мәсәлән, шулардан берсе итальян Пикалотти, ничек итеп Кыпчак ханлыгы аркылы үтеп, Кытайга бару хакында шундый мәгълүмат бирә: «Элек хәзерге Новороссийский урынындарак булган Тана шәһәреннән коман (кыпчак) телен белә торган бер тәрҗеман һәм ике хезмәтче, саклык өчен он һәм тозлы балык алырга кирәк, чөнки юлда ит күп очратып була. Кораллы сакчылар алырга кирәк түгел, чөнки Танадан алып

[1] Мөхкәм – таза, нык.
[2] Замкаларда – замокларда.
[3] Мөтәгаддид – күпсанлы.
[4] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[5] Задәкян — аксөяк; җирбиләүче.
[6] Тәүсыя кылып – киңәш итеп.

Кытайга кадәр бара торган юлны саклау өчен татар ханнары бик тырышканга күрә, монда кораллы сакчылар алуда хаҗәт юк», – ди. Пикалоттиның язуынча, юл хәраҗәте[1] бик аз чыга: ул хәраҗ бары китергән яисә алып килгән малның процент өлешен[нән] генә тора: «Малны 30–40 пот күтәрә торган повозкаларга төяп алып барасың. Бу повозкаларга өч дөя җиккән була». Пикалоттиның планы буенча, Тана шәһәреннән алып Җаек буендагы Сарайчыкка кадәр 34 көн вакыт кирәк, моннан инде степь белән һәм диңгез белән дә барырга мөмкин. Аннан Үргәнче утраулыгына барасың, ди. Шуннан башка итальяннар тарафыннан ясалган берничә Кытайга бара торган юлның карталары да бар. Ләкин 1370 елда Кытайда Чыңгыз сөяләсенең хакимияте бетеп, анда Милки[2] сөяләә эш башына кичкәч, Кытай белән монголларның арасы бозылгач, бу сәүдә дә зәгыйфьләнә, ләкин моннан соң да Һиндстан шикелле бай өлкәгә бара торган юл һаман да Алтын Урда аркылы шул ук югарыда күрсәтелгән юл белән бара. Ләкин Сарай яныннан узгач кына, Шәрыкка таба борылып китәсең. Шулай ук Иран маллары да Кавказдагы Дәрбәнд («Баб әл-Әбуаб»[3]) аркылы яисә Каспий диңгезе белән Әстерханга төшеп, анда Идел белән барып Донга төшеп, Тана шәһәреннән үтә. Менә шул юллар белән итальян вә рум сәүдәгәрләре йөриләр иде. Яисә Шәрык вә Гареб маллары, Идел елгасына төшеп, Болгарга кадәр күтәрелеп, шундагы зур базарда сатылалар. Бер яктан, Алтын Урда Гареб вә Шәрык маллары белән сату итсә, икенче яктан, алда сөйләгән үзендә ясала торган малларны төрле җирләргә, рус вә фин халыкларына сата һәм Алтын Урданың бер провинциясе булып киткән Болгар, Суар, Кашан, Биләр шәһәрләрендәге базарларда зур роль уйныйлар. Финнар вә руслардан чыга торган мехлар, Истанбулдан килгән җакмалар[4], Мисырдан килгән материяләр, фил тешеннән ясалган зиннәт әсбаплары, иярләр, кораллар, Мисырдан килгән пыяла нәрсәләре, Ираннан вә Кытайдан килгән чи йон вә ефәк материяләр, Бохарадан килгән мамык материяләр, Һиндстан-

---

[1] Хәраҗәте – салымы.
[2] Биредә сүз Кытайда 1368–1644 еллар аралыгында хакимияттә торган Мин династиясе турында бара.
[3] Баб әл-Әбуаб – Капкалар капкасы. Дәрбәнд шәһәренең борынгы атамасы.
[4] Җакмалар (ягмалар) – кием-салым; тукымалар.

нан килгән энҗе-мәрҗән, төрле дару вә тәмле исле тамыр вә үсемлекләр – һәммәсе Алтын Урда базарларында сатылып торалар.

Алтын Урданың шәһәрләрен тасвир кылучы шул заманның гарәп мөхәррирләре шәһәрләрдә христиан, мөселман, кыпчак, чиркәс, рус, рум, Гыйрак, Мисыр, Шам вә башка халыкларның сәүдәгәрләре булып, шуларның һәркайсына махсус үзләренең урам (асвак)лары булганын вә һәрбер милләт сәүдәгәрләренең урам вә кварталлары шуларның малларын саклар өчен мөхкәм диварлар белән әйләндерелеп алынганлыкларын язалар. Бу безгә чын-чыннан феодализм хөкем сөргән Яурупадагы «коммуна» шәһәрләренең тормышын тасвир иткән төсле тоела. «Алтын Урдада татарлардан сәүдәгәрләр булганмы?» дигән сөаль башка килә. Билгеле, аларда һөнәрчелек хөкем сөргән булып, ул осталар үзләренә махсус эшләп тә зәвык ясаган булсалар, аларда ник сәүдәгәрләр булмасын?

Чынлап та, ярлыкларда «базарда торганлар» дигән сүздән үз сәүдәгәрләре морад[1] булса кирәк. Нитәкки[2], феодаль Яурупада вә Русиядә бераз «сәүдә кылучы дворяннар» бар иде, шуның шикелле үк Алтын Урдада да булган булырга кирәк. Шулай ук итальян хөкүмәтләренең Алтын Урда белән ясаган могаһәдәләреннән[3] дә Алтын Урданың үз сәүдәгәрләре булганы бик аңлашыла.

**Акча.** Билгеле, сәүдә, бер яктан, алмаштыру ысулы белән булса, икенче яктан, алтын-көмеш, бакыр акчалар васитасы белән барган. Алтын Урдада чит халык акчалары йөрсә дә, үзенең дә Алтын Урданың төрле шәһәрләрендә сугылган үз акчалары ифрат та күп табыла.

Татарлар Чыңгыз хан заманында ук алтын, көмеш, бакырдан акча суга башлаганнар иде. Чыңгызның алган мөселман җирләренә махсус акчасы көмештән, бакырдан булып, өстенә гарәп хәрефе белән «падишаһе галәм»[4], «малик рикаб әл-имам»[5], «ходавәндә

[1] Морад – күздә тотыла.
[2] Нитәкки – шул рәвешле.
[3] Могаһәдәләреннән – килешүләреннән.
[4] Падишаһе галәм – галәм патшасы.
[5] Малик рикаб әл-имам – имамнарны яклаучының хуҗасы.

галәм, падишаһ руй зәмин»[1], «падишаһе җиһан»[2] күк ләкабләр[3] язган буладыр иде.

Алтын Урдада, гомумән, татар-монголлар хуҗа булган җирдә «даң», соңрак «тәңкә»[4] аталган акчалар булган. Бу акчалар дирһәмнең чирегә, бәгъзы урыннарда чирек мыскал авырлыгында булган. Алтын Урда акчаларының өстенә күп вакытта хөкүмәт сөрүче ханның «тамга»сы төшерелгән була, гарәп хәрефе белән шул заманның ханның исеме сугылган елы буладыр иде.

Борынгы татарларда Алтын Урда дәүләтендә акчаның хисабы «бәлиш» белән йөртеләдер иде. Безнең рубль, германнарның маркасы, французларның франкы күк, бәлишнең алтыны, көмеше булып, алтын бәлиш – биш мыскал авырлыгында, көмеш бәлиш сигез дирһәм көмеш авырлыгында буладыр иде. Ләкин бу бәлишнең бәһасы заманы белән үзгәрә, күтәрелә һәм төшәдер иде. Алтын Урдада акча суга торган җир Олуг Болгар, Суар шәһәрләрендә булып, шул ук вакытта Сарай шәһәрендә акча сугыладыр иде. Алтын Урдада үз акчаларыннан башка чит халык акчалары да йөри, мәсәлән, Иран туманы һәм динары, рум акчалары, соңра рус акчасы.

**Кәгазь, күн акча.** Кытайларда бик борынгы заманнан бирле кәгазь акча йөри, татарлар Кытайны алгач, алардан күреп, Үгәдәй хан кәгазь акча чыгарткан. Моны «чаю» дип йөриләр иде. Соңгы заманда бу кәгазь акча бик күбәеп киткән, Чыңгыз ясаган дәүләттәге берлек заманасында һәм соңыннан безнең Алтын Урдада бу кәгазь акча йөридер иде. Бу акча да «бәлиш» белән хисапланадыр иде. Ләкин алтын бәлишкә караганда кәгазь бәлиш шактый ким йөридер иде.

Шулай ук Алтын Урдада монголларда булган күннән ясалган «алатак» аталган акча да йөргән булырга кирәк.

**Юллар, почта.** Сәүдә турысында сөйләгәндә, юл вә почта системасы хакында да сөйләп китми мөмкин түгел. Бер яктан, юл вә почтаны Кытай, Һинд, Урта Азия һәм Иран шикелле җирләр белән

---

[1] Ходавәндә галәм, падишаһ руй зәмин – галәмнәр хуҗасы, җир йөзенең патшасы.
[2] Падишаһе җиһан – җиһан патшасы.
[3] Ләкабләр – исемнәр.
[4] Шуннан русча «деньга» дигән сүз чыккан. *(Авт. иск.)*

сәүдә мөнәсәбәте китереп чыгарса, икенче яктан, юлларның яхшылануы үзе сәүдәне арттырды.

Кыпчак иленең урыны төрле-төрле булып, анда урманлык җирләр, сахралар, сазламык җирләр бар иде. Бу зур җирне, төрле табигатьле өлкәләрне идарә кылу өчен, анда юл булырга кирәк була. Юл булмаганда, сәүдәгәрләрнең йөрүе, илчеләр күндерү, кирәк урыннарга гаскәр җибәрү, төрле олыслардан хәбәр алу мөмкин булмаячак. Шуның өчен дә Алтын Урда хөкүмәте юллар ясау өчен бик тырышадыр иде. Зур елгалар янында кеше үткәрер өчен көймәләр, махсус кешеләр куелган буладыр иде. Бәгъзы җирләрдә яр буйларында өйләр салып куеп, шунда түрәләр, елга аркылы чыгаручылар торалар иде. Кайсы урыннарда елгалар аркылы күперләр дә салынган буладыр иде. Бу хезмәттәге кешеләрне «кәмәче», «күперче» дип атыйлар иде.

Хөкүмәт түрәләрен үткәрер өчен, йөртер өчен халык ат бирергә тиеш, аларны кундырырга, ашатып-эчертергә тиеш иде. Моны «голуфә» (алапа) дигәннәр. Мондый түрәләрне «кунак-төшен» диләр. Шуның өчен зур юл өсләрендә «ям» исемле йортлар буладыр иде. Бу йортларда түрәләр өчен хәзерләнгән почта атлары хәзер торалар; юллар исә төзәтелеп, күперләр дә салынган иде.

**Дәүләт төзелеше.** Югарыда сөйләгәннән күрелгәнчә, Алтын Урда җәмәгатендә феодализм өчен икътисади вә иҗтимагый шартлар хәзер иделәр. Хәзер без аның сәяси төзелеше ничек булганын күреп карыйк, монда да без феодализм әсасларын нык табарбыз.

Әле Мәнгү хан үлгәнчегә кадәр (1259), Чыңгыз заманында тәшкил ителгән империянең берлеге бетмәс борын, Алтын Урдада Бату вә Бәркә хан булып торган чакта, Каракорымда торучы хан суверен (баш) булып хисапланып, Алтын Урда исә олуг ханлыкның вассалы хисапланадыр иде. Алтын Урда үзенең эчке эшләрендә мохтариятле[1] булса да, сугыш, солых, салымнар тәгаен кылу шикелле мөһим эшләрдә мәркәзгә табигъ[2] иде.

Ләкин Кыпчак иленең Монголиядә булган мәркәзгә бәйлануы акрынлап зәгыйфьләнә башлап, Мәнгү ханнан соң бөтенләй бетте. Шул чактан алып Алтын Урда ханнары үзләрен бик зур ләкабләр

[1] Мохтариятле – ирекле.
[2] Табигъ – буйсынган.

белән атыйлар: «хакан әл-әгъзам»[1], «әс-солтан әл-гадил»[2] диләр, русларда аларны «Царь»[3] дип йөриләр, рум кайсары белән бертигез зурлыкта итеп атыйлар иде.

Бу «чар[4]» ләкабен Алтын Урда ханы Үзбәк кайсар кечек Андроник Палеолог[5] кызына өйләнгәч, рәсми рәвештә йөртә башлаган булырга кирәк. Бу вакыйга Русия тарихында Иван III София Палеологка өйләнгәч булганын күрәбез. Шуның өчен дә без Үзбәк заманасында сугылган тәңкәләрдә Палеолог сөлäләсенең галәмәте булган ике башлы бөркет басылганын күрәбез.

Хан булыр өчен, Кыпчакта – үзенә махсус корылтай җыелып, шунда сайланырга һәм Алтын Урдада хан булыр өчен, әлбәттә, Чыңгызның Җүҗи исемле улы нәселеннән килергә тиеш иде. Алтын Урданың шәүкәтле заманасында ханнар мөстәбид[6] иделәр. Кыпчак ханнарының хакимияте «ханның атының тоягы кай җиргә басса, шул җир ханныкы була» дигән халык мәкале белән тәгъриф кылынадыр иде[7]. Ләкин, шулай булса да, Бәркә вә Үзбәк ханнар заманасыннан соң ханнарның хакимияте чикләнде.

Аны чикләүче элемент та аксөяк вә алпавытлар, ыруг башлыклары вә аларның җыены булган корылтай иде. Корылтай феодализм дәвере Яурупаның вассаллар җыелышыннан артык бер нәрсә булмаган. Ханнар үзләренең фәрман вә ярлыкларында үз исемнәреннән генә хәрәкәт кылмыйлар, бәлки аның хакимиятен чикләүче бөтен гонсырларның исемен санап чыгадыр иде. Мәсәлән, Үзбәк хан тарафыннан бөтен Русия митрополитына бирелгән бер ярлыкта: «Безнең бөтен кенәзләр (бикләребез)гә, олуг, урта һәм түбәнгеләренә (ягъни бикләр – феодалларның) һәм көчле воевода һәм вельможларыбызга һәм безнең төрле олысларны идарә кылучы (удельный) кенәзләребезгә» дип башлана, икенче бер Киев митрополитына Айтүләк хан тарафыннан бирелгән ярлыкта: «Урда һәм Олыс бикләренә» (князья

[1] Хакан әл-әгъзам – Бөек хакан.
[2] Әс-Солтан әл-гадил– гадел солтан.
[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[4] Чар – царь.
[5] Андроник II Палеолог (1259–1332) – Византия императоры (1282–1328).
[6] Мөстәбит – чиксез ирекле.
[7] Тәгъриф кылынадыр иде – аңлатыла иде.

Ордынские и Улуские[1]) дигән феодаллар да очрыйлар. Бу феодаллар Яурупадагы шикелле тәбәкага (иерархиягә) бүленеп, шуның бик зур эше булганы шикелле, бик аз әһәмияте дә бар иде. Менә шул татар феодалларының тәбәкасын шулай басарга мөмкин:

Олуг бик.

Түбән бик.

Олыс бик (удел кенәзе).

Ил бик (людский кенәз)[2].

Тархан (Яурупадагы рыцарьларга туры килә).

Алтын Урданың дәүләт төзелеше вә иҗтимагый ясалышы шулкадәр феодаль Яурупаныкына охшыйдыр иде ки, моны белгән Кара диңгез буенда торучы итальян сәүдә колонияләре Алтын Урда белән булган мөнәсәбәтләрендә андагы тормышны турыдан-туры Яурупадагы «герман халкының мөкатдәс империя»сенекенә охшаталар иде. Шуның өчен дә алар могаһәдәләрендә ханны – «император», бикләрне «барон» дип вә кечек феодалларны «квакеры» (шевалье-рыцарь) дип кенә атыйлар иде.

**Канун, ярлыклар.** Алтын Урда дәүләтендә төп законнар, башка олыслардагы күк, Чыңгызның «Яса»сы иде. Соңыннан ислам дине кабул ителгәч, мөселман шәригате дә керә башлады. Һәрбер ханның яңа чыгарган законнары, фәрманнары булып, аларны «ярлыг» дип атадылар. Ярлыклар баштарак монгол телендә йөртелгән булса да, соңыннан кыпчак илендә төркләр күплектән, ханнар, Монголиядән килгән монголлар төркиләшкәнлектән, ярлыклар, башка эш кәгазьләре уйгурчарак төрк телендә йөртелә башлаганнар иде. Ярлыклар, башка эш кәгазьләре Алтын Урда ханлыгында әле XV гасырда уйгур хәрефләре белән язылып килделәр.

«Ярлыг» монголча «җарлык» дигән сүздән алынган, әмер, фәрман мәгънәсендә. Монда без мисал өчен 1397 елда хөкүмәт сөрә башлаган Тимер Котлыг атлы ханның бер ярлыгының башын, ахырын күчерәбез: «Тимер Котлыг сүзем[3]. Уң кул, сул кулның угланларыга,

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[2] Русча исемнәр рус телендә сакланган язулардан алынды. *(Авт. иск.)*

[3] Әлеге текст галим А. Н. Самойловичның «Несколько поправок к ярлыку Тимур-Кутлуга» (1918) исемле фәнни хезмәтенә нигезләнеп тулыландырылды һәм төзәтелде.

төмән Әдегү башлык мең, йөз, ун бикләрегә, ичге кәндләренең [даругаларыга, казый, мөфтиләрегә, мәшаих, суфиларыга], диван битекчеләрегә, тамгачы, тартнакчыларыга, йортар юлаучыларга, букәүел, тоткауылларга, ямчы, шусунҗеләр, кошчы, барсчыларга, кимәче, күбрүкчеләргә, базарда торганларга. Бу ярлыгны тота торган Мөхәммәднең убака аталары борынгы кичкән Саин хан җагыдин бирү [бәйзә] ярлыг раст, [тар]ханлык йусуннига йөрүб, атасыны Хаҗи Бәйрәм хуҗаны безең хан агаларымыз сөергаб, тархан кылган җәркәсен аңлата үтүнде ирсә, үтүлен йүб күрүб, Мөхәммәд безең сөергал булуб, [тар]хан булыб торсун...».

Алтун нишанлык, алтун тамгалык ярлыг бирелде тарих сикез йөздә барс елы шәгъбан аеның алтынчы көнендә. Узу суының кенәредә Мучуранда ирүрдә битилде»[1]. Һәрбер ярлыкта ал, зәңгәр яисә алтын кара белән ханның исеме язылган. Шунда ук ханның тамгасы (аның гербы) төшерелгән буладыр иде.

**Ханның тормыш рәвеше.** Ханнар Сарай шәһәре янындагы «Гөлстан» дигән җирдәге зур сарайларда торалар. Ханнар күбрәк кышын гына шунда үткәрәләр, җәй көннәрендә, иске гадәтләренчә, күчеп йөриләр. Үзләренең киез өйләрендә гомер кичерәләр, аларның киез өйләре бик матурлап, алтын белән бизәлгән була. Шул өй эчендә тәхет куелган, тәхет тә алтын, асыл ташлар белән бизәлгән булып, аның аягы көмештән буладыр иде.

Бәйрәм көннәрендә тантаналы рәвештә читтән килгән илчеләрне кабул иткән вакытта хан үзе шул тәхет өстендә утыра. Олы хатыны, башка якыннары аның тирәсенә утыралар. Тәхетнең аяклары янына ханзадәләр утыралар. Әгәр дә ханның кызлары булса, хан алдында

[1] Сул канат, уң канат угланнарга, башлыклары Әдегү булган төмән бәкләренә, меңлек, йөзлек, унлыкларга, эчке авылларга, дин әһелләренә, аксакалларга, палата сәркатипләренә, чик буе тикшерү хезмәтчеләренә, үлчәүчеләргә, архитекторларга, юлчыларга, чик сакчыларына, элемтәчеләргә, азык салучыларга, кошчыларга, барсчыларга, көймәчеләргә, күперчеләргә, базар халкына. Бу ярлык иясе Мөхәммәднең белдерүенчә, аның ата-бабалары күптән үткән Саин хан заманында ук тарханлык ярлыгына ия булганнар; аның атасы Хаҗи Бәйрәм хуҗаны да абыебыз тархан иткән. Аның үтенеченең төпле, нигезле булуын күреп, белдерәбез: Мөхәммәдне тархан итәргә. Шулай итеп, алтынланган кызыл басма ярлык сигезенче елда, Барс елында җәен, шәгъбан аеның алтынчы көнендә, Днепр буенда Мөҗүрәндә булганда язылды.

утыралар иде. Ханның берничә хатыны булып, шулар эчендә берсе олы хатын аталадыр иде. Бу олы хатыннарның хакимиятләре бик зур булып, алар ирләренең рөхсәте белән төрле ярлыклар нәшер итә алалар. Бер ханның хатыны ярлык чыгарып, рус руханиларын салым түләүдән котылдырган иде. Ханнар хатыннарны татарлардан гына алмыйлар, рум кайсарларының кызларын алучы, рус кенәзләренең кызларына никахланучы ханнар да бар иде. Ханның хатыннары – аерым сарайларда, күчеп йөргәндә, аерым чатырларда торалар, аларның үзләренә махсус муллалары, мәсҗедләре була, үзләренең махсус аерым сакчы гаскәрләре булалар. Ул заманда татар хатыннары качмыйлар, голәма, шәкертләр белән һәм читтән килгән илчеләр белән утырдаш булуны бик яраталар иде.

Гомумән, Алтын Урда ханнары соңга таба иске Чыңгыз заманындагы садә тормышны онытып, рәхәт вә кәйфәгә бирелгәннәр. Эш эшләргә күп яратмыйлар, күбрәк эчке белән вә хатыннары арасында гомерләрен уздыралар булган. Мәсәлән, Үзбәк ханның[1] исерек килеш җомга намазына килеп, басып тора алмаганы мәгълүм. Гомумән, алар әхлак ягыннан да бик түбән вә бик ерткыч булганнар. Аларның кайсысы агасын, кайсысы анасын үтереп тәхеткә менгән, вә араларында үз үлемнәре белән үлүчеләре бик аз булып, кардәш ыруглары тарафыннан үтерелгәннәр.

**Идарә.** Алтын Урда ханы хөкүмәт сөргән бөтен патшалык рәсми баруларда гарәп сәйяхләре әсәрләрендә «әрд могаззәм»[2] дип аталадыр иде. Алтын Урда иле берничә кисәккә яисә өлешкә бүленеп, моны «олыс» дип атыйлар иде. Мәсәлән, Алтын Урдага табигъ булган Русия үзе берничә олыска бүленгән. Башкорт, мукшы илләре тагын аерым олыслар булып, Кавказ, Кара диңгез буйларында янә аерым олыслар булып, шундагы идарәнең башында торучы феодалларның исемнәре белән аталып йөртеләләр иде. Татарларга буйсынган, татардан башка халык тора торган олыс башында торучы кешеләрне баскак диләр иде. Русиянең һәрбер мөһимрәк шәһәрендә аерым бер баскак торадыр иде. Владимир шәһәре XII–XIII гасырларда

[1] Үзбәк хан (Мөхәммәд Солтан, ?–1342) – 1312 елдан Алтын Урда ханы. Мәнгү Тимер ханның оныгы.
[2] Әрд могаззәм – бөек, изге җир.

үзе Русиянең мәркәзе, пайтәхете булганга, анда «великий кенәз» торганга күрә, мондагы баскакны «олуг баскак» дип йөриләр.

Һәр олысның баскагы тора торган җирне «йорт» дип атыйлар. Һәрбер баскак үзенә тапшырылган җирне ханга буйсындырып тота. Аның әмерләрен, ярлыкларын җиренә җиткерә, баскак янында бер фирка гаскәр дә тора. Баскакның кул астында берничә түрәсе булып, бу түрәләр бер мәгълүм урында торып эшлиләр. Шул җирне «диван» диләр иде. Һәрбер олыс берничә кисәккә бүленгән булып, һәрбер бүлекнең башында аерым мәэмүр[1] торадыр, баскаклар буйсынган җирләрнең халкының санын язып чыгалар; халыктан салым, гошер (малның уннан бер өлешен) алалар иде.

Төп татар халкы тора торган шәһәр, олысларның башларында баскак урынына «даруга» торадыр. Аның да эше баскакныкы күк иде. Олыс, шәһәр, авыл даругалары буладыр иде.

Бөтен илне идарә кылып торыр өчен ханның янында бер мөәссәсә[2] бар иде. Бу иң зур хөкүмәт мөәссәсә дәүләт шурасы (Государственный Совет[3]) иде. Хөкем, идарә эшләренә даир зур эшләр, төрле олысларның диваннарында хәл ителә алмаган мәсьәләләр монда киләдер иде. Дәүләтнең зур түрәләре бу шураның әгъзалары иде. Эш, бу мәркәзи мөәссәсәдә каралганнан соң, ханга белдерелә, аның тасдыйкыннан[4] соң, шул карар ижра кылына[5]. Мондагы язу эшләрен башкарыр өчен «бетекче»ләре булып, алар ханга мөрәҗәгать кылынып язылган гариза, шикаятьләрне язып алалар, ханга докладлар ясарга тиешле кәгазьләрне хәзерлиләр иде.

Олысларда тиз генә эшләнергә тиешле ашыгыч эшләр өчен шул урыннарга махсус «илчеләр» күндереләдер иде.

**Дәүләтнең керере.** Алтын Урда дәүләтенең керере башлыча керем акчасыннан, халыктан алына торган салымнардан, Алтын Урдага табигъ булган халыктан алына торган, хираждан[6] торган, гомумән, салымнар Чыңгыз хан ясаган рәвештә алынган.

[1] Мәэмүр – чиновник, түрә.
[2] Мөәссәсә – оешма.
[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[4] Тасдыйкыннан – раславыннан.
[5] Ижра кылына – эшкә ашырыла.
[6] Хираждан – салымнан (кайбер ислам дәүләтләрендә мөселман булмаганнарга салына торган салым)

Чыңгыз заманасында кеше һәрбер биш җәнлек тиресеннән бер тире бирергә тиеш. Әгәр моны бирмәсә, кеше үзенең иркен югалтып, колга әйләнәдер иде. Бары тик дин руханилары гына бу салымны түләмиләр, әмма яһүд руханилары исә Алтын Урдада, башка халык белән бертигез булып, салым түләргә тиеш булган. Шулай ук йөз баш малы булган һәрбер кеше бер хайванын хәзинәгә бирергә тиеш иде.

Сугышлар кимеп, хөкүмәт төрле җирләрне алганда ганимәт[1] итеп, талап алган мал кимегәч, Алтын Урда хөкүмәте үзенең «чыкышы, хәриҗе»[2] өчен мал, акча табу юлын тәртипкә салган. Башлыча, салымнар өч төрле булып, берсе татарларның үзләреннән, икенчесе, аларга буйсынган халыклардан алына торган салым, өченчесе сәүдәгәрләрнең малларыннан алына торган пошлина яисә «тамга» салымы иде. Хөдүдләрдә[3] сәүдә урыннарында түрәләр торып, һәрбер малга ханның мөһерен, «тамга»сын салып, шул малдан бер микъдарын яисә акча алалар иде.[4] Алтын Урданың төп үз халкыннан алына торган салымнарның иң мөһиме «салигъ» атала торган, кеше башыннан алына торган салым булып, тагын «фәлән сәяк» дигән бертөрле салым булган. Амбарлары бар кешедән аерым салым алынып, аны «амбар малы» дигәннәр. Халык бәгъзы вакытта бу салымнарны түли алмый, моны «бурыч» диләр иде. Шулай ук үлчәүләрдән дә алына торган салым булып, аны «тотнак» дигәннәр. Күпердән чыккан өчен дә акча алынадыр иде. Мал, акча белән бирелә торган салымнардан башка Алтын Урда дәүләтендә халыкның хезмәте белән үтәлә торган салымнар да бар иде. Һәр кеше хәзинә малын, гаскәр йөртер өчен ат, үгез, дөя шикелле хайванын бирергә тиеш булып, моны «улак» диләр; түрәләр бер җиргә килеп төшсәләр, аларны кабул итәргә тиеш булып, моны «кунак-төшем» диләр, аларны туйдырырга тиеш булып, моны «шусун» диләр иде. Халык гаскәргә кеше бирергә тиеш булып, моны чәрик[5] «урын»

[1] Ганимәт – сугышта кулга төшерелгән дошман малы.
[2] Мәсариф һәм Расход дигән сүзне Алтын Урдада «хәриҗ», «чыкыш» дип атыйлар иде. *(Авт. иск.)*
[3] Хөдүдләрдә – чикләрдә.
[4] Русча таможня шул сүздән калган. *(Авт. иск.)*
[5] Чәрик – гаскәр.

диләр иде. Моннан соң әһали юлларны сакларга кирәк булып, моны «каравыл» диләр иде.

Салым җыю өчен элек халыкның санын язып алалар, китергән салымны ханның хәзинәсен идарә кылучыга тапшыралар иде. Баштарак бу сан алу эшен гарәптән булган түрәләр үткәргәннәр. Бу кешеләрне дә «баскак» дип йөргәннәр. Сан алучы шул ук вакытта кеше дә җыйган, һәрбер гаиләнең өч углы булса, берсен алган. Шулай ук бәгъзы кызларны вә хаерчеләрне дә алып китә торган булган. Мондый переписьләр һәрбер хан үлгән соңында ясалып торган. Мәсәлән, Батудан соң Сартак аз гына хан булып торып, үлгәч – Бәрәкә хан булгач, 1257 елда икенче сан алу булган.

Алтын Урдага табигъ булган[1] татарлардан, башка халыклардан мохтар[2] олыслар халкыннан салым шушы нәрсәләрдән алынадыр иде: чәчү җирләреннән, сукадан, су, балыклы күлләрдән, печәнлекләрдән, урманнардан, йөзем бакчаларыннан, бакчалардан, тегермәннәрдән алына. Бу салымнарны башта баскаклар җыялар. Соңыннан ханнар бу халыклардан салым җыю эшен өзеп, төрле чит җирдән килгән кешерләргә бирә башладылар. Әрмәниләр, яһүдиләр, Урта Азия кешеләре (харәзмиләр) җыя башлаганнар иде. Алар ханга үзләренә бирелгән олыс өчен бер микъдар акча бирәләр дә, халыктан үзләре теләгәнчә салым җыялар, халыкны бик каты кысалар. Шуның өчен Мәнгү Тимер хан бу эшне бетереп, салым җыю эшен татар түрәләре аркылы гына йөртә башлаган.

**Дин.** Монгол, Урта Азия төркләре Шәркый Яурупага Бату хан командасында килеп кергән чакларында Кыпчак илендәге халык төрле диндә иде. Хәзәрләрдән калган шәһәрләрдә, болгар шәһәрләрендә яһүд динендәге халык та күп иде. Ләкин шәһәр халкы Шәркый Яурупа төркләренең шәһәр халкы арасына һәм бер күчмә игенчеләр арасына да исламият таралган Болгар илендәге шәһәрләрдә исламият бик нык берләшкән, моның сәбәбе дә сәүдә аркасында, гарәп, Иран сәүдәгәрләре белән катышудан килде. Төркләрнең кул асларындагы фин халкы арасына (бигрәк тә болгарларда) исламият

[1] Табигъ булган – буйсынган
[2] Мохтар – сайланган.

бераз җәйләнгән[1] булса да, иске мәҗүсилек (шаманилык) бик куәтле, финнарның күпчелеге шаман динендә иде. Күчмә төркләрнең күбрәге һаман ата-баба динендә булып, шаманилар булган. Шулай булса да, мөселман халыклары белән икътисади мөнәсәбәт аркасында исламият тә таралган, хәтта половецларның теленә дә шактый гына гарәп-фарсы сүзләре кергән. Җирле төркләр арасында христиан динендәге кешеләр дә очрыйлар иде.

Кытай чикләреннән килүче монгол, Урта Азия төркләренең күбрәге шул ук шаман динендә булсалар да, араларында будда динендә булганнары да булган. Бу Һиндстаннан чыккан будда дине кытайлар арасына җәелгән; кытайлар белән ихтилят[2] аркасында монгол төркләренең дә кайсысы бу динне кабул иткәннәр.

Кыпчак иленә килеп хуҗа булган төрк-татар, монголлар Шәркый Яурупага килгәч, ислам, христиан галәменә күрше булганнар. Бу заманнар христианнар белән ислам дәүләтләре арасында «тәре сугышлары» (әһле салиб мөхарәбәләре) дип мәшһүр зур сугышларның дәвам кылып торган вакытлары булган. Шуның өстенә дә мәдәният ягыннан безнең Шәркый Яурупада христиан һәм ислам мәдәниятенең икесенең рәкабәт итә торган[3] урыннары иде. Шуның өчен Алтын Урда хөкүмәте дә рәсмән яисә христианлык, яисә исламият кабул итәргә тиеш иде. Татарларга иске шаман динендә дә, мәркәзе булган Кытайдан ерак торып, будда динендә дә булырга мөмкин түгел иде. Ләкин бу җирләргә булган ислам мәдәниятенең тәэсире күбрәк иде. Төрк җенесеннән булган Кара диңгезнең теге ягындагы сәлҗук төркләре, Мавәраэннәһердәге[4] төркләр инде күптән ислам динен кабул иткәннәр. Шуның өстенә дә Алтын Урда дәүләте, Бату үлеп, Бәркә хан булгач ук, Иранны алучы монгол ханнары белән дошман иде. Әмма ул Иранны алучы монгол ханнары мөселманнарга һөҗүм кылучы Яурупа христиан дәүләтләре белән иттифакчы шикелле дус иделәр; мөселманнар белән дошман иделәр. Алар мөселманнарның башлыгы булган хәлифәне төшереп, аның пайтәхете булган Багдадны алганнар иде. Мисырдагы, Сүриядәге

[1] Җәйләнгән – җәелгән.
[2] Ихтилят – дуслык.
[3] Рәкабәт – көндәшлек.
[4] Амудәрья белән Сырдәрья араларын Мавәраэннәһер диләр. *(Авт. иск.)*

мөселман дәүләтләре белән Иранны, Кечек Азиянең күп җирләрен алучы монголлар сугышалар. Шулай булгач, билгеле, кыпчак дәүләтенә дә мәҗүс Иран монголлары белән сугышырга иттифакчы эзләгәндә, мөселманнарны гына таба алачак иделәр. Менә шушы сәяси һәм мәдәни җәһәттән Бәркә хан үзенең якыннары белән рәсмән ислам динен кабул иткән; ул инде 1261 елда мөселман иде. Шуның аркасында Мисыр, Сүрия мөселманнары белән иттифак та ясалган иде.

**Дин иреге.** Исламият кабул ителсә дә, Алтын Урда илендә хәзәрләрдәге, олуг ханлыктагы күк, дингә ирек калдырылган иде. Чыңгызның «Яса»сы буенча һәммә дин әһеле хөрмәт кылынырга тиеш, беркемнең дә дине хәкарәтләнергә[1] ярамыйдыр иде. Бер-бер кешенең динен хәкарәт кылган өчен үлем җәзасы бирелә иде. Шулай итеп, Алтын Урда дәүләтендә ислам кабул ителгәч тә, дин хөрмәте калды. Бертөрле дин голәмасыннан да Алтын Урдага табигъ булган җирләрдә салым алынмыйдыр иде. Теләсә нинди диннең гыйбадәтханәсен татар шәһәрләрендә салырга ярыйдыр иде. Хәтта Русиянең православие кәлисәсенә иң тәэсирле рухание Сарай шәһәрендәге епископ хисапланадыр иде.

Ислам дине Бәркә хан заманасында кабул ителгән булса да, тәмамән җәелеп җитмәгән иде. Ислам дине иң куәтле рәвештә Үзбәк хан заманасында җәелде, аның заманасында ислам йортларыннан голәмалар бик килеп йөрделәр.

Мәшаих, фәкыйһләр, башка голәмалар күбәйгән иде. Ханнар тирәсендә Мөхәммәд нәселеннән булган сәедләр була. Алтын Урда дәүләтендә мәчетләр салынган, мәдрәсәләр дә зоһур итеп[2], аларда укучы шәкертләр хөкүмәт каршында бик кадер-хөрмәттә иде. Ханнар, хәтта ханнарның хатын-кызлары мәшаих, голәма шәкерт (талиблар) белән сөйләшергә яраталар иде. Шулай итеп, башка ислам йортларындагы күк, мәктәп, мәдрәсәләр ачылган, Бәркә хан заманында ук Алтын Урдага галимнәр, осталар чакырыла башлаган; анда зур галимнәр дә бар иде. Исламның мәшһүр галимнәреннән

[1] Хәкарәтләнергә – хурланырга, кимсетелергә.
[2] Зоһур итеп – күтәрелеп.

Котбетдин әр-Рази[1], шәех Сәгытдин Тәфтази[2], сәед Җәлалетдин, Хафизетдин Бәззази[3] күк галимнәр Үзбәк хан заманында Сарайда торганнар; алар аркасында Алтын Урданың пайтәхете гыйлем, мәгариф мәркәзе булып киткән иде.

**Алтын Урданың көчле дәвере вә инкыйразы.** Алтын Урданың иң шәүкәтле дәвере озакка бармады. Һәрбер дәүләт адәм шикелле: аның балачагы, егет вакыты, картаеп, әгъзалары бетә башлаган чагы, ниһаять, үлеп, тәне вак кисәкләргә таралган вакыты була.

Алтын Урда да шулай ук: аның яшь егет чагы Бату хан, аның хәләфе[4] Сәртак, Бәркә хан заманасында булса, аның үсеп җиткән шәүкәтле дәверләре ислам мәдәниятенә бирелгән Үзбәк хан (1312–1340) заманасында булды. Бу заманнарда бер вакыт дөньяның хуҗалары хисапланган Рум кайсарлары Алтын Урда дәүләтеннән куркып торалар, ханнарга кызларын бирәләр, алар белән кардәш булырга тырышалар, аларның мөселман булуларына карамыйлар иде. Мисыр патшалары да кыпчак ханнарына иттифакчы булырга телиләр, бүләкләр бирәләр, кода булышырга бик сөяләр иде. Рус кенәзләре дә килеп, Алтын Урда дәүләте каршында кол күк сәҗдә кылалар, Рума папаларын алырга илчеләр итеп җибәрәләр, рус руханилары да ханнардан сәдака ашарга тырышалар. Италиядәге Җәнүә[5], Венеция җөмһүриятләре дә Алтын Урда белән сәүдә могаһәдәләре[6] ясыйлар, аларны император дип атыйлар иде.

Бу чакларда Алтын Урда шәһәрләренең чәчәк аткан заманнары булып, аларда сәүдәгәрләр тулып яталар, галим-голәма ханнар

[1] Котбетдин Мөхәммәд бине Мөхәммәд әр-Рази (?–1364) – «Тәхтани» дигән ләкаб белән исеме мәшһүр дин галиме, философ, мантыйк белгече. Берникадәр вакыт Алтын Урда башкаласы Сарайда яши һәм иҗат итә.

[2] Биредә сүз 1352–1353 елда шәһре Гөлстанда (Сарай Бәркә резиденциясе) «Тәлвих галя әт-Тәүзих» һәм «Шәрхе әт-Тәлхис» исемле китаплар язып, Җанибәккә адреслаган Тәфтазани (Мәсгуд бине Гомәр әл-Хорасани ән-Нисаи әш-Шафигый) турында бара.

[3] Хафизетдин Мөхәммәд Харәзми Кәрдәри Бәззази 1343 елда Харәземдә туган, башлангыч белемне шунда алып, Болгарга килеп укыган, Сарайда, Әстерханда, Кырымда дәресләр биргән. Аксак Тимер Сарайны җимергәч, Төркиягә күчеп киткән.

[4] Хәләфе – тәхет варисы.

[5] Җәнүә – Генуя.

[6] Могаһәдәләре – килешүләре.

тирәсендә йөриләр, мөселман мәсҗедләре, чиркәүләр, кәрвансарай, мунчалар Сарай, Болгар шәһәрләрендә бик күп иде.

Шушы шәүкәт, шушы зурлык 1359 елларга кадәр барган, бу ел исә, атасын үтереп хан булучы, ахыргы куәтле Бирдебәк ханның үлгән елы иде. Шуннан соң заманнар алмашты. Алтын Урда илендә канлы кардәшләр сугышы башланды. Шул вакыттан игътибарән Алтын Урда дәүләте инкыйразга (бетүгә) йөз тотты.

XV гасырның ахырында бөтен Яурупага икътисади үзгәрешләргә вә аның нәтиҗәсе буларак сәяси үзгәрешләргә сәбәп булган бер вакыйга туган; ул исә яңа юлларның ачылуыдыр. Әүвәл заманнарда, югарыда сөйләнгәнчә, халык Кытайга, Иранга вә Һиндстанга коры юлдан йөриләр: Балтыйк диңгезеннән кереп, Идел елгасына төшәләр; Дарданелл яисә Босфор аркылы Кара диңгезгә кереп, Кырым яисә Азак шәһәре янына туктыйлар; анда Дон елгасы белән менеп, Иделгә төшәләр; Идел белән барып, иске (Итил) шәһәре яисә аның урынына салынган «Әстерхан» яисә «Хаҗитархан» шәһәреннән Хәзәр диңгезенә төшеп, кораб белән Иран яисә Урта Азия аркылы Шәрыкның мәдәни вә бай өлкәләренә барып, алыш-биреш итәләр иде. Менә XV гасырда бу юл үзенең иске әһәмиятен югалтты; сәүдәгәрләр Колумб вә башка эспаньол яисә португалиялеләр ачкан мохит диңгезләре[1] белән Һинд, Иран, Кытайга йөри башладылар. Безнең Идел буе әүвәлге «юл өсте»леген югалтты. Шул сәбәптән читләр белән алыш-бирешләре булган шәһәрләр бушый башлады. Сәүдәгәр вә сәйяхләр азая башладылар. Базарлар бушады; Гареб белән Шәрыкта гына мал алмашуда иштиракь кылган[2] татар сәүдәгәрләре вә мал йөртүче татар көймәче вә ямчы (ямщик) эшсез калдылар. Хәят үлде. Аның өстенә икенче бер икътисади бәла Алтын Урда өстенә килде: Дарданелл кырыйларын XIV гасырда ук госманлы төркләре алдылар. Соңра XV гасырда Истанбул госманлылар тарафыннан алынгач, бөтен бугазлар төрекләр кулына күчте. Кара диңгез кырыйларында, Кәфә, Азак кебек шәһәрләрдә торган вә татарлар белән сәүдә кылган Җәнүә вә Нәдикле (Венеция) итальян колонияләренең сәүдәләре госманлыларның теләгенә терәлеп калды. Госманлылар элек күп тамга малы (пошлина) ала башла-

[1] Мохит диңгезе – океан.
[2] Иштиракь кылган – катнашкан.

дылар. Шуның өстенә дә бу итальяннар белән төркләр арасында бертуктаусыз низаг вә сугышлар китте: бугазлар аркылы итальян көймәләре йөрмәс булды, шуның нәтиҗәсендә сәүдәдә чит илләр белән мөнәсәбәттә юл булып торган Идел буе икътисади яктан тәмам корыды. Хөкүмәтнең иң мөһим килере тамга малы булганлыгыннан, аның хәзинәсе бушап калды.... Шул икътисади сәбәпләрнең нәтиҗәсе буларак хөкүмәт гаскәр асрый алмас булды, шуның өчен илдә башбаштаклык вә ихтилаллар[1] башланды, хөкүмәт бик тиз алмаша башлады.

Алтын Урданың егылуына икътисади бөлгенлектән килгән идарәнең начарлыгы да тәэсир итте. Бату ханнан соң ханнар зур бер илнең хуҗалары булып алганнар; аларны тикшереп торучы бер мәркәз Мәнгү хан үлгәч беткән, «ханның ат тоягы кая басса, шул җир ханныкы» дип уйлап, алар Сарай шәһәренең «Гөлстан» аталган бистәсендәге гөлләр арасындагы матур бакчаларда үзләренең хисапсыз җария вә хатыннары белән хозур кылып яталар. Җәйнең кызу чакларында исә, күчеп китеп, киез өйдә кымыз эчеп сыйланудан бушый алмыйлар иде. Алар ифрат эчкегә бирелгәннәр. Хәтта, алда әйтелгәнчә, Үзбәк хан күк мәшһүрләре дә җомга көннәрендә намаз укый алмаслык, аякта басып тора алмаслык кәефле булалар иде. Алар эш белән шөгыльләнүне сөймиләр, Үзбәк хан иң эшлекле ханнардан хисапланса да, эшнең тәфсыйләтен тикшерергә һич сөйми иде.

Бервакытта аңар Мисыр хөкүмәтеннән килгән хатны укый башлагач, «әгәр анда сәламнән башка нәрсә язылган булса, вәзирләр белән сөйләшегез» дип, эшне аксөякләр һәм бикләргә тапшырган иде. Тора-Мәнгү хан (1281–82)[2] исә эш белән шөгыльләнүдән нәфрәт итәдер иде. Әлхасыйль, хөкүмәт эшләрен ханнар үзләре күп карамыйлар, һәммә эшләрен вәзирләре башкаралар иде. Аларның бөтен эшләре шул хозур кылу, фәкыйрьләр, шәехләр, фәкыйһләр һәм читтән килгән сәйяхләрнең экиятләрен тыңлау иде.

Алтын Урда ханнарының хәрәмнәрендә әллә никадәр күптөрле милләттән хатыннар буладыр иде. Менә шул хатыннар исә хөкүмәт

[1] Ихтилаллар – фетнәләр.
[2] Тора-Мәнгү хан (Тода-Мәнгү хан) – 1282–1287 елларда Алтын Урда ханы, Батый ханның икенче улы Туканның улы.

эшләренә катышалар, ханнарның ярлыкларының кайсысында «хатыннар һәм әмирләрнең фикерләре шулай» дип язылган буладыр иде. Бу хатыннар мөстәкыйль бүләкләр алалар, бүләкләгән кешеләрне яклыйлар. Мәсәлән, рус кенәзләре үзләренә олуг кенәзлек ярлыгы алырга килгәндә, иң элек ханның тәэсирле хатыннарына ошар өчен, аларга кыйммәтле бүләкләр алып киләләр, шуның өстенә дә хан хатыннары күбесенчә төрле милләтләрнең патша кызлары булганлыктан, үзләренең ватаннары файдасына хәрәкәт итеп, Алтын Урда дәүләтенә зарар иттерәләр иде. Ханнарны үтерүдә, яңа хан менгезүдә һәрвакыт шул ханнарның хәрәмендәге хатыннар роль уйныйлар, әлхасыйль, һәр җирдәге күк, Алтын Урда дәүләтендә дә сарай хатыннары эшкә катышалар иде. Бер яктан, ислам Габбаси хәлифәләренең башларына шул «хәрәм» шактый бәһага төшкән булса, Алтын Урданың бетүенә дә кыйсмән шул ук сәбәп ярдәм итте, ханнар үзләре эшкә күп катышмагач, билгеле, дәүләттә сарай тирәсендә йөргән кешеләр баш булалар, теләгәнчә халыкны талыйлар, илне саталар, ниһаять, ханнарын үтереп, тәхеткә үзләре кичәргә тырышалар иде. Нугай, Мамай, Идегәй күк сарай хезмәткәрләренең фетнәләре шул иде.

Шулай итеп, башта эшлекле, кулларында кылыч, күз алларында корылтайда нәшер ителгән Чыңгызның «Ясса»сы булган хәлдә идарә иткән Бату, Сартак күк садә ханнар урынына башка төрле ханнар килеп чыкканнар. Болар исә сарайда тәмле ашап, исерткеч эчеп, җарияләр, биюләр, җырлар эчендә үскән нәзек табигатьле кешеләр булып, аларның әхлаклары да бозылган: бер-берсен үтерәләр, ата баланы, бала атаны, борадәрне үтерүне нәрсә дип тә белмиләр иде. Бирдебик хан[1] үзенең улы тарафыннан үтерелгән, Җанибик[2] (1342) исә үзенең борадәрен үтергән иде.

**Үзара сугышлар һәм аның нәтиҗәсе.** Күп хатын алу аркасында Җүҗи балалары шулкадәр күбәйгәннәр иде ки, алардан аерым бер арду ясарга мөмкин иде. Ләкин алар ватан вә халык өчен начар эштән башка бер нәрсә дә эшләмиләр, аларның һәркайсы[ның максаты] җылы урын алу яисә үзенең кардәшен, ханны үтереп, үзе яны-

[1] Бирдебик – Бирдебәк хан (1310–1359), 1357 елдан Алтын Урда ханы Җанибәк ханның улы.

[2] Җанибик – Җанибәк хан (?–1357/58), Алтын Урда ханы, Үзбәк ханның улы.

на партия җыеп, Алтын Урда тәхетенә кичү иде. Шуның аркасында ифрат каты канлы сугышлар башланды. Ханнар берсе артыннан икенчесе тәхеткә менә, төшә башладылар. Бер үк вакытта өчәр хан тәхеткә менеп, бер-берсе белән якалаша башладылар.

Алтын Урдада иллегә якын хан булып узды. Шушы ханнар тәхминән[1] 250 ел хөкүмәт сөрделәр: димәк, һәркайсы гомумән алганда бишәр елдан артык тормадылар. Шуларның бик күбесе үз үлеме белән түгел, бәлки бер-берсен үтерешеп, дөньядан киттеләр.

Шулай итеп, мәркәзи хөкүмәт зәгыйфьләнде. Ул зәгыйфьләнгән саен төрле олысларны идарә кылып торучы бикләр, ирләр куәтләнделәр, аларның әүвәледә үз гаскәрләре буладыр иде. Бу ирләр истикъляль[2] алып киттеләр. Мәркәзи хөкүмәт боларның үзләреннән курка башлады. Алар бер-берсе белән сугышып, кырылыша башладылар. Һәркайсы үз исеменә нәкъ мөстәкыйль хөкүмәтләр күк акча сугалар, чит илләр белән мөнәсәбәттә булалар иде. Боларның илчеләре сарай ханыннан рөхсәтсез чит патшалыклар белән сугыша, солых ясый, иттифакка керер өчен төрле илләргә йөреп торалар иде.

**Икътисади ярлылык.** Бу бертуктаусыз сугышлар, мәркәзи хөкүмәтнең зәгыйфьлеге аркасында халык хөкүмәтне санламас, хөкүмәткә салым түләмәс булды. Теге истикъляльият алган бикләр дә, халыктан алган салымны хөкүмәткә тапшырмыйча, үз мәсарифларына[3] тота башладылар. Шуның өстенә дә тагы әүвәлге «тамга» салымы яисә пошлина да хәзинәгә кермәс була башлады. Чөнки бу тәртипсезлек хөкем сөргән, бертуктаусыз сугыш булып торган җиргә чит сәүдәгәрләр, куркып, малларын китермәс булдылар. Илдә мал бетте, хәзинәдә акча кимеде. Идел өстендә сәүдә көймәләре югала башлады. Әүвәлге «Һинд юлы» аталган Идел елгасы буенча йөри торган Яурупа сәүдәгәрләре юлны башка җирдән, диңгездән эзләп, Африканы әйләнеп йөрү юлын эзли башладылар. Менә шушы икътисади сәбәп Алтын Урданың төшүен тизләткәннән тизләтте.

**Күршеләрнең куәтләнүе.** Әүвәл Алтын Урдадан куркып, хираҗ (дань) түләп торган күршеләр дә хәзер Алтын Урданы санламас булдылар. Алтын Урда хөкүмәтенең аларга каршы тоткан кешелек

[1] Тәхминән – якынча.
[2] Истикъляль – бәйсезлек.
[3] Мәсарифларына – чыгымнарына.

нигезенә һәм мохтарият әсасына[1] корылган сәясәте үзләре зәгыйфьләнеп, берлек беткәч, үзләренә зарар гына булып төште. Уралның теге ягындагы Себер халыклары, башкортлар истикъляләият ала башладылар. Әүвәлге бүленгән Русиянең урынына хәзер Мәскәү тирәсенә җыелган великорусь милләте зоһур итте[2]. Боларның мөстәбид[3] кенәзләре элек ханга тәрилкә тотып[4], иелеп, сәҗдә кылган булып, аларның түрә, хәрәмнәрен сатып алып, «дань» җыю эшен үз кулларына алдылар, соңра[к] ханга бер дә салым бирмәс булдылар. Алтын Урдага түли торган салым белән үзләренең «калта» (бумажник)ларын тутыра, татарларга һөҗүм итәр өчен ул акчага гаскәр, корал хәзерли башладылар. Ниһаять, берничә сугышта татарларны җиңделәр, ханнарның баскакларын куа, ханның ярлыгын аяк астына салып таптый башладылар. Үзләре һөҗүм итеп, сатлык татар ханзадәләре белән берләшеп, Сарай шәһәрен берничә мәртәбә яндырып чыгып киттеләр. Шулай итеп, XV гасырның ахырында 50 ханны тәхеткә менгезгән, 250 елдан артык гомер сөргән бер бөек татар дәүләте ишелде, шәһәрләре таш өеме, байгыш оясы булып калдылар.

**Алтын Урда беткәч.** Алтын Урда дәүләте урынына берничә вак ханлыклар килеп чыкты. Җәнүби Шәркый Яурупада – Кырым ханлыгы, Уралның Азия ягында – Себер ханлыгы, Иделнең түбәнге агымында – Әстерхан ханлыгы, Идел, Җаек елгалары арасындагы сахраларда – Нугай урдасы, Кама, Идел буйларында Казан ханлыгы ясалды. Бу исә яңа дәүләтләр ясалу түгел, бәлки Алтын Урданың вассаллары, сувәрән[5] көчсезләнгәч, тәмам истикъляль алып китүләреннән генә гыйбарәт иде. Шуның өчен дә бу илләр үзләре дә феодализм әсасларын саклап калдылар.

### 3.2. Казан урдасы яисә ханлыгы

**Казан урдасының килеп чыгуы.** Кама, Идел елгаларының йортлары Алтын Урда дәүләте ясалганнан соң, шул дәүләтнең бер

[1] Мохтарият әсасына – ирек, бәйсезлек нигезенә.
[2] Зоһур итте – килеп чыкты.
[3] Мөстәбид – изүче.
[4] Тәрилкә тотып – ярарга тырышып.
[5] Сувәрән – суверен.

олысы рәвешен алган иде. Бу өлкәдәге монголлар һөҗүме вакытында бозылган шәһәрләр төзелгән, Болгар шәһәрләре XVI гасырда, XV гасырның ахырларында шактый әһәмиятле мәркәзләр булып торганнар; әле Алтын Урданың күбрәк акча суга торган урыннары шушы шәһәрләр иде. Болгар иленең төп җирле халкы, элекке замандагы күк, үзләренең ыруг тормышлары белән көн күреп, мохтар бикләре тарафыннан идарә кылыналар иде. Ләкин Болгарның мөстәкыйль дәүләт булган чагындагы төрк гыйркыннан[1] баш милләт булган болгар халкы акрынлап башка төрк-татар ханнары белән катнаша башлады.

Иске Болгар төркенең теле акрынлап хәзерге Казан татарының теленә якын бер телгә әверелә башлады.

Алтын Урда дәүләте бетәргә якынлашты. Хан тәхетенә утырырга теләүчеләр күбәйде. Шуларның бәгъзысы бер урынга, кайсысы икенче урынга килеп утырып, үзләрен мөстәкыйль хан итеп игълан итә башладылар. Мондый башлыклар үзләренә ияргән гаскәрләр белән безнең борынгы Болгар өлкәсенә дә килеп йөри башладылар.

Алтын Урда илендә башбаштаклык булып торган чакта Болгар өлкәсе дә Алтын Урда мәркәзенә иярүдән чыгып, үзенең җирле ханнары тарафыннан идарә кылынып торадыр иде. Ләкин XV гасырда Болгарның иске шәһәрләре, Болгар шәһәре үзе элекке әһәмиятен югалткан иде, ул ничә мәртәбә рус, Суздаль кенәзләре тарафыннан, Новгород ушкуйниклары тарафыннан таланган, Алтын Урдада башбаштаклык булу сәбәпле, Идел, Чулман (Кама) елгалары буенда барган сәүдә дә тукталган, шул сәбәпләрдән Шәһре Болгар да үзенең иске мәркәзлеген югалткан иде. Хәзер бу илнең мәркәзе олы юл булган Идел, Кама елгаларыннан бераз читтә, Казан суы аталган иделгә[2] коя торган бер суның кырыендагы Казан (Иске Казан) атлы бер шәһәрдә булып, бу шәһәр бер Болгар ханчыгы тарафыннан идарә кылынып торадыр иде. Ләкин Иске Болгар илендә яңадан бер тәртипле дәүләт оешмасының ясалуының бәйнәлмиләл[3] бер кирәклеге дә бар иде. Яурупаның шимале хәзер уяна башлаган, Шимали

[1] Гыйркыннан – нәсел-нәсәбеннән.
[2] Иделгә – биредә: елгага мәгънәсендә.
[3] Бәйнәлмиләл – халыкара, дәүләтара.

Германия, Голландия, Англия җирләре XV гасырдагы сәүдәдә зур роль уйный башлаганнар, шуның өчен дә болар белән Җәнүби Яурупадагы итальян җөмһүриятләре арасында сәүдә конкуренциясе туган иде. Дарданелл-Босфор госманлылар кулына керү, Кырымның да XV гасырның ахырыннан алып госманлы солтанлыгының вассалына әйләнүе аркасында да Алтын Урдада башбаштаклык хөкем сөрү сәбәпле, Шәрык маллары иске юл белән килеп, итальян (Җәнүә-Венеция) сәүдәгәрләренең кулына төшми башлады. Диңгез юллары акрынлап килеп чыга башласа да, әле бу юлларның артык әһәмияте юк; Африканы әйләнеп, җир читендә ерак Сүәеш каналы ачылмаган да, ул җирләр дә әле Яурупаның тәэсиренә төшмәгәннәр иде. Шуның өчен Шәрыктан килә торган маллар, бигрәк тә Иранның ефәге яисә Төркия аркылы йөри яисә Каспий белән килеп, Идел елгасын менеп, аннан ук Москва-река белән килеп, Клязьмага кереп, шулай елгадан елгага барып йөреп, Балтыйк диңгезенә чыгарга кирәк иде, вә акрынлап яурупалылар татар вә руслар аркылы малны хәзер зур әһәмият кәсеп итеп бара, шул юлның уртасы булган Иделнең ярымагымындагы борынгы Болгар олысы зур бер юл өсте иде. Бу җир кем кулында булса, Яурупа белән Шәрык сәүдәсенең ачкычын шул кеше тотарга тиеш иде. Ләкин, алда сөйләгәнчә, XV гасырның яртыларына кадәр бу юл өстендә бер көчле хакимият вә бу юлны саклар өчен бер көч юк. Шуның аркасында иренмәгән һәрбер группа бу юлдагы кәрваннарны талыйдыр иде. Менә шуның өчен вә шул әһәмиятне белеп булса кирәк, Алтын Урдада тәхет даулап йөреп тә, соңра[к] аннан сөрелгән хан балалары – Чыңгыз нәселеннән булган аксөякләр килеп йөри башлаганнар.

XV гасырның урталарында Кырыкташ ханның торыны элек Сарай ханы булып та, соңра[к] аннан куылып, Кырымга киткән, соңра[к] аннан да сөрелгән, Олуг Мөхәммәд хан бу башта Алтын Урдага вассал булган Болгар олысына килеп, Казан шәһәрен алып, шул җирдәге халыкларны үз кулына кертеп, ханлык төзеде.

Казан дәүләте XV гасырның беренче ярымыннан алып 1552 елга кадәр гомер сөрде. Шушы йөз елдан бераз артык хәяттә Казан дәүләтенең тәхетендә уналтылап хан булып үткән, шуларның сигезләбе Олуг Мөхәммәд женесеннән (сөляләсеннән) булып, берсе

Себер ханнары Шәйбаниләр, өчесе Кырым ханнары (Гәрәйләр) җенесеннән, икесе Алтын Урда ханы Кечек Мөхәммәд[1] җенесеннән булган Касыйм ханнары, калганнары исә Нугай мирзаларыннан иде. Болар һәммәсе дә Чыңгыз хан нәселеннән килә торган кешеләр булып, бары шул җенестән булган кешеләр генә хан була алалар. Алар бикләрнең биге дип хисапланып, башкаларына караганда хөрмәтле, аларга баш хисапланадыр иде.

**Казан ханлыгының җире, халкы вә мәдәни дәрәҗәсе.** Казан ханлыгы үзенең табигате вә һавасы ягыннан урманлык вә ярымурман, ярымсахра җирләрдән гыйбарәт. Аның Сура елгасыннан алып башланган Урал тауларына кадәр барып тигән чикләре могтәдил[2] һавалы, ләкин иген чәчәргә яраклы бер урын иде.

Моның халкы да Алтын Урданың мәркәзендә булганы шикелле бер генә җенестән гыйбарәт түгел, бәлки аның төп дәүләт вә хаким гонсыры Алтын Урдадан менгән төрек-татарлар булса, анда татарлашкан борынгы болгарлар, мари, мукшы, ар шикелле финнардан вә чувашлардан гыйбарәт иде.

Менә шушы этнографи гонсырлар бер гасырдан артыграк вакытта бер икътисади вә сәяси халәттә яшәп, бер казанда кайнадылар вә бер-берсеннән мәдәният алыштылар, соңра Татарстан җөмһүрияте ясарлык бер дус кардәшле халыкларга әйләнделәр.

Казан ханлыгының күпчелеге булган читтән килгән вә болгар төркләреннән кушылып ясалган татарлар башка күчмә татарларга караганда мәдәни иделәр. Шуның өчен Казан ханлыгы Мәскәү кулына кермәстән 20 еллар элек Русиягә килеп йөргән сәйях немец үзенең хатирәләрендә «Казан татарлары башкаларга (татарларның башкаларына) караганда мәдәнирәк, чөнки алар кырларын игәләр, өйләрдә торалар, төрле һөнәрләр белән шөгыльләнәләр» дип, Казан ханлыгында халыкның утраклы булганлыгын һәм аларның иген белән шөгыльләнгәнлекләрен сөйли.

Вакыйган, монда халык авылларда тора, иген чәчәдер иде. Ләкин игенчелек күбрәк бик иске ысуллар белән, бәгъзы урманнарны яндырып, урынына ашлык чәчү, соңра ул җирне ташлап китеп, икенче

[1] Кече Мөхәммәд хан (якынча 1305–1450 еллар тирәсе) – Алтын Урда ханы (1437 елдан), Тимер ханның улы.
[2] Могтәдил – уртача.

җирне шулай ук итеп игүдән гыйбарәт булган. Ханлыкның җәнүби ягы комга таба башлана торган сахраларга ачык булганга күрә, ул җирләрдә күбрәк халык мал асрау белән шөгыльләнгәннәр. Татарлар никадәр XV–XVI гасырларда иген игә белсәләр дә, аларда күчмә гадәт бетмәгән, ярымкүчмәлекнең гадәтләре һаман да калган, җәйләүгә чыгу һаман да дәвам кылган булырга кирәк дип уйлана. Хәтта хөкүмәт сөрүче ханнар вә сыйныфлар да, җәй көннәрендә чатыр-тирмәләр корып, кәеф вә сафа кыла торган булганнар. Чөнки бу эш аларның мал асрау хуҗалыклары белән бәйләнгән булырга кирәк дип уйлана.

Ханлыкта бакчачылык та булган, чөнки иске татарча хатирәләр хәзерге Казан янындагы Архиерей йорты урынында һәм Зөя шәһәре урынында ханнарның алма бакчалары булганлыгын белдерәләр. Билгеле, әгәр бу кәсеп халыкта булмаса, ханнарда гына булмас иде. Димәк, Казан ханлыгының урманлы вә мәнбәт[1] җирләрендә гомер итә торган татар вә башка халыклар күчмә тормыштан үткәннәр, шулай да ярымкүчмә гадәт һаман калган, әмма аның сахралы җирләрендә мал асрау хуҗалыгы һаман дәвам кыла. Ләкин Казан ханлыгында да масса тормышы белән шәһәр халкының тормышы арасында зур аерма бар. Шуның өчен без хәзер Казан ханлыгындагы шәһәрләр хакында бераз сөйләп узабыз.

**Шәһәрләр.** Шәркый Яурупага монголлар килеп, Алтын Урда ясалганчыга кадәр Болгар илендә шәһәрләрнең күп булганлыгын күреп уздык. Ләкин Алтын Урда ясалгач, сәүдә юлы Кара диңгезгә күчте. Шуның өчен Болгар вә Иделнең урта агымы бары фин вә рус славяннары белән сәүдә өчен генә әһәмиятле бер урын булып калды, шуның өчен, бу җирләрдә сәүдә кимегәч, шәһәрләр дә артмады. Алтын Урдада башбаштаклыклар заманында исә шәһәрләр тагын да кимегән булырга кирәк. Без Казан ханлыгында да Казанның үзе, Арча вә берничә ныгытмалардан башка шәһәрләр очратмыйбыз, ләкин Казан исә XV–XVI гасырда зур шәһәр вә экономика мәркәзе.

**Татар Казаны.** Татар Казаны Болакның уң ягындагы биек урынга салынган иде. Хәзерге Кремль урынында булган биек урын Казанның башка урыныннан Таҗик чокыры (җырмагы) дигән бер тирән чокыр белән аерылган. Казанның эчендә Черек күл дигән

[1] Мәнбәт – үсемлекле урын.

күлләр булып, бу күл хәзерге Черек күл дигән бакча урынында иде. Күл кырыенда мунчалар булган, Казанның бер ягы Казанка (Казан суына) барып терәлгән. Казанканың ярлары биек, текә, бик биек булган. Казанканың уң ягы сазламыклар белән капланган булып, бераз баргач, кара урманнар башланган. Хәзерге Бишбалта ул заманда да булган. Бу бистә белән Казан арасында Ичкә[1] дигән бер агар су булып, Казанкага төшә; безнең Казан эчендәге Кабан күле Болак аркылы Казанка белән тоташкан булып, Болак агып торган, ул шактый тирән су булып, бер сажин тирәнлегендә булган. Хәзерге Николаевская площадьтан[2] Арча кыры башланган. Бу җирләрдә ул заманнарда урманлык, агачлык булган. Хәзерге югары урам (Воскресенский[3]) тавы яр шикелле текә булып, аның Николаевская площадь һәм Черек күлгә таба ягы да текә булган. Әүвәлге Казанның урамнары тар булган. Казан берничә мәртәбә янып, яңадан салынган, шуңа күрә борынгы Казан бик күп үзгәргән.

Борынгы Казан ике кисәктән гыйбарәт булган: бер кисәге чын шәһәр булып, икенчесе – бистә. Шәһәрнең үзе биек тауда, Казанка буенда булып, анда хан сарае һәм биш данә биек мәчетләр булган. Шул ук мәчетләргә үлгән ханнарны күмгәннәр. Бу җир хәзерге Кремль эче. Шәһәр, Болак һәм Казанка ягыннан агач дивар белән әйләндерелгән, аның капкалары булган. Хәзерге Соборный чиркәүгә каршы хан мәчетенең уң ягында хәзерге дворец мәйданында хан сарайлары булып, аларның берничәсе ак таштан, кирпечтән салынганнар.

Таҗик чокырыннан бистә башланып, ул да агач дивар белән әйләндерелгән. Гомумән, Казан диварлары юан агачлардан ясаган дүрткырлы буралардан гыйбарәт булып, эче таш, балчык белән тутырылган. Шуның өстендә качып ату өчен янә таза бүрәнәләрдән ясалган дивар булып, бу коймаларга тишекләр ясалган. Бу диварларның кырыенда бик тирән чокыр булган, борынгы Арча шәһәре дә Казан ханлыгына табигъ булган[4]. Башка шәһәрләр дә шулай ук

[1] Ичкә – Эчке Казан елгасы. Элек Югары Кабан күленнән агып чыгып, бүгенге Победилово бистәсе тирәсендә Иделгә койган кечкенә елга.
[2] Николаевская площадь – хәзерге Ирек мәйданы.
[3] Воскресенский урамы – хәзерге Кремль урамы.
[4] Табигъ булган – буйсынган.

ясалганнар. Шәһәрләрдәге биналар борынгы Болгар биналарының өслүбе белән салынган булып, бу өслүб исә Бизанес[1] – гарәпнең мигъмарының[2] кабалаштырылып катышуыннан мөрәккәб[3] булган.

**Сәнәгать вә сәүдә.** Казан ханлыгының мәркәзе Казан, бер яктан, феодал сувәрәннең замкы булса, икенче яктан, ул Идел аркылы үтүче сәүдәнең дә мәркәзе булган. Башта бер ныгытма ителеп салынган бу шәһәр соңыннан бер сәүдә мәркәзенә әйләнгән.

Борынгы феодаль Яурупаның зур шәһәрләрендәге шикелле, Казанда һөнәр ияләре торганнар. Болар хакында ачык мәгълүмат булмаса да, әүвәлге Болгарда, Сарайдагы шикелле, монда да зиннәт әсбаплары, кораллар, чүлмәкләр шикелле нәрсәләр эшләнгән булырга кирәк дип уйлана. Әмма Казан шәһәренең сәүдә мәркәзе булуы хакында ачык мәгълүмат күп сакланып калган. Казан ханлыгы дәвере ифрат күп сугышлар белән баглы булганга, бу заманда, билгеле, сәүдә ул кадәр көчәеп китте дип әйтеп булмый, ләкин шулай булса да, Иделнең урта агымы бу дәвердә үзенең татарларга кадәрле булган Болгар дәверенә кайта язды.

Сәүдәне сөйли башламас борын, бу сәүдәнең характерын белеп китәргә кирәк була. Элекке югарыда әйтелгән немец сәйяхе Һерберштейн[4] алтын вә көмеш акчаның татар массасы кулында булмаганлыгын, аңарга бары сәүдәгәрләр генә малик[5] булганлыгын, сәүдәнең күбрәк алмаштыру ысулы белән барганлыгын сөйли. Димәк, сәүдәгәрләр бер-берләре белән акча белән сәүдә итсәләр, бу яктан монда акча хуҗалыгы хөкем сөрсә, әмма масса белән сәүдәгәрләр арасында алмаштыру ысулы белән булган.

Шул ук сәйяхнең сүзеннән без XV гасырда татарлар арасында бер сәүдәгәр сыйныфы чыкканлыкны күрәбез ки, ул сыйныф кулында алтын вә көмеш тә җыелган булган. Ләкин бу Һерберштейн сөйли торган «күбесе» ничек килеп чыккан, аны белеп булмый. Безнең фикеребезчә, бу феодализм әсасындагы җәмгыятьтә сәүдә шул ук хаким сыйныф булган феодалларда булырга кирәк. Ләкин чит ил-

[1] Бизанес – Византия.
[2] Мигъмарының – төзү-архитектура стиленең.
[3] Мөрәккәб – оешкан.
[4] Һерберштейн – Герберштейн Зигмунд (1486–1566), барон, алман илчесе һәм сәяхәтчесе.
[5] Малик – ия.

ләрдән килгән таҗик, әрмән, грузин сәүдәгәрләренең булуы – мәнбәгъләр[1] белән исбат кылыналар. Казандагы хәзерге искедән калма «Грузинский», «Әрмәнский» урамнарының булуы, шәһәрдә, нәкъ сарайлардагы шикелле, боларның аерым бистәләренең булуын да күрсәтә. «Таҗик» ермагының булуы да шуны ук исбат кыла. Шуның өстенә дә Казандагы әрмәннәр Казан мөхасарәсе[2] вакытында русларга юл күрсәтүләре, соңыннан Иван Грозный[3] аларны, сез безнең өчен дә ышанычсыз булырсыз дип, Казаннан сөрүе дә шуны күрсәтә. Казанда сәүдәгәрләр шактый күп булган булырга кирәк. Казан ханлыгы дәверендә сәүдәгәрләрдән алына торган бер салым булганлыгы, соңра руслар бу салымны Еналеевшина[4] дип атап, сәүдәгәрләрдән җыя торган булулары шуны күрсәтәдер. Казан җәйнең бер вакытында ярмаркага әйләнеп китә торган булган. Бу ярмарка күп вакытта хәзерге Усиядә[5] Идел уртасындагы бер атауда була икән. Моны руслар «сәүдә атавы» (Гостиный остров) дип йөри булганнар. Бәгъзы вакытта исә бу ярмарка Арча кырында була торган булган: хан үзе дә чатырларын корып, шунда хазир була; кабаклар ачыла, кәеф вә сафа кылып, хәзерге татар авылларындагы зур җыеннар шикелле, бер бәйрәм ясый торган булганнар. Бу ярмарканың әһәмияте нәкъ XIX гасырның Русиясендәге Мәкәрҗә ярмаркасы төсле булган. Затән[6], Мәкәрҗә ярминкәсе үзе Казандагы Иван Грозныйның атасы тарафыннан күчерелгән булган. Һерберштейн фикеренчә, Василий, казанлыларга үч итеп, гадәттә Казан янында сәүдәгәрләр атавында булып килә торган ярмарканы Нижний Новгородка күчерде һәм үзенең тәбәгаләренә[7] бу атауга барып сату итүне бик каты җәзалар белән куркытып мәнгы итте.[8] Ул бу ярмарканы күчерү казанлыларга бик зур зарар китерер дип уйлады, татарлар

[1] Мәнбәгъләр – чыганаклар.
[2] Мөхасарәсе – камалышы.
[3] Иван Грозный, Иван IV Васильевич, Явыз Иван (1530–1584) – 1547–1584 елларда (1575–1576 еллардан кала) Мәскәү һәм бөтен Русиянең Бөек кенәзе.
[4] Кирилл хәрефләре белән язылган. Еллык салым.
[5] Усия (Устье) – Казансу елгасының Иделгә койган җире, элек Казан пристане шунда булган.
[6] Затән – нигездә.
[7] Тәбәгаләренә – халкына.
[8] Мәнгы итте – тыйды.

тозны шул ярмаркада гына руслардан сатып алалар иде. Шуның белән тоз алып булмый башлагач, казанлылар бирелергә мәҗбүр булырлар дип уйлады. Ләкин бу ярмарканы күчерүдән руслар татарларга караганда күбрәк зарар иттеләр. Чөнки моның нәтиҗәсендә (Русиядә) Идел буенча Каспий диңгезеннән, Әстерхан базарыннан, Ираннан һәм Әрмәниядән килә торган нәрсәләр дә, бигрәк тә балык, лосось, Казаннан югары һәм түбән Идел елгасында бик күп тотыла торган ак балыкта кытлык булды, ди. Казанда иң күп сатыла торган нәрсә Шәрык маллары, балык һәм мехлар иде. Бу мехларны иң күп сатучы казна үзе булган. Чөнки Казан ханлыгы башкорт вә фин халыкларыннан ясак (салымны) шул җәнлек тиреләре белән ала торган булган. Шуның өчен дә 1552 елда Казанны рус гаскәре мөхасарә кылган[1] чакта рус фиркасе Арчага барып, ифрат та күп җәнлек вә тире-яры ганимәт[2] алган. Казанның бу базарларында сугышларда әсир ителеп алынган коллар да сатылып озатыла торган булганнар. Казанның феодалларының иң күп сугышлары да шушы коллардан гыйбарәт булган ике аяклы малны алу өчен ясалган.

**Иҗтимагый төзелеш.** Алтын Урда дәверендә ясала башлап, шактый муаффәкыятьләргә[3] ирешкән феодализм аталган иҗтимагый төзелеш Казан ханлыгында шактый зур муаффәкыятьләргә иреште. Вакыйган, Казан ханлыгында феодализмның чын мәгънәсе белән ясалуында болар да бар иде. Чөнки бу өлкәдә инде утраклы тормыш ясалган. Игенчелек болгарлар заманыннан бирле үк тамырын җәйгән булган.

Казан ханлыгы феодализм әсасында төзелгән бер җәмгыять, димәк. Чынлап та, без монда феодализмның әсасы булган шушы галәмәтләрне табабыз: 1) җир милке; 2) аның аристократия кулында булуы; 3) аристократия яисә «аксөякләрнең» дәрәҗәсендә тәбәка (иерархиянең) булуы; 4) аларның кулында алпавытларга буйсынган кешеләрнең булуы; 5) шушы икътисади вә иҗтимагый әсаслардан туган сәяси тормышның феодализм әсасында төзелеше (мәмләкәтнең алпавыт феодаллар кулында булуы).

[1] Мөхасәрә кылган – камап алган.
[2] Ганимәт – мал.
[3] Муаффәкыятьләргә – уңышларга.

Казан ханлыгында аерым алпавытларның җир милке бар иде. Сәхибгәрәй хан «йиде кем ирсә»не тархан ясый, ярлык бирә. Бу ярлыкта аларның «аб-зәмин[1] вә кешеләре» бар. Казан алынгачтын хан, ханзадә вә бикләрнең җирләрен Казанга алулары хакында рус мәнбәгъләре язалар. Хәзерге Татарстанда бик күп татар вә рус авылларының исемнәре ул авылларның феодалларның милекләре булганлыгын белдерәләр, мәсәлән, шундый авыл исемнәре бар ки, ул исемнәрнең татар мирза вә бикләренең булганлыгы бик мәгълүм.

Исламова, Килдиева, Дәүләкиева, Мөрәле (Әмир Гали), кенәз Камаева (бу кеше Казан ханлыгы дәверендә Мәскәү яклы бикләрдән булган), Казбаева, Гайшәбикә, Мурзиха, Морза Бирлебаш, бәгъзы авылларның исемнәре ханнарның атлары белән йөртеләләр: мәсәлән, Шәех Галиев, Ядкәрова, Ядкәр. Татар феодаллары кулында җир милке вә аларга буйсынган крестьяннар «кешеләр» булуы хакында без XVII гасырдагы чарга[2] Казан мирзалары тарафыннан бирелгән бер гаризада «шул җирләрне безнең аталарыбыз, бабаларыбыз һәм борадәрләр Казан алынганчы ук вә ул алынгач та биләп тордылар», дип әйтелә. Бу мирзаларның хуҗалыкларын алып баручы хезмәтчеләрнең авыл-авыл булып утырганлыкларын вә аларның күбесе коллар-чуралардан гыйбарәт булганлыгын без Татарстандагы берничә «Коллар» һәм «Чураниле» атлы авылларның барлыгыннан беләбез. Шуның өстенә дә, Казан алынгач, Казан архиепископына бирелгән хан вә ханзадәләрнең латифундияләрендә[3] шактый гына күп татар вә чуваш крестьяны булганлыктан беләбез. Татар феодаллары ыругларга бүленеп һәм тәбәка-тәбәка булып дәрәҗәләргә бүленгәннәр. Иң югарыгы тәбәкада карачылар торалар; болар бик зур имтиязлы[4] сыйныфлар, карачылар Казан ханлыгыннан бөтен татар вә төрк илләренә уртак булган шушы мәшһүр ыругларга бүленәләр: ширин, барын, аргын, кыпчак. Карачылардан кала руслар кенәз дип атап йөри торган бикләр, алардан кала мирзалар, алардан кала исә арханнар. Шулар эчендә тагы бер төрлесе бар, ул да булса, угланнар. Бу феодаллар һәммәсе дә башка җирләрнеке

[1] Аб-зәмин – су-җир.
[2] Чар – царь. Алга таба бу сүз текстта «царь» дип язылды.
[3] Латифундияләр – эре җир биләмәләре.
[4] Имтиязлы – хокуклы.

төсле сугышчылар, феодаллар яисә «аксөякләр» сыйныфы феодализм хөкем сөргән башка халыклардагы төсле, үзләренең кул асларындагы «җир-су кешеләреннән» алына торган ясаклары, русча әйтсәк, «оброклары» белән торалар. Феодаллар үзләре икътисади яктан бай вә тук, хокукый яктан зур имтиязлы бер сыйныф булганлыктан, болар – дәүләтнең дә хуҗалары. Болар башка төркләрнең җирләрендәге шикелле, корылтайга җыелалар. Боларның ыруглары бер-берсе белән көрәшәләр, шунда ук болар ханнарны күтәрәләр, аларны куып та җибәрәләр. Патша юк чакларда бөтен башкарма көче дә боларга күчә. Феодаллар бөтен Казан җире исеменнән күршеләре белән солых ясыйлар, сугыш игълан кылалар вә төрле могаһәдәләргә кул куялар.

Казан ханлыгында, феодаль Яурупадагы шикелле, югарыда сөйләнгән дөньяви феодаллар белән бергә руханилары да бар. Болар да шулай ук югарыдан түбәнгә кадәр төшеп бара торган тәбәка-иерархиягә бүленгәннәр. Бу рухани феодалларның башында сәед тора. Сәед, ханнан кала, болар ханлыкта иң зур кеше хисапланалар. Әлеге Һерберштейн дигән исемле немец сәйяхе яза: «Сәед татарларда шундый хөрмәттә ки, хәтта ханнар аларны каршы алырга чыгалар; сәед ат өстендә торганда хан, аягүрә торып, аңарга кул бирә һәм баш иеп кулын үбә. Бу эш бары ханнарга гына рөхсәт ителә, чөнки бикләр (кенәзләр) аның эзләренә генә кулларын тиерә алалар, башка аксөякләр аягын гына үбә алалар, әмма кара халык булса, киемен генә үбә яисә атына гына кулларын тиерә алалар», ди. Бу сәедләрнең сәяси көчләре дә зур: хан юк чакта чит илләр белән могаһәдәгә башлап сәед кул куя, чит илләргә илче булып барган һәятнең башы булып та шул сәедләр баралар. Сәедләр пәйгамбәр җенесеннән булган кеше вә иң зур рухани хисаплансалар да, Казан ханлыгында алар сәяси низагларга да катышалар. Мәсәлән, Сәхиб Гәрәй хан китеп, аның урынына унөч яшьлек Сафа Гәрәй килгән чакта, Усиягә аны каршыларга сәед тә төшә, ләкин бу сәед Мәскәү яклы булганга, яңа ханны тотып алып бәйләп, Мәскәүгә җибәрергә уйлаганы сизелә, ләкин ватанчылар сәедне тотып, шунда ук пычак белән суялар. Ләкин бу сәедләр эчендә ватанчылары да бар. Мәсәлән, Казан

алынган чакта голәманың башында Шәриф Кол[1] дигән сәед тора. Бу кеше үзенең мәдрәсәсе түбәсендә торып, шәкертләре белән бергә Казанга килеп кергән Мәскәү гаскәре белән сугыша, ниһаять аны бер стрелец түбәдән чәнчеп төшерә.

Сәедләр дә – дөньяви руханилар шикелле җир хуҗалары. Шуның өчен дә хәзерге Татарстанда «Сәидова», «Колсәидова» дигән иске авыл бар. Шуның икенчесе янында исә шуның монах дәрвишләреннән гыйбарәт булган ике авыл булган. Алар хәзер рус авыллары, аларны Дәрвишевка (Дербышка)[2] дип йөриләр.

Сәедләрдән кала Казан ханлыгында тагы мәнбәгъләрдә очрый торган шундый рухани сыйныф бар: данәшмәндләр[3], муллалар, шәехләр, хафизлар, шәехзадәләр, муллазадәләр. Боларның да феодаль җирләре бар. Шуның өчен дә хәзерге Татарстан урынында без әллә никадәр «Мулла иле», «Муллино» дигән авыллар очратабыз. Казан ханлыгында рухани феодалларның җирләре вә аларга буйсынган кешеләре – чуралары булуы мәсьәләсенә даир без бу урында Каюм Насыйриның бер кульязмасыннан шундый бер вакыйга күчереп узабыз:

«Әткәй сөйләгәне бар, Ырыс бабай риваять кыладыр икән: Габдеррәзак мулланың дүрт углы булган, әмма берсенең генә исеме мәгълүм булып калган, ул угылның берсе Йосыф исемле икән. Габдеррәзак баба үзенең заманасында бик мәшһүр бай кеше булган икән. Чар Иван Бачилич Казанны алган заманында Габдеррәзак баба сәламәт икән... Бик гаярь бай кеше вә мулла кеше икән, үзенең заманасында тирә-як халыкка падишаһ кебек булып торган, низаглары булса, Габдеррәзак бабага килеп, хөкемгә торалар икән... Габдеррәзакның гыймарәте каралае бик зур булган, авылның югары башындагы җирләр авыл чаклы күрсәтәләр, аның гыймарәтләренең ишегалдының егерме йирдән капкасы бар икән, үзе бик тәкъва вә диянәтле адәм булган, картаеп, йөзгә йитеп, вафат булган... Ханнар, патшалар белән таныш булган. Микал Федорич[4] заманасында Габдеррәзак мулла мәшһүр кеше булып, Микал Федорич аны тау

[1] Кол Шәриф (?–1552) – Казан ханлыгында дәүләт эшлеклесе, дин башлыгы (сәет), шагыйрь.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Данәшмәнд (данишмәнд) – гыйлем иясе, галим.
[4] Михаил Федорович Романов (1596–1645) – Романовлар династиясеннән беренче рус патшасы.

халкына баш итеп, имана шикелле халыктан акча җыеп, иген тару-тару җыеп, Микал Федоричка йибәрер икән... Габдеррәзак бабага тирә-яктан гошер килгәндә, юлларны, күперләрне төзәтер икән, гошергә китергән игенне бушатырга нәүбәт җитмичә, көн буе кырда куналар икән... Каршы тауда Габдеррәзак бина кылган ашлык сарайлары бар икән. Хәзинәгә китәсе ашлыкларны тотар өчен... Фәтхулла бабай риваять кыладыр Ырыс бабайдан. Ырыс бабай әйтер икән: «Бервакытны Габдеррәзак килгәч сүз чыккан. Берәү әйткән: «Габдерразактан бай адәм бу тирә-яктан юктыр», дип. Аңарга каршы икенче бер адәм әйткән: «Юк, мин Ишмирзаны Габдеррәзактан баерактыр дип беләмен», дигән. Ул вакытта бер Ишмирза дигән бай кеше бар икән. Габдеррәзак моны ишеткәч, үзенең кешеләренә әмер иткән: «Бар, әйтегез, малайлар вә хезмәтчеләр, һәр каюгыз работнай киемнәрен киеп, атларын атланып, ишегалдына җыелып, саф ясап торсыннар», дигән. Габдеррәзак боерыгы буенча, тиз үк барысы җыелып килгәннәр. Атларының дагалары вә иярләренең өзәңгеләре һәммәсе көмештән икән – ничә-ничә ат, коллары бар икән, ул заманның истилячыны[1] чура-коллар дип йөртәләр икән...».

Менә бу кисәктән без рухани феодалларның Казан алынганчы һәм соңыннан да никадәр бай вә көчле һәм сәяси куәтле икәнен бик яхшы күрәбез. Шулай ук без татар феодализмында, Яурупаныкындагы шикелле, «Алла хөкеме» (Божий суд)[2], ягъни шәхси бәгъзы сәяси мәсьәләләрне ике феодалның мөбарәзә (Единоборство[3]) белән хәл ителә торган гадәте булганлыкны да күрәбез. Казаннан куылган Шаһгали[4] хан Сафа Гәрәйгә каршы царь Василийның гаскәре белән килгәч, яшь ханга Шаһгалинең хат язып, «минем ата-бабамнан икән җиремне кире кайтарып бир», дип язгач, Сафа Гәрәй моңарга каршы: «Мәсьәләне без корал белән хәл кылыйк. Кем җиңсә, шуңарга булыр», дигән. Шаһгалигә каршы Казаннан 9 атлы җыеп, Шаһгали аңарга 150 атлы белән мөбарәзәгә барырга чыкканы мәгълүм.

[1] Истилячы – яулап алучы.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Кирилл хәрефләре белән язылган. Бергә-бер чыгып сугышу.
[4] Шаһгали хан (1505–1567) – Касыйм ханы (1516–1519, 1535–1551, 1552–1567), Казан ханы (1519–1521, 1546, 1551–1552), Кече Мөхәммәд ханның оныгы.

Әлхасыйль, Казан ханлыгының һәрбер яктан феодализм әсасында корылган бер оешма икәнен күрәбез.

**Казан ханлыгында сәяси тормыш вә көрәш.** Димәк, Казан ханлыгы суверен бер хан тарафыннан идарә кылына, ләкин дөньяви вә рухани феодаллар, ягъни гаскәри алпавыт аристократия сыйныфы тарафыннан аның хакимияте чикләнгән булган. Казанда, бер яктан, чын татар җенесеннән булган феодаллар булсалар, татардан башка мари, чуваш, ар вә мукшы халыкларының кенәз-мирза[ларыннан] вә татар ханнарыннан гыйбарәт булган. Феодаллар Казан ханының вассаллары булганнар. Казан ханлыгының дәүләт төзелеше исә шул Алтын Урда, гомумән, чыңгызилар дәүләтләренең хөкүмәт төзелешләре ысуллары белән ясалган булган. Шуның өчен дә идарә хәрби булып, халык һәммәсе гаскәри булганга, төркләрдәге шикелле унга, йөзгә, меңгә бүленеп идарә кылына торган булган. Мәмләкәт гаскәре округ-өлешләргә бүленеп, «уң би» «сул би»ләр (правое крыло, левое крыло)[1] тарафыннан идарә кылынган. Башка түрәләр дә шул Алтын Урда манерына төзелгән булган.[2] Бу аксөякләр ифрат күп булып, аларның саннары меңгә җитәдер иде. Алар арасында төрле нәселдән килгәннәре булган. Алар төрле нәселләргә бүленгән булып, бер-берсе белән низагта торганнар.

Бу мирзалар, бикләр, карачылар эчендә Алтын Урдадан Олуг Мөхәммәд белән килгән бикләрнең нәселләре Шәйбаниләрдән (Себердән), Нугайлардан, Кырым ханнары (Гәрәйләр) нәселе хан булган чакта алар белән Кырымнан килгән бикләр, мирзалар бар иде. Шуңар күрә алар төрле партияләргә бүленәләр, әмма шул ук партияләр эчендә чын-чыннан Казан истикълялиятен[3], аның мәнфәгатен саклау тарафдарлары гына булмаган... Кырым, Нугай, Шәйбани, Әстерхан, хәтта Мәскәү яклары бар иде. Төрле вакытларда боларның төрлеләре өскә чыгып торалар. Казанның бу гаскәрдән артыграк тарихы шул партияләрнең низагысы белән үткән. Элек Нугай, соңра Мәскәү, соңра Шәйбан, соңра Кырым, соңра янә Мәскәү партиясе җиңгән. Бары тик 1552 елда, рус гаскәре Казанны

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Арча кантонындагы Чулбы вә Өмин дигән авыллар картларының сөйләвенә караганда, шуны күрсәтәләр. *(Авт. иск.)*
[3] Истикълялиятен – бәйсезлеген.

камап алгач кына, татарлар уянганнар. Бу партияләрнең низагысы күбрәк хан кую хакында булып, нинди нәселдән хан куелса, шул партия җиңгән хисап кылынган.

**Гаскәр.** Казан дәүләтенең гаскәре төп татарлардан һәм Казан дәүләтенең кул астында булган башка кавемнәрдән гыйбарәт булган.

Казан дәүләтендә һәрбер татар «гаскәри» иде. Татарлардан күбрәк чирмешләр сугышларга үзләренең бикләре, мирзалары командасында киләләр. Бу халык Казан дәүләтенең мәнфәгатенә яхшы бирелгән әһалисеннән хисап кылынадыр иде. Гаскәр күбрәк борынгы татарларныкыча ук, җәя, кылыч белән коралланган була. Соңра кырымлылар хан булгач, Кырымнан мылтык, туп та китерелеп торган. Шулай ук рус партиясеннән булган ханнарга мондый коралларны Мәскәү хөкүмәте дә биргән булырга кирәк. Татар гаскәре сугышта шул ук борынгы төркләр ысулы (тактикасы) белән эш кылганнар.

**Мәгънәви мәдәният.** Казан иле үзенең бер гасырдан артык тормышында бертуктаусыз сугышып торган.

Русларның һаман һөҗүм кылып торулары, казанлыларның үзләренең Мәскәү җирләренә һөҗүм иткәләүләре, нугайлар белән һәм үзара канлы партия низаглары илне кан эченә батырган иде. Тормыш шулай булган соңында, билгеле, мәдәният арта алырга мөмкин түгел, шуның өчен казанлылар үзләренең мәдәниятләрен арттыру түгел, хәтта Болгар ханлыгы заманасыннан түбән төшергәннәр.

Бикләре, мирзалары арасында да язу яза белә торган кешеләре аз булган. Бәгъзы вакытта Русиягә илче булып барган илнең аксакал бикләре, язу яза белмәгәнлекләре өчен, могаһәдәләргә[1] мөһерләрен генә басалар. Шулай ук Казан дәүләтенең хөкүмәте тарафыннан чыгарылган ярлыкларда да хата имля белән язылган гарәпчә сүзләр очрыйдыр иде[2]. Казанлылар Болгар заманасыннан бирле ислам динендә иделәр. Үзләрен «мөселман» дип атауны яраталар, әмма «татар» дигәнне сөймиләр иде. Аларның җирендә мәчетләр күп иде.

[1] Могаһәдәләргә – килешүләргә.

[2] Казан шәһәрендә мәдрәсәләр дә бар иде. Муллалар, галим мәгънәсендә булган «данишмәнд» дигән бертөрле сыйныф. Шулай ук Коръән ятлаган (хафизлар) яисә «кабызлар» вә Казан ханлыгында «шәех» дип йөртелә торган ишаннар да бар иде. Болар руслар белән төрле могаһәдәләр ясаганда урын тотканнар. *(Авт. иск.)*

Мәгълүм ки, мөселман җирендә һәрбер мәчет тирәсендә бер мәктәп була. Шуның өчен Казан шәһәрендә мәдрәсәләр дә булган булырга кирәк дип уйларга мөмкин.

Борынгы Казан татарларыннан бер дә китаплар, әдәби әсәрләр калмаган. Аның сәбәбе шул ук сугышларның күплеге, шуның өстенә 1552 елда руслар тарафыннан Казан алынган чакта, биналар ватылган чакта, өйләр таланган вакытта боларның һәммәсе дә заегъ булганнардыр[1]. Ләкин аларда әдәбият булган булырга кирәк. Ул әдәбият күбрәк дини мәсьәләләргә гаид булган булыр.

Ләкин Казан ханлыгы дәверендә әдәбиятның бөтенләй дөньяви мәүзугъларга язылганы булмагандыр дип әйтеп булмый. Бер яктан, Алтын Урда дәүләтендә үк, Урта Азиядәге шикелле шигырьләр язып, аларның җыенын бергә төпләп, «диван»нар ясау гадәте бар иде. Мәсәлән, Алтын Урда дәүләтендә 1353 елда язылган «Мөнәҗәтнамә» исемле диван булганы мәгълүм. Табигый, мондый нәрсәләр язу белән Казан татарларының шәех-мулла, сәед вә талиб шикеллеләре шөгыльләгәннәрдер. Икенче яктан, Казан белән нык мөнәсәбәттә булган касыймилардан калма XVII гасыр язма әсәрләре бар, Касыймда язу белән шөгыльләнгәнне Казанда да шөгыльләнгәннәрдер. Өченчеләй, Казан әтрафында әлегә кадәр төрле нөсхәләрдә табыла торган вәкаигънамәләр бар, төрле кыйссалар бар, мәсәлән, «Дастане Чыңгыз хан вә Аксак Тимер». Ниһаять Казан татарларында бер ясалган әдәби вә дивани (канцелярский) өслүбле тел барлыгын күрсәтүче Сәхиб Гәрәй хан заманасыннан калма бер ярлык бар[2]. Әгәр шуның өстенә Казан артында рус вә татар авыллары янында табыла торган гарәби аятьләр вә хәдисләрдән соң, татарча сүзләр язылган кабер ташларын вә бик борынгыдан калган вә кул язмасы халәтендә йөри торган берничә тарихи хикәя вә кыйссаларны алсак, Казан ханлыгы дәверендә әдәби тел вә әдәбиятның берникадәр булганлыгы күренә. Күптән түгел генә табылган Сәхиб Гәрәй ханның ярлыгы Казан ханлыгында Алтын Урда рәсми теле белән госманлы рәсми теленең кушылуыннан гыйбарәт булган бер канцелярия теленең дә ясалган булганлыгын күрсәтә.

[1] Заегъ булганнардыр – юкка чыкканнардыр.

[2] Бу хакта ярлыкны табучы Сәид Вахидовның аерым әсәре чыгачак булганнан, ярлыкны бу җирдә китермибез. *(Авт. иск.)*

Ләкин бу бабта хәзергә әле тарихчылар кулында мәгълүмат бик аз, эзләүче вә мәнбәгъләрне җыючы булса, һәрхәлдә, материал табылачак. Тарих гыйлеме өчен татар авылларында мәчет чормаларында иске язма китапларда ифрат күп мәгълүмат вә материал ята. Ләкин болар әлегә кадәр эзләүчеләрен көтәләр.

### 3.3. Әстерхан ханлыгы

**Әстерхан ханлыгы.** Әстерхан шәһәре Алтын Урда көчле вакытта ук булган. Аның мөһим икътисади урында, Азия һәм Яурупа – итальян колонияләренә якын торуы аркасында бу шәһәр күтәрелеп киткән. Ләкин төркләрнең Дарданеллны алулары аркасында Җәнүә һәм Венеция сәүдәгәрләренең Азов вә Кара диңгезләр буендагы колонияләре инкыйразга йөз тоткач, Әстерханның да әһәмияте кимеде. Шуның өстенә дә тагы XIV гасырда Аксак Тимернең Туктамыш хан белән сугышырга килгән заманында бу шәһәр бик зарарланды. Ләкин Алтын Урда тәхлил кылына[1] башлагач, Алтын Урда заманында монда «әмир» булып торган вассал үзен мөстәкыйль итеп игълан кылып, Әстерхан ханлыгы төзелгән. Бу ханлык исә, төркләр Босфорны да алу белән, бөтенләй Төркия һәм аның вассалы Кырым ханлыгы тәэсиренә бирелгән. Ләкин шулай да мөһим бер сәүдә мәркәзе булып калган. Бу шәһәргә якын җир вә игеннәрнең аз булуы, бары Иделнең бәгъзы кырыйларында һәм Бузун[2] суының буйларында гына иген вә бакчачылык белән шөгыльләнү мөмкин булганга, бу ханлык сәүдәгә таянган бер дәүләт булып китте.

**Иҗтимагый тормыш.** Әстерхан дәүләтендәге иҗтимагый тормыш нәкъ шул Казан, Нугай Урдаларындагы күк иде. Сыйныфларда шул ук халыкның тормышы да шулай ук булган. Бу ил Иран, Урта Азия күк мөселман өлкәләренә якын торганга күрә, монда мирза, углан, бикләр белән бергә муллалар, хуҗалар, шәех вә шәехзадәләр аталган руханилар да куәтле булган. Алар сәясәт эшенә катышалар, идарә эшендә дә голәма белән әгъян[3] зур роль уйнаган. Алар ханнарны төшерәләр, чакырып китерәләр иде. Шулай ук Әстерхан,

[1] Тәхлил кылына – аерыла.
[2] Биредә Әстерхан төбәгендә Иделгә тоташкан Бузан елгасы турында сүз бара.
[3] Әгъян – аристократ.

Кырым вә Нугай Урдаларына якын торганга күрә, Әстерхан дәүләтенең эшләренә бу урдалар да катышалар, Кырым, Нугай партияләре шактый низагларга сәбәп булалар иде.

Гомумән, бу ханлыкта аксөякләр саннары ифрат күп булган: XVI гасырда ханлыкта 500 аксөяк, ун мең башка татар сыйныфлары торганлыклары мәгълүм.

**Икътисади тормыш.** Әстерхан дәүләтенең төп әһалисе татарлардан гыйбарәт булса да, пайтәхет булган Әстерхан (Хаҗитархан, Әждархан) шәһәрендә чит халыклардан әрмәниләр, иранлылар, һиндиләр дә торалар. Алар күбрәк сәүдә белән шөгыльләнәләр. Илнең икътисади тормышы күбрәк сәүдә белән булган, чөнки Әстерхан XV гасырларда, IX–X гасырлардагы Итил урынын тотадыр иде. Шәрык малы Әстерхан аркылы Яурупа, Русиягә китә, Кырымга килеп урнашкан Италия (Җәнүә) вә Рум сәүдәгәрләре дә килеп йөриләр: үз малларын китерәләр, Шәрык малларын алып китәләр иде. Әстерханның үзендә дә ул заман өчен мөһим микъдарда мал чыга. Ул исә балык булып, Әстерханда тотылган балык Русиягә озатыла. Әстерханлылар Казан белән дә сәүдә кылалар иде.

Шулай ук Әстерхан дәүләтенең әһалисе игенчелек, бакчачылык белән дә шөгыльләнәдер иде. Әстерхан тирәсе күбрәк комлы сахра, степьләрдән гыйбарәт булганга күрә, игенчелек белән күп шөгыльләнеп булмый: Идел елгасының сул ягына агып төшә торган Бузан (Бузан)[1] елгасы тирәсе генә мөнбит булганлыктан, күбрәк шул урында иген чәчәләр иде.

Әстерхан урдасында әһалинең күпчелеге күчмә халык булып, алар мал асрап көн күрәләр. Ләкин бу әһалидән күп файда юк, чөнки алар күбрәк үзләренең ыруг башлыклары – бикләргә табигъ итәләр[2]; Әстерхан хөкүмәтенә аз әһәмият бирәләр иде.

Әстерхан ханлыгының икенче бер мөһим икътисади таянычы булса, ул да балыкчылык булган. Бу мал, бер яктан, Русиягә китә торган булган. Шуның өчен дә XVI гасырның ахырында Әстерхан Русия кулына кергәч, Русиядән Англия вә Голландиягә китә торган малларның мөһимнәреннән берсе балык уылдыгы (икра) булган.

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Табигъ итәләр – буйсыналар.

### 3.4. Нугай Урдасы

**Гомуми мәгълүмат.** XIII гасырда Алтын Урда дәүләтенә кергән бик күп феодаллар эчендә Нугай Урдасы да бар иде. Бу урда XV гасырда вә XVI гасырның урталарында әһәмият алып китте, бу вакытка кадәрле бу халык бик аз мәгълүм булган. XV–XVI гасырларда исә, бу халык сәяси җәһәттән куәтләнеп киткәч, күршеләре белән мөнәсәбәт башлаганнар. XVI гасырда нугайлар үзләре өч зур урдага бүленәләр, бу урдаларның һәркайсы бер мәгълүм җирдә күчеп йөриләр. Үзләренә махсус бикләре (кенәзләре) тарафыннан идарә кылынганнар. Бу хөкемдарлар, бу аксөяк мирза һәм кенәзләр һәммәсе дә, башка татар урдаларындагы шикелле, Чыңгыз нәселеннән булган Идегәй җенесеннән килә торган булганнар. Нугайлар үзләре берничә урдага бүленгән булганнар, һәм башка татарлар шикелле, болар бербөтен дәүләт ясый алмаганнар. Шуларның берсе Җаек елгасы буенда булып, бу елганың Каспий диңгезенә коя торган урынында Алтын Урда заманында ясалган Сарайчык шәһәре дә булган. Кама белән Идел елгалары арасында икенче бер Нугай урдасы булып, шуларның ханнары бөтен Башкортстанны үз кулында тотып, алардан ясак алып торганнар. Бәгъзы мәнбәгъләргә бинаән[1], хәзерге Уфа янында аларның пайтәхетләре дә булган. Өченче Нугай урдасы Себер урдасы дип аталган.

**Нугайларның тормышы, шөгыльләре.** Нугайлар күчмә халык булганлыкларыннан, аларның шөгыльләре дә күбрәк мал асрау булган. Алар атлар үстерәләр дә, аларны ерак җирләргә илтеп саталар. Бәгъзы вакытта нугайлар Мәскәүгә илле мең баш ат китерәләр икән. Аннан башка алар мөгезле мал һәм дөяләр асрыйлар, мөгезле малны Казанга китерәләр, әмма атны, Казан төшкәч, күбрәк Мәскәүгә илтеп саталар. Бәгъзы вакытта Мәскәүгә куйлар да китерәләр иде.

Бәгъзы нугайлар бераз гына игенчелек, бакчачылык белән шөгыльләнәләр. Сарайчык янында аларның игенлекләре булып, күбрәк бодай чәчкәннәр. Нугайларның игенчелек белән шөгыльләнүчеләре – юаш, мал асрап торучылары исә, һәр күчмә халык күк, ифрат сугышчан булганнар.

[1] Мәнбәгъләргә бинаән – чыганакларга нигезләнеп.

Бәгъзы нугайлар сәүдә белән дә шөгыльләнгәннәр. Болары исә Сарайчык күк мәркәзирәк җирләрдә, су юллары өстендә торалар, аларның хөкүмәтләре сәүдә малыннан пошлина аладыр иде. Бу эшләр белән, Алтын Урдадагы күк, даругалар шөгыльләнәләр иде.

Калада торучы нугайлар – «йорт нугайлары», күчеп йөри торган нугайлар «олыс» нугайлары дип аталалар иде. Күчмә нугайлар кыш көне җылырак урында, Каспий диңгезе буенда торып, җәй көне Идел һәм Җаек буйларында күчеп йөргәннәр. Күчеп килә торгач, алар Кама (Чулман) елгасына кадәр, Казанга чаклы килеп җиткәннәр.

**Дин.** Нугайларның диннәре ислам дине, аларның да муллалары хөрмәттә булып, бикләрнең якыннары, дуслары хисапланганнар. Бу халык үзләре күбрәк күчмә булсалар да, каберләренең өстенә төрбәләр (кишән) салырга яратканнар. Гыйлем өйрәнергә нугайлар күбрәк Кырымга баралар, чөнки Кырым Төркия кулында булганлыктан, анда мәдрәсәләр күп иде, бигрәк тә Бакчасарай Кырым ханлыгының гыйлем мәркәзе хисапланадыр иде.

**Нугайларның иҗтимагый, сәяси тормышы.** Нугайлар ыруг тормышы белән көн күрәләр, аларның урдаларының башында бик (кенәз) тора, аның балалары, нәселдәшләре мирза аталалар иде[1]. Әгәр бик үлсә, аның ыругындагы иң карт кеше яисә зур улы тора, бик үзенең ыругдашлары аксөякләр арасында «ата» яисә «олуг борадәр» хисапланып, башкалары бикнең «энеләре» хисапланганнар. Мирзаларның дәрәҗәсе аларның картлык-яшьлекләре белән булып, карт мирзаның хезмәте артыграк булган. Бик үзе кыш көне Сарайчык шәһәрендә торган.

Һәрбер мирзаның махсус олысы була, бу олыста исә гади нугайлар яисә, үзләренең тәгъбиренчә, «олысын кешеләре» торалар иде. Әгәр мирза яхшы булып, аны халык сөйсә, аның олысы зур була иде, димәк, мирзаларга буйсыну бер дәрәҗә халыкның кулында булган. Бәгъзы олыслар кайсы мирзаларга вәрасәтән (атадан балага) да күчкән.

[1] Зуррак дәрәҗәле бикләрне «олы» дип атаганнар. Бу олы бик Нугай урдасының башы хисаплана, аның кул астында шул ук аксөякләрдән бер кеше анык булып, Кырымдагы кебек, «Нуретдин» дип йөргәннәр. Шулай ук Нугай урдасында борынгы нәселдән туган «карачы» атала торган, Кырым вә Казандагы кебек аксөякләр дә булган. *(Авт. иск.)*

Бикнең мирзаларга мөнәсәбәте, хакимияте бер мәгълүм рамкага куелмаган. Әгәр гайрәтле вә тәдбирле[1] бик булса, аңар мирзалар да, халык та яхшы буйсыналар. Димәк, нугайларның иҗтимагый тормышында берникадәр халыкчылык әсасы салынган булган.

Бу эш һәрбер күчмә халыкта була; бик бит ул гаскәри командан, чөнки нугай халкы, күчмә халык булганга күрә, күбрәк сугыш, талау белән яшәгән. Әмма мондый хәятта команданның гайрәте, сугыш эшендә осталыгы шактый әһәмиятледер. Әгәр инде бик мондый кеше булмаса, аның тәбәгаләре дә, мирзалары да башка бер олысның бигенә барып табигъ булалар, шуңар хезмәт башлыйлар, яисә Кырым, кыргыз урдалары күк, нугайларга кардәш булган башка төрк урдаларына кушылалар иде. Шуның өчен нугай бикләреннән берсе рус царена «безнең халык кырда тора. Калалар юк, халыкны тотып булмый» дип, үзенең хакимиятенең азлыгыннан зарланган иде.

**Төрле сыйныфларның бер-берсенә мөнәсәбәтләре.** Шундый халәт хөкем сөргәнгә күрә дә, мирзалар, кара халык та күп вакытта бикләренә каршы корал күтәреп ихтилал[2] чыгаралар. Бөтен урдага гаид мәсьәләләр хакында бик (кенәз) үзенең ыругдаш һәм чит җенестән булган мирзалар белән киңәшергә тиеш, карар бик тарафыннан гына түгел, бөтен урда исеменнән чыгарыладыр иде. Бик мөһим мәсьәләләрдә, мәсәлән, сугыш игълан кылу, бер-бер ил белән могаһәдә вә солых ясау шикелле эшләрдә бик мирзалар белән генә киңәшеп калмый, мондый вакытларда ул олысның аксакаллары, картлары, баерак кешеләре белән дә киңәшергә, алардан да рөхсәт алырга тиеш иде. Мәсәлән, бер вакытны бер бик (кенәз) Русия белән сугышырга уйлап, шундый халык вәкилләрен чакырган иде. Ләкин вәкилләр моңар каршы килеп, сугыш булмый калган иде. Бәгъзы вакытта нугайларның җыеннарында «карасөяк» – гади фәкыйрь халыкның тавышы да көч алып киткән. Мәсәлән, бер вакытны кара халык эшкә катышып, Кырымга илче җибәрүдән бикне тыйганнары мәгълүм. Казандагы күк нугайларда да карачылар, угланнар булып, аларның дәрәҗәсе башка мирзаларга караганда югары булган.

Димәк, һәрбер сыйныф нугайларда эшкә катышалар, ләкин бу сыйныфларның бер-берсе белән икътисади мәнфәгатьләре бергә

[1] Тәдбирле – эшлекле.
[2] Ихтилал – баш күтәрү, фетнә.

туры килмидер иде. Бик өчен күршеләргә дәфгатән[1] һөҗүм кылып, әсир алып, ул әсирләрне Каспий диңгезе артындагы илләргә илтеп сату файдалы, әмма бәгъзы мирзалар сәүдә белән шөгыльләнеп гомер иткәнгә, бикнең сугышасы килгән илләре белән дус торасылары киләдер иде. Шуның өчен руслар һәрвакытта бикләргә каршы аларның тәбәгаләре булган мирзаларны котыртып, аларга корал, мылтык, туп, хәтта гаскәр биреп торалар. Күп вакытта кенәз белән мирзалар арасында низаг булып тора, кара халык та мирзалар белән көрәшәләр, әгәр мирза халыкны кысса, каһәрли башласа, халык аны ташлап китә һәм шуның белән мирзаларны аптырата, чөнки мирзаларның һәркайсының үзенә күрә гаскәре була, әгәр дә халык башка мирзаларга китсә яисә башка олыска китсә, мирзалар ике кулсыз булып калалар иде.

**Нугайларның мәдәни дәрәҗәләре.** Нугайлар мәдәнияттә бик түбән булганнар. Алар XVI гасырда үзләре калалар сала, истихкямнәр[2] ясый белмәгәннәр. Мондый эш өчен алар осталарны Мәскәүдән китерәләр. Шулай ук тимер кием, сугыш бүреге (Шлем)[3], кылыч шикелле нәрсәләр дә читтән килгән. Мылтык, туп күк кораллар күбрәк Мәскәүдән килә. Җәйге, кышкы киемнәр, киемлек тулалар, кәгазь, кара савыт, мөһер, буяу, ияр, тарак шикелле нәрсәләр дә чит илләрдән, күбрәк Мәскәү патшалыгыннан килә торган булган. Алда әйтелгәнчә, гыйлем-мәгариф тә, мәктәп-мәдрәсә шикелле нәрсәләр дә нугайларда юк, алар гыйлем алыр өчен Кырымга йөргәннәр.

**Нәтиҗә.** Бу сөйләгәннәрдән күреләкки, нугайлар һәм икътисади, һәм иҗтимагый җәһәтләрдән Казан вә Әстерхан оешмаларыннан артта калганнар. Аларның җәгърафи мәүкыйглары[4] нугайларны бергә җыеп, бер дәүләт ясарга ирек бирмәгән. Ыруг-патриархат тормышы аларда шактый көчле рәвештә сакланып калган. Шулай булса да, без нугайларда бу тормыштан феодализмга таба атлауны күрәбез. Шиксез, без аларның иҗтимагый тормышында феодализмның

[1] Дәфгатән – кинәт, көтмәгәндә.
[2] Истихкямнәр – ныгытмалар.
[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[4] Җәгърафи мәүкыйглары – географик урыннары, географик урнашулары.

бик күп ноктасын сизәбез, ләкин болардагы феодализм үзләренә, ягъни күчмә халыкныкына махсус.

**Бу урдаларның бер-берсенә мөнәсәбәте.** Казан, Әстерхан, Нугай урдалары арасында мөнәсәбәт бер мәгълүм рамкага кермәгән, аларда бер сәяси аң, иттифак дигән нәрсә юк иде. Дөрес, бәгъзы вакытта Казанда Әстерхан ханнары нәселеннән килә торган ханнар була һәм шул вакытта Казан белән Әстерхан иттифак ясыйдыр иде. Әгәр инде Казанда Кырым ханнары Гәрәйләр нәселеннән килгән ханнар булса, ул вакытта нугайлар Казанга дошман булалар, чөнки нугай мирзалары күбесенчә Гәрәйләргә дошман иделәр.

Элегрәк Казанда Олуг Мөхәммәд җенесе ханлык сөргәндә, Әстерханда Алтын Урда ханы Кечек Мөхәммәд хан җенесе хан булганда Казан, Әстерхан урдалары бер-берсенә дошман булалар, чөнки Олуг Мөхәммәд, Кечек Мөхәммәдләр белән бер-берсенә дошман иделәр, шуның өчен бу сөләләләрдә ыруг дошманлыгы хөкем сөрә иде. Шулай ук Казанда нугай мирзалары җенесенннән булган ханнар хөкүмәт сөргәндә, Казан белән Әстерхан арасы суык буладыр иде. Кабиләчелек вә ыруг дошманлыгы мәсьәләсенә бу урдаларның хөкүмәтләре күбрәк әһәмият бирәләр. Шуның өчен алар алларына килеп баскан Мәскәү тәҗавези[1] сәясәтенең йодрыгын күрмиләр иде. Бу замандагы ыруглардагы хаким сыйныфларда миллият аңы да юк иде, чөнки бу ханлык вә урдалардагы халык кабиләлектән әле миллияткә күчә алмаганнар иде. Шулай ук боларда әле дини тойгы да җүнләп юк, чөнки бу XVI гасырда татарлар мәдәнияттә тагы да артка киткәнгә, андый тойгы өчен бераз булса да аң-белем кирәк булганга, тойгы да бары голәмасында гына булса булгандыр. Мәсәлән, бикләр, мирзалар, үзләренең сәясәтләренә туры килмәсә, мөселман руханиларын үтерүдән дә тартынмыйлар иде.

### 3.5. Себер урдасы

**Себер урдасының ясалуы.** Чыңгыз үзенең империясен идарә өчен угылларына бүлгән чакта, Гарби Сибириядәге Обь елгасы вә аның тармаклары, Иртеш, Тубыл елгалары буйлары да бөтен Шәркый Яурупа белән бергә олуг углы Җүҗигә тигән, шуның өчен Ал-

[1] Тәҗавези – басып алу, буйсындыру.

тын Урда дәүләтенең көчле чакларында Уралның теге ягы да анықы булган. Ләкин бу Алтын Урда зәгыйфьләнә башлап, вак-вак урда – ханлык вә кабиләләргә бүленә башлагач, Уралның теге ягын идарә эше начарланды. Вак-төяк кабилә вә ыруг башлыклары, вак мирза вә ханзадәләрнең һәркаюсы үзләренең җирләрен үзләре биләп, Нугай урдасындагы төсле тора башладылар. Ләкин XV гасырда бер сәяси оешма ясалып, шул җирләрне бер кулга – бер идарәгә кертергә омтылу туа башлады. Халыкның утраклы тормышына өйрәнә баруы, сәүдә вә сатар өчен дә нәрсәләр ясау һөнәренең тууы да бер куәтле хакимият вә бер сәяси оешма ясауны телиләр иде. Шушы икътисади сәбәп инде XV гасырның уртасында Себер урдасы яисә ханлыгы дигән бер дәүләт тудырды.

**Халык.** Уралның теге ягында, Обь елгасының урта агымында вә аның тармаклары Иртеш, Тубыл, Ишем сулары буендагы яланнарда борынгы заманнарда фин җенесеннән булган остяк вә башка кабиләләр көн күргәннәр. Ләкин XIII гасырда Урта Азияда булган инкыйлаб, ягъни бөек татар-монгол дәүләте ясалу мөнәсәбәте белән алмашынулар туды. Төрк кавемнәре җәнүбтән шимальгәрәк тә менеп315 таралдылар. Менә шул чакта бер төркем төрк кабиләсе килеп, бу урыннарны ишгаль кылды[1]. Соңра болар шунда якын җирләрдә күчеп йөргән кыргыз вә нугай төркләре белән кушылып, Себер татарлары дигән бер халык ясалды. Теге җирле финнарның бер кисәге, төркләр белән сугышларда җиңелеп, шимальдәге тайга вә салкын урман, сахраларга күчтеләр. Бер кисәге заманының үтүе белән үзләренә караганда мәдәнирәк төркләр белән кушылып, телләрен югалттылар, татарлаштылар. Соңра, XIV гасырлардан башлап, Себер өлкәсенә Урта Азиядән таҗик вә сарт кебек мәдәнияттә югары, сәүдәгәр вә һөнәрмәнд халыклар килделәр. Болар наданрак халыклар эчендә торып, алар белән алыш-биреш ясап, үзләренең байлык вә мәдәниятләре аркасында җирле татар вә финнардан файдалану өчен килделәр. Боларның эченнән Себер татарларының буржуасы килеп чыкты. Менә шулай итеп, Себер урдасының халкы ясалды.

**Матди мәдәният.** Себер татарлары килгәнче үк ул урыннарда торган финнар шактый дәрәҗә мәдәнияткә җиткәннәр, шәһәрләр вә

[1] Ишгаль кылды – биләде.

истихкямнәр[1] сала беләләр, болан кебек хайваннар асрыйлар, төрле рәвештәге кораллар белән балык вә хайван аулый беләләр. Хәтта кечерәк патшалыклар да ясап гомер итәләр иде. Ләкин татарлар инде бу финнардан алдарак булганга, монда мәгълүм бер мәдәният иясе вә ул мәдәниятне китерүче ролен уйнап килделәр. Болар үзләре белән бергә ау, балык тоту, мал асрау, игенчелек, төрле кирәк-ярак нәрсәләр ясау һөнәрләрен һәм сәүдә китерделәр. Менә без хәзер Себер татарларының матди мәдәниятләренең һәрбер төрлесенә күзебезне йөртеп чыгыйк.

**Ау вә балыкчылык.** Шимальдәрәк яткан урманлы һәм сазламык урыннарның татарлары кошлар, яхшы тиреле җәнлекләр һәм эре кыр киекләре аулап тереклек кылалар, моның өчен төрле зурлык ук, җәяләр, капкыннар һәм очлы рогатина аталган кораллар истигъмаль итәләр[2] иде. Татарларда балыкчылык бик тәрәккый иткән булган. Себернең күлләре, елгаларындагы ифрат күп балык татарларга яхшы ризык биргән. Балыкны татарлар кармак, махсус сөңге, җәтмә вә башка төрле әсбап белән тоталар икән.

**Мал асрау.** Тубыл, Ишем белән Иртеш елгаларының урта агымнарындагы киң далалар хайван-мал асрау өчен дә бик мәгъкуль урыннар иде. Татарларның иң күп асрый торган маллары елкы булган, шуның өчен дә хәзерге көндә борынгы авыл, калалар хәрабәләренең урыннарын казыганда ат сбруе күп табыла. Шулай ук куй асраганнарына даир мәгълүмат та бар. Әмма сыер, үгез шикелле малны асраулары тарихка мәгълүм түгел.

**Игенчелек.** Тубыл һәм Иртеш буендагы иген уңа торган урыннарда торган татарлар игенчелек белән дә шөгыльләнәләр булган. Борынгы авыл вә кала калдыкларын казыганда сука тимерләре, тырма тешләре күп табыла. Шулай ук руслар татарлар белән сугыш заманнарында иске хуҗалары ташлап чыккан шәһәрләрдә руслар бик [күп] икмәк запасы табалар икән. Обь елгасының да урта агымында торган татарлар да иген игәләр икән.

**Кәсеп, һөнәр.** Мал асрау, иген игү белән генә татарлар канәгатьләнмәгәннәр. Алар төрле нәрсәләр дә эшли белгәннәр. Балта эше, чүлмәк ясау, тимерчелек һөнәрләре белән дә шөгыльләнгәннәр.

[1] Истихкямнәр – крепость, ныгытмалар.
[2] Истигъмаль итәләр – кулланалар.

Тимердән чуен кою, бакырдан төрле нәрсәләр ясау: пычак, кайчы, без, өтерге, балта, йозак шикелле әйберләр эшләгәннәр.

Бу эшләрдә чүкечләр, игәүләр, таш кайраклар истигъмаль иткәннәр, хәтта мондый нәрсәләр ясарга кирәкле мәгъдәннәрен дә татарлар үзләре җирдән чыгарганнардыр дип уйлана.

**Сәүдә.** Сибирия татарлары матди мәдәнияттә үзләренең күршеләре булган фин кавемнәреннән өстәрәк иде. Алар бу нәрсәләрне ясап, үзләре истигъмаль кылу белән генә һәм игенне дә үзләре ашау белән генә, яхшы атларны үстереп, үзләре атлану белән генә канәгатьләнмәделәр, алар үзләренә кирәктән артыгын да эшли башладылар. Үзләре эшләгән тимер нәрсәләрен татарлар остякларга (бер фин кабиләсе) илтеп, аларда күп булган җәнлек тиреләренә (мехларга) алмаштыралар иде. Шулай ук артык икмәкләрен дә шул ук халыкларга биреп, алардан җәнлек тиреләре кебек хам әшья[1] (сырой материал)[2] алганнар.

Себер татарларына читтән дә мал килеп торган, Бохарадан аларга асылташлар, корыч кылычлар, төрле мамык материяләр, әмма Кытайдан фәгъфур (фарфор) савыт-саба, ефәк материяләр килгән.

**Шәһәрләр.** Сәүдәгәр, базаркяннәр[3], һөнәрмәндләрнең тора торган урыннары шәһәрләр булган. Бу шәһәрләрнең күбесе әле татарлар килмәс борын ук ясалган булсалар да, татарлар истихкямнар ясарга өйрәнеп килгәнлектән, аларны бер мәгълүм формага куйганнар һәм саннарын да күбәйткәннәр.

Татарлар шәһәрне «тура» дип, шул шәһәрләрдә торучыларны «туралы» дип йөргәннәр. Тура елгасы кырыенда Епанчина, Чинги-Тура, Тубыл вә Ишем сулары буенда иске яисә соңра Себер исемле шәһәрләре булган. Рус вәкаигънамәләре татарларның унбишләп шәһәрләре булганын белдерәләр. (Яулы-Тура, Тархан кальга, Кызыл Тура, Куллара, Балим, Сузга Тура, Мөхәммәдкол, Атникин, Касыйм Тура, Карачин шәһәрләре булган[4].

Татар шәһәрләре елга буенда, Казан шәһәре төсле биек яр башында булып, сөзәгрәк булган якларын берничә кат үр белән

[1] Хам әшья – чимал.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Базаркяннәр – алыш-биреш итүчеләр, сатучылар.
[4] Бу исемнәрнең татарча ничек аталганын белеп булмады. *(Авт. иск.)*

әйләндереп алган булган. Шәһәрнең эче агач койма белән әйләндереп алынган булып, шуның берничә җиренә капка ясалып, үр аркылы чыгарга күперләр ясалган булган. Шәһәр үзе зур булмыйча, биш йөз белән җиде йөз мөрәббәгъ[1] сажин булган. Шуның өчен анда гаскәр, хөкүмәт әһеле сәүдәгәрләр, аларның маллары гына булып, әһеле шәһәр тирәсендәге бистәләрдә, авылларда торганнар, куркыныч булса, шәһәргә килеп сыена торган булганнар.

**Тормыш.** Бу шәһәр вә авылларда, бистәләрдәге йортлар нарат, карагай яисә чыршы кебек бүрәнәләрдән салынган булган. Тәрәзәләре карындыктан (слюда)[2], ишекләре агач булып, тимер яисә бакыр тупсалы булган. Ишеккә куелган бикләре дә тимердән хайван сурәтендә эшләнгән була икән. Авылларда йортлар кечерәк, хәтта күп җирдә колгалардан ясалган булып, күчереп йөртергә уңайлы булган, чөнки халык бөтенләй үк утраклы тормышка чыгып җитмәгән булган.

Һәр өйнең эчендә учак (яисә чудал) булып, кирпечләрдән салынган булган. Дивар кырыйларында сәкеләр һәм сандыклар куелган булган. Савыт-саба исә чуен казан, бакыр комганнар, төрле һәндәси[3] рәвештәге бизәкләр төшерелгән чүлмәкләрдән гыйбарәт булган. Байларында исә савыт-саба Кытайныкы булган. Шул ук өйдә ярма тартыр өчен кул тегермәне булган, киемнәре исә борынгы Болгар, Казан татарларыныкы төсле булган. Табылган беләзек, балдак, алка, йөзек шикелле нәрсәләр шуны күрсәтәләр.

**Сыйныфлар вә аларның көрәше.** Башка татар җәмгыятьләрендә күргәнебезчә, Себер татарлары да бер-берсеннән бик аерылган ике кисәккә бүленгән иде. Түбән сыйныф аучы, балыкчы, мал асраучы, көтүче, игенче, һөнәрче (балта остасы, тимерче)ләрдән гыйбарәт булган. Югарыгы сыйныфның башында хан, аннан кала солтан, бик, морза һәм сәедләр булган. Соңгы сыйныф сәяси яктан да, байлык җәһәтеннән дә түбән сыйныфтан өстә торган. Бикләр, морзалар бер кабилә яисә ыругның башында торганнар, идарә иткәннәр.

[1] Мөрәббәгъ – квадрат.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Һәндәси – геометрик.

Аларның кайсы мөхкәм[1] шәһәрләрдә торып, зур җирләр вә күп түбән сыйныф халыкны биләп, бер аерым мөстәкыйль патшалар шикелле тора ала. Хәтта ханнарга да буйсынмый торган булганнар.

Рус вәкаигъневисләренең[2] белдерүенә күрә, түбән сыйныф белән югарылар арасында бик каты сыйнфый низаг вә көрәш булган. Аның сәбәбе исә мирза вә бикләренең түбәнге сыйныфларны кысулары, талаулары булган. Шуның өчен дә алар байларга вә хуҗаларына каршы кубып, берничә мәртәбә сугышканнары да мәгълүм.

**Чикләре.** Себер ханлыгы шактый зур бер дәүләт иде. Гаребтә аның чикләре Урал тауларының шәркый итәкләре, шимали чикләре, Тура елгасының башыннан башлана, Шәрыкка таба исә 58 дәрәҗә гарби-шимальгә кадәр сузыла да, әмма җәнүбтән киң сахра булганга, бер мәгълүм чикләре юк иде. Ләкин җир зур булса да, халык сирәк вә аз булган.

### 3.6. Мәскәү сәүдә капитализмы белән татар феодализмының көрәше вә аның нәтиҗәсе

**Мәскәү дәүләтенең үсүе.** Алтын Урда дәүләтенең инкыйразга йөз тоткан чагы Мәскәү кенәзлегенең үсүе белән бергә туры килә: Алтын Урда вакланып, вак халыкларга бүленеп, мәркәз зәгыйфьләнгән чакта бөтен великорусь халкы Мәскәү кенәзлеге тирәсенә җыела башлаган. Мәскәү кенәзләре башта Алтын Урда ханнарына «тарелка тотып», алардан ясак җыю хокукын алдылар, соңра Алтын Урда ханнары Мәскәү кенәзләрен олуг кенәз дәрәҗәсенә менгерделәр, аларга һәрвакытта башка күрше рус кенәзләре белән көрәшләрендә булышлык кылып тордылар. Ниһаять, Алтын Урда егылып, татар ханлыгы берлеген югалтып, вак ханлыкларга бүленгән чакта, Мәскәү Русиянең великорусь кавеме тора торган урыннарын үз кулына кертеп бетерде. Димәк, рус феодализмының сәяси ягы бу XVI гасырда бетте. Табигый, моның бетүенең төп сәбәбе экономика иде. Бу заманнан инде Русиядә товар хуҗалыгы туган. Шәһәрләр үскән. Натураль хуҗалык какшаган. Базарлар пәйда булган иде. Эчке сәүдә тууы белән бергә XVI гасырның ярымында Польша,

---

[1] Мөхкәм – нык.
[2] Вәкаигъневисләренең – елъязмачыларының.

Швеция аркылы тышкы сәүдә дә аз гына яратыла башлаган, Мәскәү зур базарга әйләнгән иде. Әүвәле Яурупага Ираннан килә торган маллар, йон, татлы исле нәрсәләр, дарулар һәммәсе дә Төркия аркылы Трабзон, Истанбул йортларыннан Яурупага озатыладыр иде. Әмма XVI гасырда 1502 елда Иран туфрагында бөтен Иранны җыеп, сәфәдиләр сөяләсе кул астында зур бер дәүләт төзелгәч, 1511 елдан алып, госманлылар белән Иран арасында сугышлар чыкты. Шуның аркасында Иран вә аның аркылы килә торган маллар иске юл белән Төркия аркылы килмеш була башлады. Яңадан Идел елгасы «ефәк юлына» әйләнеп китте. Шуның өчен бу малны Русия аркылы китерү өчен юллар эзләнә башлады.

Төркия үзе дә, бер яктан, мөһим сәүдә юлын кулга төшерү өчен, икенче яктан, сәфәвиләр белән сугышта аларның малын бер җиргә дә саттырмас өчен, Идел буен кулга төшерү максаты белән булса кирәк, Казан, Нугай вә Әстерхан эшләренә катыша башлады. Шуның өчен дә Төркия үзенең вассалы Кырым аркылы Казанга үзенең вассаллары булган Гәрәйләр сөяләсеннән Сәхиб, Сафа, Үтәмеш Гәрәйләрне куйды. Шуның өстенә дә Әстерхан вә Казан арасында тотыла торган балык мәсьәләсе дә зур роль уйный башлады. Бу заманда иген базары да туганга, Русиянең ул вакытта хаким сыйныфы булган «служилое сословие» аталган алпавытлар үзләренең хуҗалыгын зурайтырга тотындылар, моның өчен аларга яңа җир, яңа крестьяннар кирәк була башлады, бу җирләрне вә бу гаскәри-алпавыт иген игәрүче служилый сыйныф Идел буенда эзли башлады... Әлхасыйль, менә Русиядәге феодализмның бетә язып, сәүдә капиталы юлына керүе, Русияне Идел буе мәсьәләсенә әһәмият бирдертә башлады, шуннан XVI гасырдан алып Иделне буып торучы Казан ханлыгына һөҗүм вә тәҗавез[1] сәясәте башланды.

Табигый, татар феодализмы бу сәясәткә каршы сугышып җавап биреп торды. Вә бу бер-берсенә каршы булган ике иҗтимагый әсас бер-берсе белән эт белән мачы шикелле бертуктаусыз сугыша башладылар. Табигый, Казан ханлыгындагы сәүдәгәр аксөякләр Русия белән план ясау, солых ясау ягында булдылар. Менә, ихти-

[1] Тәҗавез – басып алу, буйсындыру.

мал, Мәскәү яклы Җангали, Шаһгали ханнар да – шул партиянең нөмаяндәләредер[1].

Билгеле, шушы икътисади вә аннан килеп чыккан иҗтимагый вә сәяси сәбәпләр бу мәсьәләдә идеология дә ясадылар. Мәсьәләне дин өчен көрәш итеп куйдылар, русның Саратов өлкәсе тарихын язучы Гераклидов[2] шикелле иске фикерле хәзерге бәгъзы тарихчылары да бу мәсьәләне тәре белән ярымайның көрәше иттереп тасвир иттеләр[3].

**Мәскәүнең сәясәте.** Мәскәү хөкүмәте моның өчен бик кызык бер сәясәт йөртә башлады. Ул сәясәт булса, татар урдаларын бер-берсе белән сугыштыру иде. Моның өчен Мәскәү хөкүмәте бер-бер урдадан качкан, куылган ханзадә мирзаларны Мәскәүгә җәлеп кыла башлады, әгәр бер урдадан куылган ханзадә вә тәэсирле мирза, качып, Русиягә сыенырга килсә, Мәскәү хөкүмәте ул кешене бик яхшы кабул итә, аңарга идарә кылырга шәһәрләр, иген игә торган җирләр, урманлыклар бирәдер иде. Шулай ук аларны чукындыру өчен дә тырышалар иде. Чөнки мондый ханзадәләрнең чукынуы белән аларның кайтып хан була алуыннан һәм халыкның башында торуыннан котыладыр иде, шулай ук мондый ханзадәләр аркылы төрле урдаларның хәлләрен, сәясәтләрен, аларның хөкүмәтләренең серләрен белеп торадыр иде.

**Касыйм ханлыгы.** 1467 елда Ока суының кырыенда хәзерге Рязань губернасының бер кисәгендә «Касыйм ханлыгы» исемендә бер кечек дәүләт вөҗүдкә килде, башта бу ханлык Олуг Мөхәммәднең Мәскәү кенәзен җиңгәч ясалган шартнамә буенча аның углы Касыймга бирелгән җирдә ясалды. Соңра ул җиргә төрле җирдән татар җыеп, бер дәүләт шикелле нәрсә ясалды. Ләкин Казан дәүләте зәгыйфьләнеп, Мәскәү кенәзлеге үсә башлагач та, Мәскәүнең көче җитсә дә, бу ханлыкны бетермәде. Сәяси максат белән саклап асрады.

[1] Нөмаяндәләредер – вәкилләредер.
[2] Александр Александрович Гераклитов, (1867–1933) – Саратов университетының мордва теле һәм мәдәнияте бүлеге профессоры, әлеге төбәк тарихын өйрәнүче галим. «Саратов. Краткий исторический очерк» (1919), «История Саратовского края в XVI–XVIII вв» (1923), «Саратовская мордва (к истории мордовской колонизации в Саратовском крае)» (1926) кебек хезмәтләр авторы.
[3] Бу әсәр 1923 елда басылган. *(Авт. иск.)*

Хәзерге Касыймов аталган һәм әүвәлдә «Городецкий»[1] аталган шәһәрне пайтәхет ясады. Рязань губернасының бу урыны ул заманнарда фин кавеменнән булган әһалисе иде. Бу ханлык бер мөстәкыйль дәүләт түгел, монда Мәскәү кенәзе теләсә кемне хан итеп куя, татар урдаларыннан качкан кешеләр монда килеп сыеналар, кайсысы шул Мәскәү хөкүмәте тарафыннан хан итеп тәгаен ителәләр. Бу ханнарның үзләренең гаскәрләре була, ләкин алар Мәскәүдән рөхсәтсез бер эш кыла алмт иииииииииииииииыйлар иде. Ул ханнар бары Русиянең дошманнары белән генә сугыша алалар, бигрәк тә Мәскәү хөкүмәте аларны, аларның гаскәрләрен татар илләрен алу эшендә истигъмаль кыладыр[2] иде. Бу гаскәр татар ханнарының командасында күрелсә дә, асылда боларның өстендә карап, хәфиялек кылып[3], рус «глава»лары (түрәләре) торганнар. Бу ханлыкны ясауның башлыча сәбәпләре шулар: Касыйм ханлыгында кирәк вакытта Казан, Әстерхан тәхетләрендә үзләренең тарафгирларын хан итү өчен ханзадәләр Мәскәү яклы итеп тәрбия кылыналар иде. Бу үзенә күрә Мәскәүнең татар патшалыклары өчен ясалган «хан заводы» иде. Шуның өстенә дә Касыйм ханлыгы Төркиянең күзен буяу өчен ясалган бер дәүләт иде. XV–XVI гасырларда Төркиянең ифрат куәтле бер заманы булып, бу вакытта Төркиянең бөтен мөселман дәүләтләренең башы булып, аның солтаны да үзен хәлифә итеп игълан кылган заманасы иде. Шуның өчен Төркия азмы-күпме башка мөселман җирләренең хәлләрен тикшереп торадыр. Менә Русия Касыйм ханлыгын ясап, анда мәчетләр салырга рөхсәт итүе белән Төркия каршында мөселманнарга хилаф[4] дәүләт түгел икәнлеген күрсәтәдер иде. Шуның аркасында Казан, Әстерхан илләрен теләсә нишләтә ала, Төркия аның өчен «мөселманнарга тиясең» дип бәйләнә алачак түгел. Шуның өстенә дә Русия үзенең татар вә башка дәүләтләр белән сугышында ул Касыйм ханлыгының гаскәрләре белән файда итәчәк, бигрәк тә бу гаскәрләр башка татар гаскәрләре белән сугышырга бик кирәк иделәр. Болай булганда татар урдаларын алганда рус бояр балаларының каны урынына күбрәк татар

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Истигъмаль кыладыр – кулланадыр.
[3] Хәфиялек кылып – күзәтчелек итеп.
[4] Хилаф – каршы.

каны куелачак иде. Вакыйган, эш шулай булды да. Казанны алганда илле мең Касыйм татарлары, Иван Грозныйның Ливония белән сугыш кылганда йөз илле мең касыймлылар иштиракь кылдылар.[1]

Касыйм ханлыгы озак тормады, Казан, Әстерхан Русия кулына кергәч, Төркиядән дә Мәскәү курыкмый башлап көчәйгәч, ул кирәк булмады. Шуның өчен 1678 елда ул ханлык бетерелде.

**Кырым Урдасы, Казан, Әстерхан, Русия.** Алтын Урдадан аерылып, хәзерге җәнүби Русия һәм Кырым ярыматавыннан ясалган Кырым урдасында Гәрәй сөяләсеннән (тармагыннан) булган ханнар утырганнар. Кырым урдасы XV гасырның икенче ярымыннан бөтенләй госманлыларга табигъ булып, госманлы солтанлыгының мохтар[2] бер өлкәсе булып киткән иде.

Казан дәүләтендә Олуг Мөхәммәд хан сөяләсе хөкүмәт сөргән чагында Казанга булышса да, аларның эшләренә күп катышмыйдыр иде, чөнки Гәрәйләр сөяләсе Олуг Мөхәммәд белән дус булган. Ләкин 1519 елда бу сөяләә киселеп, аның урынына Касыймда тәрбияләнгән, хәйләкәр, ямьсез, усал, Мәскәүнең колы Шаһгали хан патша булганнан соң, Кырым, Казан эшләренә катыша башлаган. Шаһгали Кечек Мөхәммәд җенесеннән булып, соңгысы исә Гәрәйләргә дә, Олуг Мөхәммәдкә дә, аның нәселенә дә дошман иде.

Шуның өчен дә кырымлылар хәзер Казан тәхетенә Гәрәйләрне куеп, ике урданы (Кырым, Казан) бергә кушарга уйлый башлаганнар. Шуңа күрә Казан тәхетенә Гәрәйләр җенесеннән булган Сәхиб Гәрәй, Сафа Гәрәй, Үтәмеш Гәрәйләр хан булганнар. Шул рәвешчә, Кырым аркылы Казан да Төркиягә табигъ булган. Бу ханнар заманасында Казанда голәма хотбәләрдә дә Төрек солтанын яд итәләр. Русиянең царьларына язган хатта: «Казан, Әстерхан безнең йортыбыз, аларга тимәгез, әгәр тисәгез, безне Мәскәүдә көтегез» дигән тәнбиһләр[3] дә булгалый иде. Шулай ук кырымлылар Әстерхан эшләренә дә катышалар.

Казан, Әстерхан илләрен бергә кушып, Гәрәйләр сөяләсе кул астына бер урда ясамакчы иделәр. Казанга Сәхиб Гәрәй ханны куйгач, 1535 елда Кырым ханы Әстерханны да алган иде. Ләкин

[1] Иштиракь кылдылар – катнаштылар.
[2] Мохтар – ирекле, бәйсез.
[3] Тәнбиһләр – кисәтүләр.

нугайлар моңар каршы сугыш ачып, кырымлыларны куганнар. Ул заманнар XVI гасырда кырымлылар Төркия хөкүмәте аркасында көчле булып, Русиядән курыкмаганнар.

**Мәскәү.** Мәскәү хөкүмәте Әстерхан, Казан йортларына Гәрәйләрнең тәэсирен бетерер өчен төрле хәйләләр кыла: Казан йортына Кечек Мөхәммәд нәселеннән булган Касыйм ханнарын (Шаһгали, Җангалине) куйды. Шулай ук акча, сәясәт белән Мәскәү партиясе куәтле иде – алар Әстерханда да Мәскәү яклы нугай мирзаларын котыртып инкыйлаб ясатып, үзләренең Мәскәүгә хилаф Кырымны яклаучы ханнарын котырталар, Мәскәү җирендә тәрбияләнгән царьның икмәк-тозын ашаган ханнарны китереп куялар иде.

Әлхасыйль, бу ике бер-берсенә атыларга торган Мәскәү вә татар дәүләтләре арасында сугыш бер гасырга якын туктаусыз булып торган. Бу сугышлар да ике җанварның берсе бетү белән туктарга тиеш булган. Ике як та килешеп, үзләренең табигый чикләренә чигенеп ята алмаганнар, чөнки андый чикләр, затән,[1] булмаган: Мәскәү белән Казан арасын аеручы зур таулар, зур диңгезләр, зур чүлләр юк, билгакес[2], ике дәүләтне бергә куша торган тигезлек, аның өстендә агып, ике өлкәне икътисади яктан бергә кушып ятучы Идел вә аның тармаклары бар.

**Бу сугышта кем җиңәргә тиеш?** Бу озак, авыр сугышларда алдан ук кем җиңәсе мәгълүм иде. Татарларда борынгы батырлык, борынгы сугышчылык калган, ләкин алар икътисади, сәяси вә мәдәни яктан руслардан артта калганнар. Мәскәү крестьяны, алпавытына илне татар һөҗүменнән саклар өчен сугышабыз дигән шигарь бик яхшы тәэсир итәдер, чөнки ул чын мәгънәсе белән рус иде, икенче халык җиренә багланган, аның икътисади тормышы шул тынычлыкка багланган иде. Ярымкүчмә татарга исә бер җирдән җигелеп күчеп китүе ул кадәр авыр шикелле тоелмый, ул, күчеп киткәч, нинди бәлаләр көткәнен тиз аңлый алмаган. Шуның өчен дә Мәскәүнең татар урдалары белән сугышы бер җитди нәрсә булып күренгән булыр.

Сәяси яктан русларның хөкүмәт төзелешендә заманасына күрә татарларныкына караганда тәртиплерәк булган. Бу заманда рус-

[1] Затән – нигездә.
[2] Билгакес – киресенчә.

ларның барчасы диярлек Мәскәү тирәсенә җыелган, царьлары да үзләренең хакимиятләрен нык әсаска корырга тырыша башлаганнар, бертөрле тәхет вәрасәте хакындагы гадәтләр канунлашканнар, шуның аркасында тәхет низаглары да кими төшкән. Хөкүмәт мөәссәсәләре дә (приказлар ысулында) ясалган, канун мәҗмугалары чыгып, хөкем эшләре дә заманасына күрә чибәр куелган булган. Әмма татар урдаларында бу чакта бөтенләй анархия бара: бикләр, мирзалар, сәедләр хөкүмәтләре белән уенчык белә уйнаган шикелле уйныйлар, сөяләләр берсе артыннан берсе алмаша. Эчке сугыш, мәгълүм бер низам вә канунның юклыгы – барчасы да дәүләтләрне зәгыйфьләткәннәр.

Мәскәү үсеп килә торган Гареб-Яурупа мәдәниятенең күршесендә тора, үзе тагы христиан динендә булганга, Яурупага ят та түгел иде. Әмма урдалар Казан төшәр алдыннан XVI гасырларда мәдәни җәһәттән зәгыйфьләнгән. Бу заманда инде ислам мәдәниятенең сүнгән вакыты, Казан, мөселман йорты булганга, тәгассыблы[1] Яурупа белән мөнәсәбәте аз, шуның өстенә Казан белән Яурупа арасы ерак булып – ике арада Мәскәү иле ятадыр иде. Казан вакытын мөттәсил[2] сугышта, низагта үткәргәнгә, үзе мәдәният ясый алмый. Мәскәүнең мәдәнияте күтәрелгәнгә, руслар инде мәдәният сәмәрәсе[3] булган яңа кораллар истигъмаль кылалар, туп, мылтык истигъмале Русиядә XV гасырның ахырларында ук истигъмальгә кергән. Бу коралларны истигъмаль кылу эшендә Яурупа (бигрәк тә немец, поляк) мөһәндисләре[4] хезмәт итәләр, татарлар исә мондый коралны күп истигъмаль кылмыйлар. Аңар әһәмият бирмиләр, аларга туп истигъмален өйрәтүче юк. Дөрес, XVI гасырда госманлы төркләренең ардусында туп бик яхшы коелган, ул кораллар Кырым аркылы бераз китереләләр. Ләкин Кырым белән Казанны аерып торган үтә алмаслык сусыз, юлсыз далалар исә, ул заманның юлсызлыгы аркасында авыр туплар китерергә ирек бирмиләр. Татарларда да, бераз булса да, аларны истигъмаль кыла белүчеләр юк хөкемендә иде.

[1] Тәгассыблы – фанатик.
[2] Мөттәсил – өзлексез.
[3] Сәмәрәсе – җимеше.
[4] Мөһәндисләре – инженерлары.

Мәсәлән, бер вакытта руслар килеп Казанны мөхасарә кылганда[1] (1524) татарларның бер тупчылары үтерелгәч, казанлылар солых ясарга мәҗбүр булганнар.

Татарларның гаскәрләре бары тик гайре монтазам[2] атлы гаскәр белән укчы җәяүле гаскәрләрдән мөрәккәб[3] булган. XVI гасырда руслар мылтык белән коралланган тәртипле өйрәтелгән «стрелицин» исемендә җәяүле вә атлы гаскәр ясаганнар, әмма татарларның гаскәри тәртипләре Чыңгыз заманасындагы шикелле генә булган. Билгеле, XVI гасырда яңа кораллар, әсбаплар чыккач, мондый XIII гасыр кораллары, тәртипләре белән каршы тору мөмкин түгел иде. Менә шушы сәбәпләрдән Мәскәү татар урдаларын җиңәргә тиеш булган.

Нугай урдасы тагын да зәгыйфь иде. Дөрес, нугай мирзалары Мәскәү кенәзләренә язган хатларында «йөз мең гаскәребез бар» дип мактаналар, ләкин бу гаскәр шул өйрәтелмәгән кылыч, сөңге, ук белән генә коралланган низамсыз атлы гаскәрдән генә гыйбарәт булган. Шуның өстенә дә Мәскәү яклы мирзалар илсөяр башлыкларның Казан, Әстерханны якларга булган ниятләренә балта чабып торганнар.

Бер вакытта Казан төшәр алдыннан төрк солтаны рус яклы булган нугай мирзасы Исмәгыйльгә хат язып, Төркия гаскәр җибәргәнче, Казанны саклашып торырга боерган. Ләкин Исмәгыйль берничә йөз мең кадак, бер-ике ау лачыны, алтын зәгъфран, ияр бәһасенә Мәскәүгә сатылган. Әлхасыйль, шундый сатлыклык һәрбер татар урдасында хөкем сөргән. Комсыз татар аксөякләре, ханнары тун, кием, алтын, тәмле нәрсәләр бәһасенә илләрен сатарга хәзер булганнар, әхлакның бозылуы һәм ахыр чигенә җиткән. Мәскәүдән килгән бүләкләр теләсә нинди татар ханлыгының сараенда сәясәтне үзгәртә алган.

Казан урдасы инде XVI гасырның башыннан алып Русиянең бер мохтар вилаятенә әйләнгән. Ханнарның, хәтта Кырым урдасыннан Гәрәйләр җенесеннән булганнары Мәскәүнең рөхсәтеннән башка хан була алмыйлар. Хәтта өйләнү өчен дә рөхсәтне Мәскәүдән

[1] Мөхасәрә кылганда – камап алганда.
[2] Гайре монтазам – тәртипсез.
[3] Мөрәккәб – тупланган.

алырга тиеш булган. Шулай итеп, Казан урдасы XV гасырның ахыры – XVI гасырның башыннан алып үзенең истикълялиятен[1] югалткан, бары тик Сәхиб Гәрәй, Сафа Гәрәйләр ханлыгы заманасында бераз мөстәкыйль булып торган.

**Казан урдасының егылуы.** Мәскәү хөкүмәте тәхеткә Иван Грозный утырмас борын Казанны бөтенләй алу, ханлыкны бөтенләй тарату сәясәтен тотмыйдыр иде. Ул бары андагы Мәскәү партиясенә илһам бирү, аны куәтләп, Казан урдасын зәгыйфьләтү белән генә шөгыльләнгән. Иван Грозный тәхеткә утыргач, катгый сәясәт йөртелә башланды. Бу вакытта Гәрәйләр, Төркиянең куәтенә таянып, бөтен Идел буена хуҗа булу, бөтен татар илләрен Алтын Урда ханлыгы күк бер берлек кул астына җыю сәясәтен йөртә башлаганнар. Мәскәү өчен вакыт үткәрергә ярамыйдыр иде. Шуның өчен Иван Грозный бер-бер артлы рус гаскәрләрен Казанга таба җибәрә торган. Аның заманасында Казанга ике мәртәбә сәфәр ясалган, өченчесендә Казан алынган.

Монда Мәскәүнең корал көче генә хәрәкәт итмәде, бөтен сәясәт хәрәкәткә китерелде. Казан партясенең башы Мәскәүнең ялчысы Шаһгалине Иван ике мәртәбә Казанга хан итте. Икесендә дә халык аны куып җибәрде. Ләкин Шаһгали үзенең эшен эшләде: һәр килүендә Казанда үзенә, бинаән галәйһи[2] Мәскәүгә хилаф партия әгъзаларын үтереп китте. Туп, мылтыкларны бозды, дарыга су сипте. Ниһаять, аның тәхет өчен көрәшендә Казанның Тау ягы русларга бирелде, Шаһгалинең киңәше белән Казанның күз алдында 25 чакрым җирдә руслар тарафыннан Зөя кальгасы салынды. Шулай итеп, Казан иленең яртысы кулдан китте.

Ниһаять, 1552 елда Мәскәүдәге хәрби киңәш мәҗлесендә (шунда Шаһгали дә бар иде) Казанга сәфәр кылынырга, аны алырга карар кылынды. Йөз илле мең гаскәр, йөз илле мең авыр туп, немец мөһәндисләре, Шаһгали командасындагы илле меңгә якын татар гаскәре белән судан һәм корыдан гаскәр хәрәкәт итте. Бу вакытта Кырым хөкүмәте русларны Казанга җибәрмәс өчен Русиягә һөҗүм кылса да, җиңелеп, Кырымга чигенде, шул рәвешчә, Мәскәү хөкүмәте кырымлылардан котылгач, рәхәтләнеп Казан өстенә йөрде.

[1] Истикълялиятен – бәйсезлеген.
[2] Бинаән галәйһи – шул сәбәпле.

Казан дәүләтен барысы алтмыш мең гаскәри көч мөдафәга кылды[1]. Утыз мең кеше Казанның эченнән хәрәкәт итте. Калган утыз меңе Казанның тирәсендә торып, Мәскәү гаскәрен борчып, бертуктаусыз һөҗүм кылып торды. Соңгы гаскәр алты булып, бу гаскәр эчендә бер, ике, өч мең нугай вә чирмеш гаскәрләре дә булган. Казан төшәр алдыннан Төрек солтанының мәслихәте һәм кушуы белән нугайлар Казанга Ядкәр исемле ханзадәне хан итеп, аңар гаскәр дә биреп җибәргән.

40 көн татарлар гайрәт белән сугышып, илләрен мөдафәга кылалар. Ниһаять русларның тупларына яхшы мөһәндисләрнең Казан истихкямен[2] казып, дары тутырып күтәртүләренә чыдый алмадылар. Казан бирелде. Ядкәр хан[3] әсир төште, Казандагы ир затыннан булган күп кеше Иванның рөхсәте белән кылычтан кичерелде, бик күп хатын-кыз, бала-чага әсир ителеп алынып, Мәскәүгә җибәрелде. Шулай итеп, 1552 елның 2 октябрендә Казан дәүләте үзенең ирекле тормышын югалтты.

**Әстерхан, Нугай урдаларының Русия кулына керүләре.** Казан алыну белән руслар Идел елгасының урта агымын алганнар. Шул заманнан игътибарән Яурупаның Азия вә төрек халыкларына тәҗавезе[4] башланды. Инде нәүбәт Әстерхан, Нугай урдаларына җиткән иде. Моның өчен дә Мәскәү дәүләте шул ук Казанга тоткан сәясәтен йөртте, Әстерхан Ямгурчы[5] исемле ханы, аның тарафдарлары, нугайларның Мәскәүгә каршы булган мирзалары һәм партияләре белән хәрәкәт кыла башлаган. Нугайларда ике төрле партия булган. Моның берсенең башында Йосыф, икенчесенең башында Исмәгыйль исемле мирзалар һәм аларның балалары торганнар, Исмәгыйль мирза партиясен руслар мөмкин кадәрле яклыйлар, аларга бүләкләр җибәрәләр, Йосыф партиясенә каршы сугышу өчен мылтык, туп шикелле кораллар, хәтта стрелец фиркалары

[1] Мөдафәга кылды – каршы торып сугышты.
[2] Истихкямен – ныгытмасын.
[3] Ядкәр Мөхәммәд хан (?–1565) – Казан ханлыгының соңгы ханы (1552). Казанны камаган рус гаскәрләренә каршы көрәшне оештыручыларның берсе. Әсир төшә, Симеон Касаевич исеме белән чукындырыла.
[4] Тәҗавезе – басып алуы, буйсындыруы.
[5] Ямгурчы хан (?–1555) – Әстерхан ханы (1540 еллардан). Нугай морзалары ярдәмендә тәхеткә утыра.

җибәрәләр иде. Йосыф исә Төркия һәм Кырымга таянырга омтыладыр иде. Мәскәү хөкүмәте 1554 елда нугайларның Мәскәү партиясенә утыз мең гаскәр белән килеп, Әстерханны алды. Хан хатын бала-чагаларын калдырып качты. Мәскәү үзендә хезмәттә торган үзе яклы Дәрвиш ханны[1] китереп куеп, шуның белән солых ясады. Бу солых буенча инде Әстерханның истикъляլиятe бөтенләй беткән иде.

Дәрвиш Русиягә ел саен утыз мең акча (Алтын)[2] һәм өч мең зур балык бирергә булды. Русия балыкчыларына Әстерхан суларында балык тоту хокукы бирелде. Әгәр Дәрвиш хан үлсә, дәүләт теләсә кемне хан итә алмаячак, бәлки Мәскәү хөкүмәте кемне теләсә, шуны куя алачак булды. Димәк, Мәскәү Әстерханга нисбәтендә шул Казанга тоткан сәясәтне тотты. Шушы вакытларда нугайлар эчендә дә үзара каты сугышлар бара, ике партия бер-берсе белән бик каты сугышалар иде. Ниһаять, Йосыф мирза үтерелеп, Исмәгыйль өстен чыгып, бөтен Нугай урдасына баш булган, ләкин эш моның белән генә бетмичә, Йосыфның балалары кырымлылар белән дус булып, һәрвакытта Исмәгыйльгә һөҗүм кылып торалар иде. Әстерханда Дәрвишнең хәле дә шәп түгел иде. Качкан хан килеп, һаман һөҗүм кылып торадыр, Дәрвишкә Төркия хөкүмәте дә, Кырым да дошман иделәр. Дәрвиш ике ут арасында калган иде. Ниһаять, Дәрвиш Кырым һәм Йосыф балалары партиясе белән хәрәкәт кыла башлап, русларга каршы яшерен хәрәкәткә башлаган иде. Нугайларның Мәскәү яклы Исмәгыйль партиясе үзенең дошманы Дәрвиштән котылу өчен башка чараларга керешкән, ул чара Әстерханның истикъляլиятен бөтенләй бетереп, аны Казан шикелле Русиянең бер өлкәсе итеп калдыруны Русия хөкүмәтеннән таләп кыла иде. 1550 елда Мәскәүнең гаскәре килеп, Әстерханны алды. Бу килүдән бер генә тамчы да рус каны түгелмәде. Дәрвиш хан качты. Нугайлар үзара талашу, сугышуда дәвам кылдылар. Кырым, Төркиядән китерелгән тупларның һәммәсен дә русларга нугайлар үзләре бирделәр. Шул рәвешчә, Әстерхан бөтенләй Русиягә кушылды.

Хәзер Мәскәү бер дә сугыш кылмыйча нугайларны да үз кул астына кертте. Әстерхандагы рус воеводаларының эшләре бер генә нәрсәдән гыйбарәт булды: ул исә нугай мирзаларын бүлеп, бер-берсе

[1] Дәрвиш Гали хан (?–1558 тирәсе) – Әстерхан ханы (1554 елдан).
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.

белән сугыштыру, аларны Төркия һәм Кырымга дошман итәргә тырышу иде. Нугайлар да үзара кисештеләр, һәрбер ягы зәгыйфьләнделәр. Алар акрынлап бер ыруг артыннан икенчесе Мәскәү хөкүмәтенә буйсынды. Шулай итеп, Идел буенда бер генә төрле дә мөстәкыйль татар дәүләте калмады. Мәскәү аларның барысын да йотты.

Димәк, феодализм әсасыннан үтә алмаган Казан, Әстерхан урдалары һәм ыруг патриархат тормышыннан яңа гына феодализм нигезенә күчә башлаган Нугай урдалары сәүдә капитализмына күчеп бара торган Мәскәү царствосының аяк астына килеп еглады. Бу эш татарларның органик тәрәккыйләренә, аларның дәүләт төзелеше белән бергә үсүләренә, бер яктан, зарар итсә, икенче яктан, бу эш феодализм ныгытмасын татарлар өстеннән алып ташлап, татарларга сәүдә капитализмына тизлек белән күчәргә ярдәм итте. Ләкин бу эш татарның бөтен сыйныфларына да авыр булды. Бу операция татарлар өчен ифрат читен булды. Шуның өчен Казан алыну белән генә эш бетмәде: Мәскәү тиз көндә бөтен Идел буеның Мәскәүгә каршы кубуы факты алдында калды. 1553–1558 елга кадәр кузгалышы дәвам кылды. Бу кузгалышы, бер яктан, татар феодалларының үзләренең хакимиятен кире кайтару өчен татар массасының җирне Мәскәү алпавытларына бирмәү өчен ясалган иде.

Мәскәүнең бу кузгалышны бастыруы исә Казан өлкәсенең моңарчы алынмаган эчке җирләрен алу димәк иде.

### 3.7. Идел буенда татар-фин кузгалышы

**Казан өлкәсендә Мәскәү идарәсе.** Мәскәү хөкүмәте Казан өлкәсен кул астына керткәч тә, үзендәге идарәне бу өлкәдә дә төзеп җибәргән. Бөтен казак өлкәсенә баш иттереп бер наместник боярин, янә шуның өч данә меньший боярин дип, яисә меньший воевода дип йөртелә торган могавиннәре[1] куелды. Илдәге бар хакимият шул наместник кулына бирелгән иде.

Озакламый Казанга Мәскәүдәге күк зинданнар салганнар, Казанның ватылган истихкямнәрен[2] төзәтеп, Казанны саклау эшенә бик зур әһәмият биргәннәр иде. Чөнки Казан үзе алынган булса да,

[1] Могавиннәре – ярдәмчеләре.
[2] Истихкямнәрен – ныгытмаларын.

аның тирә-юнендәге татарларга Мәскәү хакимияте кереп җитмәгән, көн-төн истихкям диварларында сакчы стрелецлар коралланып саклап йөргәннәр. Калада чиркәүләр салганнар, Казан илендә монастырьлар салу эшенә дә бик зур әһәмият биреп керешкәннәр, Казан шәһәренең эченнән татарларны куганнар. Алар хәзерге Иске Бистәгә төшерелгәннәр, Казанның капкаларыннан бер генә гайре руска да, воеводадан аерым рөхсәт алмыйча, калага керергә ясак ителгән.

Иван Грозный Казанга Мәскәү һәм башка рус шәһәрләреннән боярлар вә аларның балаларын күчереп утырта башлаган, алар белән бергә рус крестьяннары да киләләр иде. Казан алынганга берничә көн үткәч тә, хөкүмәт фәрман чыгарып, ясак түләргә кушты. Ясак шул иске ханнар заманасындагы үлчәүдә алынып килде. Ясак хөкүмәткә җәнлек тиресе, бал, балавыз белән бирелә, чөнки халыкта акча аз. Ясак олы кешеләрдән тулы алынып, яшьләрдән яртысы гына алынадыр иде. Бу исә һәркемнән алына торган гомуми ясактан башка «Поминочный ясак»[1] аталадыр иде. Бу царь һәм аның вәли гаһденә[2] бирелә торган бүләк иде. Янә бер «Десятичный ясак»[3] дигәне булып, һәрбер малның уннан бере хәзинәгә бирелергә тиеш иде. Казан алыну белән Мәскәү хөкүмәте өлкәгә рус идарәсе кертсә дә, ул аны, югарыда әйтелгәнчә, наместник тарафыннан идарә кылдыра һәм өлкәне аерым бер җир итеп танып, аны «Царство Казанское» дип атап йөртә, царьлар үзләренең титулларында да «Царь Казанский» дигән бер кушымтаны арттырганнар иде. Бу эш 1708 елда бөтен Русия губерналарга бүленгәнче дәвам кылды.

**Кузгалышның сәбәпләре.** Югарыда без кузгалышның төп сәбәпләрен әйтеп уздык. Ләкин моны без хәзер бераз тәфсиллерәк итеп сөйлибез. Казан өлкәсенең бөтен халкы бөтен сыйныфлары Русиягә кушылудан наразый[4] иде. Чирмеш, чуваш шикелле халыклар Казан дәүләте исән чакта ирекле рәвештә үзләренең башлыклары идарәсендә торалар. Аларның малына, гадәтләренә, хокукларына беркем дә катышмый. Әмма Мәскәү хөкүмәте хәзер аларга катыша башлады. Аларның кенәзчекләренең царьга бер дә шартсыз буйсынуын һәм

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Вәли гаһеденә – варисына.
[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[4] Наразый – канәгать түгел.

халыкның ясак түләвен таләп кыла башлады. Казан ханлыгының төп хаким сыйныфы булган феодаллар (бикләр, карачылар, мирзалар, угланнар һәм тарханнар) булса, болар, алда әйтелгәнчә, күбесе Мәскәүгә кушылудан наразый иделәр. «Боларның төп хуҗалыклары чит халыклардан алынган коллар белән эшләнгән, Мәскәү әле, Казан алынганчы ук, рус колларын азат иткәнгә күрә, боларның хуҗалыклары иң мөһим булган эшче кулның бер кисәген югалтачаклар иде. Шуның өстенә дә моңарчы Мәскәү белән булып килгән сугышлар боларга күп ганимәт мал вә коллар бирәләр, алар шуларны мөселман илләренә сатып баеп торганнар, әмма хәзер бу эш бетәчәк, сугыш кылу мөмкин булачак түгел иде. Шуның өстенә дә боларның Казан алынганда мал-мөлкәтләре җимерелгән дә ватылган, Казанда калган бала-чагалары әсир ителгән, кардәш-ыруглары үтерелгән, шулай ук аксөякләрнең җирләре үз кулларында калачак түгел, аларны Мәскәү хөкүмәте бояр һәм попларга бүлеп бирәчәк. Аксөякләр, Мәскәү килеп илне алгач, үзләренең әүвәлге сәяси тәэсирләрен дә югалтканнар. Дөрес, аларның Русия яклы булганнарына яхшы, әмма аларның истикъялияләт яклылары да булып, Мәскәүгә искедән бирле дошман булып килгәннәре дә күп; шуның өчен аксөякләрнең бер кисәге дә Казанның Русия кул астына керүеннән наразый иделәр.

Үзләренең феодал һәм феодалларның илһамчысы булган голәма һәм сәедләр исә берничә сәбәптән Казанның истикъялиятенең югалуыннан рази түгел иделәр. Бер яктан, алар Мәскәүнең чукындыру сәясәтен бик яхшы беләләр, чөнки Мәскәү җиренә күчкән мирзалар, бикләр, әсир төшкән гаскәриләр чукындырылалар, әгәр Мәскәү Казан илендә урынлашса, мөселман дине өчен начар буласын, хөкүмәт христиан дине җәяргә тырышасын алар сизәләр. Казан алынгач та, Иван Грозныйның әмере белән мәчетләрнең җимерелүен, күп кешенең кылычтан кичерелүен, калган татарлар каладан, хәтта шәһәргә якын авыллардан куылуын алар үз күзләре белән күргәннәр. Бигрәк икътисади яктан мөселман голәмасы Мәскәүгә дошман булдылар. Алда сөйләнгәнчә, Казан өлкәсендә сәедләр һәм голәма бик хөрмәттә иделәр. Хәзер илдә хөкүмәт христиан булганнан соң, мөселман голәмасы бөтен тәэсирен югалтачак, шуның аркасында борынгы икътисади байлыкларын да югалтачак, аларга иганә кылучы ханнар, мөселман хөкүмәте булмаячак. Әүвәл замандагы күк, зур җир-

ләр биләп тора алачак түгелләр, әүвәл мөселман хөкүмәте бар чагында сәедләр сәяси яктан да куәтле иделәр. Инде хөкүмәт Мәскәү хөкүмәте булгач, мөселман голәмасы урынын христиан поплары тотачагын да алар яхшы беләләр. Шушы сәбәпләрдән алар Мәскәүгә каршы вә истикъляль тарафында иделәр.

Сәүдәгәрләр дә Мәскәүгә дошман иделәр. Рус сәүдәгәрләре Казан алыну белән аларның сәүдәләрен кулларыннан ала башлаганнар, шәркый халыклары Казан алыну белән туры Мәскәүгә яисә башка җирләрдәге ярмаркаларга йөриячәген алар беләләр иде. Иван Грозныйның Казан ярмаркасын Макарьевка күчергәннән нинди зур зарар килгәнен бу сәүдәгәрләр яхшы беләләр иде.

Бигрәк Мәскәүгә буйсынырга татарның чын халкы булган ярлы халык крестьяннар каршы килделәр. Аларны рус чиновниклары Казан алынгач ук кыса башладылар. Имана (ясакны) бик тыгызлап җыя башладылар, сугышларда рус казаклары гаскәрләре аларның авылларын таладылар, алар Казан, Русиягә кушылгач, рус мөһаҗирләре килүдән дә курка башладылар, чөнки элек Казан алынмас борын руслар тау ягын алгач, руслар килеп утырып, татар һәм башка гайре русларның крестьяннарын кысрыклый башлаганнар иде. Шуның өстенә дә татар крестьянына тагы бер куркыныч нәрсә бар, ул да булса, татар феодалларының кулларында булган рус коллары азат ителгәч, бу феодалларның татар крестьянын кол итәчәге мәгълүм иде.

**Ихтилалның[1] барышы.** Казан вә әтрафы руслар тарафыннан 1552 елда алынса да, аның бөтен җиренә руслар кереп җитә алганнары юк иде. Борынгы заманда Казанны чолгап алган калын урманнар, агар сулар, баткаклык, сазлык-күлләр эчендәге татар авыллары һәммәсе дә бирелеп җитмәгәннәр иде. Казан алынганда Казанны ташлап, рус гаскәрен ярып, берничә мең татар чыккан, бу татарлар урман араларындагы татар авылларына барып, халык арасында агитация йөртә башлаганнар. Хәрәкәтнең башында бәгъзы сәедләр, муллалар, бикләр, мирзалар, йөз бикләре (Сотные князья)[2], халыктан гайрәтле егетләр төзеделәр. Ихтилал, Казан алынып, бер ай үткәч тә башланды. Шул ихтилал 1560 елларга кадәр дәвам итте.

---

[1] Ихтилалның – күтәрелешнең, бунтның.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.

Бу кузгалышны татар хаким сыйныфлары Төркия вә Кырымга таянып башлаганнар, алда әйтелгәнчә, Төркиянең ефәк вә Иран сәүдәсе юлын кулга төшерәсе килгән. Бу замандагы Төркия солтаны Сөләйман үзенә бөтен мөселманнарның хәлифәсе ләкабен такканга, «ислам җирләрен кяфер кулыннан коткарам» дип, идеология ясарга да бик мөмкин булган. Казанлылар исә Сәхиб Гәрәй ханнан бирле Төркияне үзләренең башы дип беләләр, ләкин Кырым ханнары исә монда үз сәясәтләрен йөртәләр иде. Алар төрекләргә һәрвакыт «без үзебез генә барып, Казанны котылдырырбыз» дип, төрекләрне катыштырырга куркалар, аларның фикеренчә, әгәр дә Төркия Казан, Әстерханны алса, ул вакытта Кырымны да бөтенләй алып, андагы ханлыкны бетереп, Төркиянең бер вилаяте ясап калдырыр дип куркалар иде. Бер Кырым ханы (Дәүләт Гәрәй) әгәр Төркияне шималь эшләренә катыштырсак, Кырым кулыбызда калмас (Кырым дәхи әлемездә калмас), дигән имеш. Ихтилалчы татарлар нугайларга да зур өмет баглаганнар. Хәтта нугайлардан бер ханзадәне китереп, Арча ягына куеп, Казан ханы итеп игълан кылганнар иде. Ләкин бу эшкә нугайларның һәммәсе дә катышмыйлар, бары тик аларның Йосыф мирза һәм угыллары кул астында булганнары гына катышалар. Китергән яңа хан да халыкны җәберләп, үз кешеләре белән бергә Арча ягы халкының сыер-үгезләрен сораусыз суеп ашаганнар, шуның белән үзенә каршы хәрәкәт куптарган, шуңар күрә дә халык аны үзе китергән, үзе тотып башын кискән иде.

Шул рәвешчә, нугайларның азмы-күпме катышлары белән ихтилал башланган иде. Ихтилалчылар күбрәк Казан артында хәрәкәт итәләр. Ихтилалның учагы Арча тирәсе һәм хәзерге Лаеш өязендәге Мишә суы буенда булып, хәтта Мишә буенда Казаннан 70 чакрым җирдә ихтилалчылар бер ныгытылган шәһәр дә салганнар. Кама буенда да берничә шундый истихкямнар ясаганнар. Бу ихтилалга татарлардан башка чирмешләр дә бик катышканнар. Гомумән, ихтилалда илле меңгә якын коралллы халык иштиракь иткән[1].

1553 елда татарлар Казан тирәсендәге Биектау янына килеп, истихкямнар ясап ныгыдылар. Шуннан Казанга һөҗүм кылып тордылар. Җибәрелгән рус фиркаларын җиңеп, бик күп казак һәм стрелецларны әсир алдылар. Икенче яктан, татарлар, вак фирка-

[1] Иштиракь иткән – катнашкан.

ларга бүленеп, Нижний, Муром шәһәрләренә дә һөҗүм итәләр. Ун елга якын дәвам кылган ихтилалда башлык булып йөргән берничә мәшһүр ихтилалчы бар. Шуларның кайсысының исемнәре дә мәгълүм. Алар – Сары баһадир, Зәйн сәедләрдер.

Бу ике ихтилалчы 1553 елда русларның боларга каршы күнделгән Салтыков дигән мәшһүр команданнарын әсир алганнар. Янә Кабынак, Корбангали кенәзләр, Колай мирза һәм баштарак Нугай исемле бер шөһрәтле Казан кешесе үзенең угыллары белән дәһшәтле рәвештә Мәскәү гаскәре белән сугышканнар. Боларның ничек үлгәннәре мәгълүм түгел. Ләкин тагын ике мәшһүр татар ихтилалчылары Дәүләт мирза белән Бирде исемле теге нугай мирзасын китерүче, үтерүче ихтилалчы Мәскәү гаскәренә әсир төшкәннәр иде. Бирдене тотып бирүче Алтыш исемле татар булды. Бу да ихтилалның соңында өметсезләнеп, русларга бәйгать итүче Җанбик дигән кеше бар.

**Ихтилалны бастыру.** Бу ихтилал әүвәл замандагы Русия өчен бик куркыныч иде, берничә мәртәбә русларның ихтилалны ясарга җибәргән гаскәре җиңелгәч, Боярский Думада бояр һәм руханилар Иван Грозныйга Казанны кире татарларга биреп, гаскәрне алып кайтырга мәслихәт иткәннәр. Моннан Мәскәү хөкүмәтенең бик каушаганы күрелә. Ләкин Казанны бирү яңа гына алган Әстерханны да бирү, ул якны Кырым вә Төркия кулына тапшыру дигән сүз булганга, Мәскәү яңадан Идел елгасыннан киселәчәк иде. Иван Грозный актык гайрәтен һәм осталыгын сарыф кылып, ихтилалны басарга карар кылды. Казанга ихтилалны бастырырга әллә ничә арду[1] җибәрелеп торды. Бу фиркалар очраган бер татар авылын яндыралар, ирләрен кисәләр, хатын-кыз, бала-чаганы әсир алалар иде. Бер сугышта гына ун мең ир татар үтерелеп, алты мең ир, уналты мең хатын әсир төшкән. Мәскәү гаскәре үткән татар авыллары җир белән тигез ясала, кырлар таптала, яңа салынган шәһәрләр җимерелә иде. Шуның өстенә дә Мәскәү хөкүмәте алтын, мал белән халыкны алдарга тырыша: ихтилалчыларга каршы татарлардан мөрәккәб[2] гаскәрләр җибәрә, Касыйм татарларын китереп сугыштыра иде. Бәгъзы татар фиркалары үз халкы белән сугышмыйча, ихтилалчылар ягына чыгалар, ләкин бәгъзылары ихтилалчыларны тотып бирәләр иде.

[1] Арду – биредә: гаскәр.
[2] Мөрәккәб – тупланган.

Шуның тәкабеленә[1] хөкүмәттән акча һәм дәрәҗә алалар. Бирдене тоткач, Мәскәүгә үзе Алтыш иткән иде.

Ниһаять, Төркиядән көткән иганәт килмәде, кырымлылар да берничә мәртәбә Русиягә һөҗүм кылып карасалар да, файда чыкмады. Нугайлардан гаскәре белән килгән ханзадәдән дә мәгънә чыкмады. Татарлар эчендә мәэюсият,[2] гаксел-хәрәкәт[3] башланды. Һәр җирдә татарлар бирелә башладылар. Арган, талган, илләре таланган татар ихтилалчылары кылычларын кыннарына тыгарга мәҗбүр булдылар. Шулай итеп, ихтилал басылды.

Ихтилалның нәтиҗәсендә кысулар тагын куәтләнде. Татарларның бик күбесенең җирләре боярлар, попларга бирелде.

**Ихтилалның нәтиҗәсе.** Бу кузгалышны бастыру зур нәтиҗәләр бирде. Берничә яктан Казан өлкәсендә кузгалыш соңында 1500 татар аксөяге үтерелгәнлектән, бик күбесе качып киткәнлектән, истикъляль[4] уен булдыру өчен башта йөргән кешеләр югалдылар, калган аксөякләр исә үзләренең икътисади мәнфәгатьләре теләгәнчә, Мәскәүгә садыйк кол булып калдылар да, соңра Мәскәү болар белән файдаланып, татар мирза вә бикләреннән гыйбарәт «йомышлы татарлар» килеп чыктылар. Болардан вә аларның коллары татар крестьяныннан мөрәккәб, Мәскәүнең татарларыннан гайре монтазам[5] атлы гаскәр ясалды. Шул гаскәр белән Мәскәү хәзер файдалана башлады. Мәсәлән, Иван Грозныйның Балтыйк буе Ливония немецләре белән сугышта мондый гаскәрдән илле мең атлы татар иштиракь кылды. Ихтилалның чыгуы, бастырылуы Мәскәүгә бер сабак булды. Ул да булса Казан илен тиз генә рус гонсыры белән тутыру вә колонизовать итүнең кирәге дәресе иде. Шуның өчен хөкүмәт Казан алынгач ук башлаган бу эшен ихтилал барган чакта вә ул басылгач эшләргә керeште.

**Казан ханлыгын колонизация.** Мәскәү хөкүмәте, Казан алынгач ук, Казан хан вә феодалларыннан калган җирләрне Казанны алышуда иштиракь кылган гаскәр башлары воеводаларга өләшеп

[1] Тәкабеленә – бәрабәренә.
[2] Мәэюсият – өметсезлек.
[3] Гаксел-хәрәкәт – реакция, тәшвиш.
[4] Истикълял – бәйсезлек, ирек.
[5] Гайре монтазам – тәртипсез, рәтсез.

биргән иде. Ихтилал басылгач исә, хөкүмәт фәрман чыгарып, Казан тирәсендә тәхминән 30 чакрым тирәсендәге татарлар ташлап качкан вә мөсадәрә кылынган[1] җирләрне рус алпавытларына өләшә башлады. Бәгъзы җирләр исә татар крестьяны белән бергә үк шул алпавытларга эләктеләр. Алпавытларга бу яңа җирләрдә хуҗалыкларын төзеп җибәрергә асат булсын өчен читтән китерелә торган рус крестьяннарын 10 ел мөддәтендә[2] төрле салым вә повинностьлардан котылдыра торган закон чыгарылды. Яңа вә мөнбит[3] урыннарга алпавыт золымыннан гаҗиз булган эчке өлкәләрдән рус крестьяннары агылып килә башладылар.

Шуның өстенә дә Иван 1555 елда Казан өлкәсендә яңа епархия ясап, Казан өлкәсенә поплар күчерә башлады. Беренче Казан архиепископы Гурий дигән попка вә аның яраннарына Идел буендагы хан вә бикләр җире булган мөнбит вә печәнлек, урманлык вә бакчалык җирләрне вәкыф итте[4]. Бу җирләрнең күбесендә татар уллары булганга күрә, попларга бик күп татар крестьяны эләкте. Болар рухани рус феодалларга әүвәлдә хан вә бик-сәедләргә түләгән төсле оброк түли вә хезмәт итә башладылар.

Шулай итеп, Казанның әтрафы мөдафәгагә[5] уңай булсын өчен русның гаскәри феодалларына бирсәләр, Идел буйлары руханиларына вәкыф ителделәр.

Мәскәү хөкүмәте илне тиз генә руслаштыру өчен алпавытлардан качып килүче рус крестьяннарын башта тотмады, гайре рәсми булса да, Казан җиренә килеп утырырга мөсагадә[6] бирде. XVI гасырның ахырында бу рус крестьянының килүе шулкадәр күбәйде ки, Мәскәү өлкәсендә җирләр бушап кала башладылар. Хәтта хөкүмәт бу Казан өлкәсенә качып, гайре монтазам килүчеләрне тыярга чаралар кыла башлады. Шул мәсьәләдә Русиядә крепостнойлыкның ныгуына зур ярдәм итте.

---

[1] Мөсадәрә кылынган – кулга төшерелгән.
[2] Мөддәтендә – срокта.
[3] Мөнбит – уңдырышлы.
[4] Вәкыф итте – бүләк итте.
[5] Мөдафәгагә – каршы торуга.
[6] Мөсагадә – мөмкинлек.

Хөкүмәт Казан өлкәсен тизрәк колонизация ясау өчен башта бөтен мәгъюб[1] кешеләрне вә сәяси мөттәһим[2] кешеләрне шунда сөрә башлады. Шундый кешеләрдән гыйбарәт Казанда берничә урам да ясалды. Бигрәк тә Иван Грозный бу хакта кызык бер чара уйлап чыгарды: ул да булса Русия уртасында булган, самодержавиегә хилаф булып, Русиядә боярлар идарәсе ясарга омтылучы кенәз вә боярларны Казан өлкәсенә җибәреп, андагы мирзаларның җирләрен аларга тартып алып, җирле татар мирзасын Мәскәү өлкәләренә җибәреп, теге боярлардан калган җирләрне аларга бирде. Моның белән Иван Грозный берьюлы ике еланның башын кисте: эчтәге дошманнарын яңа җирләргә җибәреп, алардан котылып, ул дошман боярларны самодержавиегә бәйләде. Чөнки күчкән дошман боярлар Мәскәү өлкәләрендә торганда царьга дошман булсалар, гайре рус өлкәсенә килеп утыру белән аның колы булып китәләр иде. Чөнки аларның малларын вә җирләрен саклау өчен Мәскәү көче вә хөкүмәте һәрвакытта кирәк булып торадыр иде. Казан өлкәсеннән калган мирза вә бикләрне рус арасына илтеп, аларга рус крестьяны бирү белән аларны да янә хөкүмәткә баглыйлар иде. Чөнки инде ул җирләреннән вә халыктан аерылган татар аксөякләре үзләренең мал вә җаннарын бары Мәскәү хөкүмәте вә царе аркасында гына саклап кала алалар, шуның өчен алар садыйк колга әйләнәләр иде.

Алпавыт кулындагы җирләр, эшче кулы булмаганга күрә, игелми кала башладылар.

Иван Грозный Казан вә аның әтрафына купец һәм һөнәрмәндләрне дә сөрде. Болар исә Новгород һәм Псков шикелле әүвәлдән ирекле җөмһүрият булып та, Мәскәү царьлары тарафыннан көчләп Мәскәүгә кушылган вә әүвәлге ирекне әле дә онытмаган шәһәр әһалисе иде. XVI гасырда Казанда болардан гыйбарәт әллә ничә урам ясалды. Бу купец һәм осталар Казанга килеп йөрү белән мәнфәгатьтә Мәскәү хөкүмәте белән нык багланып, әүвәлдәге аларның ихтилалчы фикерләре югалган иде.

Җирне колонизовать итү өчен хөкүмәт яңадан бер җай тапты. Ул да булса, Казан өлкәсендә монастырьлар салырга тырышуы иде. Хөкүмәт татар вә башка гайре руслар арасында руханиларга җир

[1] Мәгъюб – гаепле.
[2] Мөттәһим – гаепле дип саналган.

бирә дә, руханилар шунда илтеп мәхкәм[1] коймалар белән чолгап алып, монастырь сала да, монахларны коралландыра, шуның янына крестьяннар килеп утыралар, җирле халыклар һөҗүм кылсалар, бу монастырь крестьяннары шул мәхкәм коймалар эченә кереп качалар иде. Шулай итеп, тирә-юньдә рус җенесеннән булган халык күбәя иде. Шул ук заманда XVI гасырның эчендә Идел буенда вә башка елгалар кырыйларында ныгытма вә шәһәрләр салдырыла башлады.

1556 елда Чабаксар, 1557 елда Лаеш, 1578 елда Тәтеш, 1589 елда Алат, 1587 елда Уржум, 1584 елда Чар (Краснококшайск), 1585 – Санчурск, 1603 елда Яранск шәһәрләре салынадыр. Бу шәһәр вә ныгытмаларга хөкүмәт төрле сыйныфтан булган русларны күчереп утыртадыр иде. Ул шәһәрләрнең коймаларына куелган тупларның химаясендә койманың читендә дә бик күп бистәләр вә алар янында истихкямнарның башлыклары – түрәләргә (воевода, дьяк, стрелец башлыклары) бирелгән җирләргә янә дә 10 еллык льгота белән кызыктырылып, рус крестьяны китертелеп утыртыладыр иде. Бу шәһәрләргә хөкүмәт гаиләләре белән стрелец вә пушкарь аталган гаскәрләрне китертеп утыртадыр иде.

### 3.8. Идел буе өчен көрәшкә бәйнәлмиләл сәясәтнең катышуы

**XVI гасырда Идел, Дон һәм Кара вә Хәзәр диңгезләре сәүдәсе.**

Казан алынган чорларда Төркиянең иң зурайган вә көчле чагы булганлыктан, Дарданелл вә Босфор, Кырым ханлыгы Кавказның гарби ярлары Төркиянең кул астында булганлыктан, Кара диңгез аның күле мислендә булып калды.

Шул сәбәпле, Кара диңгез вә Дарданелл, Дон вә Идел аркылы булган сәүдә дә аның кулында иде.

Казан төшеп, Русия Әстерханга таба хәрәкәт кылып, аны алуы Төркиянең икътисади хәятына, аның сәүдә вә таможнясына зур бер зарбә-ору иде. Табигый, Идел Русия кулына керү белән, бу сәүдә башка юлдан китәргә вә Русиягә табигъ булырга кирәк иде.

Шул сәбәптән Төркия үзенең вассалы Кырым аркылы, әлбәттә, Идел буе мәсьәләсенә мөдахәлә итәргә[2] вә Русия белән бәрелешергә

[1] Мәхкәм – нык.
[2] Мөдахәлә итәргә – керешергә.

тиеш иде. Шуның өстенә дә Идел буе мәсьәләсендә Төркиянең тагы бер икътисади, сәяси мәнфәгате бар иде. Ул да менә нәрсәдән гыйбарәт:

XVI гасырда Шәрыкта, хәзерге Иранда бер зур дәүләт килеп чыкты. Бу исә шигый мәзһәбтәге сәфәвиләр сөляләсе кул астында Иранның берләшүе иде. XVI гасырда инде солтан Сәлим вә Сөләйман заманында Иран белән Төркия арасында бертуктаусыз канлы сугышлар башланды. Бу сугышларның сәбәбе Төркия вә Иран хөкүмәтләре сөнни вә шигый мәзһәбләрнең бәрелешүе дип карасалар да, асылы икътисади иде. Иран зураеп, Төркиягә вә аның аркылы Яурупага килә торган Һинд, Урта Азия вә Кытай маллары йөртелә торган кәрван юлларын ишгаль кылган[1] иде. Төркиягә исә бу зарарлы бер эш булып чыкты. Шуның өчен сугышлар башланды. Менә шушы сәфәвиләр мәмләкәтенә каршы сайлау зарбәсе белән Иранны буйсындырып булмый, аның артына Хәзәр диңгезе аркылы яисә шуның гарби ярлары буйларыннан һөҗүм кылып җиңәргә мөмкин, моның өчен дә Идел буе Төркия кулында яисә Сәхиб[2], Сафа[3] һәм Үтәмеш Гәрәйләрнең[4] заманындагы шикелле вассаллары кулында булырга тиеш иде.

Мәгълүм ки, һәрбер икътисади вакыйга өстенә махсус бер идеология үсеп чыга. Төркиянең Идел буе эшләренә Кырым аркылы катышуы өчен мондый бер юаныч табылды вә, ул да булса, Русия кул астына кергән татарларны дини-милли яктан кысылуларын бәһанә[5] вә дәлил итеп тотудыр. Моңарга, билгеле, татарның үз арасында муафәкать[6] бар иде. Чынлап та Мәскәү хөкүмәтенең татарларны чукындырырга димләве, көчләве һәм аларның җирләрен тартып алуы, татарларның кубып та, үз көчләре белән Мәскәү кулыннан чыга алмауларын аңлау Төркия вә аның вассалы Кырымга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр итәдер иде. Шул сәбәпле татарлар, хәтта башка гайре руслар Истанбул вә Бакчасарайга илчеләр җибәреп, Кырым-

[1] Ишгаль кылган – биләгән.
[2] Сәхиб Гәрәй хан (?–1551) – Казан (1521–24), Кырым (1532–1551) ханы.
[3] Сафа Гәрәй хан (1510 тирәсе – 1549) – Казан ханы (1524–1531, 1535–1546, 1546–1549).
[4] Үтәмеш Гәрәй хан (1546–1566) – Казан ханы (1549–1551), Сафа Гәрәй хан белән Сөембикәнең улы. Нугай бәге Йосыфның оныгы.
[5] Бәһанә – сылтау, сәбәп.
[6] Муафәкать – туры килү, ярашу.

ны, Төркияне чакыралар иде. Ләкин Идел буе мәсьәләсендә әһәмият бирүче Төркия-Кырым вә Мәскәү генә түгел, бәлки гарби Яурупа да бар иде. XVI гасырның 60 елларында Русия белән Англия арасында нык сәүдә мөнәсәбәтләре башланган. Мәскәүдән Архангельгә, аннан инглиз көймәләренә төялеп, хам әшья (сырой материал) Англия вә Голландиягә китә башлаган иде. Шул маллар эчендә иң зур урын тоткан нәрсә Идел буеннан вә Себердән килә торган мехлар һәм Әстерханнан килә торган балык вә икра, Идел буе белән Мәскәүгә килә торган ефәк иде. Иван Грозный заманыннан башлап, бу малларны сату өчен, инглизләр белән могаһәдә[1] ясалган булган. Шуның өчен дә Казан тагы күтәрелеп китkән, анда инглиз вә голландиялеләрнең сәүдә агентлары да куелган иде. Бу ике күтәрелеп килә торган илләрнең мәнфәгатьләре Идел буен Русия кулына кертү иде, чөнки Ираннан килә торган мал Төркия аркылы үтә алса да, ул инглиз вә голландиялеләр кулына түгел, бәлки Венеция һәм Җәнүә сәүдәгәрләре кулына керергә тиеш иде. Бәлки шуның аркасындадыр, бер Казан–Мәскәү сугышында мөһәндис һәм тупчыларның яурупалылар булганын һәм Казан өчен соңгы көрәштә Казанның нытмасының мөһим бер урынын күтәртеп, татарларны куркыткан вә мөдафәгатьне[2] ташларга мәҗбүр иткән кеше дә яурупалы иде.

Һәрхәлдә, иң элек Идел буе өчен Мәскәү Кырым, Төркия белән бәрелешергә тиеш иде. Менә шушы бәрелешләрнең кайсысын искә төшереп узабыз[3].

**Төрек һәм Кырым гаскәренең һөҗүмнәре.** Казан әтрафында ихтилал булып торган чакта 1555 елда Кырым ханы Төркиядән алган «янычари» исемле гаскәрләр белән Русиянең хөдүден[4] үткән, русларның аңар каршы җибәргән гаскәрләре җиңелгән, татарлар Тула шәһәренә якынлашып киләләр. Иван Грозный моңар каршы гаскәр күндергән. Ләкин Кырым гаскәре ни өчендер борылып кайтып киткән. Моннан соңгы ике елда да кырымлылар һаман да Русиягә

[1] Могаһәдә – килешү, солых.
[2] Мөдафәгатьне – каршы торуны.
[3] Бу хакта озын мәгълүмат «Мәгариф» журналында «Идел өчен көрәш» исемле мәкаләбездә бар. *(Авт. иск.)*
Биредә авторның «Идел буе өчен көрәш тарихыннан» (Мәгариф. 1923. № 5/6) мәкаләсе турында сүз бара.
[4] Хөдүден – чиген.

һөҗүм кылалар, Кырым татарлары казанлыларның ихтилалына булышу өчен вак-вак йөз, ике йөзлек фиркалар булып килеп торалар иде.

1566 елда елда Төркия солтаны Сөләйман Кануни үлеп, аның урынына Сәлим II тәхеткә утыра. Инде бу солтан эш үткән, Казан, Әстерхан руслар кулына төшкән булса да, кире Әстерханны алырга уйлады. Солтан Сөләйман Кануни (Төркия солтаны) чынлап эшкә керешергә уйлап, 1563 елда Кырым ханы Дәүләт Гәрәйгә гаскәргә ашарга, эчәргә, атлар хәзерләргә һәм язга Әстерханга һөҗүм итәргә боерды. Яз көне Төркия хөкүмәте янычар гаскәрен һәм моктәдир[1] команданнар да күндерде, Кырымда туп, ядрәләр төяргә йөз арба хәзерләргә кушты. Төрекләр Дон суы белән туп вә гаскәрләрне төяп барып, Идел елгасына кадәр нәрсәләрне атка төяп, соңра Идел елгасы аның кырые белән барып, Әстерханга һөҗүм итмәкче булдылар. Шул ук вакытта Мәскәүнең Кырымдагы илчесе хөкүмәткә, Әстерхан татарларының да төрекләр белән кырымлыларны көткәнен язды. Ләкин Кырым ханы моны теләми, алда әйтелгәнчә, төрекләр Идел буен алсалар, «Кырым һәм әлемездә[2] калмас», дип куркалар иде. Шулай булса да, Дәүләт Гәрәй Русиягә ультиматум биреп, Казан һәм Әстерханны кире кайтаруын, Казанга хан итеп улы Гадел Гәрәйне куюны сорады. Табигый, Русия хөкүмәте моңар каршы җавап кайтарды.

Ниһаять, 1563 елда Төркиянең әмере белән булачак Әстерхан сәфәре булмый калса да, Кырым ханы җәнүби Русиягә һөҗүм итте. Ләкин Русия гаскәре тарафыннан каты каршылык күреп, кире борылып кайтып китте. Моннан соң да Кырым хөкүмәте Казан вә Әстерханны соравыннан дәвам кылды. Чөнки бу җирләрдән илчеләр килеп торалар. Хәтта чирмешләрдән дә Кырымга илче килеп, Казанга бер ханзадәне хан итеп гаскәр белән җибәрүне сорыйлар һәм үзләренең Кырым гаскәренә булышлык кылып, 66000 гаскәр белән Казанга һөҗүм итәчәкләрен белдерделәр. Ләкин Кырым һаман да Русиягә гаскәр белән килә алмады. Бикләр, мирзалар, карачылар шурасы ханнан Казанга баруны таләп кылдылар. Шуннан соң Кырым ханы яңадан ультиматум белән илче җибәреп, Казан вә Әстерханның татарларга кире кайтарылуын сорады, ләкин Мәскәү

[1] Моктәдир – көчле.
[2] Әлемездә – кулыбызда.

хөкүмәте рази булмый, шулай да куркып, ханга акча җибәрә һәм килешер өчен шундый юл күрсәтә иде: «Ханзадә Русиягә килсен, аңар сабикъ[1] Казан ханы Шаһгалинең кызын (асрамага алган) бирәм, Касыйм шәһәренә хан итәм», – диде. Моның белән Кырым ханын алдамакчы булды. Аңар Кырым ханы болай дип җавап бирде: «Минем баламны ашатырлык хәлем бар. Касыйм ханлыгы аңар кирәк түгел, әгәр яхшылык белән Казан, Әстерханны бирмәсәк, Төркия хөкүмәте барыбер аны синең кулыңнан алыр».

**Солтан Сәлимнең Әстерханга таба килүе.** 1566 елда Төркиядә солтан Сөләйман Кануни үлгәч, аның урынына Сәлим II тәхеткә утыра. Ул инде чынлап та Идел буе мөселманнарының һәм гайре русларның теләгеn җиренә җиткерергә керешмәкче була. Шушы вакытларда Бохара, Хивадан килгән мөселман төрк хаҗилары Истанбулда хөкүмәткә Русиянең Казан, Әстерханны алуын, андагы мөселманнарның хурлыкка төшүләрен, башка мөселман илләренә дә һөҗүм кылу ихтималын, Әстерханга килә торган сәүдәгәрләрне талап, бик күп пошлина алуын сөйләп, зарланып, гариза бирделәр. Солтан Кырым ханына Әстерханга барырга хәзерләнергә, кирәк-ярак хәзерләргә боера һәм Төркиядән гаскәр дә, туплар да күндерә. Төркиянең Әстерханга килергә теләвенең икенче бер сәбәбе дә бар иде. Төркия Сәлимнең черкастан булган бер вәзире алда сөйләнгән Иранны Каспий диңгезе аркылы җиңеп булу хакындагы ляихәне[2] тәкъдим иткән иде. Дәүләтгәрәй хан һәртөрле ялганнар белән солтанны куркыта: «Русиянең Әстерханда гаскәре күп, әгәр җиңелсәк, бөтен мөселман галәмендә даның бетәр, суыкка гаскәр чыдый алмас, әгәр Дон белән Идел кушылса, русларга Кырым, Кара диңгез белән Төркиягә һөҗүм кылырга юл ачылыр», – ди иде. Әмма үзе Русиядән Казан, Әстерханның бирелүен таләп кылырга һәм аны Төркиянең кылырга теләгән эшләреннән хәбәрдар итеп торадыр иде. Солтан Дон белән Идел елгасын бергә кушып, шуның аркылы флот җибәрергә уйлыйдыр иде. Төпләп уйлаганда, бу ляихәдә бер дә акылга ашмаслык нәрсә юк, чөнки монда Дон белән Иделнең хәзерге Камышин янында бары бер-берсеннән 25 чакрым гына килеп якынлашкан урыны бар. Шул максат белән 1569 елда бу эш өчен 17000 гаскәр, казыр

[1] Сабикъ – элеккеге.
[2] Ляихәне – проектны, тәкъдимне.

өчен кораллар, эшчеләр һәм илле мең татар гаскәре күндергән. Гаскәр, көймәләр бик авырлык белән Донның Иделгә якын килә торган урынына барып җиткәннәр. Кырым ханы төрекләрнең шималь төркләре кушылуларыннан куркып, төрек гаскәре арасына төрле ялган тәшвишле хәбәрләр тарата башлаганнар. Имеш, бу җирдә кыш көне караңгы була, җәй көне төн булмый, бик күп намазлар калдырырга кирәк була, диләр иде. Каналны һич казыр хәл юк, эш бик акрын бара, гаскәр арасында да наразыйлык[1] күренәдер иде.

Әстерханнан килгән илчеләр дә: «Бер дә канал кирәк түгел, тиз генә Әстерханга килеп, безне руслардан хәляс[2] итегез», дип үтенәләр иде, шул рәвешчә, төрек гаскәре Әстерханга якынлашкан, командан паша тиктомалга Әстерханга һөҗүм итәргә уйламый, ул шунда истихкям[3] салып, язга кадәр кышларга уйлаган иде. Ул арада Кырым гаскәре белән хан да Кырымга кайтып киткән иде. Шушы вакытта төрек гаскәре арасында ихтилал чыкты. Кайтуны тели башладылар. Ул арада Иран, рус гаскәре һәм Мәскәү тарафлы нугайлар киләләр икән, дигән хәбәр чыкты. Шул ук көннәрдә чынлап та Мәскәү гаскәренең якынлашкан хәбәре килде: төрек гаскәренең башлыгы истихкямнәрен бозып, яндырып кайтырга чыкты. Юлда солтаннан әмер алынды. Бу фәрманда Әстерхан янында кышларга һәм җәй көне зур иганәт гаскәре җибәрәчәген сөйләгән иде. Ләкин гаскәр моны тыңламады.

Дәүләт Гәрәй хан үзенең максатына ирешкән иде. Ул Иван Грозныйга хат язып, төрек солтаныннан котылдырганына мактанган иде. Шул ук вакытта бик күп мал, акча сораган һәм Казан белән Әстерханны таләп кылуын да яңарткан иде.

**Мәскәү хөкүмәтенең каушавы.** Бу заманда Иван Грозныйның боярларны үтерә башлаган, яхшы боярлар аннан кача башлаган, немецлар (Ливония) белән Польша сугышып торган чаклар иде. Солтан Сәлим дә фикереннән кайтмаган иде. Яз җитү белән һөҗүм кылырга уйлыйдыр иде.

Шул сәбәптән Кырым ханы да зур хираҗ, бүләкләр җибәрергә уйлаган һәм солтан алдында үзен акларга тырышып, Истанбулга илче җибәргән иде. Илче бүләкләр алып барып, сүз арасында солтанга:

---

[1] Наразыйлык – канәгатьсезлек.
[2] Хәляс – азат.
[3] Истихкям – ныгытма.

«Царьга каршылык кылмаган казанлылар бик хөрмәттә, аңар хезмәт итәләр, үз урыннарында торалар, царь аларның диненә тими, аларның мәгъбәдләрен (мәчетләрен) җимерми, менә царь хәзер Касыйм шәһәренә Булатны хан итә, мөселман шәригатенчә мәчетләр, кяшанәләр (мәкъбарә) эшләргә кушты. Әгәр ул мөселман шәригатенә хилаф булса иде, Русиянең уртасында Булатка хан булырга һәм мөселман шәригатенчә торырга кушмас иде», дип әйтергә кушкан иде. Солтан илчегә Иванны бик орышып, Әстерхан юлын ачарга һәм аңа салынган истихкямнәрне ватарга кушкан иде. Иван яңадан илче җибәреп, Әстерхандагы мәчет вә кяшанәләрнең җимерелүе Иван әмере белән булмаганлыгын белдерергә кушкан. Ләкин солтан һаман да Казан белән Әстерханның мөселманнар кулына бирелүен таләп кыладыр иде.

**1571 ел һөҗүме.** Мәскәү хөкүмәте Төркия белән Кырымнан бик каты курка башлаган. Ул бик күп гаскәр тота иде. 1570 елның башларында ук вак татар фиркалары Русиянең чикләренә һөҗүм кыла башлаганнар, 1570 елда Дәүләтгәрәй үзе йөз егерме мең татар гаскәре белән Русиянең чиген үтеп, Мәскәү янына килеп җитте.

Русиянең аңар каршы җибәргән гаскәре җиңелеп, Иван үзе дә качты. Тирә-юньдәге халык бөтен малын җыеп, Мәскәүгә кереп бикләнде. Татарлар Мәскәүне мөхасарә иттеләр[1], Мәскәү һәр яктан яна башлады. Татарлар Мәскәүгә кереп талый башладылар. Бәгъзы риваятьләргә күрә, сигез мең кеше үтерелде, йөз илле меңгә якын әсир алынды, шушы кадәр әсир, әллә никадәр мал алып, Кырым ханы Мәскәүнең зур гаскәре килә дип ишетеп чигә башлады.

### 3.9. Себер ханлыгының бетүе

**Сәбәпләр.** Сәүдә капиталы үзенең сәүдәсенә җирне һаман арттыру, зурайтуны сорый, шуның өчен Мәскәүнең сәүдә капитализмы үскән саен аның аппетиты да артканнан артты, йон, мех вә тире белән чит илләр белән сәүдәнең үсүе царьның хәзинәсенең туймас күзләрен Уралның теге ягына да чупырттыра башлады. Казан алынгач, башкортлар да Мәскәүгә бәйгать итеп, хәзинәгә ясак түләргә разый булып, илчеләр җибәргәнлектән, базар тагы киңәйсә дә, сәүдә

[1] Мөхасарә иттеләр – камап алдылар.

капиталының туймас мигъдәсе[1] тагы яңа маллар сорый башлады. Затән, Казан шикелле башка татар ханлыкларына вә урдаларына караганда организацияле вә мәдәнияте яхшырак бер ныгытма Мәскәү кулына кергәч, калганнарының җеп очлары үз-үзләреннән сүтелә башлады. Себер ханлыгы да Мәскәүнең капитализм әсасына күчә башлаган икътисади вә иҗтимагый тормышы белән көрәштә табигый җиңелде. Бу көрәшнең ничек башланып, ни белән тәмам булганын белер өчен Себер урдасының сәяси әхвәленә күзебезне төшереп карыйбыз.

**Себер ханлыгында.** Борынгы заманда Себер татарларының мәркәзе Ишим суы буенда булып, ул заманда аның Иртешкә коя торган урынында Кызыл Тура дигән шәһәр булган. Борынгы заманда бу җирләрнең беренче ханы Ун яисә Уныс булган, имеш. Бу кеше ханлыгын зурайткан, бик күп җирләр алып, ханлыкка кушкан имеш. Моңарга каршы XVI гасырда Чыңгыз яисә Чингин исемле бер бик кубып, Унны үтергән. Ләкин бу бик ханның ыругдашларының үч алуларыннан куркып, үзенең иярченнәре белән качып, Тубылга коя торган Тура елгасы буена качып китеп, шунда Чинги Тура исемле шәһәр салган, соңра бу шәһәр Төмән аталган. Ун үтерелгәннән соң, Ишим буе Ун ханның балалары тарафыннан идарә кылынып килгән, ләкин дәүләт зәгыйфь булган, әмма Чингинның углы Тайбуга Тура елгасы буенда идарә итә башлап, шактый көчле хөкүмәт төзегән һәм йөз еллап Себер ханлыгын идарә кылып килгән. Ханнар шушы нәселдән (сөяләдән) булганнар. Ләкин XV гасырның яртысында Ун хан нәселеннән килгән Ибраһим яисә Ибак Чинги Тура ханын җиңеп, Тайбуга кулыннан хакимиятне алды. Чинги Тура яисә Төмән шәһәрен мәркәз итеп, Ибак бөтен Себер татарларын бер хөкүмәт кулына җыйды. Бу хан үзенең тәэсирен гаребкә таба да җибәреп, нугай татарлары белән берләшеп, Алтын Урданың Әхмәд исемле ханын төшереп, бер вакытта тарала башлаган Алтын Урдага да баш була. Ләкин бу заманда инде Шәркый Яурупа һәм Гарби Себергә куркыныч булган Мәскәү дәүләте үсеп килә. Хәтта Мәскәү гаскәрләре Пермь, Вятка өлкәләре аркылы Гарби Себернең фин кабиләләрен үз кул асларына кертергә омтылалар. Шуның өчен һәм ханлыкта үзенең дошманнарына каршы бер көчкә малик булу

[1] Мигъдәсе – ашказаны.

өчен Мәскәү кенәзе Иван III белән иттифак ясарга теләп, илчеләр җибәреп тора. Ләкин Тайбуга нәселе һаман да Ибакка һөҗүм итеп тәхет даулаудан кире тормый. Шуның өчен 1414 елда Тайбуга нәселеннән Мөхәммәд исемле берсе һөҗүм итеп, Ибраһимны (Ибак) үтерде: Иртеш кырыенда аның Тубылга кушыла торган җиреннән 25 чакрым өстәрәк борынгы Искәр исемле шәһәр хәрабәсе урынына Себер шәһәрен салып, мәркәз ясады. Шулай итеп, хакимият яңадан Тайбуга сөлялəсенә кайтты. Моның белән эчке низаг, тәхет өчен көрәш бетмәде. Ибакның углының углы ифрат булдыклы Күчем яңадан тәхет дауларга тотынды. Шуның өчен Мөхәммәднең хәләфе Ядкәр Күчемгә каршы көрәшкәндә иттифакчы булыр дип өмет итеп, Мәскәү патшасына хираҗ түләргә дә разый булды. Хәтта 1555 елда Ядкәр Мәскәүгә илче җибәреп, Иван Грозныйны Казан, Әстерхан алыну белән тәбрик итте вә ел саен мең җофар тиресе бирергә дә вәгъдә итте, соңра Мәскәүдән килгән илчегә Ядкәр Себер халкын бәйгать иттерде, салым түләү өчен халыкның санын алдырды. Шулай итеп, Себер ханлыгы 1555 елда комсыз хакимият өчен халыкның истикъляллиятен бирергә разый булган ханы аркасында Мәскәүгә буйсынды. Димәк, Себердә дә бер Шаһгали табылды. Ләкин Мәскәүнең Ядкәргә файдасы тимәде. Ул вакытта Мәскәү үзенең гарби күршеләре булган Ливония немецлары, поляклар белән сугышта һәм Кырым ханының һөҗүмнәреннән мөдафәга[1] белән мәшгуль иде. Җиде ел Ядкәр Күчем белән сугышты. Ниһаять Күчем җиңеп, Ядкәрне һәм аның борадәрен үтерде, ханлыкка шулай итеп баш булып калды. Шулай да эчке низаглар һаман дәвам итеп торды.

**Күчем[2] вә аның идарәсе.** Күчем бөтен Гарби Себерне берләштереп, көчле бер патшалык ясарга омтылды. Бу вакытка кадәр әле татарлар арасында да, аларга буйсынган фин кавемнәрендә дә мәҗүс дине – шаманилык хөкем сөрәдер иде. Күчем илне берләштерү өчен яңа бер сәясәт тотты. Ул халыкны исламияткә өнди, Урта Азия белән мөнәсәбәт тота, шул дин берлеге аркасында Урданы да берләштерергә уйлады. Исламият татарлар арасында шактый шаигъ булды[3].

[1] Мөдафәга – каршы тору.
[2] Күчем (?–1598 ел тирәсе), Себер ханы (1563–1598), Шәйбан хан нәселе варисы Мортаза улы.
[3] Шаигъ булды – таралды.

Шулай итеп, 1570 елларда инде Себер ханлыгы шактый куәтләнде. Ләкин халыкны фикер белән генә туйдырырга мөмкин түгел икәне күренде, бикләр, мирзаларның халыкны талавы, кысуы һаман да кимемәде, шуның аркасында илдә иҗтимагый солых була алмады.

**Күчем хөкүмәтенең Мәскәүгә мөнәсәбәте.** Казан төшкәч, Мәскәүнең Шәрыкта тотачак империализм сәясәтенә юл ачылган, шуның өчен Мәскәү белән ике араны бер мәгълүм даирәдә тотарга тиешлеге мәгълүм иде. Кама буйларында, Урал тауларының итәкләрендә Мәскәүнең алпавытлары килеп утыра, крестьяннарын да үзләре белән бергә алып килә, азмы-күпме истихкямнәр дә сала башлаганнар иде. Иван Грозный Строгонов дигән кешеләргә 1558 елда Кама буйларындагы буш җирләрне һибә[1] иткән, 1574 елларда исә шул ук фамилиядән булган алпавытларга Тубыл елгасы буендагы җирләр дә бирелгән. Шулай итеп, Мәскәү акрынлап Урал тауларына менеп, аннан Гарби Себергә килеп чыккан, боларның агачтан салган истихкямнәре Мәскәү хакимиятенә бер илтиҗагяһ[2] булган иде. Күчем хәзер Урта Азия белән ихтиляттa[3] тора. Аннан гаскәр китертә, Гарби Себердә ислам мәдәнияте җәяргә тырыша, шулай ук Казан мәсьәләсенә дә Күчемнең эче поша, Казанга таба да үзенең тәэсирен җәяргә омтыладыр иде, шуның коткысының тәэсирендә нугай татарларының Русиядән аерылуларын да һәм бик канлы сугышлар белән беткән Казан йортындагы чирмеш кузгалышын да күрәбез. Күчем Иванга Ядкәр шикелле тарелка тотмый. Ләкин араны алай рәсмән бозарга да куркадыр иде. Хәтта Ядкәр заманында бирелеп килгән ясакны да 1571 елда тулы килеш күндерде. Чөнки бу чакта Күчемнең артында икенче дошманнары – кыргыз казакларының һөҗүмнәре бар иде.

Күчем дошманнарын җиңгәч тә, Мәскәүгә мөнәсәбәт үзгәрде. Күчем Мәскәүгә ясак (хираж) җибәрмәс булды. Шуның аркасында Күчем Пермь областендагы башкорт-татарларны котыртты. Бәгъзы вакытта ул җирләргә һөҗүм кылуны бик еш ясый башлады. Димәк, Мәскәүгә каршы сугыш ачылды. Ләкин Мәскәү аңарга каршы колонизация сәясәте белән җавап бирде. Ул исә Строгоновларга Себердә

[1] Һибә – бүләк.
[2] Илтиҗагяһ – сыену урыны.
[3] Ихтиляттa – дуслыкта.

җир бирү, ул җирләрне эксплуатация ясарга, крестьяннар күчерергә, анда утырган гайре русларны идарә кылырга һәм ясак җыярга, хакимиятне сакларлык гаскәр тотарга ирек бирү иде.

**Строгоновларның гаскәре.** Бу заманда алпавытларның золымыннан гаҗиз булган, җир-суларын ташлап, казак-качак булган, төрле кыйсемнән рус, татар вә башка гайре руслар далаларда, Идел буйларында качып, талау белән мәшгуль булып йөргән бер гөруһ халык бар, менә шулар шул ук талау фикере белән йөргән Строгоновларга гаскәр булып язылалар иде. Болар хәтта Идел буйларындагы хөкүмәт көймәләрен дә талаганга, хөкүмәт каршында алар җинаятьче, ихтилалчы хисап кылыналар да, Мәскәү алардан котылу өчен, ул казакларның көчләрен башка җиргә чәверү[1] өчен, Строгоновларга аларны ялларга рөхсәт биргән. Менә шундый казак ихтилалчы гонсырның башлыкларыннан берсе Ярмәк Тимофеев дигән кеше гаскәре белән Строгоновларга ялланган иде.

**Сугыш.** Шушы гаскәр белән Күчем арасында сугыш башланды. Ярмәк үзенең бик азсанлы мылтык, туп белән коралланган гаскәре белән көймәләргә утырып сугыша-сугыша, татарларның күп шәһәрләрен алды. Ниһаять, 1581 елда Күчемнең пайтәхете Себер (борынгы Искәр) шәһәре янындагы сугышта Күчем җиңелде. Монда да Яурупаның Шәрык илләрен кол итәргә сәбәпче булган мылтык һәм туп – борынгы кораллар белән коралланган казаклар ук, сөңге, кылыч белән коралланган халыкны җиңде. Шулай итеп, Гарби Себер Русиягә кушылды. Күчем качты. Алай да Күчем һәм аның угыллары кылычларын кыннарына тыкмадылар. Һаман казакларны рәхәтсезләүләрендә дәвам иттеләр. Хәтта 1584 елда Күчем гаскәре казакларга һөҗүм итеп, кырып торды. Ярмәк үзе суга батып үлде, калган казаклар Себерне ташлап, Русиянең иске чикләренә чиктеләр, Күчемнең углы кире Себер кальгасын ишгаль итте. Ләкин мирза, ханзадәләрнең үзара низаглары бетмәде, тагы үзара канлы сугышлар башланды. Мәскәү дә инде казаклар вә Строгоновларның көчләренә генә карап тормады: мәркәздән гаскәр җибәртеп, яңадан акрынлап Себерне Русиягә кушты[2].

[1] Чәверү – җибәрү.

[2] Бу X фасылны укыганда Америкага беренче эспаньоллар килү, Һиндстанга беренче мәртәбә инглизләрнең ничек итеп истиля итүләре сөйләнсә, шәкертләргә […] өчен яхшы булыр. *(Авт. иск.)*

# IV Татарларда сәүдә капитализмы дәвере

## 4.1. Феодализмның дәвамы вә аның җимерелә башлавы

**Феодализмның дәвамы.** XVI гасырның ярымында Идел буе татарларының Мәскәү дәүләте кулына керүләре аларда иҗтимагый җәһәттән зур үзгәреш ясамады. Татарның феодал сыйныфының Русиягә садыйк[1] булып калганнары Мәскәү хөкүмәте тарафыннан шул ук гаскәри вә җир биләүче алпавыт сыйныфы булып калдылар.

Мәсәлән, алда күргәнчә, хәтта мулла, феодал Габдеррәзакның XVII гасырның башында да әллә ни кадәр җир-сулары вә андагы хезмәткәр чуралары бар. Хөкүмәт татар феодаллары үзләрендәге Мәскәү патшалыгының служилый сословиесе белән гаскәрилеген бер төсле ясап, татар фиркалары ясавы, аларның башына да татар бик вә мирзаларын куеп, гади гаскәриләрне дә «служилый (йомышлы) татарин» дип атап, алардан ясак вә салым алмый торган булды. Бу гаскәри фиркалар белән хөкүмәт сахра халыклары, Кырым, башкорт һәм калмыкларга каршы сугышларда һәм Балтыйк диңгезе өчен сугышканда Ливония немецлары һәм polякларга каршы хәрәкәттә кулланып килде. Бигрәк тә мондый эшләрдә Касыйм ханнары вә аксөякләре вә йомышлы татарлары («служилый татарин» һәм «йомышлы татар» икесе бер сүз: болар гаскәри кешеләр) Мәскәүгә зур хезмәтләр күрсәттеләр. Шуның өчен Касыйм феодаллары җир-су һәм чураларын XVIII гасырга кадәр бер дә киметмичә саклап килделәр. Бигрәк тә ифрат зур вәхшәт вә чапкынлыкны 1558 елда Ру-

[1] Садыйк – тугры.

сиянең Ливония немецларына каршы булган сәфәрендә кылдылар. Шул заманның немец рузнамәчеләре бу хактагы вакыйгаларны язганда сөйлиләр вә бу илле меңлек татар гаскәрләренең башында торучы сабикъ[1] Казан ханы Шаһгалине гаять зур вәхшәтләр ясаганын белдерәләр. Менә шушы хезмәтләре өчен татар феодаллары вә гади йомышлы татарлар, рус служилыйлары белән бер төсле үк, әүвәлге ата-бабаларыннан калган җирләрне вә андагы мөселман динендә булган крестьяннардан биләргә һәм сугышларда алган әсирләрне бу җирләрдә эшләтергә хокук алдылар, хәтта боларның хезмәтләре бәрабәренә Мәскәү хөкүмәте боларга рус крепостнойлары белән бергә яңа «поместье»лар да (җир-сулар) бирә торган булды. Шулай ук татарның иң югарыда торган феодаллары – бикләр вә ханзадәләр (князья и царевичи)[2] сарайда да зур урыннар тотып, царьлар янына керәләр: бигрәк тә Мәскәү патшалары Иран, Кырым, Төркия вә Урта Азиядагы мөселман җирләреннән илчеләр килгәндә аларны түргә утырта, аларга иткән хөрмәте белән бу җир мөселман мәмләкәтләренә яхшы атлы булып күренергә тырышадыр иде.

Ләкин шулай булса да, татар феодаллары XVI–XVII гасырларда сәяси хокук җәһәтеннән үзләренең рус сыйныфташларыннан түбән иделәр. Мәсәлән, бик вә ханзадәләрне тантаналы мәҗлесләргә кертсәләр дә, түргә утыртсалар да, аларны ул заман Русиясенең иң гали закон чыгару корылтае булган Боярский думага кертмиләр иде. Шулай ук бик вә мирзалар татар фиркаларының башлыклары хисаплансалар да, бу исемдә генә булып, гаскәрнең чын башлыклары «татар головасы» исемендәге рус түрәләре буладыр иде. Шулай ук бу феодаллар Мәскәү патшасы алдында мөселман җирләреннән килгән илчеләр булган мәҗлестә түрдә утырсалар да, Казанда вә Касыймда булсын, аларның өстләреннән махсус рус түрәләре бу халыклар белән мөнәсәбәттә булмыйлар иде. Казан, Касыйм аркылы үткән илчеләр белән күрешеп сөйләшмәсеннәр дип куркып тикшереп торалар иде.

Хокук Русия дәүләте каршында аз булса да, бу феодаллар үзләренең татар җәмгыятендә зур урын тоталар, коллар-чуралар асрыйлар иде. Бу мәсьәләне ачып бирү өчен без монда 1639 елда язылган

[1] Сабикъ – элеккеге.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.

Галикәй Аталык исемендәге бер аристократның васыятьнамәсенең бер кисәген үз имлясы белән күчеп узабыз, монда XVII гасырда да вассаллык вә суверенлык хөкем сөргәнен дә күрәчәкбез һәм феодалларның хуҗалыклары белән бер дә шәрехсез-нисез танышачакбыз, шул замандагы мәдәниятнең дә ни дәрәҗәдә булганын гарәп сүзләренең ялгыш имляларыннан күрәчәкбез: «Бер Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре гыйнаяте[1] хакиме берлән тәкый[2] газиз пәйгамбәрләренең хәдисен Коръән аятьләре берлән тәкый дәүләтлыг патша хәзрәтләре, хан һәм олуг бик Михаил Фёдорович Всея Русның ярлыгы һәм уложениесе берлән, тәкый шәраит[3] дөрестлеге берлән, тәкый сәед вә сәгадәт, мулла вә мәүҗүдатларның шәһидлекләре (шаһидлык урынына) берлән, иямез (суверен дигән сүз) Арыслан хан хәзрәтләре углы иямез Сәедборһан солтан хәзрәтләренең ярлыкаб боерган рөхсәтләре берлән, Тәңре Тәгалә хәзрәтләренең бәндәсе Акай мирза углы Галикәй Аталык үз икърар[4] күңелемез берлән, иямез Сәедборһан солтан хәзрәтләрегә баш орып, рөхсәт теләп, гакылымыз-усымыз[5] дөрестлегендә, дөнья вә ахирәтлек эшләремез асатлык берлән аман булгай ирдек тиб[6], бу васыятьнамә хатымызны күземез түрендә яздырдык… (монда бик күп мөһим булмаган урыннарны төшереп калдырабыз)… Бу васыятемезчә, иямез Сәедборһан солтан хәзрәтләренә, тәкый аналары – иямез Фатыйма солтан бикәч хәзрәтләренә баш оргайсыз, без колларына ярлыкаб, күңелләрдин фәгыйль[7] итеп биргән эчкән ашларын-суларын бергә хәләл итсеннәр, безнең биргән, иткән хезмәтемез, көчемез аларга хәләл булгай… Аларның ярлыкашында (аларның иганәте белән) беткән йортымыз, тәкый мәхәллә караларымыз, иямез Сәедборһан солтаннарның хакы торыр, һәрничек итсәләр, һәркемгә ярлыкасалар – аларның ireke бар торыр, тәкый иркән кеше иямез Фатыйма солтан бикәч хәзрәтләренә Уразмөхәммәд Башмаков мирас биреп киткән Айсылу атлыг хатын берлән баш орамыз (бүләк итеп калдырабыз) без карт

[1] Гыйнаяте – ярдәме.
[2] Тәкый – тагын, шулай ук.
[3] Шәраит – шартлар.
[4] Икърар – раслау.
[5] Усымыз – һушыбыз, акылыбыз.
[6] Булгай ирде тип – булсак иде дип.
[7] Фәгыйль – бәхил.

колларын. Шуның берлән яд итсеннәр безнең коламызда[1] үскән үз мадъянымыз (күк бия ат[2]) берлән баш орамыз… Янбулат углы Котынай хатыныннан сатып алган Иренә углы Корманай атлыг нимес[3] чурам (колым) ага мирасын иттем… Тәкый Ахид Мөхәммәдсәед углы киявем Тинмөхәммәд сәед берлән йөченем Табыш бикәч бергә фәгыйль булгай ирделәр, аларга шул ук Котынай хатыныннан сатып алган Иренә углы Иванай атлыг нимес чурам бездин соңра мирас булсын. Аларга тәкый Галибәк Хафиз углы, киявемез Ишмөхәммәд берлән харындашымыз солтан бикәчкә аларның икесенә Борнай углы Үтәмешдин сатып алган нимес марҗам Корманби атлыг мирас булсын (бу чуралар татар-рус гаскәрендә сугышып, әсир итеп алып кайтып, соңра ул әсирләрнең татарлашкан крепостнойлары, коллары)… Имди тәкый бу мирас бер көн ясирләремездин (әсир[ләремездин]) башка үземезнең айламал хакымыз Андрей углы Япәс атлыг чурамны Хак ризасы өчен, пәйгамбәр галәйһиссәлам шәфкате өчен, кыямәт өмиде өчен үз башымыздан азад иттек, үзгә азадларының Котынай хатыныннан сатып алган Иренә атлыг чураның хатыны Юрья кызы Дәүләшне һәм азад иттек. Үзгә азадларның азад булсын, тәкый аларның азад хатларын һәм үз күземез бетерүендә, күземез алдында яздырдык… Тәкый Андрей атлыг рус чурамыз һәм ирекле кешедер, һәркайда сәүсә үз ирке берлән анда барсын. Саладагы кече өемезгә биреп йибәргәйсез…»[4].

Бу документта без бары поляк, рус, немец җенесеннән булган колларны гына күрәбез, әмма шул заманнарда ук башка бер васыятьнамәдә исә татар коллары да зикер кылыналар. Мәсәлән, Кешбикә бикәч дигән бер хатын аристократ үзенең васыятьнамәсендә: «Мин Кешбикә бикәч дөньядин рихләт кылган соңра Балтач атлыг чура, аның угланнары Уракай берлән Шабай вә һәм Сөенечгали вә

[1] Коламызда – утарыбызда.
[2] Вельяминов-Зернов тәрҗемәсе *(Авт. иск.)*
[3] Нимес – немец.
[4] Бу документны шулкадәрле генә күчереп, башка җирен калдырабыз, монда ничек татар булмаган чураларны гына котылдыралар дип уйланса, җавап бик асат иде. 1628 елда татарлар кулындагы христиан колларны азат итү хакында әмер чыккан, бу ләкин әле гамәлгә ашмаган иде, шуны сизеп булса кирәк, алпавыт Галикәй саваплы булу өчен колларын үзе котылдырырга ашыга торгандыр. *(Авт. иск.)*

һәм Кармыш әүвәлге шикелле иремә хезмәт кылсыннар да, ул хәләлем Аллагол дөньядин рихләт кылгач азад булсыннар», – ди.

Казан ханлыгы урынында да XVII гасырның башында алпавытлар әле шактый күп, ләкин ул алпавытлар вак, эреләрнең кулларында алтмыш тугызар буйсынган крестьяннан артыклы булганы юк. Мәсәлән, Казан арты Алат юлында 166 йомышлы татарның йорты бар. Шунда йомышлылар 382 җан торалар, шунда чура – дворовыйлар 86 кеше, әмма калган бу алпавытларга хокук яисә икътисади яктан буйсынган төрле исемдәге крестьяннар, дворовыйлар белән бергә 322 җан. Арча юлында 99 мирза вә йомышлы йорты (дворы) булып, шунда 295 алпавыт җенесеннән булган җан бар. Чура – дворовыйлар 35, әмма бөтен крестьян 482 кеше. Җөри юлында мирза һәм йомышлы татарларның 203 йорты һәм шунда 868 җан алпавыт җенесеннән кеше тора, шуларның авылларында 724 крестьян бар. Әмма шуның эчендә чура – дворовыйлар 4 кеше, моннан күренә ки, XVII гасырның урталарына таба Казан өлкәсендә татар алпавытлары күп калсалар да, боларның крестьяннары, чуралары бик аз. Шуның белән бергә бу заманда инде бу алпавытларның хуҗалыклары ялланган эшчеләр васитасы белән эшли башлаганнары да күреләә. Алат, Җөри, Арча юлларындагы татар алпавытларының кулларында 43 ялланып эшли торган, русча «наймит» аталган хезмәтче – крестьяннар күренәләр.

Казан алыну белән татар феодалларының идеологияләрендә үзгәреш булмады. Вассал, бик, мирзалар үзләренең татар суверенннары булган ханнарын Мәскәү патшасына гына алмаштырдылар һәм аларны шулай ук хөрмәт итә торган булдылар. Мәсәлән, чар[1] Борис заманында язылган бер фарсы тарих китабы тәрҗемәсенең мөкаддимәсендә шундый сүзләр укыйбыз: «Җөмләтел-керистан[2] падишаһ хәзрәтләре Борис Фёдорович олуг бик ак хан… айналасы (әйләнәсе) алты хан, түгәрәге түрт хан, дөньяның турт борчын (почмагын) биләгән хан...» дип мактап китә вә татар ханы белән рус чарын һичбер аермый, чөнки хан шикелле үк ак хан вә аның сыйныфташыдыр.

[1] Чар – царь.

[2] Җөмләтел керистан – барлык христианнарның.

**Феодализмның бетүе.** Алда китергән рәкымнардан[1] бик яхшы күренә ки, XVII гасырда татарлардагы феодал сыйныфлары акрынлап кими барадар, димәк, феодализм, Казан алынгач, акрынлап зәгыйфьләнеп килә. Билгеле, моның берничә сәбәбе бар. Иң элек татар феодализмына аяк чалган, аны таудан тәгәрәтеп төшерергә сәбәпче булган нәрсә – Идел кырыйларындагы һәм Казан тирәсендәге татар феодалларының җирләрен ихтилал[2] бастырылгач мөсадәрә кылып[3], рус алпавыт вә руханиларына бирү булды. Шуның нәтиҗәсендә XVI гасырда татар феодалларыннан алынып, рус кулына кергән җирнең микъдары: Тау ягында 200,503 дисәтинәгә, әмма Казан артында (Кыр ягында) 1,352,800 дисәтинәгә җитте.

XVII гасырның башында Казан архиескопына гына бирелгән җирнең микъдары да 11830 дисәтинәгә җитте. Димәк, татар феодалларының җирләренең яхшы урыннарда булганнары рус рухани, бояр һәм служилый сословиесенә кереп бетте, бераз җир татар мирза вә йомышлылары кулында калдырылса да, ул җирләр Казаннан, Идел кырыеннан ерак булганлыктан, анда иген белән шөгыльләнү файдасыз иде. Татар алпавытының эшләре базарда рус алпавытыныкы белән көрәшә алмады, ашлык татар алпавытына кыйбатка төшәдер иде. Шуның белән бәрабәр Казан алынганда, сугыш һәм ихтилалны тыйдырганда, бу татар алпавытының бер кисәге качты, ләкин зур бер кисәге кырылды. Мәсәлән, 1557–1558 еллар кузгалышын бастырганда гына 1500 татар мирза вә бикләре кырылдылар. Чар Фёдор[4] (1584–1598) вә аның исеменнән мәмләкәтне идарә кылучы чукынган татар мирзасының углы Борис Годунов[5] «Казан патшалыгы мөдире» ләкабен йөртсә дә, шул ук сәясәтне йөртте, ләкин бу

[1] Рәкымнардан – саннардан.
[2] Ихтилал – баш күтәрү.
[3] Мөсадәрә кылып – кулга алып.
[4] Фёдор I Иванович (1557–1598) – Явыз Иван һәм Анастасия Романовнаның өченче улы, Рюриковичлар династиясе Мәскәү тармагының соңгы вәкиле. 1584 елның 18 мартыннан Мәскәү бөек кенәзе һәм Бөтен Русия патшасы.
[5] Борис Фёдороич Годунов (1552–1605) – бояр, патша Фёдор I Ивановичның җизнәсе, 1587–1598 елларда рус патшалыгының фактик хакиме, 1598 елның 17 февраленнән 1605 елның 13 апреленә кадәр Годуновлар династиясеннән беренче рус патшасы.

заманаларда татар гаскәре әле Мәскәүнең Кырым, Ливония[1], башкорт, нугай, Польша белән сугышларында кирәк иде, шуның өчен дә Иван Грозныйны үзенең соңгы көннәрендә һәм чар Фёдор бер яктан татар мирза вә бикләре үз ватаннарында экономика ягыннан кыссалар да, Мәскәүнең эчке җирләрендә аларга җирләр биреп хезмәт иттерүдә дәвам кылдылар, хәтта аларга рус чураларын (крестьяннарын) һәм сугышларда әсир итеп алынып кайткан поляк (пан чура), немец колларын кулларында тотарга ирек бирделәр. Ләкин бу ирек вакытлы гына бер чара иде, мирзаларның рус конкурентлары, билгеле, моннан разый түгел иделәр, бу бер. Икенче яктан, «бусурман» (руслар мөселманнарны шулай атыйлар булган) алпавытлары кулына рус вә христиан крепостнойларын бирү исә Русия дәүләте шикелле теократизм (дин) әсасында төзелгән бер мәмләкәтенең әсасына да хилаф[2] иде. Шуның өчен рус хаким сыйныфы булган бояр вә служилыйларның идеологлары поплар, руханилар моңарга чыдый алмадылар. Мәсәлән, Казан архиепископы Гермоген[3] чар Фёдорга шикаять язып, Татарстанга килеп утырган русларның бозылганлыкларын, телләрен вә диннәрен онытып, мөселман татар әсиренә төшкәнлекләрен белдерде. Моның нәтиҗәсендә бөтен мәсҗедне җимерергә дип бер фәрман чыкса, 1593 елда татар служилый кешеләрендә рус вә гомумән христианнарны хезмәт иттермәскә [д]игән указ чыкты. Мондый указлар соңыннан күп чыктылар, бу – шуларның беренчесе иде. Ләкин бу канунның татар феодализмын җимерергә зур бер фактор булганлыгын онытырга ярамый, чөнки моның белән татар алпавытлары бик күп эшче кулыннан җөда булырга[4] тиеш иделәр, әгәр татар алпавыты мөселман чурасын каты вә көчләп эшләтә башласа, татар алпавытлары кулындагы татар мөселман чурачылары да чукынып, шуның аркасында котылу ихтималлары бар иде. Әмма мондый буш эшли торган кешеләрне юга[л]ткач, әгәр татар алпавыты әүвәл хуҗалыгын дәвам кылды-

[1] Ливония – хәзерге Латвия һәм Эстония территорияләрендә булган тарихи өлкә.
[2] Хилаф – каршы.
[3] Гермоген (Ермоген, дөньялыкта Ермолай; 1530–1612) – дин һәм сәясәт эшлеклесе, язучы. Башта Казан архиепископы, аннары Мәскәү һәм Бөтен Русия Патриархы (1606–1611).
[4] Җөда булырга – аерылырга.

рам дип, ялланган эшче көче белән хуҗалыгын алып барырга кирәк иде, болай булганда татар алпавытының җирендә иккән иген русларныкы белән базарда конкуренция ясый алачак түгел иде. Шуның өстенә дә тагы ул заманда ялланган кеше табуы да уңайсыз булган. Әгәр, югарыда сөйләнгәнчә, татар алпавытлары җирләренең Казаннан вә су юлларыннан ерак булганлыгын хәтергә алсак, татар алпавытлары хуҗалыкларын бөтенләй алып бара алачак түгел иделәр. Ләкин чар Борис заманында ук Русиядә 1598 елдан 1613 елга кадәр дәвам кылган «Смута» аталып йөрелгән иҗтимагый вә сәяси хәрәкәт башланды. Менә бу хәрәкәттән татар йомышлысы, бер яктан, яңадан кирәк булды, икенче яктан, аны ачуландыру да хаким сыйныфлар өчен куркыныч булды. Менә без хәзер феодализм җимерелү мәсьәләсен калдырып торып, шул вакыйганы сөйләп алабыз.

**Татарларның ихтилалга катышулары.** XVII гасырда чар Борис үлеп, 1613 елда Романовларны сайлагач, берничә вакытлар дәвам кылган ихтилалда татарлар да иштиракь кылдылар[1]. Монда татарлар әле бер милләт булып түгел, бер сыйныф булып катыштылар. Русия тарихыннан мәгълүм булганча, бу ихтилалның иң зур көче алпавытлардан качкан «казак» аталып, кырлар, далаларда бөек су юллары буенда йөргән бер гонсырыннан мөрәккәб иде[2]. Бу казак арасында күбрәге рус булса да, башка, гайре рус вә татарлар да юк түгел. Әле Иван Грозный исән чакта ук нугай мирзалары патшага казакларның талавыннан шикаять кылып язгач, чар аларга: «Казаклар рус кына түгел» дип, боларның эчендә Казан, Кырым, Азак татарлары да барлыгын белдергән иде. Менә шуның өчен дә татарның ярлысы, төрле кысынкылыклар күргәнче, рус крестьяны белән бергә «казак» булып хәрәкәт кылган.

Татарларның мирза, кенәз, гомумән, служилый кыйсеме булса, үзе икегә бүленеп хәрәкәт кылган. Бер төрлесе булса боярлар тарафында, димәк, гакселхәрәкәт[3] ягында эш күргән. Аларның кайсысы

[1] Иштиракь кылдылар – катнаштылар.
[2] Бер гонсырыннан мөрәккәб иде – бер өлешеннән оешкан иде.
[3] Гакселхәрәкәт – каршы йөрү.

бояр – патша Василий Шуйский[1] (1606–1610) тарафыннан тәшәккер[2] язуларын да алгалаганнар. Мәсәлән, 1609 елда 12 апрельдә Зөя татар, чуваш, чирмешләренә язылган бер тәхсин мәктүбендә[3]: «Сез Алланы һәм мөселман динегезне онытмыйча, безгә яхшы хезмәт итәсез, ялган Димитрийләргә минем гаскәрләрем белән бергә каршы сугышасыз», дип мактый, шуның өчен дә бу сыйныф татар аксөякләре Мәскәүгә язган грамоталарда катыштылар, үзләренең сыйнфый мәнфәгатьләре өчен митрополитлар белән бергә хәрәкәт кылудан тартынмадылар. Менә мисал өчен шул грамотаның берсен алыйк: «Казаклар үзләренең гаһедләрен[4] бозып, бөтен ватан дошманнары, поляклар, литвалылар һәм рус ворларына каршы сугышалар ... Без митрополит һәм Казан мәмләкәтенең бөтен кешеләре Тау ягын һәм нугай татарлары, чирмешләр, Нижний Новгород вә Идел буеның башка шәһәрләре белән бергә карар бирдек: без һәммәбез һәрвакытта бер киңәштә булырга һәм Мәскәү, Казан илләренең бер булуын якларга, бер-беребез белән тату торырга, хыянәт итүчеләр, гаеплеләрне гөнаһларына күрә җәза итәргә булдык. Без Мәскәү тәхетенә: «Алла бер, патша җибәргәненә чаклы һәмишә шулай булырбыз… Әгәр казаклар безнең ризалыктан башка берәр кеше сайласалар, без аңар риза булмабыз». Мондый грамоталар бик күп, болар бары шуны күрсәтәләр, бу сыйныф аксөяк татарларның мәнфәгатьләре, русларныкы белән бергә, карасөякләрнең, «казакларның» баш булуы куркусы боларны үзләренең әүвәлге дошманнары белән дә берләштерә ала.

**Мәскәүдән аерылу фикере.** Ләкин кара халык вә бәгъзы иске мөстәкыйль тормышны кире кайтарырга теләүче аксөяк вә голәма сыйныфы һаман да ихтилал ягында хәрәкәт итәләр, хәтта ярыммөстәкыйль Касыйм ханы Уразмөхәммәд үзенең гаскәре белән

[1] Василий IV Иванович Шуйский (1552–1612) – кенәз Иван Андреевич Шуйский һәм Анна Фёдоровнаның икенче улы. Шуйскийлар (Рюриковичларның Суздаль тармагы) кенәз нәселенең вәкиле. 1606 елдан 1610 елга кадәр рус патшасы (Василий IV Иоаннович). Тәхеттән төшерелгәннән соң, полякларда әсирлектә яши.
[2] Тәшәккер – рәхмәт.
[3] Тәхсин мәктүбендә – мактау хатында.
[4] Гаһедләрен – вәгъдәләрен.

«Тушин карагы»[1] дип мәшһүр ихтилалчы вә казаклар ягында тора. Аның углы[2] хәтта Тушинда, соңра «карак» Калугага качкач, анда тора. Башкортлар, Себер татарлары, нугайлар һаман да шул Шуйский гаскәренә, соңра поляк гаскәренә каршы сугыша, гаскәри фиркалар белән хәрәкәт кыла.

Шуйский тәхеттән төшерелгәч, Казанда, аннан элек Мәскәүдән аерылган Әстерханда, бөтенләй Мәскәүдән аерылып, Иран кул астында[3], Идел буенда аерым бер дәүләт ясау фикере туа. Никанор Шульгин[4] дигән дьяк (воевода – вали[5] кул астындагы түрә) 1611 елда тагы да көчләп, мөселман вә русларның ярлы сыйныф гонсырына таянып, ихтилал чыгара. Хәтта бу хәбәр ул замандагы углы Мәскәү тәхетенә сайланган Польша короле Сигизмундка[6] да ишетелә, шуның өчен ул Мәскәүдәге үзенең тарафдарларына шундый бер язу яза: «Мәскәү дәүләтенең вак кисәкләргә бүленүеннән сакланыгыз». Псков һәм Новгород әһалисе[7] Швеция короле углы ягында, сездә исә шундый хәбәр бар: Әстерхан, Казан вә башка татар ягы шәһәрләре белән килешеп, Иран шаһына буйсынмакчы булалар, имеш. Әмма Казан һәм Әстерхан, чирмешләр һәм Кыр ягы шәһәрләре, Ак Идел буе һәм Себер калалары, Пермь һәм Вятка безнең грамоталарыбызны тыңламыйлар, һәм чыгышларны Мәскәүгә бирмиләр, һәм безнең углыбызга крәст[8] үпмиләр, боларның исәпләре юксыллар[9] башлыгы «Тушин карагын» (икенче ялган Димитрийны) патша итү. Ул үтерелгәч, аның углын тәхеткә

[1] Биредә Ялган Дмитрий II турында сүз бара.
[2] Биредә Марина Мнишек һәм Ялган Дмитрий II нең (башка бер фараз буенча Иван Заруцкийның) улы Иван Дмитриевич (Ворёнок, Ивашка царевич, 1611–1614) турында сүз бара.
[3] Бу заманда Иранның шактый көчле Сәфәвиләр сөлаләсе кул астында җыелган чагы. *(Авт. иск.)*
[4] Никанор Михайлович Шульгин – шәһәр дьягы, «Фетнәле заман»да (1611–1613) Казан хакиме.
[5] Вали – өлкә башлыгы, губернатор.
[6] Сигизмунд III (1566–1632) – 1587–1632 елларда Польша короле һәм Бөек Литва кенәзе, 1592–1599 елларда Швеция короле. 1610 елда Ялган Дмитрий II белән килешү төзеп, үзенең улы Владислав IV Вазаны (1595–1648) Мәскәү тәхетенә утыртырга тели.
[7] Әһалисе – халкы.
[8] Крәст – крест.
[9] Юксыллар – ярлылар.

кичереп[1], Иран кул астында яңа бер патшалык ясау. Шуның өчен дә Казан өлкәсе (1611–1612) елларда Русиянең ул чактагы буржуазиясенең илне поляк кулыннан котылдыру исеме белән ясаган хәрәкәтендә катышмый.

**Касыйм ханлыгы вә аның феодалларының рольләре.** Мәгълүм ки, XVII гасырда татарларның феодализм тормышының иң типик (типичный[2]) урыны Касыйм ханлыгы иде. Менә бу татар феодалларының учагының XVII гасыр ихтилалында тоткан урыннарын белеп үтүе – әһәмиятле бер мәсьәлә. Касыйм ханлыгын чар Борис танып, Уразмөхәммәдкә бу ханлыкка утырырга сәммүр гал кылып йөргән (яисә, русча әйтсәк, ленная зависимостька[3] биргән иде). Беренче Ялган Димитрий вә шулай ук аны кылдырып, шундый ук Уразмөхәммәдкә Касыйм ханлыгын идарәне тапшырды. Соңра Касыйм ханы вә аның аксөякләре Икенче Ялган Димитрий һәм поляклар, һәм казаклар ягына чыгалар. Шуның өчен заманының милләтчесе, рус язучысы Абрамий Палицын[4] Борис Годуновның патшалык дәверен сөйләгәндә: «Бу дөньяда чар Борис шөһрәт алды һәм Касыйм шәһәренә хан куйды һәм ул үлгән соңында бу бусурман горурланып, аның тәхетенә варис булган кешеләргә буйсынмас булды», ди. Хан үзенең гаскәре Ялган Димитрий Икенче торган Тушин янындагы лагерьга китеп, күп вакытлар шунда торды. Ләкин баштагы Касыйм ханы вә феодалларының рус хаким сыйныфлары «Тушин карагы» дип йөргән бу Димитрий ягында йөрүе гаҗәбрәк шикелле тоела. Чөнки Димитрий вә аның яраннары белән Касыйм аксөякләренең мәнфәгатьләре һич тә бер булмаска тиеш иде. Ләкин монда төп икътисади сәбәп бар иде, тушинчылар ягында булган качкан крестьяннар, поляк вә литвалылар, казаклар татар алпавытларының җирләрен талыйлар, аларның малларын алалар, вә шул заман документы теле белән әйтсәк, «крестьянишек грабят, бьют и мучат и даней правят и кормов копских и люцких правят же»[5]

[1] Тәхеткә кичереп – тәхеткә күтәреп.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[4] Абрамий Палицын – Авраамий Палицын (якынча 1550–1626 яки 1627), рус чиркәү-сәясәт эшлеклесе, язучы һәм публицист. Елъязмачы Варлаам Палицынның туганнан туган энесе.
[5] Кирилл хәрефләре белән язылган.

вә шуннан гаҗиз булган крестьяннар качалар, татар алпавытлары эшчесе вә крестьяннардан алына торган оброк – ясаксыз калалар иде. Менә Уразмөхәммәднең Тушин карагы ягындагы поляк-литва фиркаларының командирлары Сапекага[1] язган хатларына карасак, аннан татар алпавытлары вә ханзадәләренең Русиянең төрле җирләрендәге поместьеларын талатмый торган ярлык (грамота) сорадыгын[2] игътибарга алсак, Уразмөхәммәднең Тушин карагы ягында булуының икътисади сәбәбе ачыла. Шуның өчен дә бөтен Касыйм шәһәре һәм «бояре Касимовские»[3] тушинчылар ягына чыккаиннар иде. Шуның өстенә дә Касыйм феодалларының барысы[-ның] да, сугышчы булганлыкларын[а] да, шул сугышларда алына торган ганимәт[4], мал белән файдаланганлыкларын[а] да игътибар итәргә кирәк. Бу заманда Русия зәгыйфь булганга, чит илләр белән сугышта, чит җирләргә сугышка барып, әүвәлге шикелле аларны талап булмый, бары Русиянең эчке җирләрен генә таларга мөмкин иде. Шуның өчен дә, 1609 елда касыймлылар ихтилалчылар ягында хәрәкәт кылып, Алатыр, Кармыш, Ядрин, Арзамас һәм Темников рус, чуваш вә татарлары белән берләшеп, әүвәлге Казан ханлыгының Тау ягына, Зөя өязенә килделәр. Боларның башында Җангали Шөгеров[5], Еникиев атлы татар кенәзләре вә руслар торалар. Боларга каршы да Казаннан Шуйскийны таныган рус алпавыт вә түрәләре белән бергә татар кенәз, мирза һәм йомышлы татарлары чыгалар. Бу эшләре өчен 1609 елда Шуйский чарның гаскәрләре тарафыннан Касыйм шәһәре мөхасарә кылынып[6] алына, зинданнардан бояр партиясе вә чар Шуйскийның тарафдарлары азат ителәләр.

Озакламый Касыйм ханына вә мирзаларына ихтилалчылар ягыннан таярга юл ачыла. 1609 елның 27 декабрендә Тушин карагы (Димитрий) Тушиннан Калугага кача, шуннан соң Тушинда калган

[1] Лев Иванович Сапега (1557–1633) – Бөек Литва кенәзлегенең дәүләт һәм хәрби эшлеклесе, дипломат һәм сәяси фикер иясе. 1585–1589 елларда Литва подканцлеры, 1589–1623 елларда Бөек Литва канцлеры.
[2] Чыганакта ялгыш «суарадга» дип язылган.
[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[4] Ганимәт – табыш; трофей.
[5] Җангали Җанмөхәммәт улы Шөгеров (?–1616) – татар кенәзе (бәге). 1615–1616 еллардагы (соңрак «Җангали күтәрлеше» дип аталган ) Урта Идел буенда рус булмаган халыклар күтәрелеше җитәкчесе дип санала.
[6] Мөхасарә кылынып – камап.

гаскәрләре киңәшкә җыелалар, шунда Касыйм ханы вә аксөякләре дә хәзер булалар. Мәҗлес Польша короле ягына чыгарга карар кыла. Табигый, аристократияне баш итү вә боярствога зур сәяси хокуклар бирергә вәгъдә иткән Польша партиясе ягына Уразмөхәммәд хан үзенең юлдашлары белән чыгалар, Уразмөхәммәд вә Польша короле Сигизмунд янына Смоленскка китә. Шулай итеп, татар аксөякләренең моңарчы яшерен булган уйлары заһир була[1]. Ләкин хан яңадан Ялган Димитрий ягына күчә, моның сәбәбе булса, ул да Димитрийның Калугага күчкәч тагын көчәя башлавы вә татар аксөякләренең мал-мөлкәт, җир-суларының куркыныч хәлдә калуы булса кирәк. Ләкин Димитрий вә аның тарафдарлары белән Уразмөхәммәд хан вә аның вассаллары арасында низаг башлана. Шуның нәтиҗәсендә Димитрий ханны үтерә. Әмма шуның «үчен алу өчен» дигән булып, чукынган нугай мирзасы Морат – Пётр Урусов[2] Димитрийның үзен үтерә. Менә шуннан соң Димитрийның юлдашлары Калугада[н] татарларны куалар. **Менә без монда төрле катлаулар белән капланган сыйнфый көрәшне ачык күрәбез. Феодал татар сыйныфы башында бәгъзы вакытлы мәнфәгать вә сәясәт аркасында Димитрий белән вакытлы гына блок ясаган булса да, ләкин алпавыт белән җәмгыятьнең астында торган, качкан крестьян казактан мөрәккәб булган димитрийчылар арасындагы сыйнфый көрәш ике башлыкның да үтерелүе, бер-берсен кырышу белән тәмам була.**

**Беренче Романовларны тәхеткә утырту вә саклауда татар феодал сыйныфының роле.** Мәгълүм ки, Смута үзенең нәтиҗәсендә бояр – служилый сыйныфларының җиңелүе белән тәмам булды. Соңыннан хезмәт әһеленең күтәрелеше Русиянең феодал һәм сәүдәгәр сыйныфының союзы аркасында табылды. Бу союзга татар феодаллары да кергәннәр иде. Шуның өчен дә рус сыйныфташлары полякларны, берләшеп, Мәскәүдән кугач, качкан крестьяннарны җиңгәч, кире хакимиятләрен кайтара башлаган чакта, татар мирза вә бикләрен онытмадылар. Хәтта 1613 елда чар сайлау өчен җыелган Земский союзга да татар феодалларының вәкилләрен кабул

[1] Заһир була – ачык була.
[2] Пётр Арсланович Урусов (?–1639) – Нугай морзасы Як-Арыслан морзаның улы, Нугай бие Урысның оныгы. Башлыча Ялган Дмитрий II не үтерүче буларак билгеле.

иттеләр вә алар да үзләренең сыйныфташлары Романовларны сайлашып кул куйдылар[1].

Чар сайлау белән генә кузгалыш тәмам булмады һәм поляклар һөҗүмнәрен туктатмыйлар. Менә шул чакта Мәскәүдә Мәскәү суының кичет[2] һәм күперләрен саклауда татар кенәз вә мирзалары командасында булган татар гаскәре мәсьүлиятле[3] урынны тота. Димәк, рус югары сыйныфлары татар сыйныфташларына бик ышаныч белән карыйлар. Шуның өчен дә беренче Романовлар Әстерхан кебек татар калаларына язган грамоталарда татар мирза вә кенәзләренә яхшы мөгамалә кылырга, аларны «җумаларга» әмер итә. Мәскәү тәхетенә күрсәтелгән кандидатлар арасында бәгъзы бер татар ханзадәләренең исеме булуы да шул фикерне куәтлидер.

**Татар феодализмына яңа зарбәләр[4].** Шулай итеп, Русиядә булган егерме елдан артыкка тартылган иҗтимагый, сыйнфый көрәш татар феодал сыйныфына каршы булган хөкүмәт һөҗүмен туктатып торды. Ләкин Смутада җир вә крепостонойга гаять сусаган рус служилый сословиесенең вә сәүдәгәренең (итче Минин[5] вә компаниясенең) җиңелүе белән тәмам булгач, татар җирбиләүчеләренә каршы көрәш яңадан башланды.

Беренче Романов[6] башлап 1628 елда үзен сайлаучыларга каршы көрәш ачты. Шушы елдагы указы белән ул православный булмаган алпавытлар, мирза вә бикләр кулына христиан динендә булган крестьяннарны калдырмаска, әгәр бу алпавытлар үзләре христианлык кабул кылмасалар, аларның рус динендә булган кешеләрен, шулар чәчә торган җирләре белән хәзинәгә алырга боерды. Михаил Романовның атасы заманында 1649 елда нәшер ителгән һәм бояр – вак алпавыт һәм сәүдәгәрләр Соборы кабул иткән Уложениегә дә шул ук указ закон булып керде. Бу инде татарның феодал сыйныфын

[1] Бу хакта тәфсилле мәгълүмат безнең «Татар сыйныфлары тарихында» бар. Теләгән кеше шуннан карасын *(Авт. иск.)*

[2] Кичет – кичү.

[3] Мәсьүлиятле – мөһим, җаваплы.

[4] Зарбәләр – бәргәләүләр.

[5] Кузьма Минич Минин (?–1616) – Дума дворяны, рус милли каһарманы, кенәз Дмитрий Пожарскийның көрәштәше. 1611–1612 елларда Смута дәверендәге Икенче ополчениене оештыруның инициаторы һәм җитәкчеләренең берсе.

[6] Михаил Фёдорович (1596–1645) – Романовлар династиясеннән беренче рус патшасы.

рус служилыйсы белән христиан ясап, **бергә кушып руслаштыру, яисә аның эшче кулын алып икътисади бөлдерү иде.** Менә шул заманнан игътибарән[1] татарның служилый – йомышлы сыйныфы җирләренә әһәмият бирмичә калаларда сәүдә кылырга, үзләренең бер гаризаларында әйткәнчә, хезмәт юк вакытта үзләренең милке булган яисә иҗарәгә[2] алган кибетләрендә сәүдә итәргә яисә «кул һөнәре белән» шөгыльләнергә башладылар.

**Менә шул заманнан алып татарларда алпавытлыктан сәүдәгә күчкән, рәсми язуларда «торговый служилый татарин» дигән бер гөруһ[3]** кеше килеп чыга. Казан алынгач, Әстерхан негайлар һәм башкортлар вә Сибирия Русия кулына кергәч, Русия белән Казан ханлыгы арасындагы сәяси киртәләр беткәч, татар сәүдәгәрләре өчен сәүдә мәйданы бик киң вә бик файдалы булып калды. Әүвәлдә хөкем сөргән бер өлкәдән икенчесенә үткәндә алына торган «тамга акчалары» (пошлиналар) бетте. Бу өлкәләрнең бер-берсе белән мөстәкыйль сугышып торулары да бетеп, сәүдә юлларын Мәскәү хөкүмәтенең стрелецлары саклый башладылар. Шул ук чакта тагы Русиянең Англия вә Голландияләр белән сәүдәләре көчәйде, Архангел да заманасына күрә иң мөһим бер пост булып китте.

Казан үзе дә Русиянең сәүдә җәһәтеннән Мәскәүдән кала икенче шәһәре булып китте. Елына бер миллион сум сәүдә обороты ясый башлады[4]. Татар сәүдәләре вә Русия белән Азия сәүдәсен дә, тел вә горефләрен белгәнгә, бу халыклары белән бер диндә булганга, зур васитачылык[5] ролен ифа итә[6] башлады. Татарның мирзасы Азия илләренә хөкүмәтнең илчесе, тылмачы ителеп йөртелә башласа, татар теле бу Азия халыклары белән васитада, дипломатия теле булып китсә, аның сәүдәгәре вә сәүдәгәргә әйләнә башлаган мирза вә йомышлысы, малларын төяп, Азиягә үзе китә башлады. Әлхасыйль[7], феодализм какшады, әмма сәүдә капиталы туа башлады.

---

[1] Игътибарән – башлап.
[2] Иҗарәгә – арендага.
[3] Гөруһ – төркем.
[4] Шул ук чакта Мәскәүнең обороты биш миллион. *(Авт. иск.)*
[5] Васитачылык – арадашчылык.
[6] Ифа итә – үти.
[7] Әлхасыйль – кыскасы.

**Ирекле крестьяннар.** XVII гасырның башларыннан алып татарларда феодализм какшый башлаган чакта без татарларда хаким сыйныф булган феодаллар вә йомышлылар хакында вә сәүдәгәрләрнең килеп чыгулары хакында күп кенә тукталдык, ләкин бу XVI–XVII гасырларда күпчелек булган сыйныф – болар да вә аларның крепостной крестьян кол чуралары түгел, бәлки «ясаклы татар» аталган авыл халкыдыр. Боларның хокуклары аз, җирләре көн саен колонистлар килү аркасында кысылып тора, үзләре хөкүмәткә натураль салым – «ясак» түләп торалар иде. Болар Мәскәүнең XVII гасыр хөкүмәте тарафыннан рәсми яктан телгә дә алынмыйлар, болар бары салым – ясак түләүләре ягыннан гына хөкүмәт өчен әһәмиятле иделәр. Болар рәсмән крепостной булмасалар да, асылда, бу ясаклыларның күбесе бояр, алпавыт, мирза һәм попларга буйсынган булалар иде. XVII гасырда ясаклы крестьяннардан башка русларда нинди төрле авыл халкын очратсак, татарларда да шундый ук гөруһлар тудылар. Аларның эчендә наймит[1] аталган җирсез, ялланып эшләүчеләр бар иде. Боларның саны Казан артында (XVII гасырда) Алат юлындагы алпавытлар кулында 5 кеше, Арча юлында 35 кеше. Җөри юлында 3 кеше булганы мәгълүм, болардан кала «бабил» аталган җир вә йортсызлары бар иде. Тагы мәнбәгъләр[2] татарлар эчендә «надворный» дигән бер нәүгъ[3] татар крестьяннарын телгә алалар.

**Ирексез крестьяннар.** XVI–XVII гасырда татар алпавытлары кулында икътисади вә хокукый яктан кол булган крестьяннарны феодализмның дәвамы хакында сөйләгәндә әйтеп уздык, ләкин XVII гасырда алар рус алпавытлары вә руханилары кулында да бар иделәр. Казан архиепископларына хөкүмәт әүвәлге хан вә аларның ыругларының җирләрен тапшырган. Менә шул җирләрдә татарлар да бар иде. Мәсәлән, 1623–1624 елларның хисабы буенча Казан архиепископы кулында 7 чиркәүле авыл, бер кечкенә татар авылы, 20 данә рус вә татар авыллары булганы, шуларда 386 крестьян йорты (руслар), 233 рус бабилләре йорты һәм **76 татар йорты булганы мәгълүм.** 1649 елдагы закон буенча христиан булмаган крестьян рус кулында, мөселман булмаган крестьян мөселман

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Мәнбәгъләр – чыганаклар.
[3] Нәүгъ – төр.

кулында торырга ярамый диелсә дә, бу закон белән хөкүмәт руханиларга җир биргәнен гамәлен кылмыйдыр иде. Мәсәлән, 1681 елда архиеписко[п]лар кулында саф татар авыллары булганы мәгълүм. Шул авыллардан Кара Буа, Селик Кабан[1] һәм Карашивә[2] (хәзер татарлар Каришә дип йөртә торган Лаеш контонындагы рус авылы) дигән мөселман авыллары бар иде, ләкин руханилар бу авылларны чукындырырга тырышалар, әгәр теләмәсәләр, куып җибәреп? рус крестьяны китереп утырталар иде. Табигый, татар крестьяннары да, руслар шикелле үк, руханилар кулындагы җирләрдән, аларга хезмәт итәселәре килмичә, качалар иде. XVII гасырда шулай Караеш авылында ике татар качып, Казан өязендә торганы мәгълүм.

Архиепископларга оброк түләүче тагы бер төрле авыл халкы бар иде. Болар исә умартачылардан гыйбарәт иделәр. Әле бу заманда умартаны бакчада асрау юк, бәлки бер нәүгъ авыл халкы калын урманнарда йөреп, йөзләп умарта оялаган агачны табалар да шуңарга үз тамгаларын салып китәләр иде.

Әгәр бу урманнар алпавытлар яисә руханилар кулында булса, шул умарта башыннан салым – оброк түлиләр иде. Мәсәлән, 1623 һәм 1624 еллар эчендәге мәгълүматка караганда, архиепископ урманнарында 44 татарның (шуның берсе йомышлы) 2330 умартасы булып, шуннан шул заман акчасы белән бер рубль, 14 алтын, 4 деньга – акчалата, әмма 67 батман[3] 35 фунт[4] баллата архиепископка оброк җыеладыр иде. Кайсы татарларның умарталары күп кенә булган. Мәсәлән, югарыда күрсәтелгән еллардагы хисап алу дәфтәрендә (Писцовая Книга[5]) шундый мәгълүмат очратабыз: «Митрополичьи деревни Татаровя деревни Кабанов, Андербаш, Амелеков дельних триста дерев, а оброку дает три батмана меду да восемь алтын две деньги – знамя (гот) Андербашева № 14»[6].

[1] Селик Кабан – Татарстанның Лаеш районындагы авыл. Бүген Татар Кабаны исемен йөртә.
[2] Карашивә (Каришә) – Татарстанның Лаеш районындагы авыл. Бүген Караеш исемен йөртә.
[3] Батман – Россиядә искергән үлчәү берәмлеге. 1 батман – 4,1 кг.
[4] Фунт (татарча: кадак) – Россиядә искергән үлчәү берәмлеге. 1 фунт (кадак) – 0,40951241 кг.
[5] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[6] Кирилл хәрефләре белән язылган.

Архиепископка мәнсуб булган[1] авылларда торучы йорт-җирсез бабил аталган татар крестьяннары да акча белән оброк түлиләр иде. Оброкның микъдары XVII гасырда һәрбер йортка ул заман акчасы белән унар алтын (Алтын[2]) түлиләр иде.

**Бер нәтиҗә.** Архиепископка оброк түләүче татарлардан умартачы һәм бабилләр эчендә без оброкны акча белән түләгәнне күрдек. Бу мәсьәлә безнең бу фасылда әйткән сәүдә капиталы татарлар арасында тууын яхшы күрсәтә. XVI гасырның беренче чирегендә язучы Һерберштейн[3] татарларның гадиләрендә акча юклыгын, алтын-көмешнең бары сәүдәгәрләр кулында гына булганын сөйли. Әмма шуннан йөз ел үткәч, без башка бер картинаны күрәбез: крестьяннарның байлары булган умартачыларның каюсы оброкны акча белән түли. Димәк, бал табу, умартачылык эше татарлар арасында товарный хуҗалыкка әйләнгән, алар балларын саталар, аны акчага әйләндерәләр. Шулай ук татар крестьяннарының иң ярлылары бабилләрдә дә акча бар, димәк, алар да архиепископ җирен чәчеп, шуннан хасил булган игенне акчага саталар. Димәк, сәүдә капитализмы Казанның үзендә генә түгел, караңгы авылларга вә караурманнар эченә дә керә башлаган.

**Крестьяннарның хуҗалыгы.** Татар крестьяннарының җирләре община рәвеше белән биләнә. Шуның өчен дә Писцадагы[4] кенәгәләр һәрбер татар йортын аерым-аерым сөйләсә дә, аларның җирләрен гомуми хисап белән йөртәләр. Ләкин бәгъзы авылда исә, җәмәгать җире булмаган һәрбер йортның аерым милке булган җирләр дә бар. Ләкин болар крестьян түгел, бәлки вак йомышлы татарлар. **XVII гасырның беренче чирегендә үк өч басуга бүлеп иген игү хөкем сөрә.** Шуның өчен без мәнбәгъләрдә татар авылларын вә аларның җирләренең микъдарын сөйләгән чакта шундый җөмләләр

[1] Мәнсуб булган – билгеләнгән.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Сигизмунд (Зигмунд) фон Герберштейн (1486–1566) – барон, Австрия дипломаты. Рус дәүләтенең географиясе, тарихы һәм эчке төзелеше турындагы зур хезмәте белән таныла. Биредә шулай ук татарлар, аларның яшәү рәвеше, йолалары, хөкемдарлары, рус-татар, татар-төрек һәм рус-төрек мөнәсәбәтләре, шулай ук Казан ханлыгы турында мәгълүматлар да теркәлгән.
[4] Писцадагы – писцовый.

очратабыз: «На все три поля иметца по три десятины ...»[1], димәк, Казан алыну белән, илгә рус колонизациясе башлангач, җир кимеп калгач, татарларда өч басулы система иген игүгә күчә башлыйлар. Вә шул җир XVII гасырда тыгызлана, азая башлады (табигый, элек Казан янындагы җирләр), мәсәлән, 1636 елда митрополит кулындагы Кириски авылының рус крестьяннары белән Каратай авылының ясаклы татар крестьяннары арасында печәнлек хакында низаг чыгып, түрәләр шул мәсьәләне тикшерүләре вә хөкем булуы мәгълүм. Югарыда сөйләнгән сүзләрдән ачык бер нәтиҗә чыгарырга була: **татарларның феодал сыйныфы XVII гасырның уртасындагы кол асрау мәсьәләсенә даир законнар аркасында хөкүмәткә чын ихластан дуст була алмыйлар иде.** Шуның өчен дә XVII гасырның икенче ярымында Казан өязе Урман дигән авылның йомышлысы Җангали исемле кеше кул астында күтәрелештә булып, алдап, аны Ямәй атлы бер татар тотып биргәч, бу хәрәкәт бастырылган, аның угыллары Ишбулат һәм Айтуганнарның да җирләре мөсадәрә ителеп[2], Новгородка сөргенгә җибәрелгәннәр иде. Бу йомышлы вә ми[р]залардан килеп чыккан йомышлы сәүдәгәр татарлар да хөкүмәт белән килешеп бетә алмадылар. Чөнки, бердән, боларны хөкүмәт мәҗбүри гаскәри хезмәт иттерә, шуның өстендә зур налоглар аладыр иде. Крестьяннарга килсәк, бу мәсьәлә ачык: аларны, тотып, попларга, мирзаларга чура-кол итеп биргәннәр яисә аларны шуларга зур оброклар түләргә мәҗбүр иттеләр.

Шуның өстенә дә табигый дини кысынкылык вә мөселман динендә булганлыклары өчен хокуксыз булалар, хәтта бер рус җинаять эшләсә, шаһит булу хакына да малик[3] була алмауларын алырга кирәк. Әгәр шуңарга җирнең азаюы, рус алпавыт вә руханиларына җирләрен биреп, үзләре чукынмасалар, иске авылларыннан куылуларын гына хәтергә алсак да, **татар крестьянының хөкүмәткә ничек каршы булганын белербез.**

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Мөсадәрә ителеп – конфискацияләнеп.
[3] Малик – ия.

Степан Разин[1] татарларның төрле сыйныфларында хөкүмәт вә хаким служилый бояр сыйныфының каршы булган рухларын бик яхшы белгән булырга кирәк. Моны белдерүчеләрнең берсе мәгълүм. Ул да булса татар аксөякләреннән Хәсән (Асан) Карачура углы Айбулатов дигән кеше. Бу кеше кулында Касыйм янындагы Кадом һәм Керенский өязләрендә җир-сулары булган. Ихтимал, Хәсәннең кулындагы христиан динендәге крепостной чуралары алынып, алар били торган җирләре дә хөкүмәткә алынгач, Хәсән хөкүмәткә каршы хәрәкәттә иштиракь кылгандыр. Һәрхәлдә, бу кеше Степан Разинның янында булган. Разин татар халкына татар телендә прокламацияләр, «прелестное письмо»[2]лар җибәрә торган булган. Менә шуның Казан вә өяз әһалисенә, төрле сыйныфларына карап язылганы шушы Хәсән исеменнән язылган булган. Шул хитабнамәнең русчасы сакланып калган. Без бу урында шуның татарча тәрҗемәсен китерәбез: «олуг войско (чирү)дән, Степан Тимофеевичтан мәгълүм булсын: сез ки, Казан бистәсе мөселманнарына һәм әһле мәчет башы абзыйларга, барча әһле исламга һәм фәкыйрь вә колларга мәрхәмәт вә шәфкать итүчеләргә, Икеш муллага һәм Мамай муллага һәм Ниш мирзага, Москов мирзага, барча бистә һәм өяз мөселманнарына Степан Тимофеевичтан, бу дөньяда һәм киләчәктә, баш орам (в этом свете и в будущем челобитне[3]). Сәлам соңында бездән хәл-әхвәл сорасаңыз, без сәламәтбез һәм сез дә сагъ булгай идеңез. Сүзебез шулдыр: Тәңре, пәйгамбәр һәм патша (для государя[4]) вә гаскәр (казаклар морад[5]) өчен сез безнең белән бергә булгай идегез, әгәр дә бергә булмасагыз, соңра безгә үпкәләмәгез. Тәңре шаһиттыр кем, сезгә бертөрле дә начарлык булмаячак вә без сезнең өчен тырышабыз. Янә мәгълүм булгай иде: мин Хәсән Айбулатов Степан Тимофеевич янында һәм безгә бу хакта ышаныгыз, мин Хәсән сезгә бу тугрыда мәслихәт итәм[6], әгәр миңа инансаңыз, начар

[1] Степан Тимофеевич Разин (1630–1671) – Дон казагы, Дон гаскәре атаманы, 1670–1671 елларда Пётр чорына кадәрге Россия тарихында иң зур күтәрелешнең җитәкчесе.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[4] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[5] Морад – аңлатыла. Биредә: күз уңында тотыла.
[6] Мәслихәт итәм – киңәш итәм.

булмас. Барчаңыздан үтенәм. Мин сезнең барчаңыздан разыймын, әмма бездән сезгә – баш ору. Бу ярлыкка үз мөһеремне бастым!»

Вакыйган[1], татар вә гайре русларның чуваш, марилар, Разин Семберне мөхасәрә кылган[2] чакта, Семберне җолып алырга килгән хөкүмәт гаскәренә юлда әллә ничә мәртәбәләр һөҗүм кылалар. Бу фиркалар хәтта чуваш байларына да һөҗүм кылалар. Мәсәлән, Чуел өязендәге өч бай чуваш хөкүмәткә гариза биреп разинчылар тарафыннан таланганлыкларын сөйләгәндә: «Воровские татары и чуваши хотели до смерти избить»[3] диләр.

Димәк, монда тагы гайре русларның үз араларында сыйнфый көрәш галәмәтләре күренә башлый. Семберне котылдырырга Мәскәүдән җибәрелгән икенче бер фирка гаскәр җиңелеп, Тәтешкә чыккан иде, шуның башлыгы Иван Барятинский Алексей патшага язган рапортында: «Атлы гаскәрдә һәм казак гаскәрләре эчендәге татарлар начар һәм ышанычсыз, беренче сугышта ук качып киттеләр. Алардан өмид юк, аларны юкка туйдырып мал әрәм итәргә ярамый», ди.

Ләкин шулай булса да, Разинның бөтен татар-мөселман сыйныфларына таянуы хата чыкты. Сәгыйть Хәлфиннең[4] 1767 елда Мәскәүгә закон чыгару комиссиясенә Казан мирза вә йомышлыларыннан алып килгән наказда мактанып, Казан мирза вә йомышлыларының Разинга каршы нык сугышканлыклары белдерелә. Димәк, Смута вакытындагы шикелле бу вакыйгада да татар феодал калдыклары үзләренең рус сыйныфташларын онытмыйлар.

**Касыйм ханлыгының бетерелүе.** Татар халкы XVII гасырда сәүдә капитализмы дәверенә аягын басса да, әле феодализмның нык оясы Касыйм ханлыгы исемендә генә исән торадыр иде. XVII гасыр бу учакны да бетерде. Менә шул хакта бераз сөйләп узмый хәл юк. Казан белән Мәскәү дәүләте арасында буфер (фасилә) Касыйм

[1] Вакыйган – чыннан да.
[2] Мөхасәрә кылган – камап алган.
[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[4] Сәгыйть Хәсән ул Хәлфин (1732–1785) – педагог, тәрҗемәче. Казанда Татар бистәсенең йомышлы татары улы, 1750 елларның икенче яртысыннан Казан адмиралтей診ствосында тылмач. 1769–1785 елларда Казан гимназиясендә татар теле укыта. Казан бистәләренең йомышлы татарларыннан Яңа кануннар эшләү комиссиясе (1767–1769) депутаты.

(Ханкирмән ханлыгы) Русиядә ихтилал – Смута булган чакта исән иде. Аның ихтилалдагы роле, Русия хөкүмәтенең юклыгы яисә зәгыйфьләнүе аны бетерергә ирек бирмәгән. Романовлар баш булу белән ачыктан-ачыкка ханлыкка каршы хәрәкәт башлана. Мәскәү бу ханлыкны ничек оста бетерә дә. Ләкин бу ханлыкны туры гына юк итү мөмкин түгел иде. Чөнки Русия бу ханлыкны асравы белән Төркия вә Иран һәм Кырым ханлыгы алдында исламга тимәүче булып күренәдер иде. «Ник Казан вә Әстерханны алдың?» дигән сүзгә рус чарлары: «Менә без бит, үзләре яхшы торгач, Касыйм ханлыгына тимибез, бәлки билгакес[1] анда мәсҗедләр салдырабыз. Аларга ирекле торырга рөхсәт бирәбез. Казан, Әстерхан үзләре безгә каршы хәрәкәт кылдылар, без аны шуның өчен бетердек», диләр иде. Икенче яктан, Касыйм ханнары вә аларның гаскәрләре гайре мөнтазам[2] атлы гаскәр булып, поляклар вә Кырым татарлары белән булган сугышларда иштиракь итәләр[3]. Шуның өчен аның хәзергә кирәге булган. Өченче яктан, Мәскәү хөкүмәте Касыймның ханнары белән Мәскәүгә, Иран, Урта Азиядән килгән илчеләрне кабул иткәндә файдаланганнар, алар килгәндә Касыйм ханнары хәзер булып, бертөрле Мәскәүнең зурлыгын һәм ислам дөньясы белән дуслыгын күрсәтә торган булган. Дүртенче сәбәбтә, Касыйм ханлыгын дәфгатән[4] бетерсәк, Мәскәүнең үз кул астындагы мөселман ханлыкларының разыйсызлыгы кубарга мөмкин булган. Ниһаять Русияне идарә кылучы да, алпавыт, хан да, шулар шикелле үк ханлыктан тышта да әллә никадәр җире булган бер алпавыт, аның сыйныфташлары – зур байлар ханны рәҗетмәскә теләгәннәр булыр.

**Бетерүнең юллары.** Касыйм ханнарын хөкүмәт бик хөрмәтли, төрле тантаналы мәҗлесләрдә аларны булындыра. Урынның бик югарысына утырта. Хәтта Арыслангали яисә Алыпарыслан[5] хан

[1] Билгакес – киресенчә.
[2] Гайре мөнтазам – тәртипсез, рәтсез.
[3] Иштиракь итәләр – катнашалар.
[4] Дәфгатән – кинәт.
[5] Арыслан хан (?–1627) – Касыйм ханы (1614–1624). Гали ханның улы, Күчем ханның оныгы.

Мәскәүгә килгәч, шунда аны Англия сәфире[1] Жон Мәрикәдән[2] югарырак утырттылар. Шулай булса да, рәсмән[3] алар рус байлары белән бертигез булсалар да, ханнарны Русиянең гали диваны булган Боярский Думага кертмиләр, алардан шикләнәләр, өсләреннән карап торырга «головалар» куялар иде. Беренче Романовлар заманасында Касыйм ханлыгында рәсмән хакимият хан кулында хисапланса да, асылда илне Мәскәүдән җибәрелгән воевода идарә кылган. Шулай ук судта да ханның вәкиленә керергә рөхсәт ителмәгән.

XVII гасырда инде Касыйм ханлыгы Русия өчен әүвәлге сәяси әһәмиятен югалткан иде. Казан ханлыгы беткән. Шуның өчен Мәскәү белән Казан арасында андый буфер да кирәк түгел иде.

Касыйм ханнары үзләре, соңгы Бохара әмирләре шикелле, вакытларын Мәскәүдә үткәргәннәр, анда кунак булып ятканнар. Шуның өчен алар бик нык рус боярлары белән катышып, руханиларның тырышуы аркасында руслашалар, хәтта 1573 елда Саин Булат хан[4] чукынып, Семён аталган.

Касыймның соңгы ханы Сәедборһанны[5] элек, Алексей патшаның[6] кызын алып бирәбез дип, чукынырга димләсәләр дә, 12 яшендә генә булганлыктан, балигъ булганчыга кадәр калдырылган. Соңра 1653 яисә 1655 еллар арасында Сәедборһанны хөкүмәт алдап чукындырып, Василий дип исем биргән, шуның өчен дә Кырым ханы Мөхәммәдгәрәйнең олуг вәзиренең Русиягә биргән нотасында: «Ханкирмән солтанын сәясәт итеп көч белән христиан әйләеп, ошаусыз эш итәдер», дип үпкәләгән вә тәһдид иткән[7]. Бу Сәедборһанга кадәр булган Касыйм ханнарын Мәскәү хөкүмәте

[1] Сәфире – илчесе.
[2] Джон Мейрик (якынча 1559–1639) – Англиянең Россиядәге илчесе, Мәскәү компаниясе эшлеклесе.
[3] Рәсмән – рәсми рәвештә.
[4] Симеон Бикбулатович (чукынганчы Саин Булат хан; ?–1616) – Касыйм ханы (1568–1573), Әхмәд хан оныгының улы. 1575 елда Русия бөек кенәзе Явыз Иван урынында патша булып торган.
[5] Сәед Борһан хан (1624–1680) – Касыйм ханы (1627–1679). Арыслан хан белән Фатыйма Солтанның улы.
[6] Алексей Михайлович Тишайший (1629–1676) – Романовлар династиясеннән икенче рус патшасы. Михаил Фёдорович һәм аның икенче хатыны Евдокиянең уллары, Бөек Пётрның атасы.
[7] Тәһдид иткән – янаган.

тәгаен кылып[1] килде. Аларны чарга садыйк[2] хезмәт итүе хакында ант иттергәннәр. Сәедборһан Василийга әйләнгәч тә, «чар» ләкабе белән Ханкирмән солтаны булып торды, ул 1679 елда үлде. Аның урынына хан тәгаен кылынмады, аның анасы үлгәнче «Касыймов хуҗасы» исеме белән торды.

Шулай итеп, сонгый[3] ясалган Касыйм ханлыгы сонгый рәвештә бетерелде. Димәк, татар феодализмының соңгы учагы Касыйм ханлыгы да җимерелде.

**Феодализмның бетүен туктатып торган бер вакыйга.** Шулай итеп, XVII гасырның ахырына таба Русиянең эчендә сәүдә капиталы үсү Идел елгасы вә Казанның сәүдә дә әһәмияте арту аркасында, югарыда күрсәтелгән эчке сәбәпләр аркылы татар феодализмы бетә вә аның сыйныфы да яисә гади крестьян булып кала, яисә сәүдәгәргә әйләнә башлады. Ләкин кешеләрнең үткәнендә бара торган тарих арбасының көпчәгенә таяк тыгылган вә шуның аркасында вакытлы уларак тарихның көпчәге тәгәрәми торган вакытларын да очратабыз. Дөрес, бу тәсадефи[4] вакыйгалар тарихның китешен туктата яисә аны кире борып җибәрә алмый, ләкин вакытлы булса да, аның китешен акрынлатырга хәлләреннән килә.

Менә без XVII гасыр татар тарихында аның, феодализмнан тәмам чыгам дип торганда, китешен акрынлаткан бер вакыйганы күрәбез. Ул менә нәрсәдән гыйбарәт: Алексей патшаның углы Фёдор 1682 елда үлгәч, 1689 елга кадәр яшь шаһзадә Иван вә Пётр яшь булганлыктан, мәмләкәтне Алексейның кызы Софья[5] идарә кылып тора.

Шушы вакытта Русиянең эчендә тәхет тирәсендә тагы низаг башлана. Стрелец исемле җалланган гаскәр башлыклары Хованский[6] кул астында Софьяга каршы кубалар, боларга каршы Со-

[1] Тәгаен кылып – билгеләп.
[2] Садыйк – тугры.
[3] Сонгый – ясалма.
[4] Тәсадефи – очраклы.
[5] Софья Алексеевна (1657–1704) – Алексей Михайловичның кызы, энеләре Иван һәм Пётр балигъ булмаган чорда регент булып тора.
[6] Иван Андреевич Таруруй Хованский (XVII башы – 1682) – Михаил Фёдорович, Алексей Михайлович, Фёдор Алексеевич һәм Софья Алексеевна идарә иткән чорларда рус хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, воевода, наместник һәм бояр.

фья служилый сословиедән гыйбарәт гаскәри куәт куеп, низагны бастыра. Табигый, бу сыйныфтан булган гаскәр эчендә татар йомышлылары да булган булырга кирәк[1]. Ләкин боларның кулларындагы «христиан динендәге крестьяннар вә мирза йомышлылар православие кабул итмәсәләр, җирләрен дә мөсадәрә кылырга кирәк» дигән закон буенча җирләре алына башлагач, боларның Софьяны якламау ихтималлары бар иде. Шуның өчен дә Софья 1682 елда мирза вә йомышлы татарларның бу хакта булган шикаятьләрен игътибарга алып, бер указ чыгарды. Бу указ буенча татар алпавытларының христиан динендә булган (яисә шул дингә чыккан) крестьяннарын азат иткәндә мөсадарә кылырга тиешле җирләренең яртысын мирза вә йомышлыларының үз кулларында калдырып, калганын гына мөсадарә кылырга әмер иткән иде. Менә бу закон, табигый, татар феодалларына тагы ял итәргә вакыт – миһләт бирде. Аларның җирләре бөтенләй бетмәде. Соңра Пётрның яшьлеге, соңра ул мәмләкәтне, идарәне үз кулына алгач булган стрелец гаскәренең кузгалуы, Пётрның сәяхәтләргә китеп йөрүләре, Азов өчен Төркия белән сугышы, соңра 1700 елдан алып 1709 елга кадәр Шималь сугышы[2] вә ул сугышта башта Русиянең җиңелүе, 1706 [елда] Әстерханда фетнә, 1711 елда Прут янында Пётрның гаскәренең җиңелүләре, 1708 еллардагы татар-башкорт кузгалышы бетүдә татар йомышлы вә мирзаларыннан гыйбарәт гаскәр фиркаларының кирәк булып чыгулары – һәммәсе дә Русия хөкүмәтен татар алпавытларына игътибар итәргә вә алар белән шөгыльләнергә ирек бирмәде, шуның өчен татарның феодал сыйныфы үз җае белән генә бетеп барса да, һаман исән калды, **шулай итеп, феодаллары зәгыйфьләнгән, таланган, бик күбесе сәүдәгәрләргә әйләнгән килеш XVIII гасырга аяк бастылар.**

[1] Бу хакта мөфассал мәгълүматны безнең «Татар сыйныфлары тарихыннан» караңыз. *(Авт. иск.)*

[2] Төньяк сугышы (1700–1721) – Россия белән Швеция, шулай ук аларның союздашлары арасында Балтыйк төбәген контрольдә тоту өчен барган хәрби конфликт. Сугыш Россиянең җиңүе белән тәмамлана һәм зур территориаль казанышларга һәм аның бөек держава статусын ныгытуга китерә.

## 4.2. Татар феодализмының җимерелүе вә аның калдыгы (1713–1775)

**Феодалимзга тагы бер зарбә[1].** Русия хөкүмәте 1709 елда Полтава янында, конкуретный Швецияне җиңеп, «Яурупага тәрәзә ачып», Балтыйк кырыйларына чыгып, сәүдә капиталын тагын көчәйтеп җибәргәч, яңа форма, Яурупаныкы төсле, даими өйрәтелгән гаскәр дә ясап җибәргәч, хәзер Пётрның хөкүмәте вә әүвәлге шикелле йомышлыларга гына таянычы сәүдә капиталы сахибләренә[2] вә таяна башлагач, татар феодализмына вә үз-үзеннән бер зарбә орылырга кирәк иде.

Шундый эш һәм булды да. 1713 елда башка мәсьәләләрдә гаять дингә өстән карый торган, шуның өчен рус динчеләре тарафыннан «Антихрист – Дәҗҗал» дип аталган Пётр гаять диндар бер указ чыгарды. Бу указ шул атасының мирза вә йомышлы татарларга гаид чыккан[3] указын тагын да катырак рәвештә тәкрардан[4] гыйбарәт иде. Әгәр татар мирза вә йомышлыларының поместье вә вотчиналарында[5] христиан динендәге крестьян дворовыйлары булса, мирзаларын ярты ел эчендә чукынырга әмер итәргә. Әгәр дә алар теләмәсәләр, крестьян дворяннарын вә җирләрен патшага мөсадәрә кылырга (взять и отписать на него Вел. Государя[6]), шул ук елда вә айда указ тагы тәкрар кылынды. Монда мирза вә йомышлыларга миһләт[7] бирмәскә кушылган иде. Бу указ Пётр заманының барча указлары шикелле ачык язылмаган вә аны төрлечә итеп аңларга мөмкин булганлыктан, татар алпавытларының кулларындагы бик күп крестьян үзләре чәчә торган җирне генә алып калып, үзләре котылу белән генә канәгать итмичә, алпавытларның үзләре чәчә торган җирләрен дә ала башладылар һәм аларны усадьбаларыннан да куып чыгара башладылар. Димәк, татар алпавытларына каршы чын бер җир хәрәкәте чыкты.

[1] Зарбә – бәрү, сугу.
[2] Сахибләренә – хуҗаларына.
[3] Гаид чыккан – караган.
[4] Тәкрардан – кабатлаудан.
[5] Хөкүмәт тарафыннан хезмәтләре өчен бирелгән яисә ата-бабаларыннан калган җирләрендә.
[6] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[7] Миһләт – кичектерү.

Билгеле, Пётрның хөкүмәте моңарга чыдый алмады. 1715 елда бу указларны шәрехләүче бер указ чыгарып конфискация ясаганда, бары татар мирза вә йомышлылары кулындагы христиан динендәге кешеләрне генә котылдырып, алпавытларның үзләре игә торган җир, болынлыкларга вә аларның усадьбаларына тимәскә иде. Болай итмәгәндә, мөселман алпавытларына каршы купкан крестьяннар православный алпавытларга да һөҗүм кылулары бик ихтимал иде.

**Моннан чыккан бер нәтиҗә.** Менә бу указдан татар алпавытларының крепостной хуҗалыкларына да бер-бер нәтиҗә дә чыга, әгәр татар алпавытлары үзләре **өчен чәчеп торган җирләре аерым булып, крестьяннарныкы башкача бүленгән булса, татарлар барщина белән түгел, бәлки христиан динендәге крестьяннарны оброк түләтү ысулы белән хуҗалык алып барганлыклары, әмма үзләренә тигән җирләрне исә, яисә ялланган кешеләр көче белән баеп, мөселманнан булган чуралар – дворовыйлар васитасы белән эшләнгәннәре аңлана.**

Татар алпавытлары бу указлар чыгу белән күбесе чукынмады. Җирләре, крестьяннары мөсадәрә кылынды[1]. 1718 елга кадәр Казан губернасының – биш, Азовский губернаның ике өязендәге 17 алпавыт дворы, 540 крестьян дворы, 3 скотник, мәҗмугысы[2] 560 йорт мөсадәрә кылынды. Шунда 39 җан ир вә хатын чура – дворовый, 3748 ир вә хатын – крестьян, 8 скотник, барысы 3795 җан бар иде. Касыйм мирза вә йомышлылары кулыннан 302 йорт 175 җан крестьян мөсадәрә кылынган.

Бу «мөселман кулында христиан торырга ярамый» дигән закон бөтен XVIII гасыр буенча бакый кала. Бу закон татарлардагы феодализм калдыгын сындырырга зур ярдәм итә: моның аркасында **мөселман-татар мирзалары эшчесез калалар,** чөнки, бер яктан, христиан динендәге крестьян кулларыннан китсә, икенче яктан, татар алпавытлары мөселман җенесеннән булган колларын көчләп эшләтә алмыйлар, әгәр ныклап көчли башласаң, татар крестьяны да чукынып, татар алпавытлары кулыннан котылу ихтималы бар. Соң ничек татар алпавыты үзе чукынып, җир вә крестьяннарын саклап алып калмый? Моңарга җавапны без тәфсилле рәвештә түбәндә

[1] Мөсадәрә кылынды – тартып алынды, конфискацияләнде.
[2] Мәҗмугысы – барлыгы.

күрәчәкмез, ләкин хәзергә асат кына җавап биреп узабыз: татар алпавытлары кулындагы җирләр яхшы урыннардан – шәһәр, су буйларыннан ерак булганга, файдасыз бу заманда Русия Шәрыкка таба сәүдәдә сәясәтен сузганга, татарның гали сыйныфлары сәүдәгә бирелгәнгә, ул Азия белән сатуны бары татар мөселман булган вакытта гына кыла алачак булганлыктан (чөнки Урта Азия халыклары мөселман булмаганнарны кертмиләр), бу татар алпавытларына җир чәчеп мәшәкатьләнеп торганчы, сәүдәгәр, әмма мөселман булып калуы яхшырак булган.

**Татар мирза вә йомышлыларын лашман ясау.** XVIII гасырның башында хөкүмәт татар феодал сыйныфы белән бер дә хисаплашмый башлады. Мәгълүм ки, Пётр I Русиядәге һәрбер сословиене бер мәгълүм эшкә кушып баглаган иде. Һәрбер сословие дәүләтнең кулы, аңарга нәрсә белән булса да хезмәт итәргә тиеш иде. Пётр рус алпавытларының шляхствосының имтиязларын[1] тартып алмаса да, аларны үсеп беткәнче укырга мәҗбүр итеп, соңра, егет булгач, үлгәнче гади гаскәр булып хезмәт итә башлый торган ясавы, шуннан үсеп кенә рус «дворяны шляхтые» зур урыннарга менә ала вә бары хезмәт итсә генә, ул крепостной көче белән файдалана аладыр иде.

Дөрес, Пётр татар мирзаларының мөселман җенесеннән булган крестьян – чураларны кулларында тотып эксплуатация ясауны бетермәде, ләкин һәрничек булса да, аларны ул рус дворяны белән бертигез ясамады, ләкин шулай да ул аларны гайре мөнтазам[2] гаскәр вә хезмәт итәргә мәҗбүр итеп килде вә соңыннан Пётр аларның иң күбесен башка бер мөһим эшкә баглап куйды. 1718 елда йомышлы татарлардан бер гөруһ халык ясалды. Бу гөруһ Идел һәм башка елгалар буенда Пётр заманында ясала башлаган сугыш көймәләре өчен агач киптерүче лашманчылар иде. Бу лашман сүзе немесчә «ласа ман» «кисүче кеше» дигән сүздән алынган. Бу елның 31 гыйнвар указы белән хөкүмәт берничә губернадан 56113 җан гайре русны кораблар ясарга, агач хәзерләү вә аларны ясатыр өчен тәгаен итте. Бу гөруһ халык арасында гади йомышлы татарлар булган күк, аристократ мирзалар, вә биш кораб ясап бирергә акчасы җитә торган Бурашев шикелле предпринимательләр дә бар иде. Шуның өчен

[1] Имтиязларын – привилегияләрен.
[2] Гайре мөнтазам – тәртипсез, рәтсез.

бу лашманчылар бер сыйныф түгел, бәлки хокукый яктан гына тәгъриф кылу[1] мөмкин булган бер гөруһ иде. Бу кешеләргә хезмәтләре тәкабеленә[2] акча түләнми, һәрбер шуңар язылган кеше 15 яшьтән 60 ка кадәр хезмәт итәргә тиеш иде. Һәрбер 9 кешедән кыш һәм көз көннәре өчен алты ай мөддәткә[3] ике кеше алына. Әгәр бөтен ел буена эшләргә тиеш булса, 15 кешедән 9 кеше алына иде. Болар эченнән байлар исә яллап эшләтәләр иде. Үз кул көчләре белән эшләмәгән өчен байлар казнага 2 сум 30 тиен акча түлиләр иде.

Пётр заманында лашманчылар Казанга бертөрле дә салым түләмиләр иде. Ул үлгәннән соң, аларның хәлләре авыр иде. Алардан, башка халыктан алган төсле, салым түләтеп, башка төрле повинностьләр эшләтеп, һәм солдатлар ала башладылар. Бөтен XVIII гасыр буенча татар лашманчылары хөкүмәткә гариза биреп, илчеләр җибәреп, үзләренең тормышларыннан шикаять итеп тордылар. Хәтта хөкүмәт аларның әйткән хезмәтләре тәкабеленә мунчадан алына торган бер сум салымны алудан да туктамады. Бу чакта Казан купецы Бурашевның Питербурда кенәз Вяземскийга[4] 1783 елның 4 апрелендә язылган хатының бәгъзы бер урыны бик матур дәлил була ала. Бурашевның хатының башында: «Сез, гали кенәз, лашманчы татарлар өчен бу хезмәтнең мөһлик[5] һәм зарарлы икәнен беләсез», дип башлап китеп, урман кискән чакта үлүчеләр һәм кул-аягы зәгыйфьләнүчеләрнең күплегеннән, бу эштә яшь буыннар күбрәк хезмәт иткәнлектән, рекрут алганда солдатка яраклы яшьләрнең бик аз чыгуын әйтеп китә. Димәк, бу хезмәт татарларның икътисади хәлләренә генә түгел, димәк, аларны җисмани[6] эштән чыгарган.

Дөрест, күп шикаятьләр соңында 1757 елда лашманчылардан алына торган салым тәкабеленә хезмәтләрен хисаплый башласалар да, аны хөкүмәт бик арзан хисаплыйдыр иде. Атлы лашманчының

[1] Тәгъриф кылу – билгеләү.
[2] Тәкабеленә – бәрабәренә.
[3] Мөддәткә – срокка.
[4] Александр Алексеевич Вяземский (1727–1793) – кенәз һәм дәүләт эшлеклесе. Сенатның генерал-прокуроры постында хезмәт иткән чорда ул шулай ук Уложенная комиссиянең фактик җитәкчесе була. Вяземский финанслар, салым алу, сәүдә һәм акча эшен контрольдә тоткан.
[5] Мөһлик – һәлакәткә, үлемгә илтүче.
[6] Җисмани – физик яктан.

көнлек хезмәтен кыш көне – сигез, җәй көне ун тиен, җәяүлене биш тиен хисаплый иде, әгәр соңгы вакытта салымны 170 тиен хисапласак, атсыз фәкыйрь кешегә үзенә төшкән салымны түләү өчен генә 34 көн хезмәт итәргә кирәк иде.

Шул ук Пётр заманында бу эшкә мирза вә йомышлылар җитмәгәч, хөкүмәт бу эшкә ясаклы татар, фин, чуваш крестьяннарын да китерде, димәк, хөкүмәт бу феодал калдыкларын ясаклы «кара сөякләр» белән тигезләде, менә бу факт та татар феодал сыйныфына кырылган бер зарбәдер.

**Сәүдәгәр вә сәүдәнең үсүе.** XVIII гасырдан башлап Русиянең тагын Шәрыкка таба тәҗавез[1] башлавы, Каспий буенда Баку вә Гилатның алынуы, кыргызларның Русиягә табигъ булулары[2], Башкортстанны хөкүмәтнең мунчаклавы вә аның автономиясе һәм рус колонизациясенә каршы көрәшләрен бастыру, – һәммәсе дә татар сәүдәсенә киң мәйдан ачтылар. Затән[3], татар мирзалары үзләре үк, алда сөйләгәнчә, сәүдәгә күчәргә мәҗбүр булганга, алар шул Шәрык илләрен Русия тәэсиренә төшерүгә зур хезмәтләр дә иттеләр. Котлыг Мөхәммәд Тәвкилевнең 1724 елдагы Пётрның Иран сәфәрендә Пётр янында «советник һәм тылмач» булып баруы, шул ук мирзаның Пётрны Кыргызстанны Русиягә кушу кирәклеген сөйләп котыртуы, соңра Анна Ивановна заманында кыргыз ханына илче булып барып, аларны, алып, Русиягә бәйгать иттереп[4] кайтуы, табигый, татарның сәүдә капиталы белән бик баглашырга мөмкин вә тәсадефи[5] бер вакыйга түгел. XVIII гасырда татарның сәүдәсенең күләме[н] цифрлар белән күрсәтеп булмый, ләкин шулай булса да, аның хәрәкәтләрен шактый дөрес тасвир итәргә була.

XVIII гасырның эчендә татар сәүдәсенең ике мөһим базары бар: 1) эчке базар, ягъни татарларның үз ватаннарында үзләре белән сату итү; 2) тышкы базар, димәк, татарларның Башкортстан, Кыргызстан, Бохара, Хива вә гомумән Төркестан белән сәүдәләре. Әмма

[1] Тәҗавез – басып керү.
[2] Табигъ булулары – буйсынулары.
[3] Затән – нигездә.
[4] Бәйгать иттереп – ант иттереп.
[5] Тәсадефи – очраклы.

XVIII гасырның соңгы көннәрендә исә Кытайдан (Кяхтадан[1]) чәй китерү, анда исә мөгез[2] һәм кәзүл[3] иләтү.

Бу сәүдәне сөйли башламас борын XVIII гасыр Русиясенең сословный тормышының сәүдәгә бик комачаулы булганын белеп вә игътибарга алып узарга кирәк. Русиядә һәрбер сословие бер эшкә багланганга күрә, крестьян – ясаклы вә алпавыт – мирза вә йомышлыга сату итәргә мөмкин түгел иде. Бераз имкян[4] булгалап торса да, Пётрдан соң тагы бетерелгән, бары сәүдә итү купец сыйныфына язылган, шуның бер гильдиясенә кереп, капитал түләгән кешегә генә мөмкин иде[5]. Шулай булса да, татарның бай-кулак крестьяны һәм мирза вә йомышлысы төрле рәвештә законны хәйләләп сату итәдер иде. Ләкин юл өстләрендә торган крестьяннарга вак-төяк белән сәүдә кылырга, нәрсәне ваклап сатарга рөхсәт булган, әмма крестьян калага китергән малын иң элек купецка сатарга тиеш булган.

Бер сословиедән икенче сословиегә күчү XVIII гасыр законнары буенча җирле түрәләрнең разыйлыгы вә Сенатның указы белән генә мөмкин булганга, бай татарлар үзләренең сословиеләреннән тизлек вә асатлык белән чыга вә купец була алмаганнар, ләкин Казанда торган, югарыда әйтелгән «торговый служилый татар» дигән бер гөруһ, татар купецы булмаса да, хөкүмәткә хезмәт йомышларын үтәгәч, сату итә алганнар. Крестьян вә гади йомышлы татарлар оптовый сәүдә кылу өчен шундый хәйлә кылганнар: алар рус купецларыннан аз гына мал алып, алардан доверенность алып, яисә аларның приказчиклары булып күренгәннәр дә, шул аз гына мал өстенә тагын үз акчаларына күп кенә мал алып, приказчиклар яллап, ярмаркаларга барып сату итә биргәннәр.

---

[1] Кяхта – Бүген Бурятия республикасындагы зур булмаган шәһәр. XVIII–XIX гасырларда Кяхта Бөек чәй юлында төп транзит пункты һәм Кытай белән эре сәүдә үзәге булган.

[2] Бу бертөрле кыр кәҗәсе мөгезе, кытайлар аны дару урынына истигъмаль кылалар, бик кыйммәт йөри. XX гасырның башларында әле татарлар кытайларга Мәкәрҗә ярмаркасында шуны саталар иде. *(Авт. иск.)*

[3] Кәзүл (кәҗүл) – иләнгән кәҗә тиресе.

[4] Имкян – мөмкинлек.

[5] Моның тәфсилен безнең «Татар сыйныфлары тарихыннан» караңыз. *(Авт. иск.)*

1) Үзара алмашу: татар сәүдәгәрләре татарның кустар малын җыя да, татар арасында булган ярмарка, базар вә авылдан авылга йөреп сата, үзе алардан төрле материаллар, җон-җабага, сүс, балавыз, бал, ит, тире-яры, агачтан ясаган нәрсәләр ала, яисә үзенең малын шул нәрсәләргә алмаштыра. Татар купецлары права алмас өчен, яисә хөкүмәтнең крестьянга сату итәргә ирек бирмәгәнлеге өчен, сәүдәсен шулай вак сәүдә дип күрсәтергә тырышадыр иде. Авыл, ярмарка вә базарларда җыйган малны татарлар калаларга илтеп, купецларга саталар иде; 2) шуның белән бергә татарлар арасында зур вә бай купецлар да туды. Болар приказчиклар яллап Төмән, Троицк һәм Оренбур[г] ярмаркаларына баралар. Меновой двор һәм Гостиный дворларда иң яхшы кибетләрен ишгаль итәләр[1], маклерлар тотып, кыргыз-башкортны тел белү аркасында кулларына алганнар иде. Рус купецлары XVIII гасырның яртысында Азия вә Себер базарларында гайре руслар белән сәүдәнең бөтенләй татар кулына кереп бетүен, сата алмагач, алып килгән малларын зарар итеп, татар сәүдәгәрләренә сатып бетереп кайтырга мәҗбүр булганлыкларын белдереп шикаять кылалар иде. Татар сәүдәгәрләре бу ярмаркаларга Яурупа малларын, материяләр, мәгъдин[2] нәрсәләрен алып килеп, шуларны кыргыз вә башка Азия халыкларына саталар иде. XVIII гасырның соңына таба Хива вә Бохарага илтеп, Русиядә эшләнгән мылтыкларны да качырып сата башлаганнар иде. Бу хакта XVIII гасыр эчендә хөкем эшләре булганлыгы мәгълүм. Мондый эре татар буржуазиясе Русиядә генә сәүдә белән канәгатьләнми, чит җирләргә дә чыгып китә иде. Бу эшне легальный[3] рәвештә эшләве кыен булганга күрә, Казан вә аның янындагы бистәләрдә торган татар сәүдәгәрләре 1767 елда хөкүмәткә биргән язуларында хариҗи[4] сәүдәнең кирәклеге вә теләгән кешене читкә чыгарга рөхсәт итүнең кирәген сөйләгән соңында, «Яурупадан килгән малны Государственный банк алып, сәүдәгәрләргә таратсын» дигән мәелдә[5] бер сүз дә кыстырып китеп: «Ибо приобретение продуктов от другого государства делает прибыль Российской империи. Ближайшая

[1] Ишгаль итәләр – биредә: тоталар.
[2] Мәгъдин – казылма байлыклар, руда. Биредә: металлдан эшләнгән.
[3] Легальный – рәсми.
[4] Хариҗи – тышкы.
[5] Мәелдә – теләктә.

и великая всей империи польза, чтобы иностранных рук, через утверждение государственные банки»[1], капитализмны тәмам кабул итү дәрәҗәсенә ирешкәнлекләрен белдергәннәр иде.

Татарлар XVIII гасыр Русиясендә иң хәйләкәр сәүдәгәр хисапланып, аларны рус конкурентлары – купецлар мал бозу, хыянәт кылып балавыз, май шикелле нәрсәләргә арзанлы нәрсәләр кушып сатканлыклары белән гаеплиләр иде. Димәк, XVIII гасырда татарда зур гына капиталистлар булган. Әгәр югарыда сөйләнгән сүзләргә Габделгази Бурашев дигән Казан купецының 1783 елда хөкүмәт белән җиде данә «стопушечного ранга»[2] сугыш корабы ясарга мөгаһәдә[3] ясаганын күз алдына китерсәк, XVIII гасырның ахырында татарда капиталның үскәнен күрербез.

**Татарның сәүдә колонияләре.** Кыргызларның Русия кулына керүләре, Оренбург шәһәре вә ныгытмаларының салынуы татарларның сәүдәләренең вә сәүдәгәрләренең әһәмитяләрен арттырды. Хөкүмәт үзе үк җиңеллекләр вә имтиязлар биреп, татарларны кыргыз вә Урта Азия белән мөнәсәбәттә васитачылык ясау өчен чакыра башлады. Татарларның диннәрен үзләренең ватаннарында тәгъкыйб кылган[4] хөкүмәт 1734 елда Оренбург хакындагы тәгълиматында[5] мәчет салырга да, шәһәрне идарә эшенә катыштырырга да рөхсәт бирде. Ниһаять, Казанның бай һәм маллы кешеләреннән Сәгыйд исемле сәүдәгәр 1745 елда Оренбургтан ерак түгел бер урында, бары бай кешеләрне генә китерү, бары 200 генә гаилә утырту, мәчет салырга ирек бирү шартлары белән «Каргалы бистәсе» яисә «Оренбургская подгорная Сеитова слобода торговых татар»[6] исемле бистә салырга рөхсәт алды. Мондагы халыкның саны илле ел эчендә ифрат[7] артты, купецлар 1820 кешегә җиттеләр.

Шуларны җәлеп кылу белән Оренбург округының бюджеты да яхшыланды. Әүвәле беренче елларда Оренбург өлкәсен идарә өчен,

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Мөгаһәдә – килешү.
[4] Тәгъкыйб кылган – эзәрлекләгән.
[5] Тәгълиматында – директивасында.
[6] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[7] Ифрат – чиктән тыш.

ел саен хөкүмәттән 30 мең сум акча алынганы хәлдә, 1750 елларда доход 50 мең сумга җитеп, бөтен расходларны каплый башлады.

**Кыргызстан чигендә рус-татар акционерный сәүдә җәмгыяте.** Шулай итеп, җирле вә мәркәзи хөкүмәт Азия – Русия сәүдәсенә татарларның файдалы булуларын аңлап алды. Шуның өчен дә беренче Оренбург губернаторы мәшһүр колонизатор Неплюев[1] 1750 елларда рус-татар катыш егерме мең сум капитал белән бер сәүдә акционер оешмасы ясады. Бу оешманың директоры татар булырга тиеш һәм Урта Азиягә баручылар да татар әгъзалар, яисә рус әгъзаларының татар приказчиклары булырга кирәк иде.

Ләкин чикләрдә хөкүмәт татар сәүдәгәрләре белән файдаланса да, Казанда һәр төрле рәвешләрдә татар сәүдәгәрен кысадыр иде. Мәсәлән, Елизавета Петровнаның[2] соңгы көннәрендә Казанда татарларны сәүдә иттермәс булганнар иде. Бер елны гына 23 данә татарга кул нәрсәләре белән сату итә торган татар кибетләре ябылган, хәтта шул заманда татарга иске-поскы һәм сумса, ит, бәлеш шикелле, базарга килгән крестьяннарга ашамак-эчмәк нәрсәсе сатучыларга да сату итәргә манигъ ителгән[3] иде.

**Крестьяннар (кол вә ясаклылар).** XVIII гасырның башыннан алып татар җәмгыятенең башына буржуа-сәүдәгәр кичә[4] башлаганын вә феодал сыйныфын җимерергә хөкүмәт үзе дә булышканлыгын без күрдек.

Ләкин бу феодал һәм буржуазия татар халкының азчылыгы иде. Аның ядрәсе дә халис[5] милләтең үзе булган бер сыйныф булса, ул да татар крестьяннары иде. Кол – чура крестьяннар XVIII гасырда аз калганнар иде инде. Боларның мөгайян[6] күпме булганлыкларын хәзергә басылган, мәгълүм булган мәнбәгъләрен белер хәл юк. Шулай булса да, 1781 ел мәгълүматы буенча, Казан

[1] Иван Иванович Неплюев (1693–1773) – рус адмиралы, яшерен киңәшче, дипломат, мемуарлар авторы.
[2] Елизавета Петровна (1709–1761) – 1741–1761 елларда патшалык иткән, Романовлар династиясеннән булган Бөтенроссия императрицасы. Пётр I һәм Екатерина I нең кече кызлары.
[3] Манигъ ителгән – тыелган.
[4] Кичә – килә.
[5] Халис – чын.
[6] Мөгайян – ачык кына.

наместниклыгында (13 өяздә) 33779 ир җан татар йомышлылары кулында 555 дворовый татар булганы мәгълүм. Билгеле, бу бик аз. Ләкин, һәрхәлдә, 1767 елга кадәр Казан вә әтрафы мирза вә йомышлыларның кулында кол – креспостной крестьян шактый булганлыгын без беләбез. Хөкүмәт үзе дә татар мирзаларына һаман татар ясаклы крестьяннары белән җир вә авыллар бирүен дә, аларның хезмәтләре өчен шундый «мал» бүләк итүен дә дәвам кыладыр иде. Мәсәлән, хәзерге Алабуга өязендә Котлыгмөхәммәд Тәфкилевнең кулында 1740 елларда берничә авыл бар иде (Балтас, Кирсә, Салавыш[1] вә башкалар). Бу коллар һаман да искечә алыналар, сатылалар, мирас ителеп калдырылалар, хатын алганда приданый итеп кияүләргә биреләләр иде. Ләкин ничек булса да, крепостнойлык безнең татар арасында бетүендә дәвам кыла, сәүдә капиталы бездә аны йотадыр иде. Дөрест, бу XVIII гасырда Русиядән икмәкнең ифрат күп дәрәҗәдә Англия, Голландия шикелле җирләргә чыгуы сәүдә капиталын крепостной хуҗалык белән вакытлы блок ясарга имкян биргән булса, алпавытның крепостной хезмәтче белән икмәк эшләве, аларның поместьеләрен икмәк фабригы ясатса, бездә эш алай булмады. **Татар алпавыты җиргә әһәмият бирмичә сәүдәгә тотынып, Шәрык белән сәүдәдә васитачылык[2] ролен ифа итеп[3] китте. Чөнки аларның җирләре мәркәз вә су буйларыннан ерак булганга, татар мирза вә йомышлысының икмәге базарда рус алпавытының икмәге белән конкуренция ясый алмады. Шуның өстенә дә сөйләнгән законнарның да комачаулаганын хәтергә алырга кирәк.**

Татар халкының күпчелеге XVIII гасырда ясаклы крестьяннар иде. Болар хөкүмәткә ясак түләүче, аңар подвод бирү, рекрут бирү, түрә вә гаскәрләргә квартир бирү, аның төрле хезмәтләрен үтәү шикелле хезмәтләр белән мәҗбүр ителгән, шәхсән ирекле игенчеләр иде.

1769 елда тәмам булган беренче ревизия аталган налог түләүче халкының санын алу мәгълүматына караганда, Казан провинциясендә (хәзерге берничә кантоннан гыйбарәт) 37621 ясаклы ир

[1] Балтач, Тирсә, Салагыш авыллары (Татарстан Республикасы Әгерҗе районы).
[2] Васитачылык – арадашчылык.
[3] Ифа итеп – үтәп.

татар бар, әмма 1780 елларда Казан наместниклыгында болардан 32293 мөселман-татар җан (ревизская душа) бар иде. Бу сыйныф крестьян башта ясакны казнага тире-яры, җон-җабага, җәнлек тиресе, бал, балавыз белән түләсә дә, XVIII гасырда акча белән көнкүреш көчәйгәнгә, хөкүмәт гайре рустан ала торган ясакны акчага күчерде. 1712 елга кадәр һәрбер биш мең татар хөкүмәткә биш сум акча түләсә дә, моннан соң ул акча арттырылып, ун сумга җиткерелде. Бу түләү әле рус крестьяны түли торган салымнан кимрәк булса да, Пётр Великий заманында ук татарларга җан башыннан (подушный) салым, яисә имана кертелде. Бу заманнан игътибарән[1] һәрбер татар иленә 1 сум 14 тиен түли торган ясалып, соңра бу түләү 1 сум 70 тиенгә җиткерелде. Әгәр бу чакта арыш онының бәһасе поты 10 тиен булганын игътибарга алсак, һәрбер татар елына 10–11 пот чамасында казнага арыш бирергә мәҗбүр иде.

Пермь губернасындагы татарлар Пётр заманасына кадәр салымны җәнлек тиресе белән түләп килсәләр дә, соңыннан 44 тиен түли торган булдылар. Бу салымнарны татарларның үзләреннән сайланган сотник вә старосталары җыялар иде. Шуның өстенә дә татарлар түрәләргә әллә никадәр ришвәт тә бирергә мәҗбүрләр иде. Мәсәлән, XVIII гасырның урталарында Әгерҗе тирәсендә торган татарлар һәрбер җан иясе, урман башлыклары (вальдмейстер) килгәндә 9–10 тиен түләгәнлекләре мәгълүм. Бу акча түләменнән башка, татарлар хөкүмәткә хезмәт итәләр иде. Мәсәлән, истихкямнәр[2] салырга, Питербур[г] шикелле калалар салырга, яңа каналлар казырга рус вә гайре рус крестьяннары белән бергә әллә никадәр татарлар да китәләр иде.

Ясаклы татар вә гомумән татарның иреккле крестьяннары хакында сөйләгәндә, берничә моментны хәтергә алып китәргә кирәк була. XVIII гасырның яртыларында татар крестьяны ясаклы вә чуралардан гына гыйбарәт түгел.

Йомышлы татарлар да бу чакта тәхлил кылынып[3], болар арасыннан, бер яктан, алпавытлар чыкса, икенче яктан, болар арасыннан бай сәүдәгәрләр туса, өченче яктан, болар арасыннан үз кул көчләре

[1] Игътибарән – башлап.
[2] Истихкямнәр – ныгытмалар.
[3] Тәхлил кылынып – аерылып.

белән иген игүче авыл халкы да чыкты. Соңгысы исә аның шактый күп бер сыйныф иде. Мәсәлән, Казан наместлигында 1781 елда бу йомышлылларның саны 33779 ир зат булса, ясаклыларның – 32293 иде. Димәк, йомышлыларның саннары күбрәк. Шуның өчен дә Казан рус сәүдәгәрләренең бер вәкиле үзенең 1767 ел комиссиясендәге нотыгында: «ясаклы татарлар бар да бер, алар крестьяннар», дигән иде. Боларның ясаклылардан аермасы байлык вә ярлылыкта түгел, бәлки җир биләү рәвешенең башка төрле булуында иде. Ясаклылар җирне община хөкемендә биләп торсалар, йомышлылар исә вотчина правосында, димәк, һәрбер гаиләнең үзенә тигән милке булган җире бар. Соңыннан, 1840 елларда, боларга, көчләп, община керттеләр. Димәк, татарның үз көче белән эшләп иген игә торган халкын рәсми сословный тәгъбир белән аталган[1] караганда, аларны туп-тугры «татарның авыл халкы» дип йөртергә кирәк була.

**Авыл халкының ярлылануы.** XVIII гасырдагы татар авыл халкының без, бер яктан, тәхлилен (дифференция)сен күрсәк, икенче яктан, аның ярлылануын күрәбез: аның ярлылануы, әсасән[2], ике сәбәптән килеп чыга:

1) Колонизациянең дәвамы.

2) Татар җиренә шул колонизациянең тиз һөҗүме аркасында җирнең азаеп калуы (безгә моны 1867 ел комиссиясенең татар наказлары белдерәләр, чөнки һәм ясаклы, һәм йомышлы татарлар җир азлыктан шикаять кылалар) вә татарның авыл халкының шул аз җирне яхшылап эшләп файдалануы өчен яхшы ысулга күчә алмавы.

3) Өченче яктан, хөкүмәтнең татарны чукындыруны бәһанә итеп, чукынмаган өчен артык налог түләтүе, яхшы урыннардан куып, начар җирләргә утыртуы, чукынган гайре руслар өчен дә налог вә рекрут алуы, шул ук дини мәсьәләне алга сөреп, татарны хөкемдә мөдафәгасез калдыруы (татар руска шаһид була алмау, хөкүмәт телен аңламау шикелле), менә шуның нәтиҗәсе татар авыл халкының XVII гасырда башлаган Башкортстанга, Казахстанга вә башка җирләргә күчеп, иске Казан ханлыгы урынында зур күпчелек ясый алмыйча калуы.

[1] Аталган – атаганга, әйткәнгә.
[2] Әсасән – нигездә.

**Колонизациянең дәвамы.** XVII гасырдагы Смута «Мәскәү хөкүмәтенә, ачыктан-ачык Идел буена колонизация ясау вә аны каба рәвештә[1] үткәрү никадәр начар нәтиҗәләр биргәнен күрсәтте. Шуның өчен икенче Романов Алексей заманында, 1649 елда, «Уложение» исеме белән чыгарылган закон мәҗмугасында татар җирен – руска, рус җирен татарга бирмәскә, дигән канунны чыгарды. Ләкин бу канун чыкса да, татар халкы үзен Идел буйларыннан кууы, начар җирләргә утыртуның ачыктан-ачык рәвештә, Разин ихтилалында, колонист монастырь вә алпавытларга һөҗүм белән алды. Шуның өчен ачыктан-ачык, каба сыйфатта, колонизация XVIII гасырда туктады. Хәтта 1737 елда императрица Анна Ивановна заманында (1730–1740) теге Уложениедәге закон тагын тәкрар ителде[2] һәм зур штраф белән тәһдид ителеп[3], рус белән чукынмаган татар арасындагы сатылган җирләргә купчи һәм закладнойларның ясалуы мәнгый[4] ителде.

Ләкин бу законга карамыйча, Идел буендагы татарлардан җирнең русларга күчүе дәвам кылды. Пётр I (1682–1725) хөкүмәте заманында тышкы икмәк базарының көчәюе аркасында крепостнойлыкның көн саен үсүе, алпавытларда крестьяннарга хуҗа булу хокукының көн саен көчәюе, рус алпавытларына җир күбәйтүнең әһәмиятен арттырды. Шуның өчен алар мөмкин кадәрле күп җир алып, шунда төрле җирләрдән рус крестьянын китертеп утыртуга кызыктылар һәм шуңар тырыштылар. Шуңар күрә дә алар хөкүмәтнең алда сөйләгән законын ничек тә ташлап, «хәйләи шәргый» ясарга тырыштылар. Бу эш асат иде. Чөнки хөкүмәт вә алпавытлар бер сыйныф кешеләре булганга, мәнфәгатьләре бер, шуның өчен законнан тышка чыгуы ул кадәр читен түгел иде.

Моның өчен алпавытлар кулында көчле бер корал булып, ул да «дин», «чукындыру» татарны православиегә күчерү иде. Элек алпавыт бер татар крестьянын күрсә, яисә бөлгән мирза баласын алып тәрбияли, эчертә, исертә, соңра аның исеменнән татарлардан җир сатып алдырта, соңыннан аны чукындыра. Инде егет христиан

[1] Каба рәвештә – тупас рәвештә.
[2] Тәкрар ителде – кабатланды.
[3] Тәһдид ителеп – янап.
[4] Мәнгый – тыелган.

динен кабул иткәч, аның җирен алдалап, яисә гасбәләп[1] үзенә ала. Шул җиргә рус җенесеннән булган кол крестьяннарны китертеп утырта. Бу хакта төрле вакытларда татарлар хөкүмәткә гариза биреп, шикаять кылып тордылар. Бәгъзы вакытта рус кулаклары татар крестьяннарының җирләрен көчләп тә алалар. Шәһәр халкы татар крестьяннарының җирләрен, татарларның шикаятьләрендәге истигъмаль кылынган[2] русча истыйлях[3] белән әйтсәк, «своим насильством» алалар. Шуның өстенә дә XVIII гасырда, Пётр заманыннан башлап, татар вә башкорт җирләренә барып мәгъдин кярханәләре[4] ясаучы рус капиталистларын яклау гадәткә кереп китә. Менә бу капиталистлар Пермь губернасы шикелле җирләрдәге татар җирләрен мөсадәрә кылып[5], фабриклар салалар да, аларның җирләренә үзләренә эшче итеп рус крепостнойларын китертеп утырталар. Шуның өстенә дә хөкүмәт XVII гасырдан башлап «черта» атала торган Казан ханлыгы урынын күчмә халыклар вә башкортлардан саклау өчен ныгытма сызыклары ясый башлады, бу сызык XVIII гасырның башында тагы да шәрыккарак илтеп, һәм үз ителде. Бу ныгытмалар сызыгы колонизациягә зур хезмәт иттеләр.

Бик озын окоплар ясалып, шул чокырлар буена ныгытмалар салынып туплар куела, аларны саклар өчен шул окоплар буена китертелеп солдатларны гаиләләре белән утыртылып, шулардан гыйбарәт әһалиле авыллар туадыр иде. Менә моның белән вә бу сызык җирләре руслар белән ишгаль кылыналар[6] иде.

**Христианлаштыру сәясәте, аның икътисади сәбәбе вә колонизациягә хезмәте.** XVIII гасырдан алып, Русиядә исляхат[7] башлана. Бу – Пётр I дәвере. Бу дәверне исляхат дәвере дип йөртәләр. Бу чорда Русия иске әсаслы идарәне ташлап, Яурупада ул чакта мәкъбүл булган[8] «гакыл фәлсәфәсенә» таянган «тәрәккыйпәрвәр

[1] Гасбәләп – көчләп, тартып.
[2] Истигъмаль кылынган – кулланган.
[3] Истыйлях – термин.
[4] Кярханәләре – заводлары.
[5] Мөсадәрә кылып – кулга төшереп.
[6] Ишгаль кылыналар – кулланылалар.
[7] Исляхат – үзгәртүләр, реформалар.
[8] Мәкъбүл булган – яхшы дип табылган.

истибдад»[1] юлы белән идарә кылына башлый. Бу дәвердә Русиядә сәнәгать[2] капитализмы тәрәккый иттерелергә тырышыла. Матди галәмдә генә түгел хәтта гаклый, фикри мәйданда да исляхат ясарга тырышалар, Яурупа нәзари фикриясен, фәлсәфәсен кертеп, иске Бизанес[3] әсасларын ташларга омтылалар. Ләкин бу яңалык, дөресен әйткәндә, югары даирәдә вә калаларда гына, гали сыйныфларга мөнәсәбәттә генә калды. Гайре русларга вә хосусан татарларга мөнәсәбәттә искечә калды. Иске Мәскәү сәясәте, исеме үзгәртелеп, башка буяуга буялып, һаман да XVIII гасырның ахыргы елларына кадәр дәвам итте.

Дөрест, иске Казан ханлыгы урынындагы җирләр «Казанский царство» исемен югалтып, Русия 1708 елда сигез губерниягә бүленгәнендә, моның берсе Казан губернасы булды, «Казан воеводасы» исеме губернаторга әйләндерелде. Ләкин иске рух вә сәясәт шул килеш калды. Бу иске сәясәтнең иң күзгә күренгәне хөкүмәтнең православныйдан башка булган дин әһеленә мөнәсәбәтендә булды. Хөкүмәт Иван Грозный вә аның углы Фёдор[4] корып җибәргән христианлаштыру сәясәтен тәгъкыйб кылуда[5] дәвам итте генә түгел, хәтта Екатерина Икенчегә кадәр булган дәвердә, бер яктан караганда, тагы да катырак вә остарак рәвештә дәвам кылдырды, бу сәясәттә, билгеле, икътисади хисап зур роль уйнады.

XVIII гасырда, алда сөйләгәнчә, икмәк базарының ачылуы. Англия, Голландия флотларының паруслары Русиядән алпавыт крестьяннары эшләгән парусин белән тәэмин ителә. Бөтен Яурупага чуен янә шул Русиянең ирексез крестьян кулы белән эшләнә торган заводларыныкы киткәнгә, рус феодал сыйныфының күңеле бик күтәренке. Бу сыйныф һаман үзенең буш эшче колы булган крестьяннарының санын арттырырга тырышадыр иде. Әмма Идел буенда әле бер дә кол итмәгән күпсанлы татар вә фин крестьяны бар иде.

[1] Тәрәккыйпәрвәр истибдад – прогрессив абсолютизм.
[2] Сәнәгать – промышленность.
[3] Бизанес – Византия.
[4] Фёдор I Иванович (1557–1598) – Бөтен Русия патшасы һәм Мәскәү кенәзе. Явыз Иван һәм Анастасия Романовнаның уллары. Рюриковичлар династиясе Мәскәү тармагының соңгы вәкиле.
[5] Тәгъкыйб кылуда – күзәтүдә.

Ләкин моны рус крестьянын эшләгән шикелле асат кына крепостной ясап булмыйдыр иде, чөнки бу эш югарыда сөйләнгән законнарга хилаф иде. Чөнки 1756 елларда, миссионер Вячеславның хисабына караганда, Казан губернасында һаман да 98,913 мөселман татар, 3382 чукынган татар бар иде[1]. Димәк, әгәр бу йөз мең кешене чукындырсаң, алпавытларга йөз мең крестьян артачак, әгәр болар чукынмыйча торып, аларга каршы репрессияләр ясап, аларны яисә качарга мәҗбүр итсәк, яисә хөкүмәт үзе чукынмауларын бәһанә итеп[2] куып җибәрсә, янә алпавытларга бирергә җир артачак һәм аларга өләшергә дә крестьян ишәячәк иде. Чөнки рәсми җәһәттән христиан крестьяннарны льгота вакыты – мөддәте үткәч, христиан алпавытларына бирергә мөмкин иде. Гәрчә хөкүмәт үзенең рәсми фәрманнарында чукынмаганнарны крепостной ясамаска кушса да, без мондый вакыйгаларны очратабыз. Алда сөйләнәчәк «чукындыру комиссиясе»нең христиан кануннарына өйрәтү өчен дигән булып, яңа чукынган кешеләрне крепостной ясаулары һәм Зөя архимандриты Алексейның урынбасары Кузьмин дигән кешенең керәшеннәрне алпавытларга өләшүе мәгълүм.

Менә шушы иҗтимагый вә икътисади мәсьәлә татар крестьянын чукынмау ягына тартты, шуның өстенә дә эчке базарда сату итү өчен татарның чыгып килә торган сәүдә капиталы ияләре, сәүдәгәрләр дә татар крестьянын диннәрендә тоту өчен агитациядә голәма руханиларга мал белән булыштылар, шул сәбәпле дә татар крестьянының бик аз проценты чукынды.

**Чукындыру процессы.** XVI–XVII гасырларда бу чукындыру процессы әле туктап, әле көчәеп, бик каба[3] рәвештә көчләү формасында эшләнеп килде. Бу заманда хөкүмәт күбрәк татарның хаким сыйныфы булган мирза вә бикләрне чукындыру ниятендә хәрәкәт кылды, чөнки боларны авыштырган тәкъдирдә, аларның нык тәэсирләрендә булган крестьяннар белән эш кылу асат булачак иде. Әмма XVIII гасырда татарның хаким сыйныфы сәүдәгәрләр һәрьяктан татарның мөселман булып торуында мәнфәгатьдар иделәр, шуның өчен XVIII гасырда хөкүмәт 1773 елга кадәр крестьянны

[1] Мөселман татарның бу дәвердә болай гына булуында шөбһә бар. Ләкин без башка мәгълүмат таба алмадык *(Авт. иск.)*

[2] Бәһанә итеп – сылтау, сәбәп итеп.

[3] Каба – тупас.

чукындыру юлы белән хәрәкәт кылды. Бу хәрәкәт Пётр Великийга кадәр зәгыйфь барды, чөнки, алда сөйләгәнчә, хөкүмәт башка мәсьәләләр белән мәшгуль иде.

Пётр заманында исә хөкүмәт православие дине бабындагы кадәр хөр хисапланса да, алпавытлар вә колонизация эшенә файдасы булырлык булгач, православиедән ачык көлүче Пётр татарларны чукындыру эшенә зур әһәмият бирде. Монда, табигый, тагы бер сәяси хисап та бар иде. Староверларга каршы Пётр аларның гакселхәрәкәтче[1] булганлыклары өчен шиддәтле[2] мөгамәләдә булды. Билгеле, православиенең бер мәзһәбен бу кадәр кыскан хөкүмәт бу эшен каплар өчен мөселманнарга да шул ук хөкемне йөртергә кирәк иде. Шуның өчен Пётр патриархлыкны бетереп, православиене үзенең буйсынган бер коралы итеп, 1721 елда мөкатдәс Синод[3] ясагач ук, чукындыру эшенә зур әһәмият биреп, бу эшкә тәшәббес итте[4] һәм Казан митрополиты Тихоннан: «Ничек итеп татарларны христиан динендә тотарга мөмкин һәм ничек итеп аны таратырга кирәк?» дип сорады. Бу сөальгә Тихон: «Мөселман балаларын гаиләләреннән алып, христиан динендә тәрбияләп укытырга кирәк», дип җавап бирде. Моннан бер ел элек саран Пётр дәүләтенең ярлылыгына, акчаның юклыгына карамыйча, 1720 ел указы белән, бөтен христиан динен кабул итүчеләрне 3 елга салымнардан котылдырырга кушып, Казан митрополитына һәр елны чукындыру эшләренә тотарга мең сум акча, димәк, ун мең пот арышлык сумма бирергә кушты. 1721 елда Казан губернасында 30 мең керәшен татар булса да, болар бары исемдә генә православный булып, һаман да искечә көн күрәләр: чиркәүгә бармыйлар, попка сәдака түләмиләр, мөселман зыярәтләрендә дәфен кылыналар иде. Хөкүмәтнең: «Нинди чаралар кылырга кирәк?» дигән сөаленә митрополит шундый чаралар күрсәтте: 1) Тәһдид[5] белән иске мөселман мәкъбәрәләренә[6] үлгәннәрне күмдермәскә, үлгәннәрне поплардан башка дәфен

[1] Гакселхәрәкәтче – каршы йөрүче.
[2] Шиддәтле – кискен.
[3] Синод – 1700 елда бетерелгән Патриарх вазифасын алмаштыру максаты белән Пётр I боерыгы буенча төзелгән чиркәү идарәсенең югары органы.
[4] Тәшәббес итте – кереште.
[5] Тәһдид – куркыту, янау.
[6] Мәкъбәрәләренә – каберлекләренә.

итмәскә[1] әмер итәргә, иске зыярәтләрне бөтенләй юк иттерергә, бәйрәм вә якшәмбе көннәрдә чиркәүгә йөрергә мәҗбүр итәргә. 2) Бер мәгълүм микъдар керәшен баласын алып, көчләп дин гыйлеме укытырга башларга.

Пётр үлгәч, хөкүмәт дин сәясәтен тагы да куәтләп җибәрде. 1731 елда, Зөядәге бер монастырь янында «Комиссия крещеных дел» дигән бер мөәссәсә[2] тәэсис кылды[3]. Ләкин бу комиссиянең хезмәте аркасында шактый мәҗүси христиан динен кабул итсә дә, комиссиянең башында торучы архимандрит Алексей тәгъбиренчә[4], татарлар «гадәтләрендә каткан» «в обычаях весьма замерзшие»[5] булганлыкларыннан, бик аз христианлыкка күчтеләр, күчкәннәре дә бары матди файдалар өмет итеп кенә күчтеләр. (Разве кого к тому привелечет из них какая нужда[6]). Ләкин хөкүмәт моңар карамый эшен киңәйтеп, Казанда махсус рухани семинария вә башка мәктәпләр салып, анда татарлардан поплар вә миссионерлар җитештерергә кереште. Озакламый комиссиянең хөкүмәт каршында игътибары төште, чөнки комиссия турыдан-туры чукынган кешеләрне алпавытларга үзләшү[7] белән мәшгуль булуы мәгълүм булды. Шуның өчен 1740 елда комиссия бетерелеп, «контора новокрещенских дел» зоһур итте. Бу конторның хокукы да зур иде. Ул Казан, Әстерхан, Мәкәрҗә һәм Воронеж губерналарында үзенең эшен кыла башлады. Конторага дөньяви хакимияттә бирелеп, миссионерларны саклау өчен гаскәр дә бирелде. Ел саен конторага ун мең сум акча, гайре руслардан җыела торган икмәктән бишәр мең пот он һәм ярма бирелә торган булды. Контора берничә җирдә гайре руслар өчен дини мәктәпләр ачып ташлады. Шуның өстенә чукынучыларны кызыктыру өчен һәрбер чукынучыга бер кат тышкы кием, күлмәк-ыштан, акча бирергә һәм гаиләсе белән чукынучыларга тәре дә бирергә ясалды. Эш моның белән генә бетмәде, чукынучылардан 3 ел эчендә имана, башка салым һәм икмәк алмаска ясалды. Ләкин шунысы

[1] Дәфен итмәскә – җирләмәскә.
[2] Мөәссәсә – оешма.
[3] Тәэсис кылды – төзеде.
[4] Тәгъбиренчә – әйтүенчә.
[5] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[6] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[7] Үзләшү – биредә: өләшү.

фаҗигалы булды ки, бу салымнарның һәммәсен (шул ук чукынмый калган гайре русларга салдылар). Чукынучыларны хәзинә заводларында эшләүдән котылдырырга, алардан солдат (рекрут), никах акчасы алмаска булды. Ләкин бу өлешенә төшкән рекрутны да чукынмый калган гайре руслардан алырга ясалды. Без алда күрдек ки, чукынмый калучыларның күбесе татарлар иде. Бәс, татар крестьяны чукынучылар өчен һәм салым түли, һәм солдат бирәдер иде. Хәтта эш шулкадәрлегә җитте ки, бәгъзы вакытта бер татар авылыннан бишәр мәртәбә рекрут алдылар. Шул рәвешчә, татар халкы хөкүмәтнең бу сәясәте аркасында ифрат күп матди вә мәгънәви авырлыклар күрде. Чукынучыларга бирелгән бу җиңеллекләр моның белән генә бетмәде, хөкемне җиңел вә тиз ясау, җинаятьтә гаеплеләрне котылдыру шикелле нәрсәләрне дә хәтердән чыгарырга ярамый.

Чукындыру конторасы ясалган чакларда, 1738 елда, Казанда Лука Конашевич[1] исемле ифрат дәрәҗәдә мөтәгассыйб – фанатик бер монах епископ булып тәгаен кылынды[2]. Бу кеше татарның үзен, гадәтен вә мәдәниятен тамырыннан алып ташларга карар кылган бер кеше иде. Аның тәшәббесе[3] белән иске Болгар вә Казан заманыннан калган, татарның мазыйсын[4], мәдәниятен вә борынгы телен күрсәтүче бик күп кабер ташлары куптарылып, чиркәү фундаментларына куелды, иске харәбә вә мәдәният әсәрләренең күбесе ватылып юк ителде. Бу кеше дин мәсьәләсендә бөтенләй вәхшиянә мөгамалә кылды. Татарларның гаиләләреннән балаларын көчләп алып, чукындырып, дин мәктәпләренә алды. Юри татарларны котырту, аларның ачуын китерү, тәхкыйрь кылу[5] өчен бөтен чиркәүләрдән тәреләр чыгартып, татар йортлары алдыннан йырлатып йөртә торган булды. Бу попның максаты провакация булып, татар вә

---

[1] Аксак Каратун (Лука Конашевич, дөньялыкта Лаврентий Конашевич; 1758 елның 12 гыйнварында үлгән) – Рус православие чиркәве архиерее. 1724 елда Киев рухи академиясен тәмамлый. 1738 елда Казан епархиясенә күчерелә. Биредә аны күбесенчә тискәре яктан гына билгелиләр, ул бик нык исламга каршы көрәшү, җирле халыкларны көчләп чукындыру белән шөгыльләнә. Бик күп мәчетләрне җимерүе, татарларны Казаннан кудыруга тырышуы белән таныла.

[2] Тәгаен кылынды – билгеләнде.

[3] Тәшәббесе – катнашы, инициативасы.

[4] Мазыйсын – үткәнен.

[5] Тәхкыйрь кылу – кимсетү, хурлау.

рус халкын бер-берсенә дошман ясап сугыштыру иде. Ике милләтнең дә бер сыйныфташ крестьяннары моны күрделәр вә бер-берсенә каршы дошманлашмадылар, әмма татарның конторының башына шул ук Лука шикелле мөтәгассыйб Сеченов[1] дигән кеше куелды. Бу кеше чукындыру эшендә яңа бер чара уйлап чыгарды. Ул да булса, мөселман помещиклар кулында булган татар крестьяннары чукынсалар, аларның кулыннан хәляс кылу[2] чарасыз иде. Икенчеләре, әүвәлдә чукынучыларның налог–салым вә алар бирә торган солдатны, шул төбәкнең чукынмый калган кешеләре бирергә тиеш иде. Сеченов исә бу мәсьәләне гомумиләштереп, чукынучыларның салым вә солдатларын бөтен Казан губернасы мөселман вә мәҗүсиләре өстенә салуны хөкүмәттән таләп итте. Ниһаять, татар вә бөтен гайре рус өчен мөдһиш[3] бер чара эзләп тапты, ул да булса, әгәр бер-бер авылда керәшеннәр булса, андагы татарларны ул авылдан куып җибәреп, башка мөселманнар арасына илтеп утырту иде. Сенат бу тәкъдимнәрне кабул итеп, указ чыгарды. Шул рәвештә татарлар әүвәлге урыннарыннан күчерелеп, тагы начар җирләргә утыртыла башладылар. Менә бу чара яшерен колонизациянең бер юлы иде. Моның белән татарның икътисади тормышына яңадан балта чабылды. Күчерү эшенә аерым мәэмүр[4] тәгаен кылынды.

Хөкүмәт бу чаралары белән генә канәгать итмәде. Хөкүмәтнең ничә мәртәбә мәнгы кылуына[5] карамыйча, татарлар мәчет вә мәдрәсәләр салганнар иде. 1726 елда бер мәчет салмаска дип указ чыкса да, хөкүмәтнең кысуы аркасында булырга кирәк, дини реакция артып китеп, мәчетләр тагы да күбәйделәр. 1742 елның 19 ноябрендә хөкүмәт яңа фәрман чыгарып, мәчетләрне җимерергә һәм яңа мәчетләр салырга катгыян[6] рөхсәт итмәскә дип әмер бирде. Шуның нәтиҗәсендә 1742 елда инде Казан һәм өязендә генә 536 мә-

[1] Митрополит Димитрий (дөньялыкта Даниил Андреевич Сеченов; 1709–1767) – Рус православие чиркәве епископы. 1740 елның 11 сентябрендә архимандрит дәрәҗәсенә күтәрелә һәм Казан, Түбән Новгород, Әстерхан, Воронеж губерналарында яңа чукынганнар эшләре белән идарә итүче итеп билгеләнә. 1762 елдан Новгород һәм Бөек Луки митрополиты, вәгазьче һәм миссионер.

[2] Хәляс кылу – котылу.

[3] Мөдһиш – куркыныч.

[4] Мәэмүр – башкаручы.

[5] Мәнгы кылуына – тыюына.

[6] Катгыян – катгый рәвештә.

четтән 418 данәсе, Себердә исә 136 мәчеттән 89 мәчет, Әстерхан тирәсендә 40 мәчеттән 29 мәчет җимерелде. Билгеле, болар янында мәктәпләр дә бозылдылар.

**Бу кысынкылыкларга татарларның каршы җаваплары.** Татар халкы инде бу авырлыкларга каршы торырлык түгел иде. Аның XVI гасырдагы сугышчанлыгы беткән. Ул хәзер хокукта изелгән, икътисади яктан тапталган иде. Ләкин шулай булса да, татарлар бу авырлыкларга каршы дәшмичә генә калмадылар. Вак-төяк булса да, татарлар күтәрелеп, хәтта корал белән каршы килеп тордылар. Табигый, аларның бу кузгалышлары хакында хәзергә тулы мәгълүмат юк. Ләкин шулай булса да, чиновникларның татарлар өстеннән шикаятьләреннән шул күренә, мәсәлән, Воронеж губернасында, Тамбов провинциясендә 500ләп кораллы татарның чукынмаганнарны күчереп йөрүче баш түрә Яртасовка һөҗүм иткәнлекләре, аны саклаучы гаскәри фирканы кыйнаулары, «хөкүмәтнең указын тыңламыйбыз» дип игълан кылулары һәм шундый вакыйгаларның Казан губернасында да булып торулары мәгълүм. Ләкин татарлар хәзер Русия империясе белән корал көче аркылы көрәшә алмаячакларын белеп, хөкүмәткә гариза биреп шикаять итү, депутацияләр җибәрү шикелле эшләргә керештеләр. Мәсәлән, 1744 елда Казан, Сембер, Зөя өязләренең ясаклы татарлары вәкилләр сайлап, хөкүмәткә гариза биреп, бозылган мәчетләрне төзәтергә рөхсәт бирүне һәм күчерүне бетерергә сорадылар. Ләкин хөкүмәт күчерү мәсьәләсендә иске фикерендә калса да, түбәндәге сәбәпләрне күрсәтеп, бары мөселман гына тора торган җирләрдәге мәчетләрне ватмаска разый булды. Ул сәбәпләр шушылар иде: боларның мәчетләрен ватсалар, мөселман җирләренә бу хәбәр ирешер дә, анда православникларны кыса башларлар. Хөкүмәткә ант иттерү өчен бер урын кирәк булганлыктан, бераз мәчет калдырырга. Шуның аркасында Татар бистәсендә ике мәчет салдырырга рөхсәт ителде. Шуның белән бергә әгәр бер авылда халык 200–300 булса, анда ике мәчет тә ватылган булса, әрхәрәйнең[1] рөхсәте белән бер мәчет салырга имкян[2] бирелде. Шуннан артык мәчетләр булса, хәзер ватарга әмер ителде.

[1] Әрхәрәйнең – архиерейның.
[2] Имкян – мөмкинлек.

Гаҗиз калган татарлар янә бер көрәш ысулын истигъмаль кылып[1] килделәр. Ул да булса түрәләрне сатып алу иде. Мәсәлән, 1749 елда Сенатта бер кызык эш каралды. Бу эш Лука Конашевичның доносы буенча иде. Греков[2] фамилияле Казан губернаторы татарларны яклап, чукындыру эшенә комачаулык ясаган, алардан ришвәт алган, губернаторның дусты Мостафа атлы кеше хөкемгә бирелгән, җинаятьче татарларны губернатор күреп чукындырмый калдырган, янә бер авылда бер чувашны мөселман итеп сөннәткә утырткannaр да, шул эшкә Греков күз йомып калган, имеш.

Ниһаять, 1748 елда татарларның кубарга уйлаганлыклары мәгълүм. Бу хәрәкәт 1747 елда Башкортстандагы типтәр һәм мишәр аталып йөртелә торган татарларның күтәрелүләре белән мөнәсәбәттә булырга кирәк. Бу вакыйга ике яшерен хат табылу мөнәсәбәте белән беленде. Билгеле, бу вакыйганың әсасы безгә мәгълүм түгел, бәлки Луканың провокациясе генәдер. Ләкин, һәрхәлдә, бу ике хат мөнәсәбәте белән туган вакыйгалар татарларга бик кыйммәт[кә] төште. Казанга әллә никадәр гаскәр китерелде. Шушы мөнәсәбәт белән Оренбур[г] губернасыннан ике полк, җәнүбтән[3] өч драгун роталары арттырылды. Казандагы гаскәргә хәзер торырга әмер ителде. Казандагы татар бистәсенә (Иске бистәгә) һәм авылларга каты тәгълимат[4] бирелеп хәфияләр[5] җибәрелде. Казан вә әтрафындагы татарлардагы бөтен мылтык, җәдрә вә дарыны мөсадәрә кылырга[6] кушылды. Соңра теге яшерен хатларны язучыларга килеп, исемнәрен белдерергә кушылып, аларга бишйөзешәр акча тәгъйин кылынып[7] игълан асылды. Гаскәрләр килеп җиткәч тә, Казан шәһәрендәге татар бистәсенә куелдылар, калганнар Казан артында-

[1] Истигъмаль кылып – кулланып.
[2] Греков Степан Тимофеевич (1679–1755 елдан соң) – дәүләт һәм хәрби эшлекле, тайный советник. 1748–1755 елларда Казан губернаторы булып тора. 1749 елгы янгыннан соң Казанны торгызуга җитәкчелек итә. Яңа Татар бистәсен төзүдә, постау мануфактурасының кирпеч биналарын һәм башка корылмаларны салуда ярдәм итә. Архиепископ Лука (Конашевич) белән берлектә төбәктәге халыкларны күпләп христианлаштыруда катнаша.
[3] Җәнүбтән – көньяктан.
[4] Тәгълимат – күрсәтмәләр.
[5] Хәфияләр – шымчылар.
[6] Мөсадәрә кылырга – конфискацияләргә.
[7] Тәгъйин кылынып – билгеләнеп.

гы 18 татар авылына җирләштерелделәр. Бигрәк тә Җөри юлы татарлары ихтилалга[1] маил[2] күренгәнлектән, аларны сакларга артык әһәмият бирелде. Башкортстан белән чиктәш Минзәлә тирәсенә татарча белә торган түрә белән гаскәрләр куелды. Шушы тәһдидләр[3] аркасында хәрәкәт күтәрелми калды.

**Татар буржуазиясенә бер һөҗүм.** Хөкүмәт үзенең чукындыру төсендә йөртә торган сәясәтенә каршы татарның авыл халкына кем булышканын бик яхшы сизгән булса кирәк, шуның өчен ул бу сыйныфны зәгыйфьләтү өчен яңа бер чара тапты. Ул да булса – Казан бистәсендәге бу сыйныфның оясын туздыру иде. 1750 елда татарларны Иске бистәдән бөтенләй куарга әмер чыгарылды. Бу вакыйга 1749 елда Луканың доносы белән булды. Бу елда Казанда ут чыгып, татар арасыннан башлап, рус арасына төшеп, бик күп йортларны һәлак итте. Иң күп зарланган кешеләр татарлар булдылар. Лука үзенең доносында, яңа йортлар салганда, татарларны башка җиргә күчереп утыртырга кирәк икәнен, аларны керәшен вә руслар арасында тотарга ярамаганлыгын сөйләде. Ул заманда хәзерге Тихвинский чиркәү янында борынгыдан калма татар зыярәте бар иде. Аны да бетерергә, татарларны Иске бистәдән куып, хәзерге Яңа бистәгә җибәрергә карар чыкты.

Лука Конашевичның бу Иске бистәдән күчерү мәсьәләсендә Синодка язган дәлилләре бик кызык. Ул дәлилләр православный руханиларының татар халкына карашларын бик ачык күрсәтәләр. Элек Лука Казандагы янгынны чиркәү башыннан бик күп руханилар белән карап торганын сөйли вә шунда әйтә: «Күктән бер ут төшеп, элек татар йортларын вә мәчетне яндырды. Соңра алар, православныйларга татарларны үз араларында тотарга рөхсәт иткән өчен, рус йортларын якты. Шуның өчен һәм татарлар керәшеннәрне котыртканлыклары сәбәпле, аларны Казаннан башка җиргә куарга кирәк», ди.

Менә шул рәвештә Яңа бистә зоһур итте[4]. Шушы чукындыру сәясәте, шул рәвешчә, Елизаветаның соңгы көннәрендә акырынлый башлап, Екатерина Икенче заманының Пугачёв белән бергә

[1] Ихтилалга – баш күтәрүгә.
[2] Маил – тартым, хирыс.
[3] Тәһдидләр – кисәтүләр.
[4] Зоһур итте – барлыкка килде.

куйган эшче крестьянның туп вә мылтыкларыннан чыккан төтен исе хөкүмәтнең борынына керә башлаганчы, димәк, 1773 елга кадәр дәвам кылып, бары шул елда гына матди вә мәгънәви бабларда[1] татар ирек алды.

**Татарларның күчүләре.** Менә монда сөйләнгән татар крестьяны өстенә төшкән бөтен авырлыклар татар халкын ярлылаттылар. Бу җирнең тараюы, ярлылык һәм хокуксызлыктан татар крестьяны, бер яктан, үлеп кырылды. Татар лашманчыларының үзләренең хөкүмәткә язган язуларыннан без аларның тәмам изелгән, яшьләрнең аяк-куллары агач кискәндә сынган, шуның өстенә дә яшьләр картлар өчен лашман хезмәте үтәп гаҗиз булганнар. Урманнар татарлар утырган урыннан ераклашканга, эшләп чыгарга боерылган эшләрен үтәп бетерә алмыйлар, шуңа күрә нәрсәләрен сатып, кеше ялларга мәҗбүр булалар иде[2]. Алар, лашманлыкка язылмаган кешеләр, вә салым түләү өчен бөтен нәрсәләрен сатып бетерәләр, үзләрен, хәтта кабалалы шартлар белән, фабрик-заводларга сатарга мәҗбүр булалар иде. Завод хуҗалары да аларны алдап, приказчиклар җибәреп, зур акчалар биреп яллыйлар да, алган задатокларын ун ел эшләсәләр дә түләп бетерә алмыйлар иде. Чөнки хуҗалар аларга үз кибетләреннән генә нәрсә алуны мәҗбүр итеп, анда исә нәрсәне 3–4 мәртәбә артык бәһа куеп саталар иде.

Тагы татар крестьяннарының казенный һәм алпавыт мәгъдин заводларына күчелеп язылганнары булып, болар ел саен 500–600 чакрым җирләргә барып, 3–4 ай буш эшләргә мәҗбүр иделәр. Моның өстенә дә табигый, мәгънәви кысынкылыкларны да алсак, крестьянның хәле мәгълүм булыр.

Менә шушы эшләрдән котылу өчен, татар крестьянына бер генә юл бар иде. Ул да булса, Башкортстанга вә Уралның теге ягына качу иде. Бу эш бер XVIII гасырда гына түгел, бәлки Казан алынгач ук башланган иде. Әгәр гаҗиз булган рус крестьяннары Дон, Җаек суларының буена барып, ирек табып, «качак» булсалар, татар крестьяны бераз ирекле җирне Башкортстаннан тапты. Башкортстан XIX гасырда ук Мәскәү хакимиятен таныса да, ул Русиягә мәгъ-

[1] Бабларда – мәсьәләләрдә.
[2] Бу хакта тәфсилле мәгълүмат безнең «Татар сыйныфлары» дигән китаптан табарга мөмкин. *(Авт. иск.)*

лүм бер шартлар белән кушылды: башкорт җирен тартып алмаска, аның җиренә кеше күчермәскә һәм аның иске сайланган старшиналар васитасы[1] белән йөртелгән идарәне Мәскәү идарәсе белән алмаштырмаска.

XVII гасырның башыннан алып хөкүмәт бу шартларны боза башласа да, башкортлар үзләренең ирекләрен корал көче белән каршы торып саклап килделәр. XVII–XVIII гасырдагы бу күтәрелешләр бик каты рәвештә бастырылса да, хөкүмәт һаман да Башкортстанның автономиясен Екатерина Икенчегә кадәр бетерә алмады.

Менә шул Башкортстанга ярлыланган татар крестьяны, йомышлысы күчә, кача башлады.

Элек Тамбов, Пенза, Сембер, Нижгород өяз вә вилаятьләреннән «мишәр» аталган татарлар килделәр. Боларның бер гөруһы хөкүмәт тарафыннан гаскәр, көч рәвешендә китерелсәләр, күбрәге гаҗизлектән, авырлыкларга чыдый алмый качып килде.

Шуның нәтиҗәсендә XVIII гасырның башында башкортларның саны, рәсми хисапка караганда, бары 35–40 мең булганы хәлдә, 1730 елларга таба йөз меңнән артып китте. Татарстанның үзендә дә XVIII гасырның башында татар халкының саны кимеде. XVIII гасырның беренче елларында Казан өлкәсендә (провинциясендә) 37485 кеше кимегәне мәгълүм булды.

Болардан 13 меңе татар ясаклысы булып, шуның эчендә 8698 үлгән, 3832се Башкортстанга качкан иде.

1760 елда инде рус мәгълүматына бинаән[2] вә Уфа өлкәсендә (провинциясендә) 13857 мишәр ир заты бар иде. Әмма шул ук Башкортстанда Исет өлкәсендә (провинциясендә) 1683 ир җан мишәр бар иде. Шуның өстенә дә әле 1734 ел хисабы белән Башкортстанда татар вә татарлашкан финнардан гыйбарәт булган типтәрләрдән 11294 ир заты бар иде. Әмма 1777 елда типтәрләрнең саны 28937 гә җитте. 1781нче елда шулай ук 43656 ир затына җиттеләр. Димәк, боларның саны егерме ел эчендә 33% ка артты.

Моның бер кисәге табигый арту булса, икенче бер зур кисәге әлеге качып килүчеләр иде.

[1] Васитасы – арадашлыгы.
[2] Бинаән – нигезләнеп.

**Татар, мишәрләр вә башкортларның бер-берсенә мөнәсәбәтләре.** Татарларның хезмәт әһеле Башкортстанга колонизатор вә эксплуататор сыйфаты белән килмәде. Затән[1], XVIII гасырда хөкүмәт сонгый[2] рәвештә боларның арасын аерганчы, аларда дошманлык юк иде. Мәсәлән, 1724 елларда хөкүмәт качып килүче татарларны кабул итмәскә кушса да, алар һаман килеп торалар иде. Бу хакта бер мисал итеп шушы вакыйганы сөйләп узарга кирәк. 1724 елларда хөкүмәт, Башкортстанга илче итеп берәүне җибәргән иде. Аңар башкортлар шулай әйткәннәр: «Нигә сиңа Казан өязендә торырга, озакламый Русия белән сугыш була. Әүвәлге шикелле генә сугыш булмас, Себер һәм Җаек казаклары да безнең белән бергә булырлар», дип, бер крестьян татарны җибәрәселәре килмәгән, имеш. Гомумән, XVIII гасырда татар хезмәт әһеле белән башкорт халкы бик дус торганнар. Шуның өчен дә хөкүмәт аларны аерырга сонгый чаралар кылган. Башкортстан ихтилалларын тыючы түрәләрдән Румянцев[3] һәм Кириловның[4] хөкүмәткә язган хатларында: «Башкортлар баеп китеп, Казан, бистә һәм өязләрнең татарлары белән кода булышып беттеләр. Шуның өчен Казанда ни генә булмасын, хәзер башкортлар беләләр, татар вә башкортларның кыз алышып, кыз бирешүләрен Казан губернаторының рөхсәте белән генә эшләргә ирек бирергә кирәк», диелгән иде. Вакыйган[5], шундый указ чыкты да: башкорт вә татар туй ясыйсылары килсә, губернатордан рөхсәт алырга. Рөхсәт бирсә дә, мондый туй өчен кыз да, егет тә хәзинәгә берәр ат бирергә, әгәр рөхсәтсез туй ясасалар, кыз белән егетне Себер сөргенгә җибәрергә булган иде. Гомумән, XVIII гасырда, та-

[1] Затән – чынында.
[2] Сонгый – ясалма.
[3] Румянцев Александр Иванович (1680–1749) – Россия империясенең хәрби һәм дәүләт эшлеклесе. 1735 елда генерал-лейтенант чинында башта Әстерхан, аннары Казан губернаторы булып тора, башкортлар күтәрелешен бастыруга җибәрелгән гаскәр командующие итеп билгеләнә. 1735–1736 елларда Башкорт эшләре комиссиясе башлыгы булып тора.
[4] Кирилов Иван Кириллович (1695–1737) – рус галиме һәм дәүләт эшлеклесе, географ, картограф, тарихчы һәм хокук белгече. Россия география фәненә нигез салучыларның берсе. 1735–1740 еллардагы башкорт восстаниеләрен бастыруда актив катнаша.
[5] Вакыйган – чыннан да.

тарлар белән башкортларның ихтилятлары[1] бик куәтле булып, шунлыктан Русия самодержавиесе аннан бик куркадыр иде. Мәсәлән, 1735 елда хөкүмәт Румянцев дигән кешене Башкортстанга баш командан итеп җибәргән чакта, яшерен тәгълиматта шундый сүзләр бар иде: «Казанга бик күп башкорт килеп йөри, алар нинди булса да хәбәр китермиләрме икән? Мал дигән булып мылтык, дары ташымыйлармы икән? Шуларны тикшереп торырга Арча кырыена гаскәр куелды», диелгән иде.

1748 елда татар крестьяннары, самодержавиенең кысуына каршы кубарга уйлаган чакларда, башкортлар белән сүз беркеткәннәр иде. Шулай ук 1754–[17]55 еллардагы, башкорт ихтилалы алдыннан, шуның башында йөрүче башкорт итилалчысы Батырша да Казан вә әтрафы татарлары белән бергә хәрәкәт кылды. Үзенең озын вә куәтле рәвештә язылган прокламациясен Казан вә әтрафы татарларына җибәрде.

Шушы вакыйганың эчендә булган бер русның язуына күрә, Батырша[га] татарлардан, башкортлар белән бергә күтәреләчәкләрен белдереп, вәкил дә җибәргәннәр. Самодержавие хөкүмәте шуның өчен дә һәрвакыт башкорт белән татарларны аерырга теләп килде. Шуның өчен дә Башкортстан колонизаторларыннан, аларның бик күп кузгалышларын тыючы Неплюев 1735 ел ихтилалын бастыру хакында хөкүмәткә биргән ляихәсендә ачыктан-ачык: «Башкортлар үзләренең көчләре белән куркыныч түгел, бәлки качучыларның күп килеп торулары аркасында куркыныч», дип, төрле кысынкылыклардан качып килүче рус крестьяны белән бергә татар крестьянының куркынычын да белдерә иде. Шуңар күрә дә самодержавие хөкүмәте татар вә башкорт арасын төрле юллар белән бозарга тырышты һәм башкорт күтәрелешләрен басу эшендә аңлы рәвештә татар мирза, полковник вә генераллары көче белән файдалана.

Ләкин Башкортстанга күчеп килгән татар крестьяны монда да крепостной хөкүмәтнең золымыннан котыла алмады. Монда да хөкүмәтнең төрле кысулары татарларны килеп тоттылар.

**Башкортстанда татар вә фин кузгалышы.** Качып килүчеләр аркасында Башкорстанда мишәр вә типтәр атала торган халыкның көн саен саны артканын күрдек. Сарай исрафлары һәм вә күп гаскәр

[1] Ихтилятлары – аралашулары, дуслыклары.

асрау белән акчага сусаган хөкүмәт 1747 елда Башкортстандагы татарлардан двор башыннан алына торган салымны җан башыннан алына торган имана белән алмаштырып, җан башыннан 80 тиен алырга карар бирде, бу акчаны түләү, таланган, балаларын ачка үтермәс өчен җир сатарга мәҗбүр булып, бик аз гына җиргә малик булган Башкортстан татарлары өчен бик авыр булды. Чөнки ул заманда акча бик кыйммәт булып, мәсәлән, 1717 елда Казанда йөз данә вак кадак 5 тиен, 130 йөк яхшы утын 13 сум 50 тиен иде.

Димәк, 80 тиен акчага ул чакта 1600 данә вак кадак алырга мөмкин иде. Әгәр сугыш алдындагы хисапка салып, һәрбер биш данә кадакны бер тиеннән генә хисапласак, бу XVIII гасырдагы 80 тиен акча өч сум егерме тиенгә туры киләдер.

Гаиләдә урта хисап белән 4 кеше хисапласак, һәрбер гаилә 4 җан өчен түләсә, елына 12 сум 80 тиен түләргә тиеш була. Табигый, бик изелгән һәм бик иркен торырга өйрәнгән Башкортстан татарлары өчен бу эш бик авыр тоелды, шуның өчен мишәр, типтәр, чуваш-чирмешләр бу фәрманны алып килүчеләргә һөҗүм иттеләр һәм имана бирүдән баш [т]арттылар. Бу хәбәр Неплюевка ишетелгәч, ул мишәр, типтәр, чуваш һәм чирмеш авылларына аларны үгетләргә, әгәр дә алай гына булмаганда, хәрәкәтне көч белән тыярга кешеләр җибәрде. Бу хәрәкәт вакытында Мәләкәс авылы мәркәз булып торды. Ләкин гаскәр килеп җитеп, аз гына бәрелештән соң, халык иманаы бирергә разый булып итагать игълан кылды. Ихтилалны тыюда башкорт, мишәр вә типтәр старшиналары да иштиракь иттеләр. Алар шул хезмәтләре өчен хөкүмәттән бүләк кылычлар алдылар. Менә бу вакыйга да – татар-башкорт арасындагы сыйнфый көрәшнең бер сәхифәседер, чөнки байлар ярлыларны бастыралар.

### 4.3. Сәүдә капитализмы үскән дәвердә сыйнфый көрәш

**Әсаслар.** Һәрбер милләтнең яисә дәүләтнең бер төрле икътисади тормыштан икенче төрлесенә күчүе вә шуның аркасында иҗтимагый тормышның үзгәреп, картайган экономика нигезен югалтып, икенче яңа сыйныфның тарих сәхнәсенә хаким уларак чыгуы тыныч кына булмый. Мондый процесс, әлбәттә, бик авырлык һәм күп кан коюлар белән уза торган була. Бу чакта, бетә башлаган, мазыйсын[1]

[1] Мазыйсын – үткәнен.

югалткан сыйныф яңа чыккан яшь сыйныфка ябыша, аны буарга омтыла, шуның өчен дә бу көрәш ифрат рәхимсез рәвештә бара. Бәгъзы вакытта шул күчү дәверендә булган низаг, җәнҗал-орышны тарихчылар күрәләр, ләкин аларны һичбер төсле шушы күчү дәверенең тулгагы дип аңлатмыйлар. Чөнки аларның иң якын сәбәпләре бөтенләй аның белән бәйләнмаган шикелле тоелалар. Ләкин иҗтимагый тормыш – ифрат мөрәккәб[1] нәрсә. Шуның өчен бәгъзы вакытта икътисади гамил[2] тугрыдан-тугры вакыйгаларны тудырмый, бәлки кояшның нуры элек бер көзгегә төшеп, аннан икенчесенә төшеп, кояш керми торган бүлмәне яктырткан шикелле, икътисади гамил дә васиталар аркылы вакыйгаларга тәэсир итә.

Менә безнең XVIII гасыр тарихыннан без шуны күрәбез: әсасында дин мәсьәләсе, башкорт-татар бунтлары, татарларның Башкортстанга күчүләре – һәммәсе дә феодализм калдыгы белән сәүдә капиталының бер-берсе арасында ярышуыннан килгән нәрсәләрдер. Без моны моңарчы сөйләгән сүзләрдән күрдек, ләкин без хәзер бу ике әсасның көрәшен татар җәмгыятендәге XVIII гасырдан булган бер-ике сыйнфый көрәш вакыйгасын тикшереп карасак, тагын да ачык күрербез. Бу көрәш татар тарихында бик мөрәккәб (сложный[3]), чөнки без XVIII гасырда менә нәрсә күрәбез:

1) Русия дәүләте. Бу җәмгыять белән татар ифрат нык бәйләнгән, андагы һәрбер вакыйгада үзгәреш, татар халкы җәмгыяте тормышына куәтле тәэсир итә. Әгәр без бу XVIII гасырда Русия дәүләтен алсак, анда без, бер яктан, ике әсасның, ягъни феодализм вә сәүдә капитализмының, нык көрәшен, бер-берсе белән ярышуын күрәбез, бәгъзы урыннарда исә, мәсәлән, крепостной право мәсьәләсендә, бу әсаслар бе[р]лек ясап, ат кәмите ханәсендә эт белән мәче дус булганнары шикелле, бергәләшеп хәрәкәт кылалар. Мисал итеп татарны чукындыру мәсьәләсен алырга мөмкин, монда әлеге ике әсас та мөттәфикъләр[4], чөнки руханига приход кирәк, алпавыт-феодалга җир кирәк, рус купецына яисә сәүдә итүче дворянга ул көнкүреше мәхсулатының[5] татар сәүдәгәре аркылы түгел, тугрыдан-тугры үз

[1] Мөрәккәб – катлаулы.
[2] Гамил – төп фактор.
[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[4] Мөттәфикъләр – берләшкәннәр.
[5] Мәхсулатының – кеременең.

кулына төшүе кирәк, рус купецына Шәрыктагы конкурентный татар сәүдәгәрен, базарсыз калдырып, кулыннан «дин» коралын алып бетерергә кирәк.

2) Татар җәмгыяте үзе Русия белән никадәр нык багланса да, ул – аерым бер җәмгыять: аның үз эчендә көрәш бара, ул үзе бәгъзы вакытта рус җәмгыятеннән алда, бәгъзы чакта аннан арттарак калып, бер икътисади дәвердән икенчесенә күчә, бу процесска гомумрусия экономикасы тәэсир иткәне шикелле, үз экономикасы да тәэсир итә. Менә татарлардагы сыйнфый көрәшне алган чакта, шуларны белеп һәм яхшы игътибарга алып сөйләргә кирәк. Шуның өчен дә бу көрәштә, бер яктан, татар җәмгыятенең үз эчендә көрәш барса, икенче яктан, татар сыйныфлары белән рус[1] сыйныфлары берләшеп, гомум дошманнарына каршы сугышалар. Менә бу соңгы вакыйганы без сыйныфларның Пугач явындагы катнашуларыннан күрәбез.

**Казан йомышлылары вә мирзаларының татар-башкортларга каршы хәрәкәтләре.** XVIII гасырдагы сыйнфый көрәшнең бер вакыйгасы – 1707 елдагы бер факттыр. Пётрның Шималь сугышларында әле җиңелеп торган чакта, 1705 елдан алып Башкортстан күтәрелеш уты астында иде. 1707 елда бу күтәрелеш көчәеп китеп, Күсем Алдар[2] һәм Исмәгыйль исемле башкортлар хәрәкәтнең башында тордылар. 300 гаскәр белән боларга каршы киткән Уфа воеводасы Хохлов җиңелде. Ярты гаскәрен югалтып чыкты. Моның соңында ихтилалчылар хәрәкәте зураеп, татар вә башка гайре русны үзләренә ияртү өчен, Казанга таба хәрәкәт кылдылар. Юлда очраган авылларны талап, яндырып һәм әсир алып бардылар. Юлдагы яраклы татарлар һәм чувашлар ихтилалчыларга кушылдылар. Бик күп шәһәрләрне, шул җөмләдән Алабуганы, мөхасәрә кылдылар[3]. Ниһаять, Казанга 80 чакрым якынлаштылар. Хөкүмәт[нең] бу вакытта сугыш сафында аерым уңайсыз хәлдә чагы иде. Шулай булса да, хөкүмәт каты чаралар кылырга уйлап, Хованский дигән кешене баш иттереп куйды. Хованский башкортларны үгетләр өчен

[1] Чыганакта ялгыш «фәрәс» дип язылган.
[2] Күчем Түләкәев яки Күчем батыр (башкортча Күсем Түләкәев) – 1710–1711 еллардагы башкорт күтәрелеше җитәкчеләренең берсе. Тамъян кабиләсе бие, башкорт кенәзе һәм Шәгале Шакман варисы, Акай Күчемовның атасы.
[3] Мөхасәрә кылдылар – камап алдылар.

Казан татарларын тылмач ясап, аларга илчеләр күндерде. Ләкин башкортлар разый булмадылар, яңа зур салымнарны бетерүне, залим түрәләрне татар-башкорт арасыннан алуны таләп кылдылар. Ихтилалчылар һаман хәрәкәтләрендә һәм Казанга якынлашуларында дәвам иттеләр. Ниһаять, алдагы фиркалар Казанга 30 чакрымлап җиргә килеп җиттеләр. Шушы вакытларда Казан вилаяте губернаторы яңа чараларга кереште. Казанның мирза вә йомышлыларын, мобилизация ясап, аларны кузгалган крестьян вә шәкертләргә каршы җибәрде.

Бу вакытта хөкүмәткә ялчы бер кеше дә табылды, ул исә Ишбулат мулла иде[1]. Менә шул гаскәр һәм хөкүмәтнең азмы-күпме мөнтазам гаскәре чыгып, ихтилалчыларны Казан өстенә килүдән туктатты.

XVIII гасырда язылган бер татар вәкаигънамәсендә[2] бу вакыйга хакында шундый нәрсәләр укыйбыз:

«Тарих мең дә йөз дә унтукыз иде, башкорт ягы[3] булып Сидор Аристов дигән рус башлаю[4] баш улып йөрде. Ахире бар[5] башкорт Казан халаекы исендә[6] килеп, халыкны үзләренә багындырдылар. Күп илләре, монастырьлары яндырмак илә күп рус, марҗа кызларыны ясир[7] кылып, Казан халкы башкорт берлән богындылар[8], Казаннан чирү (гаскәр) чыкып, татарларга Ишбулат мулланы баш иттеләр. Рус чирүенә Романович Лика (?) дигәнне баш идеп. Әмма рус чирүе Нугай юлы Солтангали дигән илдә торып сукыш кылды. Әмма Казан халкы күп-күп углы ясир улып, татарлар дәхи ясир иттеләр. Олуг бөлеклекләр улынып, ахыры Хованский дигән бояр, падишаһның хөкеме берлән, килеп туктатты».

Ләкин хәрәкәт моның белән туктамады. Хөкүмәт башкорт-татарларга гафу-и гомуми[9] игълан кылса да, ясаклы татарлар һәм

---

[1] Менә шуннан татарларда «Ишби булды башыбыз, эшти (щи) булды ашыбыз» дигән мәкаль калды. (*Авт. иск.)*

[2] Вәкаигънамәсендә – елъязмасында.

[3] Ягы – явы, сугышы.

[4] Башлаю – җитәкчелек итеп.

[5] Ахире бар – шуның соңында.

[6] Исендә – эчендә.

[7] Ясир – әсир.

[8] Богындылар – берләштеләр, бер булдылар.

[9] Гафу-и гомуми – бөтенесен дә гафу итү.

башкортлар хәрәкәтне дәвам кылдылар. Казан, Уфа өязләрендә генә ихтилалчылар тарафыннан 303 авыл яндырылды, 12705 кеше әсир алынды. Бу вакытта тагы Дон казакларында да ихтилал башланып, алар да башкортлар белән кушылырга омтыла башладылар. Ләкин инде 1709 елда Полтава сугышында шведлар җиңелгәч, хөкүмәтнең кулы бушап калды. Күп кан түгелгәннән соң, күтәрелеш бастырылды. Казан йомышлы татар вә мирзалары соңыннан, бу вакыйгага 60 ел үткәч, үзләренең бер наказларында бу эшләре белән мактандылар, алар үзләренең хөкүмәткә иткән хезмәтләрен санаганда шулай диделәр: «В 1708 г. против бунтующих воров и других башкирцев, что с ними имели мужественный и храбрый бой, и на том бою их побили и поймали, и за что дано нам тридцать фузей (бер нәүгъ мылтык), двадцать пороху, свинца тоже. Да государство знамя и шестьдесят кремней, в чем имеем того 1708 годе похвальный лист»[1]

**Тәфкилев крестьян-татарларының кубуы.** Мәнбәгъләр[2] безгә тагы бер сыйнфый көрәшнең ачык картинасын саклап калдырды. Ул да булса, генерал-майор Котлыгмөхәммәд яисә Алексей (аны күбрәк шул исем белән йөртәләр иде) Тәфкилев кулындагы крестьяннарның кубуыдыр.

Бу кеше Касыйм, Владимир, Криницкий өязләрендә утар һәм крестьяннары булган Мамишев дигән бер мирзаның нәселенең берсе иде. Иске фамилиясен ташлап, бу кеше үзен Тәфкилев дип йөргән. Оренбург шәһәрен салып, хөкүмәт башкорт вә кыргыз җирләрен колонизация ясаганда, Тәфкилев шул эшнең башында торган кешенең урынбасары булган.

Русия хөкүмәте бик күп башкорт хәрәкәтләрен бастырганда, карательный фиркаларны команда итеп, ямьсез рәхимсезлекләр күрсәткән (мәсәлән, Оренбургка бер фирка гаскәр белән азык төяп барганда, аңар бер авыл янында башкорт көчләре һөҗүм иткәч, шул авылның мең башкортын бетергән, авылны яндырткан, йөз дә биш кешене бер өйгә ябып тереләй яндырткан). Менә шушы хезмәтләре өчен хөкүмәт Тәфкилевкә, төрле бүләкләр вә дәрәҗәләр белән бергә, хәзерге Алабуга кантонында күп җир-сулар һәм татарлардан крестьяннар биргән иде. Менә 1774 елларда шул авылдагы татар

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Мәнбәгъләр – чыганаклар.

крестьяннарын ифрат рәхимсез рәвештә эксплуатация ясый башлагач, моңа чыдый алмыйча, Балтас вә Мордвинково авылларындагы татар крестьяннары мирзага каршы чыктылар.

Болар мирзаның усадьбаларына һөҗүм иттеләр, яндырдылар, хәтта үзен үтерә яздылар. Соңра бу ихтилалчыларны бастырыр өчен, гаскәр килде. Крестьяннар аларга да каршы тордылар. Күп вакытлар кара урманнарда качып, каршы торуда дәвам кылдылар. Ниһаять, яңадан гаскәр килеп, аларны буйсындырды. Ләкин шулай булса да, бу крестьяннарның башында торучы Хәбибулла исемле крестьян качты. Бу хәбәр мәркәзгә дә ишетелеп, шау-шуга сәбәп булды.

Менә бу – татар крепостной крестьяннарының Пугач явына кадәр актив көрәшләренең берсе.

**1767 ел комиссиясендә татар сыйныфларының көрәше.** XVIII гасырда татар сыйныфларының теләкләрен вә аларның бер-берсенә булган мөнәсәбәтләрен күрсәтә торган урын, 1767 елда Екатерина Икенче хөкүмәте тарафыннан яңа законнар чыгаруның ляихәсен[1] ясау өчен җыелган комиссиядә булды.

Бу комиссиянең тарихын монда без озак сөйләп торырга уйламыйбыз. Моны теләгән кеше Русия тарихы дәреслегенең һәркайсында табар. Бу комиссиягә мәгълүм бер микъдарда вәкилләр гайре руслардан да чакырылган иде. Татар-башкортның да өч сыйныфыннан 27 гә якын вәкилләр монда сайланып килделәр.

1) Мирза вә йомышлы татарлардан; 2) муллалардан; болар аерым бер сыйныф булып түгел, бәлки, яисә йомышлы, яисә ясаклы татарлардан сайландылар; 3) ясаклы татарлардан; бу татар вә башкорт вәкилләре төрле вилаять вә провинцияләрдән килделәр.

Бу вәкилләр үзләренең сайланганлыкларына кәгазьләр алып килделәр һәм комиссиянең мәҗлесләрендә тел белән һәм язу белән үзләренең фикерләрен белдерделәр.

Бу мәсҗлесләрдә мирза вә бай йомышлылар нәрсә сөйләделәр, нәрсә теләделәр?

Беренче мәртәбә алар үзләренең рус дворянствосы белән бертигез булуны сорадылар. Үзләренең аксөяк җенесеннән килгәнлекләреннән, үзләренең хөкүмәткә искедән бирле төрле сугышларда вә төрле бунтларда «изменниклар» белән көрәшүдә иштиракь

[1] Ляихәсен – проектын.

кылганлыкларын сөйләп, рус дворяны шикелле үк имтиязга[1] хаклы булганлыкларын белдерделәр. Бу фикерләр мирзаларның һәммәсенең наказларында бар иде. Алар бу чакта үз исемнәреннән мирза Әюп Еникиевне чыгарып, аның язган гариз – докладына һәммәсе дә кул куйдылар. Үзләрен гади татар белән бер дәрәҗәдә саналмауны таләп кылдылар. Мирза вәкилләре моның белән генә канәгатьләнмәделәр. Рус дворянствосы хөкүмәттән имтияз (привилегия)ларны арттыруны сорап мәҗлескә биргән мәгърузәләренә[2] безнең татар феодалларының вәкилләре дә кул куеп, рус сыйныфташлары белән теләкләренең, телләренең, мәсләкләренең бер булганын белдереп тордылар.

Икенчедән, татар мирзалары үзләренең кулларында чура-крепостнойлар булып, аларның, хуҗаларның, сүзләрен тыңламауларын, качуларын [бә]ян кылган соңында, татар мирза вә йомыш[лы] ларына да рус дворяннарына бирелгән аларны солдатка тотып бирү, сөргенгә җибәрү шикелле хокук бирелүен теләделәр.

Без бу вакыйгада татар крепостной хуҗалыгының эчендәге алпавытлар белән крепостнойлар арасында булган көрәшен ачык күргәнлегебездән, Казан шәһәре мирзаларның наказларындагы шул теләкнең русчасын монда китереп узабыз: «А из оных «дворовых людей» крестьян некоторые бывают не в послушаньи нас и иногда бегаюта будучи в том побеге, чинят воровство и проведены бывают в присутственные места и изобличаютя. Того ради, повелено б было таковых прилагавшееся, или без оного изобличения (ягъни хөкемсез) только в одном случае подачи на них от нас, от владельцев, донешеньев атсылать их в казенные работы, куды указом повелено, в сет за них иль дворовых людей «крестьян работы»[3].

Шул вакытта ярлы йомышлылар һәм ясаклы татарлар нәрсә сорадылар?

Боларның сораган нәрсәләре җир булды. Җирнең аз калуы, аның, алда сөйләгәнчә, рус алпавытларының кулына кереп бетүе аларның иң зур моңнары иде. Крепостной хөкүмәтнең күп салым алуы, постой төшерүе вә башка нәрсәләр түләтүе, лашманчылыкка язып, аларны фактта крепостной ясады.

[1] Имтиязга – өстен хокукка.
[2] Мәгърузәләренә – биредә: прошениеләренә.
[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.

Аларның янә бер мөһим теләкләре бар иде. Мәгъдин заводларының аларны кызыктырып яллап алып китеп талавы, аларның аннан качкан кешеләренең алдан алган задаткаларын круговой порука белән түләтүләрен сөйләделәр. Татар хезмәт әһеленең эксплуататорлар белән киләчәктә Пугач явында көрәшәчәк канлы көрәшләренең мөкаддимәсе[1] иде.

Татарның баерак сәүдәгәрләргә әйләнгән авыл халкы, купецлар белән нәрсә өчен көрәште? Боларның беренче зарбәләре феодализм калдыгы «сословный» тормышка булды. Бу бабта аларның иң ачуланган нәрсәләре бары купец булган кешеләр генә сату итә алып та, башка кешенең рөхсәтсез булуы иде. Бу бабта безнең өченче «сословиебез» нәкъ француз революциясеннән алдагы буржуазиянең таләбе төсле иде. Алар комиссиядәге сүзләрендә: «Адәм нигә вә ни эшләргә лиякате бар[2], шуны гына эшли ала. Адәм ирекле булырга кирәк», диделәр. Ләкин бу комиссиягә татарның крепостной вәкилләре килмәгәнгә күрә, аларның тавышларын ишетә алмадык. Ләкин бу халык, башка хезмәт халкы белән бергә, үзләренең тавышларын Пугачёв явында туп, мылтык тавышын, җәяләре белән крепостной хөкүмәткә аткан укларының сызгыруы белән тарихка ишеттерделәр. Шуның өчен дә бу вакыйгада татар сыйныфларының катнашуының төрле-төрле булуы – сыйнфый көрәш тарихының иң яхшы манзараларыннан берседер.

**Пугач явында татар сыйныфлары[3].** Пугач явы татар сыйныфларының моңарчы ачылмаган бер-берсенә каршылыгын ачык итеп ачып бирде. Бу заманда ыруг тормышы вә бигрәк тә феодализм тормышы тәхлил кылынып[4] бетмәгән, рус вә башка халык колонизациясенә каршылыкта һәммәсе бер фикердә булган башкорт халкы, Пугач явында барысы дип әйтерлек ихтилал ягында булсалар, бу хакта инде сәүдә капитализмына тәмам кереп манчылган татар милләте бербөтен халык буларак түгел, бәлки төрле сыйныфлар уларак төрлечә катыштылар.

[1] Мөкаддимәсе – башламы, кереше.
[2] Лиякате бар – кулыннан килә.
[3] Бу хакта безнең аерым бер әсәребез чыгачакка күрә, озак тукталмыйбыз, бары нәтиҗәләрен генә биреп китәбез. *(Авт. иск.)*
[4] Тәхлил кылынып – аерылып.

Аксөяк мирзалар, мирзалардан чыккан мулла-ахундлар, гади йомышлыдан чыгып та, мирза булган татар чиновниклары, табигый, үзләренең сыйныфташлары булган Русиянең хаким сыйныфлары – дворяннар вә алардан гыйбарәт булган хөкүмәт тарафында булдылар.

Шуның өчен дә хәрәкәт башлану белән хөкүмәт башкорт вә татарларны үгетләү өчен бер «яхшы кешене» (билгеле мирза вә ахуннардан) Башкортстанга җибәрде. Екатерина үзенең Казан вилаятенә мөрәҗәгать кылып язган манифестында да боларга ышанганлыгын бәян кылды. Мәгълүм Котлыгмөхәммәднең углын – майор Тәфкилевне хөкүмәт, башкортларны үгетләр өчен, Башкортстанга күндерде. Соңыннан бу кеше башкорт гаскәренә командан булып, хөкүмәт ягыннан сугыша башлап, үз башкортлары ук аны тотып, ихтилалчыларга бирделәр. Янә бер татар мирзасы капитан Башаринның[1] хөкүмәт гаскәрендә булып, башкортларга әсир төшеп, бары аның кул астындагы солдатлары: «Башарин солдатлар өчен яхшы иде», дип йолып калулары аркасында гына котылып асылмый калды. Гади бер йомышлыдан лашманнар конторасының тылмачы булып, соңра Казан мирзаларыннан 1767 ел комиссиясенә вәкил булып барган, соңыннан бригадир булган Сәгыйд Хәлфин хөкүмәт ягында булып, башта Пугач Казан ныгытмасын мөхасәр[ә][2] вакытында әрхәрәй вә рус-татар алпавытлары, түрәләре белән Казан Кремлендә утырды, Пугачёв тәмам җиңелгәч, аның ягындагы кешеләрне җәза кылу өчен төзелгән следовательный комиссиядә, Сембер шәһәрендә, граф Панин кул астында мәсьүл тылмач[3] булып эшләде.

Сәүдәгәргә әйләнгән йомышлы татарлар да хөкүмәт ягыннан булып, Пугачёвка каршы хәрәкәт иттеләр. Боларның саннары бик күп, ләкин эчендә исемен әйтеп китәрлеге – Кишет авылының йомышлы татар вә фабриканты Ибрай Йосыповтыр. Бу кеше башта Оренбургны хөкүмәт мөдафәга кылганда[4], Пугачёв аны камап ятканда,

[1] Иван Башарин (1735–1774) – Россия офицеры, Тубыл гарнизон батальоны капитаны. Пугачёв восстаниесе вакытында әсирлеккә алына, солдатларының яклавы аркасында җәзадан котыла һәм Емельян Пугачёвка ант итә. И. Башаринның язмышы белән А. С. Пушкин да кызыксына, һәм ул аны Пугачёв восстаниесенә багышланган тарихи романында төп персонажларының берсе итә.

[2] Мөхасәрә – камап алу.

[3] Мәсьүл тылмач – җаваплы тәрҗемәче.

[4] Мөдафәга кылганда – саклаганда.

хөкүмәт ягында эшләсә, Пугачёв Казанга килгәч, шуның артыннан килеп, аңарга каршы хәрәкәт кылды. Шуңар мөкяфәт[1] уларак Әюп Йосыпов фабрикант бөтен Русиядә үзенә вә үзенең балаларына «купец салымнары түләмичә» сату итәргә һәм, һәрбер җиргә илтеп, үз фабрикасында эшләнгән малларны сату хокукын алды.

Татарның руханиларына килсәк, бу сыйныф үзе берничә катлауга бүленгән иде. Аның ахунд, бай – алпавыт булганы һәм гади авыл мулласы булганнары бар иде. Шуның өчен беренчеләре хөкүмәт ягыннан хәрәкәт кылдылар.

Мәсәлән, Чиләбе тирәсендәге зур алпавыт, комиссиягә вәкил булып барган ахунд Габдулла Мөслимов – Дәвеш мирза нәселеннән килә торган аксөяк мулла халыкны Пугачёвка каршы хәрәкәткә өндәде һәм үзе дә Пугачёвка каршы активный хәрәкәт кылды. Әмма гади Казан мулласы Габдерәшид хөкүмәт тарафыннан тотып астырылды. Саба авылы мулласы, үзе гади крестьян баласы булу белән бергә, элек Пугачёв ягыннан хәрәкәт итте, соңра ул Казан янында җиңелгәч, әүвәл Казакъстанга, аннан Бохарага качты. Хәтта бер мулла Пугачёвның «рус Азия ардусында» команданлык та итте. Хәзер без татар буржуазиясенең Пугачёвка булган мөнәсәбәте мәсьәләсенә киләбез.

Билгеле, бу сыйныф табган[2] Пугачёвка каршы булмаска тиеш иде, рус купецлары да Пугачёв яклы бик күп иде, чөнки Пугачёв хәрәкәте – крепостнойлыкка каршы күтәрелгән бер хәрәкәт иде, әмма крепостнойлык вә феодализм калдыгын бетерү, әлбәттә, бу сыйныф өчен яхшырак булырга кирәк иде. Чөнки, әгәр халыкның бик күп бер кисәге әсарәтеннән[3] котылса, базар яхшырачак, сәүдә күбәячәк, буржуа да баеячак иде. Ләкин ул заман сәүдәгәре әле бу кадәр төптән уйларлык аңга малик булмаган. Вакытлы уңайсызлыклар, кәрваннарның талանулары (мәсәлән, пугачёвчылар тарафыннан Бохарадан килгән кәрванның талануы – еш булып торган вакыйгаларның берседер. Хәлбуки[4], Урта Азия исә татар сәүдәгәрләренең беренче базарларыннан санала иде), тәртипсезлек, татар сәүдәгәрләренең төп базары

[1] Мөкяфәт – бүләк.
[2] Табган – табигый рәвештә.
[3] Әсарәтеннән – әсирлегеннән.
[4] Хәлбуки – шулай булуга карамастан.

булган Башкортстанның ихтилал уты эчендә калуы, бу сыйныфның күп әгъзасын Пугачёвтан йөз чөерергә мәҗбүр итте.

Шуның өчен дә Каюм Насыйриның бер кулъязмасында ул чактагы сәүдәгәрләрнең Пугачёвка каршы булганлыгын аңлата торган бер вакыйга сакланып калган. Без аның бер кисәген монда күчереп китәбез: «Аитов Мөхәммәдҗан хәзрәтләре риваять кыладыр: Казан сәүдәгәрләреннән, Җаекта иң әүвәл безнең Ает бабай сату итә башлаган, аңарчы безнең Казан халкының Җаек белән эше булмас икән, әткәмез сөйләр иде. Шуннан соң Пугачёв Казанга килгәндер, әмма безнең Ает бабай ул заманда Җаекта икән. Ул вакытта Җаекта сөйләшәләр икән: «Пугачёв Казанны алырга китте», дип. Ает бабай аларга әйтер икән: «Пугачёв Казанны ала алмас, сар[1] Иван Василич өч ел камап, көчкә алды икән». Бу сүзне Пугачё[в] тарафыннан куелган Җаек атаманга җиткерү белер. Аннан соң атаман әмер итәр, Ает бабайны тотып, чи каешы белән беләкләреннән һәм ботларыннан будырып, кырга чыгарып ташлыйлар. Ул арада Ает бабайның дуст-ишләре барып, атаманга гозер итеп: «Ул алдый», – дип әйткән, – аның гөнаһысы юк», дип әсбаплар күрсәткәч, житешергә әмер иткән… Ает бабай шуннан соң тизүк ике җефәк җаулык алып, Пугачёв гаскәренә әләмгә дип бүләк итеп, ата[ма]нга илтеп бирүенә, Ает Бабай әйтер икән: «Җаекта аннан соң шундаен низамсызлык булуы, минем ничә мең куй тиремне Җаек суының кичүенә күпер урынына түшәп, гаскәр чыгардылар», дирләр икән».

Шуның өчен дә татар сәүдәгәре, «низамсызлык» өчен малы талanudан куркып, Пугачёв ягыннан хәрәкәт кылмады, шул ук вакытта ул хөкүмәт ягыннан да артык фәгалият[2] күрсәтмәде, ул авышмалы торды, үзенең вакытлы мәнфәгатьләрен күзәтте.

Татар сәүдә капиталы ияләре чынлап та Пугачёв явыннан шактый зарар күреп тордылар. Мәсәлән, Казан артында Кышкар атлы байлары вә фабрикалары (кытат[3] эшләнә торган) вә бик искедән бирле мәдрәсәләре белән мәшһүр авылының бер баен талау хосусында бер кулъязмада: «1774 мәсихия[4] июльнең 15 көнендә Җәмалҗан (Емельян Пугачёв)ның командасы килеп, Кышкарның

[1] Сар – царь.
[2] Фәгалият – эш, гамәл.
[3] Кытат – киҗемамык.
[4] Мәсихия – милади.

Сәгыйд Госман углыны таладылар», диелгән, шулай ук Пугачёв Оренбург Каргаласыннан киткән чакта Каргалыдагы шактый күп байларны үтертә һәм аларның йорт-җир вә малларын яктырта.

**Ни өчен татар буржуазиясе бу заманда Пугачёв вакыйгасында ихтиятлы[1] бер сәясәт йөртеп, икеле роль уйнады?**

Мәсәлән, Казан буржуазиясе аны кабул итеп бүләкләр китерде, әгәр халык телендә йөри торган хәбәрләргә ышанылса, хәтта Пугачёв Казанның ул заманадагы сәүдәгәре Муса Апанаевта кунакта да булган (әмма рус купецларында сыйлануы, мунчаларына керүе мөхаккактыр[2]). Пугачёв Казанга килгән, аның Казанга җитүе Мәкәрҗә ярминкәсенә барыла торган вакытка тугры килгән, ләкин губернатор Бистә кешеләрен Мәкәрҗәгә барудан манигъ кылды. Ул вакытта Казан татарларының (димәк, Мәкәрҗәгә барырлык буржуазиянең) кяргөзар (башлык, аксакал) адәми карт Ибраһим әйткән икән: «Бу кеше бистә халкына әйтептер, һәр ни Мәкәрҗәгә барырга хәзерләнгән күмәч, бавырсак, сохари, икмәк, бал, май, җомырка, сыра вә һәм моның кебек нәрсәләрне мәчет алдына китерергә» дә, һәм мәчет алдына эскәмияләр ясап, шул тәгамнарны (ашларны) мәчет алдына эскәмияләргә өеп куйдылар. Шуннан соң Казан буржуазиясе Пугачёв белән килүче башкорт гаскәрен сыйлый һәм бу башкортларның: «Ил (дуст) булсаңыз, атайга (Пугачёвка) барыңыз, бәһият биреңез» дип кыстый башлагач, Ибраһим карт халыкка әйтептер: «Имди чара юк», дип һәм ул җиде кешене коралландырып, атка атландырып, уң беләкләренә Пугачёв тарафының галәмәте күк чүпрәк бәйләтеп, үзе һәм җәяү күсәккә таянып киткәннәр, Пугачёвка булышлык кылабыз дип күрсәтергә теләгәннәр, чөнки әле бу вакытта Пугачёвның Казанда хөкүмәт гаскәрен җиңгән тантаналы көннәре булган, ләкин Ибраһим карт ул җиде кешене башлап барганында, Мәскәү юлында зур тузан күреп әйтептер: «Һай егетләр, атыгыздан төшеп, иярләрегезне бергетеп, чүпрәкеңезне сул кулыгызга бәйләгез!» дигән. – Аннан соң имди атланыгыз, бу тузан патшадан калага ярдәм килә торган Михельсон[3]

---

[1] Ихтиятлы – саклыклы.

[2] Мөхаккактыр – төгәл мәгълүм.

[3] Михельсон Иван Иванович (1740–1807) – чыгышы белән алманнардан булган хәрби башлык, рус император армиясендә кавалериядән булган генерал. Барыннан да элек Пугачёв восстаниесен бастыру белән билгеле.

йәнирал (аның дөресте полковник)ның гаскәре булса кирәк, аңар барыгыз!» диептер. Шуннан бу егетләр, комрап чабып, Михельсон гаскәренә барып кергәннәр (бу полковник – Казан янында Пугачёвны җиңгән кеше)[1]. Михельсон килеп, хөкүмәт гаскәре Пугачёвны җиңгәч, шул ук Казанның буржуазиясенең аксакалы Ибраһим карт Мәкәрҗәгә дип хәзерләнгән «азык бүләкне крепостька илтеп, төп ишекләреннән солдатларга өләшү» илән. Менә шундый ике яклы сәясәт белән Казан татар сәүдәгәрләре һәм мещаннары (вак буржуазиясе) мал-мөлкәтләрен талана яздырудан саклап калдылар, чөнки бөтен Казан яндырылган чакта сукно фабрикындагы эшчеләр тора торган бистә белән бары Татар бистәсе генә исән калды. Әмма хөкүмәткә яхшы атлы күренү аркасында, хөкүмәт тә Татар бистәсе халкын Пугачёв яклы булдылар дип, җитди гаепли алмады. Татар сәүдәгәрләренең икенче бер оясы булган Оренбург Каргалысында да буржуазия шулай ук икеле сәясәт йөртте. Пугачёв Оренбургны алырга килгәндә, Каргалы халкының күбесе хөкүмәт тарафыннан мобилизовать ителеп, Оренбургка алып килгәннәр иде. Әмма калганнары исә Пугачёвны тантаналы рәвештә каршы алдылар, хәтта бу вакыйганы тасвир кылучы мәнбәгъләре каршы алу мәрасимен «бер патшаны каршылай» шикелле итеп тасвир кылалар: бер мәйданга паласлар җәеп көтеп, соңра Пугачёв үзенең яраннары белән килеп йиткәч, халык олуглап, бөгелеп торып, бары Емельян торырга әмер иткәч кенә торганнар, имеш. Әмма Пугачёв Оренбургны калдырып чыккач, Каргалы бистәсенең халкының күңеле башкарган, Каргалыда калган хатын вә углын алырга китешли кергән Пугачёвның иң булдыклы полковниклардан Хлопуша[2] дигән казакны вә аның юлдашларын тотып хибес итеп[3], базга япканнар, вә хөкүмәткә яхшы булып күренер өчен, аны баулар бәйләп, Оренбургка илтеп тапшырганнар.

Ләкин Оренбургка мобилизовать ителеп алып киленгән вак буржуазиянең хәле башкачарак булган, ул һаман Оренбургта качып торган, шуның өчен Оренбург мөхасарәдә чакта, соңра аларга хөкүмәт кешеләре ышанмас булганнар, хәтта бик күп Каргалы та-

[1] Мондагы сүзләр наширенең кулъязмасыннан алындылар. *(Авт. иск.)*
[2] Хлопуша (чын исеме Афанасий Тимофеевич Соколов; 1714–1774) – Пугачёв восстаниесендә катнашучы, баш күтәрүчеләрнең бер отряды атаманы.
[3] Хибес итеп – кулга алып.

тар гаиләсен ирләре белән каладан да сөргәннәр, сөрелгәннәр исә туп-туры Пугачёв лагерена киткәннәр.

Татарның хезмәт әһеле булса, бөтенләй Пугачёв яклы булган. Мәсәлән, Оренбургта Бохара сәүдәгәрләрендә хезмәтче (работник) булып торган Казан өязенең бер кешесе Пугачёв ягына качып барганда тотылып, тәүкыйф ителгәне[1] мәгълүм.

Пугачёв ягында иң яхшы хәрәкәт кылучылар татар крестьяннары иде. Чынлап та, бөтен крестьяннар милләт вә җенес аермасына карамыйча Пугачёв ягында булдылар. Татар-башкорт фиркаларына рус крестьяны, мәгъдин заводларында эшләүче крестьяннар баш булып йөрсәләр, татар-башкорт хезмәт әһеле рус хезмәт әһеленә командир булып, крепостнойчы хөкүмәт гаскәре белән сугыштылар.

Ук, кылыч, хәтта мылтык, пистоллар[2] [белән] коралланган татар вә башкорт фиркалары граф вә кенәзләренең мәгъдин заводларын талап йөрделәр. Аларны ектылар, яндырдылар. Чөнки бу заводлар һәммәсе дә шул җирле халыкның җир вә урманнарын талап салынганнар иде. Шуларга рус крестьян эшчеләре кушылып, татар вә башкортлар бертуган кардәшләр шикелле көрәштеләр. Хәтта кораллы татар эшче вә крестьяннары коры сугышып кына калмадылар, бәлки алар мәгъдин заводларына вә рус авылларына килеп, Пугачёв файдасына агитация дә ясап йөрделәр. Хәтта хөкүмәт түрәләре боларның бу кадәр оешуларыннан куркып, үзенең хитапнамәләрендә провокацияләр ясап, рус вә татарны аерырга теләп: «Татарлар алар сезне таларга, хатын-кызларны көчләргә телиләр», дип язып торды.

Пугачёв 1774 елда Казанга таба хәрәкәт кылып, аның татар авылларыннан үтүе бер тантаналы йөреш булды. Татарлар аларга казаннар асып, сыйлар хәзерләп көтеп торалар, әмма Пугачёв та, киткәндә, татарларга үз араларыннан башлыклар сайлап калдырадыр иде. Мәнбәгъләрнең әйтүенә күрә, Пугачёвның Казанга килгән гаскәренең күбесе татар, чуваш вә башкортлардан мөрәккәб[3] иде. Бер мәртәбә Пугачёв Казан астында Михельсон тарафыннан җиңелгәч, ул татар арасына кешеләр җибәртеп гаскәр җыйган вә шул вакыттагы аның кул астындагы 25 мең гаскәренең күбесе татар крестьяны булган.

[1] Тәүкыйф ителгәне – кулга алынуы.
[2] Пистоллар – пистолетлар.
[3] Мөрәккәб – оешкан.

Шуны сизеп булса кирәк, Пугачёв килгәнче, хөкүмәт татарларга гыйбрәт булсын вә курыксыннар дип, Казанга китертеп, бер татар крестьянын ихтилалчылыкта гаепләп астырган иде. Бу Михельсон тарафыннан пугачёвчылар тагын җиңелделәр, шунда үлгән ихтилалчылар арасында 2000 татар, авыл кешеләреннән гыйбарәт булган.

Пугачёв җиңелгәч, хөкүмәт татар керстьяны белән бик начар мөгамәлә кылды. Аның гаскәре, фиркалары Конгур тирәсендә ике көн эчендә генә 800 татар йортын яндырды һәм халкын кылычтан кичерде. Хәтта бер авылда бөтен кеше качып, бер сукыр, бер телсез генә калган иде. Хөкүмәт гаскәре аларны: «ихтилалчыларның кайда киткәннәрен яшерәләр, әйтмиләр», дип, аттырып үтерде. Ләкин татар крестьяннары да тиз бирелмәделәр, бер авылга хөкүмәт гаскәре һөҗүм иткәч, татар крестьяннары актык хәлгә кадәр йорт тәрәзәләреннән атып, бик күп гаскәрләрне кырдылар вә җәрәхәтләделәр.

**Нәтиҗә.** Менә шушы тарих азагына саклап калган вакыйгаларын XVIII гасырда сәүдә капиталы үсеп килгән чакта, татар халкының эчендә каты рәвештә сыйнфый көрәш барганын без күрәбез. Билгеле, әле бу вакыйгалар – ул сыйнфый көрәшнең бер кечкенә генә кисәкләре. Тагын архивларда казына торгач, мондый вакыйгаларны бик күп очратачагыбызга әминбез[1].

### 4.4. Сәүдә капиталының хакимияте вә сәнәгать чаткылары

**Татар мирзасы рус дворяны белән хокукта тигезләнде.** Пугачёв явы бик яхшы күрсәтте ки, татар мирзасы чынлап та хөкүмәткә таяныч булган бер гонсыр[2] иде. Шуның өчен ул азмы-күпме калган җир хуҗасы мирзаларның йөз елдан бирле теләп, таләп кылып килгән теләкләренә ирештерергә кирәк иде. Моңарга тагы гомум Русия күләмендәге бер сәбәп вә хөкүмәтне татар мирзасы белән рус дворянын бертигез ясарга мәҗбүр итте. Ул да булса, Екатерина Икенче заманында хөкем сөргән феодал реакциясеңер. Бу заманда Русиядә сәүдә капитализмы хөкем сөргәненә карамыйча, һәрбер нәрсә хаким алпавыт сыйныфы мәнфәгатенә каралып эшләнә башлый. Менә шул эре алпавытка таянган, 1773 елдан бирле диндә

[1] Әминбез – ышанабыз.
[2] Гонсыр – элемент.

тигезлек принцибын игълан кылган Екатерина хөкүмәте, билгеле, татардан кем вә нинди сыйныф тигез булырга дигәндә, татарның эре алпавыт вә аксөякләре, дип җавап бирергә тиеш иде. Элек, 1783 елда, хөкүмәт әгәр мөселманнарыннан «чин ияләре булган кешеләр» (чиновные люди) гаскәри хезмәткә керсәләр, аларга «убер офицер» чинын бирергә (димәк дворян ясарга) диелде, ләкин шунда да әле «премьер майор» дәрәҗәсеннән югары чин бирергә кирәк булса, императрицаның үзеннән рөхсәт сорарга, диелде.

Ләкин 1787 елда яңа указ чыгып, хөкүмәткә хезмәт иткән данлыклы вә аксөяк нәселеннән килә торган яисә шәхси яхшы хезмәтләр күрсәткән мөселман динендәге кешеләрне рус дворянствосы белән бертигез ясарга вә аларга бер дә алынмый торган имтиязлар[1] бирергә, диелде. Ләкин никадәр бу халык яңа хокуклар алмасыннар, икътисади терәкләре беткән, ахыргы чиккә килеп җиткәннәр иде. Алда без Казан наместниклыгында, татар алпавыты кулында, 1781 елда бары 555 дворовый татар калганлыгын күрдек. Соңыннан аның саны бик тиз кими башлап, 1838 елда мирза оясы булган Пенза губернасында 945 мирзага бары 4 данә дворовый калган, 1842 елда Рязань губернасында (Касыйм шәһәре шуңарга керә) 4145 татарның бары 66 крепостное булганын күрәбез.

**Мирза вә йомышлыларның купецка чыгулары.** Сәүдәнең үсүе һәрхәлдә феодал калдыгы йомышлы татарларның купецлыкка чыгуларын күбәйтә башлады. Мирза вә йомышлыларга дворянлык хокукы ачылса да, хезмәт күрсәткән өчен зур чиннар алу мөмкин булса да, XVIII гасырның ахырында вә XIX гасырның башында татарларның берничә гаилә берләшеп яисә берән-берән купецлыкка чыгуларын капитал игълан кылып (чөнки купецлык өч дәрәҗәгә бүленеп, һәрбер гильдиягә бер мәгълүм микъдар капитал тәгаен кылынган иде)[2], Сенатка прошение биреп, эшне әйләндереп чыгарганнарын, шулай итеп, купец булганлыкларын күрәбез. Мәсәлән, 1800 елда йомышлылардан Казанда 8 гаилә – икенче гильдиягә, 27 гаилә өченче гильдиягә 1799 елда Сенатка бирелгән гаризалары буенча чыктылар. Боларның барысы 140 җан булып, игълан

[1] Имтиязлар – ташламалар.
[2] Беренче гильдия булу өчен капитал ун меңнән ким булмаска, икенче гильдия өчен капитал мең сумнан ким булмаска, өченче гильдия булу өчен 500 сумнан ким булмаска тиеш иде. *(Авт. иск.)*

кылган капиталлары 37 100 сум иде. Билгеле, сәүдәгәрләр азрак процент түләү өчен капиталларын аз күрсәткәнгә, бу капитал, билгеле, хакыйкатькә ерак вә аз булган булыр. Чөнки һәрбер купец бу заманда капиталыннан 4% ел саен хәзинәгә түләргә тиеш булган. Без мәнбәгъләрдә берәмләп купецлыкка чыгучыларны да бик күп очратабыз, шуңарга күрә шушы бер мисал белән канәгатьләнәбез.

Купецларның саны вә аларның рәсми капиталлары XIX гасырның башыннан алып шушы йомышлы вә мирзаларның купецлыкка чыгулары, ясаклыларның да кайсысының баеп китүләре аркасында, купец сыйныфының да саны шактыйга чыкты. Казан татар ратушасының хисабы буенча, биш ел эчендә купецларның саны вә аларның үзләренең налог өчен күрсәтүләре буенча капиталлары шулай күренә: 1800 елдан алып 1807 елга кадәр беренче гильдия купецлар юк, ләкин 1800 елда икенче гильдия 8 гаилә – 30 җан, аларның капиталы 20056 сум, 1800 елда өченче гильдия 23 гаилә – 94 җан, аларның капиталы 14503 сум.

1800 елда бөтен Казан купецларының саны 31 гаилә – 126 җан, аларның капиталы 34559 сум. 1801 елда Маннапов дигән бер мирза гаиләсе купецның язылуы аркасында татар купецларының саны 191 җанга җитеп, аларның капиталы да 37704 сумга баса. Димәк, Казан купецларының капиталы бер ел эчендә 3145 сумга арта.

1802 елда икенче гильдия купец 8 гаилә – 32 җан, аларның капиталлары 20671 сум. 1802 елда өченче гильдия купец 108 җан, аларның капиталы 21554.

1802 елда купецлар 148 җан, аларның капиталы 42225 сум. Димәк, бер ел эчендә Казан купецларының капиталлары 4521 сум арта, моның сәбәбе 4 гаилә йомышлының купецка чыгуы була.

1803 елда бөтен купецларның саны 129 җанга гына кала, әмма 1804 елда исә тагы артып, 132 җанга җитә, 1805 елда тагы купецларның саны артып китә дә 176 җанга җитә һәм капиталлары да 56841 сум була.

1807 елда исә без 3 гаилә – 6 җан беренче гильдия купец күрәбез, икенче исә 58 җан, әмма өченче гильдия 95 җан була. Бу аз гына материаллардан күренә ки, Казанда купецларның саны артканнан арта, ләкин боларның капиталы аз шикелле күренә, әмма бу рәсми кәгазьдәге капиталның бик күпкә ким булганы мәгълүм бер мәсьәлә.

Бераз яңарак заманга китеп булса да, тагы татар купецларының саннарын карап алыйк. Мәсәлән, Вятка губернасында, 1842 ел мәгълүматы буенча, бөтен купец (һәр милләттән) 1575 җан булып, шуның мөселманы 126 җан (ир вә хатын), әмма Рязань губернасында шул ук заманда 238 җан (ир вә хатын) мөселман татар купецы бар. Әмма 1770 елларда Каргалыда гына татарлардан 1820 купец бар. Табигый, бу мөтәфәррикъ[1] саннар безгә күп нәрсә ачып бирмиләр, һәрхәлдә алар безгә татарда XIX гасырның башында сәүдә капиталының чынлап та хакимият сөргәнен күрсәтәләр.

Ләкин татарның сәүдәгәр сыйныфы бер купецтан гына тормый, бер сословиедән икенчесенә күчүнең никадәр мәшәкатьле вә читен икәнен без күрдек. Шуның өчен XIX гасырның башында һаман да теге «йомышлы сәүдәгәр татар» дигән бер сословие исән, ләкин бу феодализм калдыгы сыйныф акрынлап кимеп бара. Менә түбәндәге цифрлардан ул бик яхшы күренәчәк:

1800 елда Казанда алар 86 җан;
1801 елда Казанда алар 88 җан;
1802 елда Казанда алар 74 җан;
1803 елда Казанда алар 71 җан;
1804 елда Казанда алар 62 җан;
1807 елда Казанда алар 65 җан.

Алдагы цифр безне бераз гаҗәпләндерсә дә, һәрхәлдә без аларның санының кимегәнен уртадагы биш юлдан бик яхшы күрәбез. Бер-ике кешенең артуы, гаиләдә бала туып китүе, авылдан Казанга килү шикелле, кешеләрдән бу йомышлы татарларның саны кайсы елда артып китүе бик мөмкин.

**Татар ратушасының ясалуы.** Димәк, Казан нәкъ Каргалы шикелле татар сәүдәгәрләренең мәркәзе булып китте. Хөкүмәт тә Казан белән кушылган иске вә яңа бистәләрне аерым бер шәһәр итеп санап, башка вак шәһәрләргә бирелгән «самоуправление»не бирергә уйлады. Шуның өчен Казан губернасы бетерелеп, аның урынына 13 өяздән гыйбарәт булган «наместничество» ясалганның икенче елында, димәк, 1782 елда, татарлар «Ратуша» атап йөрткән, әмма рәсми кәгазьләрдә «Казанская татарская Ратуша обеих слобод» аталган бер мәхкәмә вә аның янында шул ук бистә татарларына махсус Сиротский

[1] Мөтәфәррикъ – төрле.

суд ачылды. Боларның вазифалары бик киң, заманасына күрә зур иде: 1) бу Ратуша бистәләрдәге купец вә мещаннарны (ягъни суммалары[1] биш йөз сумнан ким булган вак буржуа) идарә кыла; 2) алардан алына торган салымнарны җыеп, казенный палатага тапшыра; 3) аларның гаскәрилек эшләрен карап тора; 4) алар арасында чыккан гражданский – милли хөкемнәрне кыла (уезный суд белән уртак мәҗлестә); 5) сугыш вакытларында төшкән налоглар вә милиция[2] чыгу эшләрен карый (билгеле купец, мещаннан); 6) казый сайлау эшендә иштиракь кылып, шуның мәҗлесләрен җыя; 7) сиротский суд белән бергә үлгән кешенең малын бүлә; 8) бай банкорт булса, конкурс тәгаен кыла, вексель буенча акча алу мәсьәләсен хөкем итеп хәл кылган эшне полициягә тапшыра; 9) җирле хөкүмәтнең тапшыруы белән татарларга гаид булган башка кешеләрне карый; 10) сәүдәгәрләргә паспорт бирә.

1793 елга кадәр бу мәхкәмә сайланган ике бург[о]мистр (шәһәр башлыгы дигән мәгънәдә) һәм ике ратман (киңәшчесе)нан гыйбарәт бер коллегия (һәйәт) тарафыннан идарә кылынып килгән.

Бөтен мәсарифын[3] шул мәхкәмәгә буйсынган кешеләр биреп барганнар. Ләкин 1793 елда татарда күп вакытта булгалап килгәне төсле 201 кеше гариза биреп: «Без моны тәэмин итмибез, гади хөкүмәт мәхкәмәсенә (уездный судка) буйсынабыз», – дигәч, бу хәбәр Сенатка ирешкәч, Сенат указ чыгарып: «Бары теләгән вә аны тәэмин итешүдә иштиракь кылынган[4] кешеләр генә Ратушага табигъ[5] булырлар», дигәч, җәмгыять эшенә азмы-күпме игътибар иткән 61 буржуа табылып, шуңарга буйсынып, тәэмин итеп алып барганнар, соңра бара-тора башкалары да Ратушага керә башлаганнар. Бу мәхкәмә күп еллар торып, Александр Икенче заманында, шәһәрләрнең идарәсен[ә] реформа чагында гына беткән. Ратуша һәм Сиротский судта эш йөртү рус телендә булып, бары ратман һәм бург[о]мистрлар гына татарча кул куйганнар. Ләкин русча белүчеләре русча кул куеп барганнар.

[1] Суммалары – милекләре.
[2] Милиция – сугыш вакытында чакырыла торган ополчение отрядлары. Урта гасырларда шәһәрләрне саклауда мөһим роль уйнаган, кайвакыт үзара булган сугышларда да катнашкан.
[3] Мәсарифын – чыгымнарын.
[4] Иштиракь кылынган – булышкан.
[5] Табигъ булырлар – бәйле булырлар.

Мәҗлесләрендә эшләнелгән эшләрне протокол итеп язып барып, аны гадәттәгечә «журнал» дип атаганнар, һәрбер еллык протокол вә эшләрне төпләтеп куя торган булып, гомумән, эшләрен бик яхшы йөрткәннәр.

Бу мәхкәмә шулай күп эшли, мөһим бер мөәссәсә[1] булса да, ул, аерым кешеләр тарафыннан хөсне ихтыяр белән тәэмин ителгәнгә, зур түгел иде, аның бер писаре, секретаре, бер язу йөртүчесе, бер сторожы булып, 1810 елларга кадәр хәзерге Печән базары чатындагы «Җамали кәрчүнлеге» (көфер почмагының каршысындагы) дип, мәгълүм бинаның бер бүлмәсендә булып, бөтен еллык расходы да 1807 елларда 1615 сум чамаларында буладыр иде.

**Татарларда кредит мәсьәләсе.** Татар арасында сәүдәнең үсүе, кредит мәсьәләсе бу мөәссәсәне бер кирәкле мәхкәмә итеп танытты.

XVIII гасырның ахырыннан башлап татар кредит белән файдалана. Ләкин бу заманада әле банкалар яңа гына ясала башлап, Казан, Уфа, Оренбург вә Каргалы шикелле җирләрдә аерым кешеләргә кредит бирүче бер генә дә банка юклыктан, татарлар сәүдә өчен процент белән акчаны рустан (күбрәк рус купецы вә алпавытлары) һәм бер-берсеннән алып торалар иде. Шулай ук татарлар сәүдә кылганда малны һаман акчага гына алмый, әмма бик күп кисәген көтәчәккә алалар иде.

XIX гасырның беренче елларында Урта Азиядән мал алып кайтып килгәндә кыргызлар тарафыннан таланган вә үтерелгән сәүдәгәр Гобәйдулла Ишморатовның 12 кешегә вексель буенча 26793 сум бирәчәге калды. Кредиторларның күбесе – Казан сәүдәгәрләре, руслар һәм бохаралылар да бар. Егерме меңнән артык малы талангач та, аның, Әстерханга килеп җитеп, кредиторларга өләшкән малы гына ул заман акчасы белән 15925 сумлык булган.

1800 елда банкрот булган сәүдәгәрләр йомышлы татар Рәхмәтуллинның 10 кешегә бирелгән вексельләре буенча 5386 сум бирәчәге бар. Шул ук елда Ибраһим Исмәгыйлев дигән Казан купецының бирәчәге иске вексель буенча 12497 сумлык. 1795 ел хөкем эшеннән мәгълүм булдыгына күрә, Йосып һәм Габдессәлам Рәхмәтуллиннарның 7900 сумлык вексельле бирәчәкләре калган. 1803 елда Исмәгыйль Галанский дигән кеше була. Моның 2100 сумлык бирәчәге кала.

[1] Мөәссәсә – оешма.

Шунысы кызык ки, XIX гасырның башында бу сәүдә эше һәм кредит мәсьәләсендә мөселман руханилары да катышып китәләр. Мәсәлән, 1803 ел Сиротский судның язуларына караганда, Казан ахуны Әбүбәкер Ибраһимов үлгәч, 9422 сум 16 ярым тиенлек малы калып, шуның эченә 1750 сумлык алынуы шөбһәле булган вексельләр кала.

**Эре сәүдә һәм чит илләр белән сәүдә.** XVIII гасырның башында башланган эре сәүдә ул гасырның ахырында һәм XIX гасырның башында тагы да көчәеп китте. Боларның бу сәүдәләре һаман да шул тире-яры, җәнлек тиресе, җабага, җал, бал вә балавыз булып калды. Татарлар бу малны төрле ярмаркаларга барып җыялар, Мәкәрҗәгә алып барып, тагы да эре кулларга вә яурупалыларга саталар иде. Хәзерге көндә Башкортстан тынычлаганлыктан, хөкүмәт тә Башкортстанга татарларны туктаусыз җибәрә башлады.

Башкорт кузгалышлары заманында, бигрәк тә 1750 елларда, татар сәүдәгәрләрен Башкортстанга бик читенлек вә аерым таныклыклар белән генә кертәләр, аларның халыкны котыртуларыннан куркалар иде, әмма хәзер бу читенлекләр һәммәсе бетерелде. Шулай итеп, Башкортстан вә Татарстан татар сәүдәгәрләренең базарына әйләнеп китте. Шул ук чакта сәүдәгәрләр Урта Азия вә Кыргызстан белән сәүдәне дә көчәйтеп җибәрделәр. Хәтта бу заманда татар сәүдәгәрләре бохаралылар белән кредитка вә сату итә торган булдылар. Мәсәлән, алда исеме әйтелгән Ишморатовның бер Бохара сәүдәгәре Хәсәновка 4500 сум бирәчәге бар иде. Татарлар Бохарадан мерлушка (каракүл) китерәләр, анда исә рус вә Яурупа малларын илтәләр иде. Шулай ук татарларның комач фабрикаларына XIX гасырның башында мамык, мамык җебе һәм миткаль[1] Бохарадан киләдер иде.

Мәсәлән, 1803 елда Мәхмүд Маматов дигән бер татар фабрикантына бер татар сәүдәгәре шундый малларны Бохарадан алып кайтканы мәгълүм. Билгеле, мәнбәгъләрдә мондый фактлар күп, без аны бу урында китереп, укытучының башын чуалтырга теләмибез.

Бу заманда татарларның Кытай чикеше[2] Кяхта шәһәренә үз заводларында эшләнә торган кәҗүлләрен[3] алып барып, Кытай

[1] Миткаль – эшкәртелеп бетмәгән, шуның нигезендә ситсы, муслин һәм башка шундый тукымалар эшләнә торган тупасрак юка киҗе-мамык материал.

[2] Чикеше – бередә: чигендәге.

[3] Кәҗүлләрен – эшкәртелгән кәҗә тиреләрен.

малларына алмаштыралар иде. Гомумән, бу заманда, 1840 елларга кадәр, рус вә татарларда Кяхтага кәҗүл, мөгез алып бару вә аннан чәй вә башка Кытай маллары алып кайту тәрәккый иткән бер эш иде.

Менә татар заводчылары да шул эш белән шөгыльләнәләр. Бу хакта Казан Татар ратушасы протоколларында 1807 елга даир[1] бер мәгълүмат сакланып калган. Протокол буенча, Казанның икенче гильдия купецы Мөхәммәд Габбасов Кяхтага кәҗүл алып барып, Кытай малларына алыштырган (чәй морад[2] булса кирәк) хакта таможняга пошлина өчен биш мең бирәсе калып, шул акчаны ул хөкүмәттән кичектереп алуны сорый, һәм бу эшкә кәфил булып[3], Казанның беренче гильдия купецы Йосыф Бикбов, икенче гильдия купецы Муса Юнысов кул куялар һәм кәфаләт[4] итеп 40, 160 сум акча игълан кылалар. Бу акчаның тәүмәле[5] Кытай белән булган эшнең нинди зур булганын күрсәтсә кирәк.

**Сәнәгать[6] чаткысы вә ялланган эшчеләр.** Әле генә без татарларда сәнәгать зоһур иткәнен күреп уздык. Моннан элек тә, Пугачёв явы заманында, хөкүмәт рәсми итеп таныган Кишет авылында фабрикант Йосыпов дигән кешенең барлыгын да күрдек. Шулай ук 1767 елдагы Екатерина җыйган закон чыгару комиссиясендәге кузгалган сүзләрдән үк без татарлар кулында Татарстанда вә Башкорстанда шәм, сабын, поташ[7], май кайната торган, хәтта текстиль нәрсәләр ясый, суга, буйый торган сәнәгать йортларының барлыгын, комиссиядәге купец вә завод-фабрикаларының бу эшкә эчләре пошуларыннан, бу эштә зур конкуренция күрүләреннән, без бу эшләрнең бик вак булмаганлыгын да беләбез. Билгеле, боларны хәзерге заман промышленносте белән чагыштырырга ярамый, хәзергә нисбәттән болар эрерәк кустарь йортлары, мануфактуралар иде. Ләкин шулай да болар рус алпавытлары кулындагылар төсле

[1] Даир – караган.
[2] Морад – максат.
[3] Кәфил булып – җаваплылыкны үз өстенә алучы булып.
[4] Кәфаләт – залог.
[5] Тәүмәле – биредә: күләме.
[6] Сәнәгать – промышленность.
[7] Поташ – калий карбонаты.

ирексез крестьян (посессионный[1] яисә принципиаль) тарафыннан эшләнмиләр, бәлки татар сәнәгать йортларында ялланган татар эшчеләре эшлиләр иде. Моны исбат кылу көчен башка мәнбәгъләр булса да, безгә моны күрер өчен 1783 елда гына Замещерскийның кенәз Вяземскийга язган хатының шушы бер-ике сәтырын[2] алсак: «Казан вилаяте, Арча Мулла иле авылының йомышлы татары Халид Сөбханколов Казан Яңа бистәсенең Мортаза Рахманкулов дигән татарның күн заводында ялланып хезмәт итте». «В работе по найму[3]» диләр. Димәк, ярлыланган йомышлы татар гади бае татарга хезмәткә кергән. Табигый, бу кеше – җир азлыктан, салым түләргә акча кирәк булганга, хезмәткә Казанга килгән кеше.

XVIII гасырның соңында, XIX йөзнең башында бу сәнәгать чаткысы тагы үсә башлады, Казан Татар ратушасы протоколларыннан күрелгәнчә, Казанда татарлар кулында 1800 елда 9 сабын заводы бар, шуның барысы купецлар кулында, берсе генә кенәз Зановныкы, шуларның икесе хатын кешеләрнеке, янә 4 кәзүл заводы бар, янә 10 данә күн заводы бар. Шуның берсе Миһербану Мортазинаныкы, гомумән, Казан губернасы үзенең сәнәгать йортларына караганда бөтен Русиядә 1814 елда алтынчы урында тора. Мәскәүдә боларның саны 539 булса, Казан губернасында 148 завод вә фабрик бар. Эшчеләрнең саны ягыннан Казан губернасы Русиядә 13 нче урында тора. (Мәскәү вилаятендә 42307 кеше) Казан губернасында 3982 кеше. Иң күп сәнәгать йортларының булган җире – Казан үзе (62,84%). Казан губернасындагы эшчеләрнең ялланып эшли торганнары – 2095, яисә бөтен эшченең 52,61%. Калган эшчеләр – рус алпавыт сәнәгатьчеләр кулындагы ирексез крестьяннар. Сәнәгать – Казан губернасында, әсаси[4], сабын вә күн эшләр.

Казан губернасында 89 күн заводы булып, бу яктан губерна 5 нче урында тора, шунда 910 хезмәтче, һәрбер заводка 10,2 эшче төшә. Бу заводлар 1814 елда 333719 данә төрле сорт күн эшлиләр (шуннан иң күп эшләнгәне кәҗүл – 234030 данә эшләнә). Менә шушы

[1] Посессионный крестьяннар – Россия империясендә XVIII–XIX гасырның беренче яртысында посессион мануфактураларга беркетелгән крепостной крестьяннар категориясе.

[2] Сәтырын – юлын.

[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[4] Әсаси – бередә: нигездә.

күн заводларының иң зурлары вә иң күп эшче булганы (яллаган эшче) татарларныкы (Муса Апанаев, Якуб Габбасов, Салих Аитов, Хәбибулла Яхин, Мостафа Аитов, Габбас Беляевныкы. Шуннан кала бары ике рус заводы бар). Моннан кала 1814 елда Казан губернасында иң мөһим сәнәгать – сабын заводлары. Аларның саны 24 булып, шушы елда барысында 133260 пот сабын эшләнгән. Бу микъдар бөтен Русиядә эшләнә торган сабынның 46% ын кәсеп итә. Шушы 24 заводның 13е татарларныкы: Габидә Китәеваның заводы бу елда – 10000 пот, Исай Замановның – 10000 пот, купец Габделкәрим Юнысовның – 9000 пот, Муса Адәмовның – 8000 пот, Якуб Шатуновның 8000 пот эшләгәне мәгълүм.

Казан губернасында XIX гасырның башында тагын бер мөһим сәнәгать булса, ул да – мамык материаллар ясый торган фабриклардыр. Боларның хуҗалары һәм эшчеләре барысы да татарлар, губернада 9 фабрик эшли. 319 станок, 592 эшче. Шуның дүртесе Казан өязендәге татарлар кулында, әмма биш завод Чар өязендә[1] Байлар русы дигән татар авылында.

Бу Оры[2] авылындагы татар фабриклары һәммәсе Хуҗасәедовлар фамилиясенең Муса, Мостафа, Сөләйман, Мәхмүд, Мөхмихә исемлеләрнеке иделәр. Казанның үзендә булган дүрт текстиль фабриклары да Баязитов, Борнаев, Биритов, Абдулов дигән татарлар кулында иделәр. Болар күбрәк комач эшлиләр, 1814 елда бу фабриклардан 609800 аршин мал чыкты. Әгәр бу елда бөтен Русиядә комач 809800 аршын эшләнгәнен хәтергә алсак, татар текстиль сәнәгате никадәр әһәмиятле булганын күрербез. Димәк, 1814 елда бөтен Русиядә [комачның] 72,2 процентын татар фабриклары эшлидер иде.

Моннан башка тагы татар кулында поташ заводлары да бар иде. Бу сәнәгать күбрәк алпавыт эше булса да, татарлар рус алпавытларыннан җир арендага алып эшлиләр иде. Мәсәлән, Уфа губернасында Бәләбәй өязендә Гобәйдулла Максудов һәм Казан купецы Сөеровның бер поташ заводы булганы мәгълүм. 1814 елда Казан губернасында бердәнбер язу кәгазе фабригы булып, ул да татар фабриканты Мөэмин Хуҗаидов (Хозаитов) кулында иде. Бу фабрик

[1] Чар өязендә – Царёвококшайск өязендә.
[2] Чыганакта ялгыш «Коры» дип бирелгән.

Чар өязендә булып, ел саен 6000 ступ чыгара, шуның 400 ступасы язу кәгазе, 2000 ступасы нәрсә төрә торган иде.

Димәк, XIX гасырның башында инде татарларда сәнәгать чаткысы туган иде. Җирнең азлыгы, начарлыгы вә бездә крепостнойлыкның акрынлап кына башлавы эшче дә табып биргән. Әмма һаман да чын пролетарий тумаган, татарларда әле сәнәгать капитализмына ирешмәгән иделәр. Ләкин татарлар тизлек белән тәрәккыйга баралар, әмма бөтен Русия күләмендәге сәбәпләр, боларның алга бара торган тарих арбалары көпчәкләренә 60 нчы елларда таяк тыкты.

**Матбагачалык сәнәгате[1] вә китап базары.** Югарыда без Пугачёв хәрәкәтеннән берничә генә ай элек дин ирекге күк нәрсә бирелгәнен сөйләп узган идек, шул ук чакларда мәдрәсәләр ачарга да ирек бирелде. Бу сәясәтнең үзгәрүендә, бер дә шиксез, Русиянең Шәрык белән сәүдә мөнәсәбәтенең артуы вә Русиядәге мөселман халыкларына дин ирекге биреп, [шуның] аркасында кыргыз вә Урта Азия халыкларына яхшы күренү булды. Шуның өчен бөтен Русия мөселманнары өчен 1789 елда Уфада Мәхкәмәи Шәргыя ачылып[2], хөкүмәт Мөхәммәдҗан Хөсәенов шикелле искедән бирле Русиянең Шәрыкка тәҗавезенә[3] хезмәт итеп килгән агентны мөфти итеп куйды. Сайланган казыйларга да жалование куеп, муллаларны аларның башлыклары аркылы чиновник ясап, бөтен татарларны шул чиновник муллаларның контроленә бирде. Хәтта 1797 елда хөкүмәт 3600 Коръән бастырып, мөселманнар эчендә тараттыра башлады.

1782 еллардан алып кыргызларга мәчет вә мәдрәсәләр салдырта башлады вә 1785 елда бу хакта бер түрәгә язган хатында Екатерина бу эшләрнең ачыктан-ачык икътисади вә сәяси максат белән эшләнгәнен белдереп әйтте: «Видев из донесения вашего, что построение для подданных наших магометанского закона мечети в Троицкой и в Оренбурге открыты, не сомневаемся, что такое сооружение мест публичной молитвы привлечет и прочих в близости кочующих и обитающих к границам нашим»[4]. Табигый, бу халыклар белән сәүдә иң зур галәкаче булган[5] татарның буржуазиясенең дә

[1] Сәнәгате – индустриясе.
[2] Бу хакта фәрман 1788 елда чыкты. *(Авт. иск.)*
[3] Тәҗавезенә – басып керүенә.
[4] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[5] Галәкаче булган – бәйләп торучы булган.

күңелен табарга кирәк иде. Чөнки бу Шәрык чигендәге Русиянең сәүдәсе бер уен түгел, бәлки зур нәрсә булганын шушы цифр[а]лардан күреп була: Оренбург таможнясында 1768 елдан алып 1772 елга кадәр Шәрык илләреннән керелгән малның микъдары 1114883 сумлык булып, Русиядән чыкканы 978376 сумлык иде. Шуннан хәзинәгә бөтенләй килер 283315 сум тәшкил итәдер иде. Тагын шундый ук зур сәүдә вә доход Троицк таможнясыннан да киләдер иде. Шулай итеп, һәр яктан Шәрык халыклар[ын] вә татарның сәүдәгәр һәм аның идеология булган мулласын вә шулар аркылы халыкны кулда тотарга һәм бераз юатырга кирәк булды.

Татар буржуасы үзенең алыш-биреше күбрәк кыргыз, үзбәк вә таҗик белән булгач, болар белән эш кылу өчен вә алар төсле үк диндар вә аларның югарыгы сыйныфлары белгән нәрсәне белергә кирәк булгач, мәдрәсәләр дә ачтылар, шул мәдрәсәләрдә бу җирләрнең әдәби теле булган чыгтай телендәге китапларны вә ул җирләрдә бик мөстәгъмәл булган[1] фарс[ы] телен укыта башладылар, хәтта XIX гасырның башында Әфәнде хәзрәт дигән бер кеше татарларга шул Урта Азия киемнәрен киертү юлында бик күп эшләр кылды. Шуның өчен бездә чын-чыннан феодализм идеологиясе булган схоластика фикере сәүдә капиталы дәверендә торган татарларга керде. Чөнки бу система укытуны («ысулы кадимә») шул сәүдә капиталы үзе таләп кылды вә үзе чакырып китерде. Казан вә әтрафы тәгълим рәвешен вә аның әсасы булган мәфкирәсен (идеологиясен) өйрәтүче мәдрәсәләр белән тулды (бу мәдрәсәләр исә соңра татарның мәдәниятен ясашуда зур хезмәт күрсәттеләр). Башта бу мәдрәсәләр өчен китапларны сәүдәгәрләр вә укырга киткән шәкертләр аркылы татарлар феодаль Бохарадан китереп тордылар. Ләкин татарның сәүдә капиталы ияләре бу китап дигән «товар»ның да «кәсеп» өчен әһәмиятен аңладылар.

Нитәкки[2] ул уйлар да аерым шәхесләр тарафыннан сугылган, буялган комачны күпләп сугу вә буяуның файдасын сизеп, фабрика-мануфактуралар ясый башлаган иде, шуның шикелле үк, ул «матбага» дигән нәрсәдә бу китапны эшли башласаң, Бохара вә Сәмәркандның үзенә шул ук китапларны алып барып сатып кәсеп итәргә мөмкинлекне сизеп алды. 1799 елларда Казан, Оренбург вә

[1] Мөстәгъмәл булган – кулланылган.
[1] Нитәкки – шунлыктан.

башка җирләрнең татарлары (табигый, мондый эш белән шөгыльләнергә форсат тапкан сыйныф) хөкүмәткә дин китаплары бастыруга рөхсәт итүне сорап мөрәҗәгать иттеләр. Либералланып азаплана торган Александр Беренченең хөкүмәте дә цензур кую шарты белән рөхсәт итте вә Петербургта ясалган «Шәрык» матбагасын Казанга, беренче гимназия хозурына күчерергә әмер итте. Хөкүмәт татар теленең Шәрыктагы әһәмиятен аңлап, 1767 елдагы указы белән бу гимназиядә татар теле укыттыра башлаган иде.

Димәк, 1800 елның 15 декабрендәге Сенатның указы белән Казан Шәрык телләрендә китаплар баса торган матбагалы булды. Гимназиянең идарәсе отставной прапорщик Габделгазиз Бурнашевка бу эшне тапшырып, татарча, фарсыча вә гарәпчә дин китаплары басар өчен шартнамә дә ясады. Цензура да табылды, бу эшкә Габдерразаков дигән кеше тәгаен кылынды. Бурнашев өч ел эчендә шулкадәр китап басты: 1) 11000 данә «Иман шарты»[1]; 2) 1200 – «Пиргали китабы»[2]; 3) 3000 – «Фәүзән-нәҗат»[3]; 4) 3000 – «Сөбат әл-гаҗизин»[4]; 5) 300 «Өстевани китабы»[5]; 6) 2000 данә – бөтен Коръән; 7) 1000 данә – парәле Коръән.

---

[2] «Иман шарты» – мәдрәсәдә укучылар өчен беренче уку әсбабы, гади догалар китабы.

[2] «Пиргали китабы» – XVI йөз госманлы галиме Биргиви Мөхәммәд (Такый әд-Дин Мөхәммәд ибне Пир Гали әл-Биргави; якынча 1535–1573) әфәнденең иман нигезләрен, гыйбадәт һәм әхлак мәсьәләләрен яктыртуга багышланган, гадәттә, «Биргиви васыятьнамәсе» һәм «Биргиви рисаләсе» исемнәре белән мәгълүм хезмәте.

[3] «Фәүзән-нәҗат» («Котылу шатлыгы») – XVIII йөзнең соңгы чирегендә язылган дини-дидактик әсәр. ӘбүГали Мискавейхның (932/36–1030) гарәп телендә язылган хезмәтенең фарсы, аннан соң татар теленә иреклe тәрҗемәсе. Әсәрдә ислам дине тарафыннан рөхсәт ителгән яисә тыелган төп нигезләр, әдәп һәм әхлак кагыйдәләре һ. б. кыскача бәян ителә.

[4] «Сөбат әл-гаҗизин» («Гаҗизләр терәге») – суфичыл әдәбият үрнәге булган әсәр. Автор тормыштагы кыенлыкларны, авырлыкларны олы сабырлык белән каршы алырга һәм түземле булырга өнди. Максаты – Мөхәммәд пәйгамбәрне үрнәк итеп куеп, сүз сәнгате ярдәмендә укучыларда югары әхлак тәрбияләү. Авторы – Аллаһияр Суфи (Аллаяр, 1616, яки 1630–1713, яки 1723) Бохара шәһәрендә яшәп, төрки һәм фарсы телләрендә иҗат иткән суфи шагыйрь. Ата-бабаларының төп чыгышы Идел буеннан дип уйланыла.

[5] «Өстевани рисаләсе» – Иман һәм ислам дине шартларын тикшерүгә багышланган хезмәт. 1608–1661 елларда яшәгән госманлы галиме һәм вәгазьчесе Өстевани Мөхәммәд (Мөхәммәд бине Әхмәд бине Мөхәммәд әш-Шами әл-Өстевани) әфәндегә нисбәт ителә.

Озакламый Бурнашев һәм Габдерразаков яңа товар белән сату итүне арттыру, китапны һәм Иранга, вә Урта Азиядәге шәфигый мәзһәбендәге кешеләргә сату нияте белән, «Фәүзән-нәҗат» китабын баскан чакта, ахырына шигыйларны мактаганрак бер әсәр арттырып бастылар. Бу хакта, табигый, бөтен эшләре мәзһәб сугышы булган, башка сәяси эшләре булмаган бохаралылыр шикелле хилафәт[1] дәверендәге сәяси, иҗтимагый көрәш нәтиҗәсе булып туган мәзһәбләр, көрәш белән курчак уйнаган муллалар тавыш куптардылар. Эш Мәхкәмәи Шәргыя хөкемендә 8 ел йөрде. Нашир дә, цензор да хөкемгә бирелделәр, ләкин китап басу эше үлмәде, әлеге Сәгыйд углы Ибраһим Хәлфин (гимназиядә татар теле мөгаллиме һәм беренче зыялы (Яурупадагы мәгънәсе белән)) цензор булды. Нәшрият эше Казан купецы Йосыф Апанаевка тапшырылды. 1806 елда бу нашир шушы китапларны басты:

1) 19000 данә «Иман шарты»; 2) 3000 «Һәфтияк»[2] 3) 1000 данә «Пиргали китабы»; 4) 1200 «Өстевани»; 5) 1200 данә «Сөбат әл-гаҗизин»; 6) 1500 бөтен Коръән. Бу нашир заманында иң күп басылган нәрсә Коръән булды. Ул зур кулда басылып, иң күп сатылган җире Мәкәрҗә ярмаркасында һәм бәһасе дә 25 сум булган.

Менә, шулай итеп, XIX гасырның башында тагы бер сәнәгать артты.

*Г. Газиз*

[1] Хилафәт — хәлифәлек.
[2] «Һәфтияк» – аерым китап рәвешендә, кечкенә форматта төпләнеп йөртелгән Коръәннең җидедән бер өлеше.

# НАСЫЙРИ КУЛЪЯЗМАЛАРЫНЫҢ ГЫЙЛЬМИ КЫЙММӘТЛӘРЕ ТУРЫНДА

I

Казан университетының фундаменталь көтепханәсенә мәгълүм мөстәшрикъ вә заманында цензор булып торган профессор Готвальд[1] һәдия итеп[2] калдырган кулъязма Шәрык вә Гареб әсәрләре эчендә Насыйриның дүрт кулъязма әсәре сакланып калган[3], бу әсәрләрнең күбрәк кәгазьләренең кырыйлары янган. Шуның өчен әсәрләрнең Насыйрида булган зур ут казасыннан алда язылган булуы ихтимал. Бу кулъязмаларының ничек итеп Готвальд кулына кергәннәр икәненә даир[4] бер мәгълүмат юк. Ләкин бу әсәрләрнең басарга хәзерләнгән булуларына, матур, ачык язу белән язылган булуларына караганда, аларның цензорга карарга бирелеп тә, сәяси бер сәбәптән басылмый, Готвальд кулында калган булулары бик ихтимал. Ләкин Готвальд цензор булса да, соңгы цензорлар шикелле татар галәменнән ерак торган, якын килсә дә, шымчылык өчен бәгъзы провокаторлар белән генә аралашкан кеше булмаган. Ул – заманында татар язучылары вә галимнәре белән гыйльми сохбәтләрдә булып торган бер галим. Мәсәлән, Готвальд Мәрҗани белән дә бик сохбәт итә вә аралашырга ярата торган булган. Шуның өчен кулъязмаларны Готвальд карап чыгып та, бәгъзы сәяси «зарарлы» фикерләр тапкач, кулында көчләп саклап калдырган дип әйтеп булмый. Бәлки

[1] Готвальд Иосиф Фёдорович (1813–1897) – шәркыятчы, ориенталист-галим.
[2] Һәдия итеп – бүләк итеп.
[3] Әлеге кулъязмалар Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә 1341 т. номеры белән саклана.
[4] Даир – караган.

берничә мәртәбә ут казасына очраган Каюм абзый Готвальдка үзе сакларга биргәндер дип уйлана.

Беренче вә иң мөһим булган кулъязма 32 кәгазьдә булып, аның тышына нашире каләме белән «Материалы археологические[1]» дип язылган. Бу кулъязманың битләренең саны 63, арада бер үк мәсьәләне икенче мәртәбә язылган кәгазьләре бар. Аларны санамаганда 56 (бәлки алары акка күчерелгән нөсхәләрнекеләрдер). Бу кулъязмага көтепханәдә 65 номер куелган.

Икенче 64 номер кулъязмасының өстенә русча янә мөхәррирнең үзенең каләме белән – О Луке Каратуне или о Луке Канашевиче, Пугачеве, об Ишбулат-Мулле[2] дип язылган. Бу кулъязмасы бер тарихи мәҗмуга булып, шушы мәкаләләрне эченә алган:

1) «Аксак Каратун архиерей хакында риваятьләр».
2) «Пугачёв хакында әткәй мәрхүм сөйләде».
3) «Әткәйнең үзе күргән эшләре».
4) «Ишбулат мулла хакында Аитов бабасыннан риваять».
5) «Кашыймшәехләр[3] хакында».

Өченче кулъязмасы 63 нче номерда, өстенә дә русчалап, «Исторические заметки о Казани по устноме преданию (отчасти помещены были в календаре 1882 г.)»[4] дип язылган.

Бу әсәрдә телдән телгә күчеп сөйләнеп йөри торган Казан хакындагы мифология җыелган һәм боларның күбесе Насыйриның календарьларында һәм, Катанов тарафыннан тәрҗемә кылынып, «Издательство Общества археологии»дә[5] басылган, әмма шул ук мәсьәләдә профессор Катанов[6] соңыннан «Деятель» исемле журнал сәхифәләрендә дә кемнән алганын сөйләмичә мәгълүмат биреп барган. Бу Казан тарихы хакында Хөсәен Әмирханов[7] шикелле хәзердә онытылган вә исеме дә әдәбиятыбызда югалган иске бер

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Кашыймшәехләр – Касыйм шәехләр.
[4] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[5] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[6] Катанов Николай Фёдорович (1862–1922) – төрки телләр галиме, этнограф.
[7] Әмирханов Хөсәен Әмирхан улы (1814–1893) – дин эшлеклесе, тарихчы. Мөселман дөньясы тарихында эз калдырган шәхесләргә багышланган тарихи-библиографик хезмәтләр авторы.

тарих белән шөгыльләнүченең «Тәварихе Болгария»сендә бик күп мәгълүмат бар[1]. Шуның өстенә профессор Шпилевский[2] да әсәрләрендә бу Казан хакындагы миф вә ганганәләр[3] хакында сөйләгән. Шул сәбәпле, Насыйриның бу әсәре бер яңа әйбер түгел.

Дүртенче кулъязма 62 нче номерлы булып, тышына русчалап шулай язылган: «Некоторые ученые имамы бывшие в Казани и других местах»[4].

Насыйриның археология турындагы әсәрен язудан максуды – «Зөя өязе яки Тау ягы хакында бер тәварих язмак»тыр. Чынлап та, бу әсәр шулай булып чыккан да. Элек Насыйри мөкаддимәсеннән гомум Зөя өязе һәм Зөя каласы хакында мөһим вә яңа мәгълүмат биреп үткән, соңында өяздәге аерым-аерым авылларның тарихын язарга керешә. Бу мәҗмугага Зөя, Чабаксар һәм Чуел өязләреннән шушы авылларның тарихлары кергәннәр: Түбән һәм Югары Шырдан, Норлат, Шүшермә, Наратлы, Үтәк, Әҗәл, Панау, Мамадыш, Мулла Иле, Бакырчы, Тау Иле, Бәчек, Рысбуга (Урысбага), Ачасыр, Сәлам, Борындык, Шигали, Борнаш, Күгеш, Әлмән, Кармыш, Җамаш, Кошман, Тутаркасы, Кавал. Бу авылларның тарихын сөйләгәндә, Насыйри шундый бер тәртип белән бәян кыла: авылның килеп чыгуы, андагы мәшһүр кешеләр, андагы искедән калган кабер ташлары шикелле истәлекләр.

Бу мәгълүматны Насыйри, рәсми галимнәр шикелле, бер җәмгыятьнең субсидиясе, командировкасы, мандаты белән җыймый. Бәлки җәй көннәрендә, үзенең авылы Югары Шырданны мәркәз-база итеп алып, үзенең борадәре, галим бер мулла Габделкави белән атка утыра да, әһәмият биргән бер авылына китә. Анда халыктан сорашырга тотына. Шунда ишетелгән бөтен мәгълүматны җыеп, язып ала. Мин революция башында Насыйриның туган-үскән авылы Югары Шырданда бер мәктәп ачтырышып, шунда мөдир булып тәгаен кылынгач, анда бик еш барадыр идем. Бервакыт шундагы картлардан Насыйри хакында сораштым. Миңа бер карт: «Беләбез, ник белмәскә! Каюм агай безнең картлар янына килеп, юк сүзләр сорашып, тузга

[1] Бу кеше әдип Фатих Әмирханның бабасы, Казанда Яңа Бистәдә мулла булган. *(Авт. иск.)*
[2] Шпилевский Сергей Михайлович ( 1833–1907) – хокук белгече, тарихчы.
[3] Ганганәләр – кешедән кешегә күчеп сөйләнгән хәбәрләр, риваятьләр.
[4] Кирилл хәрефләре белән язылган.

язмаган нәрсәләр сөйләп, борынгы заман турында сорашып, йөдәтеп бетерәдер иде, әмма үзе шутник иде соң!» – дигән иде. Димәк, аны тарихи ганганәне[1] җыюда тоткан юлы мулла-мөәззиннән генә сорашу түгел, бәлки халыкның эченә кереп, мәгълүматны шул халыкның үз-үзеннән сөйләттереп язып алу булган. Аның мәгълүмат җыюының икенче бер юлы булса, ул да рус вә Яурупа галимнәре булдыра алмый торган бер эш иде ки: Насыйри һәрбер тикшерә торган авылындагы кульязма китапларга тотына торган булган. Шул китапларның кырыйларына язылган хәбәрләрне күчереп алып, фәнни оборотка бик оста кертеп җибәргән. Моны күрсәтү өчен, Насыйриның бу материалларындагы мөкаддимәсеннән бер мисал алабыз. Насыйри Зөя өязе халкының бер төрлесенең Болгардан килеп утырулары хакында сөйләргә ярата вә бу хакта шулай яза: «Моннан элгәре йөз ел, йөз илле ел мөкаддәм[2] язылган китапларда күренәдер: ул заман халкы без Болгар кешесе дип йөргәннәр, нәселдән нәселгә чаклы болгардан килгәнлекләре онытылмагандыр. Мәсәлән, «тәм «Шәрх әл-фәраиз әш-Шәриф» фи вакыт әл-гасри фи шәһре рәҗәб кәнә минһу 23 йәүмән фи тарихи 1195 галә яди әхкар әл-гыйбад Әмир Гали бине Габделкәрим әл-Болгари...»[3] (9 сәхифә).

Шунысы кызык: Насыйри бу әсәрен язган чакта, гомумән, бөтен тарихи әсәрләрендә үз кулы белән җыйган мәнбәгъләр[4] белән генә канәгатьләнеп, башка шул мәсьәлә хакындагы фәнни әсәрләр, башка мәнбәгъләр белән файдаланмый. Чөнки шул үзе тарих өчен мәнбәгъ-материал бирә. Шуның өчен дә без Зәки Вәлидинең[5] Насыйрины Мәрҗани белән чагыштырып, Насыйрины надан дип гаепләвен зур әдәпсезлек вә шул сүз үзе аңламаучылык дип беләбез[6]. Ләкин Насыйри бу әсәрендә вә башка тарихи әсәрләрендә үзе җыйган мәнбәгъләрне тәнкыйтьсез-нигезсез кабул итми. Беренчеләй,

[1] Тарихе ганганәне – тарихи хәбәрләрне, риваятьләрне.
[2] Мөкаддәм – элек.
[3] «Шәрх әл-фәраиз» иң кимчелекле Әмир Гали бине Габделкәрим әл-Болгари тарафыннан 1195 елда рәҗәп аеның 23 көнендә (1781 елның 14 июле) язып тәмамланды.
[4] Мәнбәгъләр – чыганаклар.
[5] Әхмәдзәки Әхмәдша улы Вәлиди (1890–1970) – күренекле тарихчы, тюрколог.
[6] «Мәрҗани» мәҗмугасындагы Вәлидинең мәкаләсен карагыз. *(Авт. иск.)*

Насыйри ишеткән сүзләрен фән теләгән рәвештә язып ала. Кемнән ишеткәнен вә ул кеше кайдан белгәнен һәрвакытта әйтеп китә. Хәтта бу мәсьәләдә борынгы гарәп галимнәре шикелле эчпошырлык рәвештә риваятьләрне тезеп китә. Бер урында булганнарның тормышын сөйләгән чакта, мәсәлән, Насыйри шулай башлый: «мәрхүм Мөхәммәд хәзрәт атасыннан – Сәид хәзрәттән риваять кыладыр икән (моны атасы сөйләгән). Әхмәд бабадан элгәре Болгар халкы күчмә халык булган...». Яисә, мәсәлән, Насыйри шулай яза: «Әткәй сөйләгәне бар, Ырсы баба риваять кыладыр икән...». Икенчеләй, Насыйри этнограф булуы сыйфаты белән мифологиягә зур әһәмият биреп, хорафи вакыйгаларны сөйләсә дә, аларга коры гына ышанмый, бәлки ул мәгълүматны бары бер кыйсса, этнографик бер материал итеп кенә ала.

Әсәрләр хакында, гомумән, шулкадәр мәгълүмат биргәннең соңында, хәзер кульязмаларның фәнни кыйммәте мәсьәләсенә күчәбез.

II

Насыйриның «Археология материаллары» фәнни яктан бик мөһим. Ул әсәр өлкәнең үткәнен өйрәнү бабында рус әдәбиятында да беренче әсәрләрдән хисапланырга тиешле.

Әсәрнең мөһим якларыннан берсе – татар эпиграфикасы (ташка язган язулар хакындагы гыйлем) бабындадыр. Безнең өлкәбезнең бөтен Русия һәм хәтта бөтен инсаният тарихы өчен мөһим бер өлкә булуы мәгълүм. Борынгы Левант сәүдәсенең безнең өлкәбез аркылы үткән булуы безнең өлкәгә Яурупа галимнәренең дә зур дикъкатен чөергән[1]. Ләкин никадәр өлкәбезнең тарихы мөһим булмасын, ул бабта мәнбәгъләр аз булганлыктан, бигрәк тә җирле мәнбәгъләр юклыктан, галимнәр һаман да бер балык башын чәйнәргә мәҗбүр булалар. Тарихыбызның иң борынгы дәверенә даир мәнбәгъләр бик аз, XIII–XVIII йөзләр тарихыбызга даир сакланып калган бераз мәнбәгъләр булса да, алар кабер ташларыннан гына гыйбарәттер. Шуның өчен борынгыдан бирле бу язуларга галимнәр зур әһәмият

[1] Бу бабта Гейднең «Geschichte des Levantehandels im Mittelalter» исемле әсәрендә күп мәгълүмат табарга мөмкин. Шул китапны укыгач кына, өлкәбезнең инсаниятнең икътисади тарихы өчен никадәр әһәмияте булганын белеп була. *(Авт. иск.)*

биргәннәр. Болгар дәүләте Алтын Урданың бер олысы булып киткән заманда XIII–XIV гасырларда язылган Болгар кабер ташлары хакында тарихи әдәбиятта күп кенә мәгълүмат бар. Ләкин, ни өчендер, рус вә Яурупа галимнәре, хәтта Мәрҗани һәм Гайнетдин Әхмәрев[1] шикелле татар тарихчылары бу XIII–XIV гасырларның ташларына зур игътибар итсәләр дә, XVI гасырдан, Казан ханлыгы девереннән калган ташларга бер дә әһәмият бирмәгәннәр. Бу ташлар бөтен Татарстанда төрле җирдә яталар. Әмма татарның XVI–XVII гасырларының сәяси, мәдәни тарихларына даир сакланып калган бердәнбер материал булса (Сәхиб Гәрәй ярлыгыннан кала), шул ташлардыр. Менә Насыйри беренче мәртәбә уларак шул ташларны укыган һәм шушы әсәренә язып калдырган, хәтта бер-икесеннән рәсем итеп тә алган. Билгеле, бу рәсемнәр шактый каба[2] чыкканнар, ләкин Насыйри ул бер рәссам түгел, шулай була торып та, алар энциклопедист Насыйриның бу бабтагы истигъдадын[3] да күрсәтеп торалар.

Мисал өчен без бу урында Насыйриның ничек итеп дикъкатьләп, әһәмият биреп бу ташларны укыганлыгын күрсәтү өчен, бер урынын күчереп үтәбез: «Вә дәхи Норлат зиярәтендә бәгъзы ташлар бар, борадәр Габделкави белән барып укып, язып алдык, бик нәфис хат белән калкытып язылган, берсе ошбу рәвештә:

«Калә Аллаһу Тәгалә: көллү нәфсин заикать әл-мәүт. Калә Сөбханәһү вә Тәгалә: вә ма тәдри нәфс би-әй арз тәмүт. Тарих тукыз йөз кырык сигездә шәүвәл аенда Тәвәккел гыялы Рабигабикә дар әл-фәнадин дар әл-бәкага рихләт кылды»[4].

Язылганына булыр 342 еллар, Казан алынмастан элгәре – 1621 елларда язылгандыр. Янә икенче таш бардыр, әүвәлгесе белән бер замандарак язылгандыр. Язулары бер кеше кулыннан чыкканга охшый, язылган ошбу рәвешчә:

«Калә Аллаһу Тәбарәкә вә Тәгалә: көллү нәфсин заикать әл-мәүт вә иләйһи тәрҗәгунә. Калә ән-нәби галәйһи-с-сәлләм: әд-дөнья

---

[1] Гайнетдин Нәҗметдин улы Әхмәрев (1864–1911) – тарихчы, археограф, педагог, җәмәгать эшлеклесе.

[2] Каба – начар.

[3] Истигъдадын – зирәклеген, сәләтен.

[4] Аллаһы Тәгалә әйтте: һәр җан үлем ачысын татыр. Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә әйтте: беркем дә үзенең кайсы җирдә үләчәген белмәс. Тәвәккәл хатыны Рабигабикә фани дөньядан бакый дөньяга күчте.

сәгатән, фә-җәгальһа тәгатән. Тарих тукыз йөз утызында сәфәр аенда шәех Хәсән углы Миһригали дар фәнадин дар әл-бәкайә рихләт кылды[1]. Бу ташның язылганына 355 ел буладыр, Казан алынмастан күп элгәре елларда язылгандыр, ташның бер кырыенда язылган бәйт:

Әй, әд-дөнья хизанән бил-игътибари
Фә-ля-йәбка мәдамән бил-карари,[2] –

дип язылгандыр. Янә икенче кырыенда язылган: күрермен дөнья вәйран бары...».

Менә бу кисәк, бер яктан, Насыйриның эпиграфика материалын ничек җыйганын күрсәтсә, шушы бик күп ташлар эченнән тәсадефи[3] алган бер мисалыбыз мөһим бер нәрсәне ачып бирә: без татар әдәбияты тарихыбызның икенче бүлегендә Кара Якуб авылы янында XIII гасырда үлеп калган бер Төркестаниның кабер ташында язылган язуларны китергән идек, анда да шул ук бәетләр язылган. Димәк, татар мәдәниятенә чыгтай вә Урта Азия тәэсире XVI гасырда да дәвам кыла. Янә мәсьәлә ачыла төшсен өчен бер мисал алыйк: «Бу Шигали авылында хәзер чувашлар тора... Зиярәтендә өч-дүрт таш бар, хәзердә бик читенлек белән укып була, берсе уалган, өч кисәк булып ята, без Мамадыш мулласы Таҗетдин белән вә һәм борадәр Габделкави өчәү барып, укып, язып алдык. Уалган ташның кисәкләрен бергә җыйгач, фи-л-җөмлә[4] укырлык булды, язулары бик нәфис гарәби хат белән язылган. Ул чагында голәма юк дип әйтергә мөмкин түгел, язылган ошбу рәвешчә:

«Калә Аллаһу Тәгалә: вә ма тәдри нәфс би-әй арз тәмүт. Калә Сөбханәһү вә Тәгалә: көллү нәфсин заикать әл-мәүт[5]… йөз кырык тукызда… углы Кужал рабигъ әл-әүвәл аенда кяфер тукышындин

[1] Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә әйтте: һәр җан үлем ачысын татыр, барыбыз да Аның хозурына кире кайтачакбыз. Пәйгамбәрбез (аңа Аллаһның сәламнәре ирешсен) әйтте: дөнья бер сәгатьлек, аны гыйбадәт белән үткәр. 930 елда шәех Хәсән улы Миһригали фани дөньядан бакый дөньяга иреште.
[2] Күрәмен дөньяны, җимерек бары. Бер нәрсә дә мәңгелек түгел [Аллаһы Тәгаләнең] әмере шундый.
[3] Тәсадефи – очраклы.
[4] Филҗөмлә – тулысы белән.
[5] Аллаһы Тәгалә әйтте: беркем дә үзенең кайсы җирдә үләчәген белмәс. Аллаһы Тәгалә әйтте: һәр җан үлем ачысын татыр.

шәһид…» Башта «йөз» дигән сүзенең алдындагысы җимерелеп төшкән, укып булмый. Янә «углы» дигәненең алдында үзенең исеме беленми. Бу таш алда язылачак дүртенче ташның язуы белән бер, икесе бер кешенең кулы вә болай булырга гуаһлык бирәдер: «йөз» дигән сүзнең алдында «тукыз» дигән сүзе җимерелеп төшкәндер, болай булганда язылганына 341 булырга кирәк. 1519 елларда – Казан алынган чорларда язылгандыр. Ташның як-ягында язылганны укырга мөмкин дә түгел вә ул кадәр тәфтиш кылынмады, тарихи исеме булгач, кифаяләндек[1]».

Шул ук авылда Насыйри тагы шул Казанның Мәскәү белән соңгы сугышында үлгән бер кешенең ташын язып алган. Бу ташта гарәпчә шул ук шаблонлы сүзләр язылган соңында: «Тарих тукыз йөз дә иллектә хаҗи углы Шиш кяфер тукышында шәһид булды» диелгән. 1923 елда бөтенрусия авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә материал җыю өчен чыккан экспедициядә мин Әтнә авылы янында да шул ук заманда үлгән бер кешенең ташын укыган идем. Ул вакытта мин ничек итеп Казан янында сугышканда үлгән кешеләрне бу кадәр ерак җирләргә алып китеп күмгәннәр дип уйлаган соңында, шул тирәдә дә сугышлар булган булырга кирәк дигән карарга килгән идем. Ләкин менә хәзер Насыйриның бу әсәрендә Казан белән Мәскәү сугышында гаскәриләрнең бер Казанда гына булмыйча, читтән килеп сугышуларына да бер мөһим мәгълүмат табабыз. Норлат авылының ганганәви тарихын сөйләгән соңында Насыйри Казан-Мәскәүнең соңгы сугышына даир шундый мөһим тәфсыйлатны[2] бирә: «Бу Үлмәс һәм үзенең углы Габделхаликъ Иван Васильевич Казанны алган вакыт сәламәтләр икән, әткәй мәрхүм Ырсы бабадан риваять кылып сөйли торган иде, Үлмәс белән Габделхаликъ Казан сугышы вакытында иртә намаз укыгач, җәяүләп (?) Казанга барып, руслар белән сугышып, ястү вакытында кайталар икән. Иске заманадан кала килгән «Казан бәете» дигән бер бәет вар, Үлмәс белән Габделхаликъның исемнәре ул бәеттә мәзкүрдер...», – ди. Вакыйган, Казан тарихы хакында язган кулъязмасында Насыйри бу бәетне китерә. Бу кешеләр турысындагы урыны шуннан гыйбарәт:

[1] Кифаяләндек – чикләндек.
[2] Тәфсыйлатны – тәфсилле аңлатма

«Бар ирде бер ир Үлмәс, исеме аның кемсә белмәс
Шәһре Казанга килгәнчә, кемсә күрмәс ирдия,
Үлмәс илә Әбелхаликъ яри бирде Җәббар, Халикъ
Мөэминнәрнең үчене барып алыр ирдия».

Икенче бер урында шул ук мәсьәләдә Насыйри тагын бер хәбәрне сөйләп уза: «Бикмәт мулла үзенең бабасыннан риваять кылып сөйләшәдер икән. Зөядән ерак түгел хәзердә бер авыл бар, Мәҗен дип йөртәләр, әмма элгәре аның исеме Өҗем яки Уҗым авылы дип аталгандыр, анда Өҗем дигән бер изге кеше булгандыр. Иван Грозный Зөя урынында кала салганда, бер кечерәк сугыш булган, бу Өҗем баба шунда барып сугышкан, аннан Тау иленә килгән канлы киемнәре, җәрәхәтләре белән, фатир сораган. Тау иле кешеләре фатир бирмәгәннәр…», – ди. Менә бу тәфсыйлат та бары Насыйрида гына сакланып калган. Казан – Мәскәү сугышының барышын без моңарчы бары рус рузнамәләре (летописьләр), кенәз Курбский[1] әсәрләре шикелле, шул заманның рус әсәрләреннән генә белә алганыбызга күрә, тәфсыйлат аз иде. Шуның өчен Насыйриның мондый хәбәрләрен без аның әсәренең гыйльми кыйммәтенең бер кисәге дип танырга мәҗбүр булабыз.

Насыйриның «Археология материаллары»ның фән өчен бер әһәмияте – борынгы Болгарга даир мәгълүматыдыр. Без борынгы Болгарның иҗтимагый тарихын бик аз беләбез. Бер-ике генә гарәп сәйях[2] вә галимнәренең әсәрләрендәге аз-маз гына хәбәрләр, рус рузнамәләрендәге кыска-кыска гына мәгълүмат, археология васитасы[3] белән табылган нәрсәләр Болгарның иҗтимагый тарихыннан бик аз нәрсә бирәләр. Шулай ук Мөслиминнең «Тәварихе Болгария»се[4] дә, мәгълүмат бирүдән бигрәк, мәсьәләне томанландыра гына. Без бу әсәр аркылы Болгар халкының иҗтимагый тормышы хакында белем алып, Ибн Фадлан вә Мәсгудинең хәбәрләренең дөреслеген тәэкид

[1] Андрей Михайлович Курбский (1528–1583) – дәүләт эшлеклесе, язучы, тәрҗәмәче.
[2] Сәйях – сәяхәтче.
[3] Васитасы – ярдәме.
[4] Сүз Шәрәфетдин бине Хисаметдин әл-Мөслими әл-Болгариның «Тәварихе Болгария» («Болгар иле тарихы», чама белән XVIII йөз ахыры – XIX йөз башына карый) исемле тарихи-әдәби әсәр хакында бара.

кыла[1] алабыз. Насыйри җирле голәма арасында авыздан-авызга әйтелеп йөргән хәбәрләр буенча шулай яза: «Элгәре Болгар халкы күчмә халык булган, җәй көннәрендә кәсеп вә хәрәкәтләре хайван асрап тәрбия кылып хәрәкәтләнәләр икән. Зөя буйлары болынлык вә урманлык булганга күрә, һәйбәт җир дип, җәй көне шунда хайван ашатып ятарлар икән һәм ул вакытта Болгарда йөз меңгә якын кеше бар икән. Болгар бик зур шәһәр булган, һәртөрлек күн заводлары бар, яхшы күннәр Болгарда эшләнәдер… Болгар төзек вакытта безнең Тау ягында байлар, фабрикантлар бар икән, ситса, комач эшләнә торган фабрикалары бар икән. Кытат вә комачка алмаштырып китәләр икән вә һәм җәй көне Зөядә Самат ханның бер ярминкәсе булып, шул ярминкәгә килеп сату итәләр икән, хайваннар вә тире-җары вә һәм эшләнгән күн китереп сату итәләр икән. Бер җомга (бер атна) ярминкә буладыр икән. Кәрван халкы Зөягә ярминкәгә килгәндә-киткәндә бер тау башында җомга укыйлар икән, хәзердә Йомату дигән рус авылы шул «Җомга тавы» дигән сүздән бозылгандыр...».

Бу мөһим хәбәрдә без Зөя каласын һәм «Самат хан» дигән сүзне укыдык. Ничек итеп XVI гасырда салынган рус шәһәре Болгар заманында булган вә Самат хан кайдан килеп чыккан? Бу сөальгә Насыйри шулай җавап бирә: «Болгар төзек вакытта ук Зөя тавында бер шәһәр бар икән, хан Самат исемле булган, Казан шәһәре гыймарәт кылынып[2], Казанда ханнар була башлагач, Казан ханы Зөя тавына җимеш бакчасы ихъя кылгандыр[3]», – ди. Димәк, Самат хан – Ибн Фадлан әйтә торган «мәлик»ләрнең берседер.

«Татар әдәбияты тарихы»ның башында, феодализм хакында сөйләгән вакытыбызда, Болгар ханлыгында феодализм башланган иде дигән сүзебез бу хәбәр белән тагы куәтләнә.

Гомумән, борынгы заманнарда шәһәрләр бер вакытларда яңа урынга салынып килмәгәннәр. Бер халык икенче халыкның әүвәле торган җиренә килеп утырып, ватылган, җимерелгән шәһәрне кире сала торган булганнар. Борынгы «Троя»ны казыганда 7–8 катлы төрле дәверләрнең шәһәрләре килеп чыгуы шуны күрсәтәдер. Зөя урынында Казан

[1] Тәэкид кыла – раслый.
[2] Гыймарәт кылынып – төзелеп.
[3] Ихъя кылгандыр – булдырган.

ханнарының бакчалары вә җәйге дачалары булуы мәсьәләсен Хөсәен Әмирханов та үзенең «Тәварихе Болгария»сендә сөйләп үткән.

«Материаллар»ның тагын бер гыйльми кыйммәте – аның XVI–XVII гасырларда татарларның баш сыйныфларыннан булган рухани феодалларның тормышын тасвирындадыр. Югары Шырдан авылы хакында сөйләгәндә Насыйри Габдеррәзак мулла дигән бер бай-алпавыт мулланың тормышын тасвир кыла. Без бу материалны Насыйриның бу әсәрендә иң кыйммәтле нәрсә дип саныйбыз. Моңарчы әле мондый материал юк иде. Вельяминов-Зерновның[1] «Касыйм хан вә ханзадәләре хакындагы тәфтиш» исемендәге 3 җилдлек әсәрендәге бер-ике алпавыт-феодалның васыятьнамәсе «Археографические исследования»нең бәгъзы җилдләрендәге бәгъзы материал – татарның дөньяви феодаллары хакында мәгълүмат бирсәләр дә, рухани феодаллар хакында Насыйри бирә торган бу материал – бердәнбер мәнбәгътер. Тарихи мәнбәгъләр Казан алынган соңында җирле халыкларның, шул җөмләдән татарларның берничә мәртәбә кубуларын ачып бирәләр. Бу кузгалуларның сәбәбе безгә чүс[2] белән генә мәгълүм булса да, бу турыда халыкның үз-үзеннән ишетелгән хәбәрләр юк иде. Менә Насыйри бу хакта да Әҗәле авылы хакында сөйләгәндә шундый мөһим бер материал бирә: «Иван Васильевич Казанны алгач, руслар килеп җәфа кылалар икән, анда-монда узсалар, олаулар сорап, ат сорап, бирмәсәләр, көчләп алып талап китәләр икән. Русның бу җәфасына чыдый алмыйча, төрле авылларга (Әҗәле крестьяннары) таралып беткәннәр, бәгъзылары мөртәд булып, рус диненә кергәннәр, хәзер дә Рус Әҗәлесе шуннан калгандыр», – ди.

Авылларның килеп чыгуларына даир Насыйриның сөйләгән сүзләрен гомумиләштергәндә шундый нәтиҗәне тудыра торган мөһим мәгълүмат килеп чыга: бертөрле авыллар Болгардан күчеп килгәннәр, бер төрлесе исә әүвәлдә я чуваш, яисә мукшы булып, шуннан мөселман диненә кереп татарлашканнар. Бәгъзы авыллар

[1] Владимир Владимирович Вельяминов-Зернов (1830–1904) – шәркыятчы галим, тарихчы-нумизмат, археолог.

[2] Чүс – дәлил.

исә, исламны ташлап, чувашка әйләнгәннәр. Насыйриның фикеренчә, чувашлар әүвәлдә мөселман булганнар, соңра гына алар «каралып чуваш булганнар». Насыйриның бу фикере Мәрҗанинең «Мөстәфад»ында[1] әйтелә торган фикер белән бертөсле, ләкин бу фикер – бик каты тәнкыйтькә мохтаҗ бер караштыр.

Насыйриның бу «Материаллар»ы тагы мөһим мәсьәләне хәл итү өчен мәгълүмат бирә. Ул мәсьәлә исә – татар теленә җәнүб төрекчәсенең тәэсире вә татарның сөеп укый торган китаплары эчендә «Мөхәммәдия»[2], «Сәедбаттал» сугыш китаплары, «Пиргули китабы»[3] шикелле госманлычадан кергән китапларның ничек итеп килеп керүе мәсьәләседер. Казан ханлыгының соңгы дәверендә Истанбул тәэсиренә бирелгән вә Төркиянең хөкүмәт сөрүче түгәрәкләренә якын торган Сәхиб Гәрәй вә Сафа Гәрәй, Үтәмеш Гәрәйләрнең хөкүмәт сөрүе мәсьәләсе XVI гасырда Казанда госманлы мәдәнияте тәэсиренең булуын сиздерәдер иде. Ләкин мәсьәлә бит сәяси якта түгел, бәлки ничек итеп югарыда сөйләгән китапларның вә бик иске язулардагы җәнүби төрек формаларының халык арасына таралуында. Насыйриның бу әсәрендә күрелгәнчә, XVI гасырда татар, хәтта мукшы, чуваш авылларында госманлы тәрбиясен алган, бәлки шулар җенесеннән булган кешеләр мулла булып, дәрес әйтеп торганнар. Насыйри Бакырчы авылы хакында сөйләгәндә, шундагы бер кабер хакында сөйли. Кабер – 939 яисә, Насыйри әйткәнчә, 1522 елда вафат булган Мөхәммәд Чәләбинең кабере. Бу хакта Насыйри яза: «Чуел өязендә хәзердә Ачбаба дигән чуваш авылы бардыр. Шул чуваш авылында хаҗи Мөхәммәд Чәләби[4] дигән адәм бар икән, ничә еллар шул авылда дәрес әйтеп, ахыр

[1] Сүз мәшһүр татар мәгърифәтчесе, фәлсәфәче, тарихчы, дин галиме, педагог, археограф, этнограф Шиһабетдин Баһаветдин улы Мәрҗанинең (1818–1889) «Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») исемле әсәре хакында бара.

[2] Төрек шагыйре Мөхәммәд Чәләбинең (?–1451) татарлар арасында яратып укылган, киң таралган, мәдрәсәләрдә дәреслек итеп файдаланган «Мөхәммәдия» китабы.

[3] Сүз төрек шагыйре Мөхәммәд Пиргулиның (1538–1573) татарлар арасында киң таралган «Пиргули васыяте» дини-дидактик әсәре хакында бара.

[4] Чәләби фамилиясе госманлыларда зур рухани вә галимнәр чыккан бер фамилиядер. *(Авт. иск.)*

хажга барган. Хаждан кайтканда Истамбулда калып, шөһрәт тоткан, аннан соң аны бер мәдрәсәгә мөдәррис иткәннәр. Ничә еллар анда дәрес әйтеп, ахыр үзенең туган җиренә кайтмакны мәслихәт күреп, монда кайтып күрсә, авыл каралып, һәммәсе чуваш булып калганнар. Аннан соң аны монда Хаҗи баба дип йөрткәннәр. Шул сәбәпле, аның авылы Ачбаба дип аталгандыр. Аннан соң үзенә авыру җиткәч, үзенең якыннарына васыять кылган: «Мин үлсәм, мине Бакырчы зиярәтенә күмегез, бу бәдбәхетләр каралып беткәннәр. Тәнем чуваш арасында калмасын», дигән. Аннан соң вафат булып, Бакырчы зиярәтенә китереп күмгәннәр, мәзкүр Мөхәммәд Чәләби дигән адәм Истанбулда байтак дәрес әйтеп, могтәбәр голәмалардан булган. Шул сәбәпле, чәләбилек дәрәҗәсен алганда, чәләби – бер дәрәҗә вә чинның исемедер». Менә, билгеле, шул кешеләрнең тәэсире белән татарлар арасына бәгъзы җәнүб төрекчәсенең грамматик формалары кергән һәм бәгъзы әсәрләрне дә шулар алып килеп, халык арасына таратканнардыр. Билгеле, бу мәсьәләне бер бу мәнбәгъ кенә хәл кылмый, моның өчен әле тагы берничә дәлил ляземдер.

Без монда бу мөһим әсәрнең гыйльми әһәмияте хакында сөйләгәндә бары берничәсен генә алдык. Табигый, бу материаллар тагы бик күп тарихи мәсьәләләрне хәл итү өчен мәнбәгъ була алалар. Бу хакта моның белән сүзне кисеп, хәзер без Насыйриның Аксак Каратун, Ишбулат мулла һәм Пугачёв мәсьәләсе хакындагы мәкаләләренә киләбез.

III

Насыйриның халык ганганәсе буенча Казан хакындагы тарихи мәкаләләре дә ифрат мөһим. Мәсәлән, андагы «Казан алыну хакындагы бәет» – үзе генә дә зур бер тарихи әһәмиятле нәрсәдер. Ләкин бу мәҗмугадагы материаллары календарьларына кергәнлектән вә русча да басылганлыктан, керми калган бары бер мөһим материалны гына әйтеп китәбез. Бу мәҗмугада Насыйри татарларның үзләре арасындагы Пугачёв явы вакытындагы сыйнфый көрәшне тасвир кылучы шушы бер кыска гына хәбәрне кертеп калдырган: «1167дә язылган бер иске «Җәмигъ»ның[1] читендә язылмыш: 1773 елда

[1] «Җәмигъ әр-ромуз» китабының. Бу хәбәр кульязмаларның бу мәҗмугага кермәгән кыйсеменнән. *(Авт. иск.)*

гакрәб[1] көнендә Җамал хан (Емельян Морад) Пугачёв дигән кеше Каргалы шәһәрен алды. 1774 мәсихия[2] июльнең 15 көнендә Җамал ханның командасы килеп, Кышкарның Сәгыйд Госман углыны таладылар». Мәгълүм ки, Кышкар авылы – татарның байлары вә фабрикантлары булган бер авыл иде. Ихтимал, Пугачёв ягында булган татарлар килеп талаганнардыр. Әмма Сәгыйд Госманов исә Пугачёвка хилаф[3] булгандыр. Насыйриның Аксак Каратун (Лука Канашевич)[4] Пугачев һәм Ишбулат мулла хакында язган әсәре үзе тарафыннан җыелган материал булмыйча, Мөхәммәдҗан Аитовның

[1] Гакрәб – октябрь ае.
[2] Мәсихия – милади.
[3] Хилаф – каршы.
[4] Миссионер Малов поп «Аксак Каратун» дигән сүзне русчага «хромой», «чернオризец» дип тәрҗемә кыла. Бу хакта: 1878 елда Маловның «О новокрещенской конторе» дип рухани академиядә сөйләгән нотыгын карагыз (166 биттә). Лука Канашевич 1738 елда Казан епархиясе архиепискобы ителеп тәгаен кылынган. Гомеренең яшь чагын төрекләргә әсир булып үткәргән. Ифрат явыз, диндар, мөтәгассыйб-фанатик, православиене Идел буе халыкларына көч белән кертергә тырышучы, аз гына ирекле фикерне басарга омтылучы, русларның иң самими вә иң эшлекле крестьяннарыннан вә казакларыннан хисапланган «старовер» динендә булганнарны җәза кылучы бер мөдһиш (куркыныч) поп иде. Моның вандализмына чик тә юк иде: татарларның тарихи хатирәләре калмасын өчен, ул Болгар хәрабәләрен җимерткән бер кемсә иде. Бу кеше хакында хәтта Екатерина Икенче, Болгар хәрабәләрен килеп карагач, шулай язган иде: «Все, что тут ни осталось, построено из плиты очень хорошей. Сему один гонитель, Казанский архиерей Лука, при покойной императрице Елизавете Петровне позавидовал и много разломал, а из иных построил церковь, погреба и под монастырь занял, хотя Петра I указ есть, что б не вредить и не ломать сию древность» (Соловьев. История России, том 27, гл. 1, стр. 330). Без монда Аксак Каратунның эшләгән эшләрен вә аның татар вә башка халыкларга кылган золымнарын сөйләп тормыйбыз. Ләкин Лука Канашевичның кылган бик күп эшләре безнең татар крестьяныының икътисади тормышына да тәэсир иткәнлектән (чукынмаганнарны авыллардан сөрү, начар җирләргә күчереп утырту шикелле) без бу кеше вә аның аркасында кылынган золымнарның тулы картинасын күреп мәгълүмат аласы килгән кешеләр өчен бу хакта мәгълүмат табарлык әдәбият вә мәнбәгъләрне күрсәтеп китәбез:
1. «Лука Канашевич». (Православный Собеседникъ, за 1858 г., ч. 3).
2. Можаровский А. Изложение хода миссионерского дела по просвещению казанских инородцев (чтения в Обществе истории и древностей российской, за 1888 г., кн. 1). 12 фасылны укырга кирәк).
3. Соловьев С. История России, том 4, 262 с.; т. 6, 330 с.

җыйган материалларыннан файдаланып язылган[1]. Насыйри бу мәҗмугасын шулай башлый: «Аллаһ разый булсын, Аитов Мөхәммәджан хәзрәтләренә бу чаклы онытыла язган риваятьләрне үзенең ата-бабаларыннан ишетелмеш рәвешчә саклап һәм бәгъзысын үзенең мәҗмугасына язып куймыш икән. Бу хосуста аның берничә статьясы беләν файдаланабыз», ди. Ләкин Насыйри бу мәҗмугадан материал алса да, аның бу бабта үз хезмәте юк дип әйтеп булмый. Мин Аитов мәҗмугасын күргән идем, ул кыйммәтле тарихи материалларның коры бер җыентыгы гына иде. Менә Насыйри шул мәҗмугадан алып җыеп, әдәби рәвешкә китереп, тарих төсле итеп язган, хәзердә бу кадәрле мәҗмуга юк. Әмма аның шуннан файдалануы аркасында бу мөһим хәбәрләр сакланып калганнар.

Иң әүвәл, Насыйриның «Аксак Каратун хакында риваятьләр»енә килик. Насыйриның бу әсәрендә тарих өчен мөһим бер урын булса, ул да – XVIII гасырның урталарында татарларның калмыклар белән мөнәсәбәтләре вә калмык «әсир»ләрен сатып алулары мәсьәләседер. Мәгълүм ки, кыр халыкларында әсирләрне сату XVIII гасырларда да бетмәгән иде. Табигый, татар сәүдәгәрләре бу калмыкларның балаларын үзләренә сатып алганнар. «Бер сәүдәгәр Идел буе калмыкларыннан берничә яшь угланнар сатып алып килгән икән, шуларны ул заманда бер мөәззин иман тәлкыйн итеп[2], янәдән Гайсә баба дигән бер баба бар икән (шумерошный Гали дигән вә һәм Шайтан Шәриф дигән адәмнәр шул Гайсә бабаның нәбирәләреннән[3] икән…) Шул Гайсә баба калмык балаларын сөннәткә утырткан икән. Ахыр бу эш рус түрәләренең колагына төшеп, бу өч кемсәнәләрне алып, һәртөрле газап белән ахырында чукындыргач, Гайсә бабаны чиркәү

4. Малов Е. О татарских мечетях в России. (Православный Собеседник, за 1867 г. кн. 12 и за 1868 г. кн. 1).

5. Малов Е. О ново-крещенской конторе. Казань, 1878, 148–158 стр.

6. Люборкий Вл. Сборник дел Казанской епархии, Казань, 1868 г.

Бу әсәрләрдә мәнбәгъләр һәм күрсәтелгән. *(Авт. иск.)*

[1] Мөхәммәджан Аитов XIX гасырның соңгы яртысында яшәгән бер кеше булып, Казанның гыйлем сөюче байларыннан булган. Аның халык арасында татарның Казанның үтмеше турында халык арасында йөргән хәбәрләрне, авыз риваятьләрен җыеп язган бер мәҗмугасы бар иде. Хәзердә бу мәҗмуга югалган. *(Авт. иск.)*

[2] Иман тәлкыйн итеп – иманга китереп.

[3] Нәбирәләреннән – оныкларыннан.

астына ябып асрап, ахырында шунда картаеп вафат булмыштыр. Әмма баягы сәүдәгәр рус диненә ихлас куйган булып, хәтта мөселман йоклаганда аркан әйләнеп[1] һәм мөселманнарның йөзенә карамаган булып, архиерейны ышандырыр икән, ләкин үзе иманында сабит булып, мөәззин [белән] Мәскәү китмәккә сүз вәгъдәләшеп, Мәскәүдә юлыкышмакчы[2] булганнар». Шуннан мөәззин Мәскәүгә киткән, әмма теге сәүдәгәрне исә Лука тәреләр, аракылар, зәиннәр[3] биреп, Закама[4] халкын православиега өндәргә җибәргән. Әмма сәүдәгәр исә бу нәрсәләрне сатып акча ясап, янә Мәскәүгә барып «юлыгышып, шуннан соң падишаһка Казан татарларының архиерейдан тарыткан җәфаларын күрсәтеп, шуннан үзләре Истанбулга качыплар», – ди.

Татар сәүдәгәрләренең Кыргызстанда ислам таратулары аркасында никадәр базар табулары мәгълүмдер. Димәк, шул ук эшне татарлар калмыклар арасында да эшли башлаган булганнар. Бу вакыйга ялган бер хәбәр түгел, бәлки башка мәнбәгъләр белән дә тәэкид ителә[5]. Бу вакыйга тагы да зурайтылып, Лука тарафыннан хөкүмәткә ирештерелгән иде. Лука үзенең Адмиралтейская канторaның баш комиссары Баранчеев[6] исемле кеше өстеннән татарларга булышлык кыла, дип язган доносында шул мәзмунда[7] язган иде: «Татар Бистәсенең сотнигы Бахмет Котлин[8] чукынган иде, тагын мөселманлыкка чыкты да, үзе белән бергә котыртып, тагы берничә яңа чукынганнарны мөселманлыкка тартты. Баранчеев боларга паспорт бирде дә, бу кешеләр Сенатка шикаять кылу өчен Петербурга барып, гаризаларын тапшырдылар». Шулай ук калмыкларны мөселманлыкка чыгаручы Сөләйман Нуркин хакында да шикаять кылып, Баранчеев бу кеше өстеннән ясала торган следствиене туктатты».

1 Аркан әйләнеп – арка тарафыннан әйләнеп үтеп.
2 Юлыкышмакчы – очрашмакчы.
3 Зәиннәр – кыйммәтле әйберләр; бизәнү әйберләре.
4 Закама – Кама аръягы.
5 Тәэкид ителә – раслана.
6 Баранчеев Алексей (?–1758) – капитан-командор, Казан адмиралтействосы обер-комиссары.
7 Мәзмунда – эчтәлектә.
8 Кайбер чыганакларда күренгәнчә, йөзбашы Бахмет Котлин, православие динен кабул итеп, исемен Корнилийга үзгәрткән була.

Димәк, Насыйри сөйли торган вакыйганың кыскачасы хакында бу мәнбәгъта хәбәр бар. Әмма Насыйри исә бу кызык вакыйганы тәфсилле рәвештә сөйли.

Насыйриның бу материлларында тагы бер мөһим мәгълүмат бар. Ул исә шуннан гыйбарәт: «Ул арада архиерей (ягъни Лука) үзенең һаман мөселманнарны гаҗиз кылуында мәсыйр булып[1], Бистәне яндырып вә һәм мәчетләр, өйләр салырга рөхсәт бирмәенчә, мөселманнарны издихамда[2] калдырып вә һәм «чукынсагыз – торыгыз, чукынмасагыз – шәһәрдән чыгыгыз» дип кысып, күп яманлыклар кылыр икән».

Вакыйган, 1749 елда Казанда зур янгын булып, Татар Бистәсеннән башланып китеп, рус арасы һәм Кремльдәге күп бина вә чиркәүләр янган иде[3]. Бу янгынның башлануы, аның сәбәбе моңарчы мәгълүм түгел, ләкин аның татарлар өчен фаҗигалы булуы башка мәнбәгъләрдән бик мәгълүм. Шулай да, Насыйри әйткәнчә, «Луканың Бистәне яндыруы» мәсьәләсенә даир шөбһә бирерлек бер мәнбәгъне күргәч, монда бер провокация булмады микән, дип уйлаган идем. Шуның өчен бу мәнбәгъ хакында бераз сөйләп узарга кирәк була. Лука бу янгын соңында 1740 елның 11 маенда Сенат һәм Синодка бер донос язып, Татар Бистәсе янып һәлак булгач, татарларны Иске Бистәдән куып җибәрү хакында шулай әйткән иде: «Оных татар, яко христоненавистных недоброходов, для происходящих от них христианскому благочестию соблазнов, от общежительства с православными христианами удалить и на том месте (ягъни Иске Бистә урынында), где оные прежде жили, строиться не допускать (разве бы кои из них пожелали восприять святую веру и святое крещение»[4]. Лука бу гаризасында хәтта үлгән татарларны да Иске Бистәдә калдырырга теләми, хәзерге Тихвинский чиркәве янында мөселман зиярәте бар иде, «монда татар зиярәте булу православныйларны каралта» дип, аны да бетерүне сорый[5]. Бу фаҗи-

---

[1] Мәсыйр булып – катнашып, дәвам итеп.

[2] Издихамда – кысынкылыкта.

[3] Бу янгынның тәфсиле: Рыбушкин М. С. Краткая история города Казани, ч. II, стр. 8. *(Авт. иск.)*

[4] Описание документов и дел, хранящихся в архиве св. Православного Синода, том 24, №272/131. *(Авт. иск.)*

[5] Луканың татарларны Бистәдән кууы хакындагы дәлилләре бик кызык, бу дәлилләр бары урта гасыр Яурупасында гына дикъкатькә алына торган булганга,

галарны тасвир итеп, Насыйри шулай яза: «Бистәдә ул заманда таш мәчетләр юк икән, агач мәчетләр һәммәсе җанган икән. Шул заманда намаз укыр өчен Бистә халкы кабыктан салаш ясап, шунда намаз укыр икән. Ул салашлар өстенә Аксак Каратун кач куйдырып, качны мөселманнар чалгы белән кисеп төшереп, ул арада Бистә җангач, һәммә йир пуста[1] булып, кеше буе алабута, кычыткан, тигәнәк үсеп, халык алабута эчендә ятадыр икән. Бистә халкының олуглары Ишбулат мулла углы Габдеррәзак дигән кеше икән. Аксак Каратун аңар бигрәк каныгыр икән, ягъни халыкны чукындырырга ирек бирмидер, нәсыйхәт кыладыр дип, кешеләр җибәреп,

---

Русиянең хөкүмәт сөрүче сыйныфларының бу дәлилгә ышанып карар чыгарулары аларның никадәр надан, тәгассыблы булганлыгын күрсәтәчәгеннән вә бу материаллар белән хәзергә бер генә дә рус тарихчысы файдаланмаганлыктан, дәлилләрне тулы хәлдә китерәбез: «Огненное знамение в той слободе соделалось по чудесному в навечерии того пожара, чрез град к той татарской слободе нечаянно страшным пожаром все тое их богомерзкие мечети до основания без остатку истреблены, а потом уже после того пожара из одной татарской слободы не в одно время лежащие огонь видим был, как преосвященный Лука, так преосвященный Дмитрий епископ был самовидящим, и такое тое чудесное огненное видение, так и действо того незапно заченившагося в татарской слободе ужасного поганства истребление оным того их татарские жилища признать должно за совершенное смотрение Божие, почему оным татарам и селиться на оном по чудесному смотрению Божию огнем чистившимся месте вблизости православных христиан для производимых от них соблазнов и важных причин позволять весьма не подлежит».

Димәк, Лука вә аның юлдашларының фикеренчә, татар арасында мәчетләрне ягып башлаган янгын – Алланың бер хикмәте; бу гыйбрәт өчен хөкүмәтнең татарларны христианнарга якын җирдә тотканы өчен булган бер җәза. Моны Лука үзе һәм епископ Дмитрий белән бергә карап торып, күктән ут төшкәнне күргәннәр. Билгеле, бу дәлилләргә караганда, Насыйриның сүзенең бик дөрес булуы ихтимал тотыла.

Икенче дәлил итеп, Лука вә яраннары татарларның яңа гына православиегә чыккан кешеләрне котыртуларын күрсәтә.

Өченче дәлил хокукы булып, Лука татарларны христианнар янында тотарга ярамаганлык хакындагы бөтен иске законнарны санап чыга.

Сенат һәм Синод мәҗлесләрендә Луканың сүзләре хаклы табылалар һәм «Описанное им (т. е. Лукой) чудесное видение признать за совершенное смотрение божие» дип карар кылына һәм татарларны хәзерге Иске Бистәдән куарга карар чыгарыла вә шуннан соң Яңа Бистә килеп чыга, димәк, татарлар сазламак малярияле урынга күчереләләр. *(Авт. иск.)*

[1] Пуста – пусто – буш.

мөселманнарны кыйнап-сугып, тәгъзиб кылырлар[1] икән. Ул вакытта Бистәдә Чумарлар бабасы Йосыф дигән вә һәм Тәкә Сәйфулла атасы Ибраһим дигән бик һиммәт[2] егетләр бар икән. Алар Аксак Каратуннан килгән кешеләргә каршы алабута арасыннан күсәкләр күтәреп чыгып, «Монда нигә килдегез, сезгә ни кирәк?» дип, каршы торырлар икән. Аксак Каратун кешеләре «Кая Габдеррәзак?» дирләр икән. «Менә Габдеррәзак» дип, Йосыф бабай белән Ибраһим күсәкләрен күтәрерләр икән. Шулай итеп, Габдеррәзак бабайны Аксак Каратун кулына төшермәенчә якларлар икән.

Аксак Каратун урамнар чатына качлар утыртып, урамнарда драгуннар йөртерләр икән, ягъни халык җыелып, бер-бер эш кылмасыннар дип. Безнең егетләр моңар бигрәк үчегеп, ялгыз-ярым йөргән рус аулакны тотып үтереп, күлгә ташларлар икән, вә һәм качларны суырып ташларлар икән», – ди. Димәк, Лука Канашевичның провокациясе ике дус – бер-берсенә гомердә дошман булмаган рус вә татар халкын дошманлаштыру дәрәҗәсенә китереп җиткерә язган иде. Хәтта Луканың бу кадәр артыкка киткән тәгассыбларын һәм Насыйри тасвир кыла торган хәлләрне чиркәү представительләреннән булган тарихчылар үзләре дә икърар кылып, татарлар бу кадәр читенлекләргә чыдый алмыйча, «Они от нетерпимости едва удержались от всеобщего смятения», диләр[3]. Лука өстеннән татарларның гаризалары, Мәскәү, Питерга качып барып шикаять кылулар, Луканың бу эшеннән Казандагы дөньяви властьларның да наразыйлыгы, Башкортстанда тынычсызлыклар, башкорт башлыкларының колонизациягә каршы кубуларын шушы Татарстанда булган вакыйгалар белән буяп күрсәтүләр күбәйгәч, 1755 елда хөкүмәт Луканы төшереп, татарларга бәгъзы җиңеллекләр ясады.

Насыйри да бу шикаятьләр хакында сөйли. Ләкин Луканың куылуларына ул башка сәбәп күрсәтә: «югарыда мәзкүр булган сәүдәгәр белән мөәззин Истанбулга барып, хәлифәгә русның мөселманнарны дин тугрысында кысып газаплаганын гарыз иткәч, руска Истанбулдан

---

[1] Тәгъзиб кылырлар – газапларлар.
[2] Һиммәт – кайгыртучан, тырыш.
[3] Кара: «История Российской иерархии» Амвросия, ч. 1, стр. 172 и 253. Без монда Казан халкы хакында гына сөйләдек. Ләкин Луканың татар крестьяннарына күрсәткән җәфалары моннан ничә мәртәбә артык иде. *(Авт. иск.)*

илче килептер. Аннан соң падиша һәм уянып, Казанга әмер җибәргән, Аксак Каратунны төшереп, Зөя монастырена япканнар», ди.

Бу Төркиягә барып шикаять кылу турыдан-туры тәэсир иткәнме-юкмы, бу хакта мин белмим. Ләкин мөәррих Соловьев Елизавета үлеп, Екатерина тәхеткә утыргач бирелгән дин иреге хакында Русиянең Төркия белән булып торган сугышларын, Русиянең Төркия кулында булган христиан халыкларын Төркия золымыннан котылдырам дип чыгуы мәсьәләләрен сөйләгән соңында, мондый бер сәбәпне алга сөрү өчен, Русиянең үзенең эчендәге мөселманнарны кысмаска тиеш булганлыгын вә шуның өчен дин мәсьәләсендә бераз ирек биргәнен бәян кыла[1]. Һәрхәлдә, Насыйри күрсәтә торган бу сәбәп сәбәпләрнең берсе булырга мөмкин.

Лука Канашевич, төшерелгәч, Насыйрича, Зөя монастырена ябылган. Әмма бу Лука турысында чыккан мифларның берсе генә, асылда, ул кеше бер дә ябылмыйча, Белград шәһәренә җибәрелгән. Гомумән, бу кеше хакында татарлар арасында төрле хикәятләр, кыйссалар вә мифлар туган иде, чөнки халык ул үзен яклаган каһарманнарны онытмаган шикелле, каһәрләгән кешеләрне дә онытмый! Менә шул мифлардан берсе Насыйри тарафыннан да сөйләнә: «Шунда (Зөя монастыренда) күп гомер сөреп, ахырында йөзе тискәре әйләнеп вафат булмыштыр», ди. Ләкин Малов исә халык авызыннан ишетеп, бу мифны шулай сөйли: «Аксак Каратун из Казани был сослан в наказание в Свияжский монастырь, где многие из мусульман видели его в ужасном положени. В изорванной одежде, он ходил по монастырскому двору, и подметили, что голова у него была обращена лицом назад, а затылком вперед»[2].

Икенче бер хикәяттә Луканы «министрлар карары белән» Себергә сөргәнлек хакында сөйләнә[3]. Насыйри бу мифларны тагы да тәфсилләп шулай яза: «Безнең Бистә халкы Мәкәрҗәгә барганда монастырь ишегалдына койма җарыгыннан карарлар икән, Аксак Каратун һаман әрле-бирле шунда йөрер икән, йөзе тискәре килгән икән. Падишаның әмере белән Аксак Каратунны төшереп, монастырьга куйганнан соң, мөселманнар бераз иркенләп йортлар һәм мәчетләр сала башлаганнар», – ди.

[1] История России, том 28, гл. 1, стр. 575. *(Авт. иск.)*
[2] О ново-крещенской конторе, стр. 166. *(Авт. иск.)*
[3] Там же, стр. 165. *(Авт. иск.)*

VI

Хәзер без Насыйриның бу әсәрендәге Пугачёв килү хакындагы хәбәрләренә күчәбез. Алар да шул Аитов мәҗмугасыннан алынганнар. Бу хәбәрләрне (Риза хәзрәт булырга кирәк) шул мәҗмугадан күчереп, 1912 елда «Шура»ның 15 нче номерының 396 битендә бастырган иде. Соңра 1886 елда Казандагы археология җәмгыятенең 3 майда булган бер утырышында Габдрахман Әмин углы Ильясов дигән кеше[1] Аитов тарафыннан сөйләнгән шул ук вакыйгалар хакында доклад ясаган вә бу доклад фельетон рәвешендә «Волжский вестник» газетасының 1886 ел 98нче номерында басылган иде. Бу хакта күп сөйләп тормыйбыз. Ләкин шулай да, Насыйриның бу хәбәре – татарның вак буржуазиясенең рухын вә аның Пугачёв вакыйгасындагы настроениесен белдерүче бердәнбер мәнбәгътер. Шуның өстенә дә бу әсәрдәге бер урын XVIII гасырдагы татарның эре буржуазиясенең Пугачёвка мөнәсәбәтен вә башка мөһим нәрсәләрне белдерә. Без аны күчереп узабыз. Кулъязманың кырыенда шулай язылган:

«Аитов Мөхәммәдҗан хәзрәтләре риваять кыладыр: Казан сәүдәгәрләреннән Җаекта иң әүвәл безнең Аит бабай сату итә башлаган, аңарчы безнең Казан халкының Җаек белән эше булмас икән, без кечерәк заманда Җаек сәүдәгәрләренең күбрәге безнең бабайдан калган приказчиклардан, малайлардан вә яки аларның балаларыннан калган сәүдәгәрләр иде» (әсәрнең кырыена язылган сүз шуның белән тәмам). «Вә янә әткәй сөйләр иде: шуннан соң Пугачёв Казанга килгәндер, әмма безнең Аит бабай ул заманда Җаекта икән. Ул вакытта Җаекта сөйләшерләр икән, Пугачёв Казанны алырга китте, дип. Аит бабай аларга әйтер икән: «Пугачёв Казанны тиз ала алмас, царь Иван Васильевич та йиде ел камап, көчкә алды», дир икән. Бу сүзләрне Пугачеёв тарафыннан куелган утаманга[2] җиткерәләр. Аннан соң утаман әмер итәр. Аит бабайны тотып, чи каеш белән beләкләреннән һәм ботларыннан будырып, кырга чыгарып ташларлар. Ул арада Аит бабайның дуст-ишләре барып, утаманга гозер итеп, «ул алай дип әйтмәгән, аның гөнаһысы юк» дип, әсбап-

[1] Габдрахман Ильясов – «Бичара кыз» исемендә татар телендә беренче театр китабы язган кеше. *(Авт. иск.)*
[2] Утаманга – атаманга.

лар күрсәткәч, чишәргә әмер иткән. Ул арада күпме-азмы яткан, кулы-боты шешеп, чи каеш капланган, күренмәс булган каешын кисеп коткарганнар. Аит бабай шуннан соң тиз үк ике җефәк җаулык алып, Пугачёв гаскәренә әләмгә дип, бүләк итеп утаманга илтеп бирер. Янә Аит бабай әйтәдер икән: «Җаекта аннан соң шундаен низамсызлык булды, минем ничә мең куй тиремне Җаек суының кичүенә күпер урынына түшәп, гаскәр чыгардылар, дир икән».

Мәкаләбезнең соңында Насыйри хәбәре белән Ильясов доклады арасында булган бер аерымлы урынны әйтеп узарга кирәк. Ильясов докладында шулай әйтә: «Когда Пугачев ушел, то Казанские дворяне собрались на совещание. Совет приговорил истребить всех татар за то, что те будто-бы поддались Пугачеву. В войске Михельсона находился генерал (Sic!) Муртаза, родом Караим, он объяснил, что татары напротив помогали нашему войску. Тоже самое и солдаты, находившиеся в городе. Они говорили: «Если бы татары не кормили нас, то мы все умерли бы с голода». Тогда только отменили приговор».

Бу мәсьәлә хакында Насыйри шулай яза: «Шуннан соң бунтовщиклар хакындагы мәхкәмәдә сөйләшкәннәр «Казан татарлары Пугачев белән бер иде, һәммәсен кырмак кирәк», дигәннәр. Һәммәсе риза булганнар, әмма Михельсон гаскәрендә татардан чукынган генерал бар икән. Ул кул куймаган икән: алар җыраклары (азыклары) белән безнең гаскәргә ярдәм иттеләр дигән һәм шуннан соң калада бикләнгән солдатлар «Әгәр дә татарлар туйдырмаса, без үләр идек. Пугачёв каладан чыгып киткәч, татарлар туйдырды», дигән һәм «шуннан соң Казан халкы рус гаскәренең ярдәмчесе дип мәдех кылынып калды дирләр иде», ди.

Ильясов докладында бары ике татарны асканны сөйли, әмма Насыйри исә бу турыда озынрак мәгълүмат биреп яза: «Калада мәхкәмә ачылып, бунтовщикларның эшләрен тикшереп, бәгъзысын астылар, бәгъзысын кистеләр. Бер Исмәгыйль исемле качкан солдат бар икән, Пугачев гаскәрендә тупчы башы булып йөргән икән, ике Бистә арасында астылар, янә берәүне күл башында астылар...» , – ди.

Билгеле, бу кыска мәкаләдә Насыйри бирә торган тарихи мәнбәгъләрнең бөтен фәнни әһәмиятен әйтеп бетереп булмый. Аның мөһимлеге бары тарихчыларның әсәрләренә кереп, бер-бер мәсьәләне ачып биргәннең соңында гына күреләчәктер.

## ГЕОГРАФИК ҺӘМ ТОПОГРАФИК АТАМАЛАР КҮРСӘТКЕЧЕ


**А**

Азак 80, 149
Азак диңгезе 14, 23, 27, 28, 37
Азия 11, 18, 21, 24, 60, 61, 68, 76,77, 78, 80, 84, 99, 100, 120, 156, 169, 173, 203, 213, 214, 218, 219, 221, 228
Ак Идел 151
Алат 130, 146, 157
Алатыр 153
Алтай 11
Алтын Урда 33, 48, 49, 52, 66, 67, 68, 69, 70, 71, 73, 74, 75, 76, 77, 78, 79, 80, 81, 82, 83, 84, 85, 86, 87, 88, 92, 97, 99, 100, 101, 102, 106, 111, 114, 118, 138, 226
Альп 13
Англия 85, 101, 132, 156, 164, 176, 181
Арал 13, 33
Арзамас 153
Архангель 132
Арча 26, 88, 89, 92, 97, 126, 146, 157, 193, 216
Арча кыры 89, 91, 193
Атникин 109
Ачасыр 224
Ачбаба 223

**Ә**

Әлмән 224
Әндәлес 22
Әрмәния 92
Әстерхан, Әждархан, Әчтерхан 9, 24, 57, 58, 59, 66, 79, 80, 84, 92, 97, 100, 101, 105, 106, 112, 114, 115, 118, 120, 121, 125, 127, 131, 132, 133, 134, 135, 136, 138, 151, 155, 156, 163, 166, 184, 186, 192, 213
Әтнә 229
Әфганстан 44
Әҗәле 232

**Б**

Бакырчы 233
Бакчасарай 103, 132
Баку 171
Балкан 17, 28, 34, 39
Балтыйк 128, 166, 167
Балтыйк диңгезе 65, 80, 86, 142
Бабил 34, 157, 159
Багдад 31, 77
Басин 37
Башкортстан 102, 171, 188, 189, 190, 192, 193, 194, 196, 202,204, 214, 240
Белая Вежа 25
Биләр 29, 66, 143
Бишбалта 89
Боз диңгезе 14
Болгар 19, 26, 27, 28, 29, 30, 31, 32, 33, 34, 35, 36, 41, 45, 48, 50, 51, 54, 56, 57, 58, 61, 63, 66, 68, 79, 80, 85, 86, 87, 88, 89, 90, 98, 110, 185, 225, 226, 227, 230, 231, 232, 235,
Болгарстан 36, 48
Босфор 80, 86, 100, 131
Бохара 66, 109, 134, 164, 171, 173, 203, 207, 214, 219, 220
Бөек Болгар 27
Бөек Луки 186
Борындык 224
Борнаш 224,
Бурятия 172

**В**

Вена 52
Венеция 79, 80, 86, 100, 133
Владимир 30, 33, 50, 73, 198, 232
Волга 12
Воронеж 184, 186, 187
Воскресенский 89
Вятка 9, 26, 30, 138, 151, 211,

**Г**

Галлия 55
Гареб 13, 19, 48, 49, 57, 66, 80, 111, 117, 138, 222

Генуя 79
Германия 13, 85
Гоби 11, 42
Городец 113
Гөлестан 58
Гыйрак 67

**Д**

Далмация 52
Дарданелл 80, 86, 100, 131
Дәрбәнд 24, 66
Дәрвишевка 95
Дәште Кыпчак 44
Дербышка 95
Димәшкъ 59,
Днепр 19, 21, 25, 28, 44, 72
Днестр 17
Дон буе 12
Дунай 13, 17, 30,

**Е**

Европа 13, 38, 48,

**Җ**

Җаек 12, 19, 23, 24, 58, 66, 84, 102, 103, 190, 192, 204, 242
Җамаш 224
Җәнүә 79, 80, 86, 100, 101, 133

**З**

Зөя 61, 88, 119, 150, 153, 182, 184, 187, 224, 225, 230, 231, 240, 241

**И**

Идел 8, 12, 13, 17, 18, 19, 21, 22, 23, 24, 25, 26, 27, 28, 30, 31, 33, 41, 42, 44, 48, 52, 53, 58, 60, 61, 63, 66, 80,81, 83, 84, 85, 86, 88, 89, 90, 91,92, 100, 102, 103, 112, 116, 118, 120, 121, 122, 127, 129, 130, 131, 132, 133, 134, 135, 140, 142, 147, 150, 151, 153, 165, 169, 178, 179, 181, 220, 235, 236
Иран 19, 24, 39, 44, 54, 59, 61, 66, 68, 76, 77, 78, 80, 86, 92, 100, 111, 125, 131, 132, 135, 136, 143, 151, 152, 163, 221
Иртеш 48, 106, 107, 138,
Исет 191
Истанбул 23, 80, 111, 132, 134, 136, 233, 237, 240,
Италия 101
Итил 24, 25, 80, 101
Ичкә 89
Ишем 107, 108, 109

**К**

Кабан күле 89
Кавказ 9, 19, 21, 22, 23, 24, 25, 38, 44, 66, 73, 131
Казан 8, 9, 29, 35, 62, 85,86, 87, 88, 89, 90, 91, 92, 93, 94, 95, 96, 97, 98, 99, 100, 101, 102, 103, 104, 105,106, 109, 110, 112, 113, 114, 115, 116, 117, 118, 119, 120, 121, 122, 123, 125, 126, 127, 128, 129, 130, 131, 132, 133, 134, 135, 136, 137,138, 139, 140, 143, 146, 147, 148, 149, 150, 151, 152, 153, 156, 157, 158, 159, 160, 161, 162, 163, 168, 170, 173, 174, 175, 176, 178, 181, 183, 184, 185, 186, 187, 188, 189, 190, 191, 192, 193, 194, 196, 197, 198, 200, 202, 203, 204, 205, 206, 207, 208, 209, 210, 211, 213, 214, 215, 216, 217, 219, 220, 221, 222, 223, 224, 227, 228, 229, 230, 231, 232, 234, 235, 237, 238, 240, 241, 242, 243
Казан суы 85, 89, 91
Казан ханлыгы 48, 84, 87, 88, 89, 90, 91, 92, 93, 94, 95, 96, 97, 98, 99, 112, 120, 123, 124, 126, 128, 146, 153, 159, 164, 165, 178, 180, 181, 227, 231, 233
Казанка 89
Калуга 151, 154
Кама 26, 27, 28, 30, 31, 48, 84, 85, 102, 103, 126, 139, 237
Каспий диңгезе 12, 49, 66, 92, 102, 103, 104
Каспий капкасы 12
Кашан 29, 66
Кара Буа 158
Кара диңгез 19, 23, 33, 34, 65, 71, 73, 77, 80, 88, 100, 131, 135
Кара Якуб 228
Караеш 158
Каралан 49,

Карачин 109
Карашивә 158
Каргалы 174, 205, 206, 211, 213, 234,
Кармыш 146, 153, 224,
Касыйм 87, 96, 99, 113, 114, 115, 127, 134, 142, 143, 150, 152, 153, 154, 161, 162, 163, 164, 165, 168, 198, 209, 232
Касыйм Тура 109
Каһирә 59
Кәфә 80
Киев 25, 33, 49, 52, 70, 185
Кишет 202, 215
Кытай 11, 13, 42, 43, 44, 49, 50, 54, 59, 65, 66, 68, 77, 80, 109, 110, 131, 172, 214, 215
Кызыл Тура 109, 137
Кыпчак иле 37, 44, 48, 53, 69, 71, 76
Кырым 19, 63, 79, 84, 86, 97, 98, 101, 103, 104, 106, 112, 114, 115, 117, 118, 119, 120, 121, 125, 127, 131, 132, 133, 134, 135, 136, 137, 139, 142, 143, 148, 149, 163, 164
Кяхта 172, 214, 215
Күгеш 224
Күк Урда 48

**Л**

Левант 226
Ливония 114, 128, 136, 139, 142, 148
Литва 151, 153

**М**

Мавәраэннәһер 47, 77
Маҗарстан 11, 12, 14, 34, 52
Мамадыш 224, 228
Мәҗен 230
Мәккә 32
Мәкәрҗә 91, 172, 184, 205, 206, 214, 221, 241
Мәдинә 32
Мәскәү 7, 84, 87, 93, 94, 95, 97, 98, 102, 105, 106, 111, 112, 113, 114, 115, 116, 117, 118, 119, 120, 121, 122, 123, 124, 126, 127, 128, 129, 130, 132, 133, 134, 136, 137, 138, 139, 140, 141, 142, 143, 148, 150, 151, 154, 155, 156, 157, 162, 163, 164, 181, 190, 216, 229, 230, 237, 240
Меотия сазлыгы 14
Мишә 126
Мисыр 59, 66, 67, 78, 79
Монголия 11, 43, 54, 57, 69, 71
Монгол империясе 45, 47, 48, 51, 53, 57,
Москва-река 86,
Мучуран, Мөҗүрән 72
Мулла иле 95, 216, 224,
Муллино 95
Муром 126,

**Н**

Наратлы 224
Нижний Новгород 150
Николаевская площадь 89
Новгород 23, 33, 85, 130, 150, 151, 160, 186
Новороссийский 89,
Норлат 224, 229
Нугай урдасы 84, 101, 102, 103, 118, 121

**О**

Обь 106, 108
Олуг Болгар 68,
Оренбург 174, 175, 198, 205, 206, 207, 213, 218, 219,
Орхон 50
Оры 217

**П**

Панау 224
Панниония 17
Пенза 191, 209
Пермь 9, 138, 140, 151, 177, 180
Печән базары 213
Питербур 170, 177
Победилово бистәсе 89
Полинезия 15
Полтава 198
Псков 130, 151

**Р**

Регенсбург 38
Рейн 13, 187,
Рим 13, 14, 17,
Рума 13, 14, 16, 17, 62, 79
Рус Әҗәлесе 232

Рысбуга 224,
Рязань 113, 209, 211

**С**

Саба 203
Салоники 38
Самара 26
Санчурск 130
Сарай 17, 19, 24, 29, 54, 58, 59, 60, 61, 62, 63, 64, 68, 72, 78, 79, 80, 81, 84, 86, 90, 102, 103
Сарай җәдид 58
Саратау, Сарытау 19, 57, 62
Саркел 25
Саян 11
Саксин 24
Скандинавия 25, 32
Селик Кабан 158
Сембер 162, 191, 202
Сеитова слобода 174
Себер 84, 86, 97, 108, 109, 110, 111, 132, 137, 138, 139, 140, 141, 151, 173, 186, 192,
Себер урдасы 102, 106, 107, 108, 137,
Сибирия 42, 106, 108, 156
Смоленск 154
Советлар Союзы 8
Спас 26, 27, 29
Суар 29,31, 58, 66, 68
Сузга Тура 109
Суздаль 30, 33, 85, 150
Сургуф 37
Сура 26, 87
Сүәеш каналы 86
Сүрия 77, 78
Сәмәндәр 24
Сәмәрканд 59

**Т**

Таҗик чокыры 88, 89
Тана 65, 66
Тамбов 187, 191
Тархан кальга 109
Татар Кабаны 158
Татарстан 7, 9, 26, 87, 93, 95, 148, 158, 191, 214, 215, 240
Тау Иле 224, 230
Тау Ягы 119, 147, 150, 153, 224, 231
Тәтеш 130, 162
Темников 153
Токай 17
Трабзон 111
Троицк 173, 218, 219
Тубыл 106, 107, 108, 109, 138, 139, 202
Тура109,111, 137, 138
Төркестан 12, 44, 54, 59, 171, 228
Төркия 79, 86, 100, 103, 111, 112, 114, 115, 118, 120, 121, 127, 131, 132, 133, 134, 135, 137, 143, 163, 166, 233, 240
Түбән Шырдан 224

**У**

Уфа 26, 30, 102, 191, 196, 198, 213, 217, 218
Украина 12
Урал 12, 23, 26, 30, 47, 48, 61, 84, 87, 106, 107, 111, 137, 139, 140, 190
Уржум 130
Урысбага 224
Усия 91, 94
Узу суы 72

**Ү**

Үксәк 58
Үргәнче 66
Үтәк 224

**Ф**

Фессалоники 38
Франция 52, 55, 64

**Х**

Хаҗитархан 80, 101
Ханкирмән 163, 164, 165
Харәзем 44, 48, 59, 79
Хопра 26
Хорватия 52
Хәзәр иле, Хәзәр дәүләте, Хәзәр мәмләкәте, Хәзәрстан 19, 21, 22, 23, 24, 24, 27, 28, 30, 31, 34, 36
Хәзәр диңгезе 24, 49, 58, 80, 131, 132

**Һ**

Һинд, Һиндстан 37, 66, 68, 77, 80, 131, 141

**Ц**

Царицын 58

**Ч**

Чабаксар 130, 224
Чар 70, 93, 95, 130, 146, 155, 217, 218
Черек күл 88, 89
Чиләбе 203
Чистай 26, 29
Чуел 162, 224, 233
Чулман 26, 85, 103
Чураниле 93

**Ш**

Шамо 11, 42
Шам 67
Шарукань 37
Шәрык 15, 23, 30, 34, 55, 57, 66, 80, 86, 92, 101, 131, 139, 141, 169, 171, 176, 196, 218, 219, 220
Шигали 224, 228
Шүшермә 224
Швеция 111, 151, 166, 167

**Э**

Эмба 48
Эстония 148

**Ю**

Югары Кабан 89
Югары Шырдан 224, 231
Юнанстан 62

**Я**

Ядрин 153
Яңа бистә 189, 216
Яранск 130
Яулы-Тура 109
Яурупа 8, 11, 12, 13,14, 16, 17, 18, 23, 24, 25, 26, 27, 28, 30, 31, 32 , 34, 35, 36, 39, 40, 41, 42, 48, 49, 50, 51, 52, 53, 54, 55, 56, 57, 63, 65, 67, 70, 71, 76, 77, 80, 83, 84, 85, 86, 87, 88, 90, 94, 96, 100, 101, 106, 111, 117, 120, 131, 132, 138, 141, 167, 173, 180, 181, 214, 221, 225, 226, 227, 238

# ТЕКСТЛАРНЫ ГАМӘЛДӘГЕ ЯЗУГА КҮЧЕРҮЧЕЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘҮЧЕЛӘР

*Гарипова Л. Ш.* – филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

*Надыршина Л. Р.* – филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Ханнанова Г. М.* – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге фәнни хезмәткәре.

# ЭЧТӘЛЕК

**Фәнни мирас яңарышы: Газиз Гобәйдуллин һәм аның «Татар тарихы» хезмәте** ........ 5
**ТАТАР ТАРИХЫ** ........ 7
Язучыдан ........ 7
**I. Татарларны тудырган гонсырлар** ........ 8
Татарлар ........ 8
Татарларның тарихы ........ 9
Төркләр вә аларның Шәркый Яурупага килүләре ........ 11
Һуннар ........ 13
Һуннарның тормышы ........ 14
Аварлар ........ 17
Хәзәрләр вә болгарлар ........ 17
Хәзәр вә аларның җирләре ........ 18
Халык ........ 19
Хәзәр дәүләте. Хакан ........ 19
Түрәләр ........ 20
Гаскәр ........ 21
Хөкем ........ 21
Дин ........ 22
Хәзәр мәдәниятенең дәрәҗәсе ........ 23
Сәүдә ........ 23
Шәһәрләр ........ 24
Хәзәр дәүләтенең шәп вакыты ........ 25
Хәзәр дәүләтенең зәгыйфьләнүе – бетүе ........ 25
Болгар иленең урыны һәм аның табигате ........ 26
Бу җирнең әүвәлге халкы ........ 27
Болгарларның килүе хакында хорафат ........ 27
Болгар дәүләте ........ 28
Болгар дәүләтенең килере ........ 28
Хөкем ........ 28
Шәһәрләр ........ 29
Болгарларның шөгыльләре ........ 29
Һөнәр вә сәнәгать ........ 31
Дин ........ 31
Әдәбият, гыйлем вә мәгариф ........ 32
Болгарларның күршеләре белән мөнәсәбәтләре ........ 32
Шәркый Яурупада күчмә төркләр ........ 33
Аларның тормышы ........ 35

Аксөяк вә карасөяк ыруглары ........ 36
Икътисади хәят ........ 37
Күчмә төркләрдә мәдәният ........ 39
Нәтиҗә ........ 41

**II. Татар халкының ясалу процессы, яисә ыруг-патриархат тормышыннан феодализмга таба күчү дәвере** ........ 42
2.1. Шәркый Яурупада Идел буе төркләренең монголлар кул астына керүләре ........ 42
Азиядә сәяси инкыйлаб ........ 42
Тимучин – Чыңгыз хан ........ 42
Корылтай ........ 43
Чыңгыз ханның фөтухаты ........ 44
Монгол гаскәренең Кыпчак иленә килеп чыгуы ........ 44
Чыңгызның шәхесе ........ 45
Монгол империясенең иҗтимагый маһияте ........ 45
Җүҗи олысы вә Алтын Урда ........ 48
1229 ел корылтае ........ 49
1235 ел корылтае ........ 50
Татарларның Гарби Яурупага һөҗүмнәре ........ 52

2.2. Алтын Урда яисә Кыпчак дәүләтенең ясалуы ........ 52
Шәркый Яурупадагы татарларның олуг ханлыктан аерылулары ... 52
Монголларның төркләшүе ........ 53

**III. Татарларда феодализм дәвере** ........ 56
3.1. Алтын Урда ........ 56
Башлангыч ........ 56
Алтын Урдада матди мәдәният вә хуҗалык ........ 57
Сәнәгать вә бакчачылык ........ 60
Сәнәгатьнең хуҗалары вә эшчеләре ........ 62
Игенчелек вә игенчеләр ........ 63
Алпавытлар вә аларның кулындагы игенчеләр ........ 64
Сәүдә вә сәүдәгәрләр ........ 65
Акча ........ 67
Кәгазь, күн акча ........ 68
Юллар, почта ........ 68
Дәүләт төзелеше ........ 69
Канун, ярлыклар ........ 71
Ханның тормыш рәвеше ........ 72
Идарә ........ 73

Дәүләтнең керере ........ 74
Дин ........ 76
Дин ирегe ........ 78
Алтын Урданың көчле дәвере вә инкыйразы ........ 79
Үзара сугышлар һәм аның нәтиҗәсе ........ 82
Икътисади ярлылык ........ 83
Күршеләрнең куәтләнүе ........ 83
Алтын Урда беткәч ........ 84

3.2. Казан урдасы яисә ханлыгы ........ 84
Казан урдасының килеп чыгуы ........ 84
Казан ханлыгының җире, халкы вә мәдәни дәрәҗәсе ........ 87
Шәһәрләр ........ 88
Татар Казаны ........ 88
Сәнәгать вә сәүдә ........ 90
Иҗтимагый төзелеш ........ 92
Казан ханлыгында сәяси тормыш вә көрәш ........ 97
Гаскәр ........ 98
Мәгънәви мәдәният ........ 98

3.3. Әстерхан ханлыгы ........ 100
Әстерхан ханлыгы ........ 100
Иҗтимагый тормыш ........ 100
Икътисади тормыш ........ 101

3.4. Нугай урдасы ........ 102
Гомуми мәгълүмат ........ 102
Нугайларның тормышы, шөгыльләре ........ 102
Дин ........ 103
Нугайларның иҗтимагый, сәяси тормышы ........ 103
Төрле сыйныфларның бер-берсенә мөнәсәбәтләре ........ 104
Нугайларның мәдәни дәрәҗәләре ........ 105
Нәтиҗә ........ 105
Бу урдаларның бер-берсенә мөнәсәбәте ........ 106

3.5. Себер урдасы ........ 106
Себер урдасының ясалуы ........ 106
Халык ........ 107
Матди мәдәният ........ 107
Ау вә балыкчылык ........ 108
Мал асрау ........ 108

Игенчелек ........ 108
Кәсеп, һөнәр ........ 108
Сәүдә ........ 109
Шәһәрләр ........ 109
Тормыш ........ 110
Сыйныфлар вә аларның көрәше ........ 110
Чикләре ........ 111

3.6. Мәскәү сәүдә капитализмы белән татар феодализмының көрәше вә аның нәтиҗәсе ........ 111
Мәскәү дәүләтенең үсүе ........ 111
Мәскәүнең сәясәте ........ 113
Касыйм ханлыгы ........ 113
Кырым Урдасы, Казан, Әстерхан, Русия ........ 115
Мәскәү ........ 116
Бу сугышта кем җиңәргә тиеш? ........ 116
Казан урдасының егылуы ........ 119
Әстерхан, Нугай урдаларының Русия кулына керүләре ........ 120

3.7. Идел буенда татар-фин кузгалышы ........ 122
Казан өлкәсендә Мәскәү идарәсе ........ 122
Кузгалышның сәбәпләре ........ 123
Ихтилалның барышы ........ 125
Ихтилалны бастыру ........ 127
Ихтилалның нәтиҗәсе ........ 128
Казан ханлыгын колонизация ........ 128

3.8. Идел буе өчен көрәшкә бәйнәлмиләл сәясәтнең катышуы ........ 131
XVI гасырда Идел, Дон һәм Кара вә Хәзәр диңгезләре сәүдәсе ........ 131
Төрек һәм Кырым гаскәренең һөҗүмнәре ........ 133
Солтан Сәлимнең Әстерханга таба килүе ........ 135
Мәскәү хөкүмәтенең каушавы ........ 136
1571 ел һөҗүме ........ 137

3.9. Себер ханлыгының бетүе ........ 137
Сәбәпләр ........ 137
Себер ханлыгында ........ 138
Күчем вә аның идарәсе ........ 139
Күчем хөкүмәтенең Мәскәүгә мөнәсәбәте ........ 140
Строгоновларның гаскәре ........ 141
Сугыш ........ 141

**IV. Татарларда сәүдә капитализмы дәвере** ........ 142
4.1. Феодализмның дәвамы вә аның җимерелә башлавы ........ 142
Феодализмның дәвамы ........ 142
Феодализмның бетүе ........ 147
Татарларның ихтилалга катышулары ........ 149
Мәскәүдән аерылу фикере ........ 150
Касыйм ханлыгы вә аның феодалларының рольләре ........ 152
Беренче Романовларны тәхеткә утырту вә саклауда татар феодал сыйныфының роле ........ 154
Татар феодализмына яңа зарбәләр ........ 155
Ирекле крестьяннар ........ 157
Ирексез крестьяннар ........ 157
Бер нәтиҗә ........ 159
Крестьяннарның хуҗалыгы ........ 159
Касыйм ханлыгының бетерелүе ........ 162
Бетерүнең юллары ........ 163
Феодализмның бетүен туктатып торган бер вакыйга ........ 165

4.2. Татар феодализмының җимерелүе вә аның калдыгы (1713–1775) ........ 167
Феодалимзга тагы бер зарбә ........ 167
Моннан чыккан бер нәтиҗә ........ 168
Татар мирза вә йомышлыларын лашман ясау ........ 169
Сәүдәгәр вә сәүдәнең үсүе ........ 171
Татарның сәүдә колонияләре ........ 174
Кыргызстан чигендә рус-татар акционерный сәүдә җәмгыяте ........ 175
Крестьяннар (кол вә ясаклылар) ........ 175
Авыл халкының ярлылануы ........ 178
Колонизациянең дәвамы ........ 179
Христианлаштыру сәясәте, аның икътисади сәбәбе вә колонизациягә хезмәте ........ 180
Чукындыру процессы ........ 182
Бу кысынкылыкларга татарларның каршы җаваплары ........ 187
Татар буржуазиясенә бер һөҗүм ........ 189
Татарларның күчүләре ........ 190
Татар, мишәрләр вә башкортларның бер-берсенә мөнәсәбәтләре ........ 192
Башкортстанда татар вә фин кузгалышы ........ 193

4.3. Сәүдә капитализмы үскән дәвердә сыйнфый көрәш ...................... 194
Әсаслар .................................................................................... 194
Казан йомышлылары вә мирзаларының татар-башкортларга каршы хәрәкәтләре.................................................................... 196
Тәфкилев крестьян-татарларының кубуы........................................ 198
1767 ел комиссиясендә татар сыйныфларының көрәше ................ 199
Пугач явында татар сыйныфлары .................................................. 201
Нәтиҗә ...................................................................................... 208

4.4. Сәүдә капиталының хакимияте вә сәнәгать чаткылары................. 208
Татар мирзасы рус дворяны белән хокукта тигезләнде.................. 208
Мирза вә йомышлыларның купецка чыгулары.............................. 209
Татар ратушасының ясалуы ..........................................................211
Татарларда кредит мәсьәләсе......................................................... 213
Эре сәүдә һәм чит илләр белән сәүдә ............................................ 214
Сәнәгать чаткысы вә ялланган эшчеләр ........................................ 215
Матбагачалык сәнәгате вә китап базары ........................................ 218

**НАСЫЙРИ КУЛЪЯЗМАЛАРЫНЫҢ ГЫЙЛЬМИ КЫЙММӘТЛӘРЕ ТУРЫНДА** ............................................ 222

**ГЕОГРАФИК ҺӘМ ТОПОГРАФИК АТАМАЛАР КҮРСӘТКЕЧЕ**.................................................................................. 244

**ТЕКСТЛАРНЫ ГАМӘЛДӘГЕ ЯЗУГА КҮЧЕРҮЧЕЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘҮЧЕЛӘР**.......................................................................... 249

**Газиз Губайдуллин**

**ИЗБРАННЫЕ СОЧИНЕНИЯ**

**Том 3**

**Духовное наследие: поиски и открытия**

Выпуск 28

(На татарском языке)

Редактор Л. Г. Шарифуллина
Компьютерная верстка Л. М. Курбангалеевой
Дизайн обложки Т. В. Семиной
Подписано в печать: 20.11.2025.
Бумага офсетная. Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс».
Усл.-печ. л. 14,9. Уч-изд. л. 13. Тираж 300 экз. Заказ...

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20